


# КАЗАН УТЛАРЫ

7
ИЮЛЬ
1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

7
ИЮЛЬ
1980

*Бу санда*

**Г. АХУНОВ. Йолдызлар калка.** Повесть . . . . 3
**Р. ГАТАУЛЛИН. Феникс — үлемсез кош.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
**А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Җомга көн, кич белән...** Повесть 95
**Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Иделдә өмә.** Шигырьләр 143

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**М. ЗАРИПОВ. Мәңгелек шәһәр.** Очерк . . . . 147

ДУСЛАР ИҖАТЫ

**Бездә кунакта: каракалпак шагыйрьләре** . . . . 160

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ СОРЫЙ

**Х. ЯНОВ. Матурлыкны күбрәк күрергә** . . . . 170
**Х. ХӘКИМУЛЛИНА. Яңа язмышлар ачылганда** . . 172
**Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Еллар чалымы** . . . . . . . 174
**З. ХӨСНЕТДИНОВ. Көннәр язга авышкач** . . . 176

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Гадиләр, гадәтиләр** . . . 177
**Л. ХӘЙДӘРОВА. Күңелгә килгән уйлар** . . . 182

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Г. Галинең тууына 80 ел** . . . . . . . . 185
**Һәрвакыт алгы сызыкта** . . . . . . . . . 186
**Ф. ИБРАҺИМОВА. Язучы-педагог** . . . . . . 186
**З. ХӘЙРУЛЛИНА. Әнвәр Бакировка 60 яшь** . . 188

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . 190

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин**, **Аяз Гыйләҗев**, **Марсель Зарипов**, **Зөлфәт**, **Фәрваз Миңнуллин**, **Туфан Миңнуллин**, **Рафыйк Нәфиков**, **Атилла Расих**, **Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким**, **Нил Юзиев**.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова*, *Т. Шакирҗанова*

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 27/III-1980 ел. Басарга кул куелды 20/VI-1980 ел. ПФ 09025. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94000 экз. Заказ У-158. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Гариф Ахунов

# ЙОЛДЫЗЛАР КАЛКА

ПОВЕСТЬ

### Әдәби берләшмә




елның башында әдәби түгәрәкнең чираттагы утырышын җыйнап, еллык эшебезгә хисап ясаган чакта, Әдип Маликов әйтте:

— Иптәшләр, мин бик арыдым. Үзегезгә мәгълүм, сәламәтлегем дә әллә ни түгел. Түгәрәкнең җитәкчесе итеп мин Ахуновны сайларга тәкъдим итәм,— диде.

Сайладылар.

Әлмәт түгәрәге инде байтак кына көч җыйган, башка урыннардагы түгәрәкләрдән авторлар саны белән дә, язган әйберләрнең дәрәҗәсе белән дә нык кына аерыла иде.

Шул ук җыелышта без үзебезне әдәби түгәрәк дип түгел, әдәби берләшмә дип атап йөртергә карар чыгардык. Барлык газеталарда берләшмә дип яза башладык. 1958 елның башында Әдип Маликов Язучылар союзына член итеп алынды, аның инде «Ташчы» һәм «Фәрдәнә» поэмалары, нефтьчеләр тормышыннан байтак кына шигырьләре басылып чыккан иде.

Яшь язучылардан Казанда, матбугат тирәсендә йөрүче, тормышны белмәү сәбәпле, интим хисләрендә генә казынучы кайберәүләрдән Әдипнең шигырьләрен яратмаучылар да бар иде.

Ләкин мин үзем Әдипне яратам, гражданин шагыйрь итеп, иҗтимагый бурычын аңлаган, җәмәгать эшләре канына сеңгән шагыйрь итеп яратам.

Бар иде ул Чупай тау,
Бөркет ял иткән куның.
Эзләмәгез, тапмассыз:
Күчте ул шәһәр булып.

«Вышкаларын сакка куеп, йоклый девон каласы», «Илем карый Әлмәт якларына, көтеп шуннан эшнең зурысын», — болар бит татар поэзиясенә яңалык алып килә торган шигъри детальләр. Әдипне союзга алган чакта кайберәүләр арасында «шагыйрь итеп түгел, про-

Ахыры. Башы 5, 6 саннарда.

заик итеп алырга» тәкъдим кертүчеләр дә булды, бу мыскыллау шагыйрь җанына авыр булачак иде, идарә утырышында миңа конкрет мисаллар белән, яттан сөйләгән шигырь юллары белән Әдипне яклап чыгарга туры килде.

Шагыйрь Әхмәт Исхак сүз алып, кабул итү комиссиясенең дөрес юлда булмавын, татар шигыренә карата союзда төпле фикер урнашмавын, поэзиянең язмышын кем ничек теләсә, шулай — бик тар субъектив зәвыгыннан чыгып — бәяләвен әйтте. Әдипне союзга шагыйрь буларак кабул иттеләр. Активлыгын көчәйтергә киңәш бирделәр. Шулай итеп, 1958 елда Әлмәттә инде ике кеше СССР Язучылар союзы члены булды.

Безнең берләшмә колачны киңрәк җәя башлады: «Хезмәт байрагы» газетасында ай саен ике мәртәбә әдәби бит бирелеп бару, ай саен диярлек нефтьчеләр клубында халык каршында чыгыш ясаулар гадәткә кереп китте.

Энже Мөэминованың «Әткәм чүкеченең тавышы» поэмасын Г. Хуҗи белән мин «Татарстан яшьләре» газетасында, хәерле юл теләп, тәкъдим иттек, ул анда басылды һәм конкурста бүләк алды.

Шушы елның көзендә Әлмәткә Азнакайдан, Лениногорскидан, Акбуа, Актүбә, Ютазы поселокларыннан утыз авторны чакырып, яшь язучылар семинары үткәрдек. Семинарга Ә. Еники, Г. Хуҗи, Г. Галиев, З. Нури килделәр. Хикәя тикшерү утырышларында булсын, поэзия утырышларында булсын, әдәби осталык турында бик күп кызыклы сүзләр әйтелде. Кызганычка каршы, татар әдәбиятында, съездлардан башка урында стенограммалар алып барылмый, үткенлеге, экспромт булып тууы, фикернең чаткыланып китүләре әнә шул семинарда язылмаган килеш югалып калалар. Бу юлы да шулай булды. Утырыш беркетмәләрен укып карасаң — аларда хәзер шул чорда сөйләнгән үткен фикерләр коры сөяккә калдырылып кына теркәлгәнннәр.

1958 елның көзендә торак, кунак өйләре табу авыр чакта үткәрелгән бу семинарның Әлмәт берләшмәсе өчен бик зур файдасы булды. Әдәби берләшмәгә кульязма күтәреп килүчеләрнең саны бермә-бер артты.

Әлмәт әдәби түгәрәген башлаган «картлачлар» янына икенче яңа буын килеп өстәлде.

## Остазларыбыз

Әлмәттә оешып килгән яшь язучылар берләшмәсе өчен остазларыбыз дип мин беренче чиратта Гомәр ага Бәшировны, Сибгат ага Хәкимне, Гази ага Кашшафны, Хәсән ага Туфанны һәм Гали ага Хуҗины санар идем.

Әлмәткә мине куалап диярлек җибәрүчеләрнең берсе — якташым Гомәр ага булды. Казанда өелеп, бурсып ятуны яратмады ул, холкына хас сабырлык белән:

— Күч син, Гариф, Әлмәткә күч. Анда һавасы ук икенче, эшчеләр һавасы, әйеме? Яшь чакта бик кирәк ул,— диде.

Гомәр ага ул чакта Казанда Язучылар союзы председателе булып эшли, Мәскәүдә дә, үзебезнең өлкә комитетында да аны яхшы беләләр, ул — СССР Верховный Советы депутаты һәм «Намус»ның авторы, аның сүзенә колак салалар, ул абруйлы кеше иде.

Әлмәткә семьябыз белән күченеп килеп, квартир алганнан соң да, беренче булып безнең тормышны карарга ул килде. (Безнең якларда ул сайлаучылар белән очрашып йөри иде, аның юлдашы итеп чибәр, җитди йөзле, татарча да, русча да бердәй матур, өздереп сөйли белүче Мөдәррис Мусинович Мусинны җибәргәннәр иде).

Гомәр абыйга гостиницада люкс бирә алалар иде, ләкин ул анда

кунуны кирәк тапмады. Безнең квартирга килеп, Әлмәт язучылары белән төнге берләргә чаклы сөйләшеп утырды. Өстәл тирәсендәге яшь-яшь чибәр егетләр аның күңеленә хуш килде бугай, ул мөлаем гына елмая:

— Менә бит, оешып та киләсез,— дип әйтеп куя.

Татар халкының телен, моңын, гореф-гадәтләрен белү, культурабызның алга китүен теләү ягыннан, мөкатдәс кешеләрен хөрмәт итү ягыннан мин аны акыллы һәм чын язучы дип саныйм. Яшьләргә йогынты ясый торган язучы ул. Бүгенге көндә әдәбиятта әйбәт эшләп килгән урта буын язучылардан кайсын гына алма — аларның һәркайсында — Рафаил Төхфәтуллиндә да, Нурихан Фәттахта да, Аяз Гыйләҗевта да — Гомәр Бәширов йогынтысы бар. Мөлаемлыгы, сабырлыгы белән ул Әлмәт егетләрендә дә әдәбиятка, сәнгатькә карата ярату тойгысы уята алды.

Әлмәткә аның килүе бер генә булмады, соңыннан үзенең иҗат эшләре белән дә, союз эшләре белән дә килеп чыкканы булды, аның килүе безнең өчен бәйрәм була иде. Ләкин — барыннан да бигрәк — ул безнең рухыбызны яңа ел котлаулары белән, әдәбият-иҗат мәсьәләләрен кайгыртып язган хатлары белән күтәреп торды. Кәҗүннилекне, китапчалыкны ул яратмый. Салкын акыл белән язылган әйберләргә карата бездә дә өнәмәү хисе уятырга тырыша иде.

Әлмәт әдипләренең икенче агае — Хәсән Туфан. Озынча ябык битле, көл сыман каты чәчле, язын-көзен генә түгел, хәтта кышын да яланбаш йөри торган бу агайда әйтеп бетергесез энергия бар. Контраст аның холкы. Я ул, иреннәрен тешләп, мәңге моңсу күзләрен җиргә төбәп, уйга калып утыра, я кинәт кенә: «Ба-а-а!» — дип сокланып кычкырып җибәрә һәм рәхәтләнеп көлә башлый.

«И тукмачың тәмле дә булган соң, сеңлем!» — дип ул хуҗабикәнең күңелен табарга да өлгерә. Кыскасы — менә дигән ихлас кеше. Әң сокландыргычы — аның яшәү рәвеше. Ул Әлмәткә, әйтик, иртән килеп төшә, кул биреп һәммәбез белән күрешеп чыга да, шигырьләрне сорап ала һәм — бер таңнан икенче таңга хәтле — өзлексез, йокламый-нитми, шигырь укый. Аның янында чебердәшеп утырган Әлмәт егетләре инде авып бетәләр, хуҗалар йокыга тала, ул һаман уяу, ул һаман шигырь укый.

Хәтеремдә, бервакыт ул безгә иртәгә XXII съезд ачыласы көнне килде. Энҗе Мөэминованың, Сажидә Сөләймановaның, Клара Булатованың, Әдип Маликовның, Лениногорскига китеп, яңа әдәби берләшмә оештырган Шамил Бикчурин егетләренең шигырьләрен төне буе укып утырды. Укып кына калмады, аларны редакцияләде һәм шул ук төнне, партия съездына багышлап, үзе дә шигырь язды.

Аның исеме Бөек Ватан сугышына кадәр үк инде Татарстанда һәм Башкортстанда билгеле иде, заманның ярсулы кайнар тойгыларын ул үзенә хас яңа ритмга сала иде. Байтак еллар туган-үскән җирләреннән аерылып тору, татар поэзиясеннән читтә яшәү аны гаять нечкә күңелле һәм корычтай нык ихтыярлы иткән. Ул үзе югында туганүскән якларындагы үзгәрешләргә сокланып туя алмый, дөньяны йотлыгып күзәтә, отыры күбрәк, күбрәк белергә омтыла иде.

1960 елны ул Әлмәттә ярты ел чамасы торды. Миңа әйтте:

— Үзең белгән әйбәт бер нефтяниклар бригадасына алып бар әле мине, акыллым, — диде.

Ул чакта мин, баш-аягым белән чумып, «Хәзинә» романын яза идем. Арыган, роман язылмыйрак торган бер араны сайлап, Октябрь бәйрәмнәре узгач, мин аны Актүбә эшчеләр поселогына, атаклы бораулаучы Мөгаллим Гыймазов бригадасына алып бардым.

Буровойда без, куныл-төнеп диярлек, унбиш көн яттык. Хәсән абыйның шул чорда миңа билгеле булмаган байтак кызыклы яклары ачылды.

Мөгаллим Гыймазов — СССР Верховный Советы депутаты — без килгәндә Мәскәүдә, бюджет комиссиясендә иде. Безгә күбрәк бригада егетләре белән эш йөртергә туры килде.

Шулай бер вакыт, культбудкада утырганда, кароттаж начальнигы, мишәр егете Якуб Хәмитов сорап куйды:

— Сугышка кадәр мин Хәсән Туфан дигән шагыйрьне белә идем, кайда ул хәзер, исәнме?

Бу сорау мине, миннән дә бигрәк Хәсән абыйның үзен кызыксындырды:

— Ничек белә идегез, күрепме? — диде ул.

— Күреп түгел, шигырьләрен укып. Хәтта яттан белә идем.

— Хәзер дә беләсезме?

— Хәзер дә беләм.

— Бер генә куплетын булса да әйтеп бирә алмассызмы?

Якуб бер генә мәлгә күзен йомып торды, аннары ачты һәм мишәрчәләтебрәк укып китте:

...Оратор да, мин сиңа әйтим, оратор,
цурту матыр!
Жыен салам сыйрак, кәгазь яка — кәмитет,
Яшәсен дә, мин сиңа әйтим, яшәсен,
Ә үзебез кацан яшәрбез...

Хәсән Туфанның күзләре зур булып ачылды, аннары кысыла төште һәм ул, күңеле тулуын күрсәтмәс өчен, башын читкә борып: «Ба-а-а!»— дип яраткан сүзен әйтеп куйды.

Озак еллар халыктан аерылып торганнан соң да халык күңеленнән чыкмаган булуы аны дулкынландырды булса кирәк.

Актыктан шагыйрь Туфан белән геофизик Хәмитов дуслашып киттеләр. Ике мишәр сәгатьләр буе сөйләшеп утыра торган булдылар.

Киң күңелле, мәзәкчән Якуб:

— Мишәр кем ул? — дип сорый.

— Кем соң? — ди Хәсән абый аптырап.

— Мин хезмәт иткән бер частьтә мишәр егете бар иде, «Милләтең кем?» — дип сорагач, «Мишәр», — дип җавап бирде.

— Кем ул мишәр? — диде сержант.

— Мишәр ул — первый сорт татарин, — дип җавап бирде солдат.

Буровой күперендә ял итеп утыручы егетләр дәррәү көлеп җибәрделәр.

Шул көнне, тагын бер сәгатьтән, без кызык бер хәлгә тап булдык. Хәсән абыйның вышка төбәсенә менеп карыйсы килде.

— Бик биек бит ул, кырык бер метрлы бит ул, — диде Якуб. — Анда бит, Хәсән абый, иләнмәгән килеш яшьләр дә бик авырдан менә...

Чыннан да, вышка түбәсенә мену ансат түгел. Селкенеп торган агач баскычтан аска карасаң, убылып төшеп китәрсең кебек тоела. Аннары — иләнмәгән килеш менсәң, ике көн рәттән аякны атлап булмый, тезгә суга. Шулай булгач, алтынчы дистәне тутырган кешегә анда менүнең никадәр кыен икәнен күз алдына китереп була инде...

Ләкин Хәсән ага бу сынауны гаҗәп әйбәт узды.

Аста карап күзәтеп торучы бораулаучы егетләр:

Хәерле юлга, туганнар,
Хәерле юлга!

— дип аны шигырь әйтеп озатып калдылар. Бу юлы барысыннан да бигрәк мин дулкынландым. Чөнки бу Хәсән Туфанның коммунистик хезмәт бригадаларына багышланган үз шигыреннән иде. Биредә шагыйрь белән эшчеләрне берләштергән тирән мәгънә бар иде. Мина калса — эшче егетләр Хәсән Туфанның яңадан сафка кайтуын, эшче-

ләр сыйныфына поэмалар багышлаган зур шагыйрьнең янә дә алар арасына килүен тәбрик итәргә теләделәр...

Актүбәнең кечерәк кенә кунак йортында, ике кешелек бүлмәдә без Хәсән абый белән ике атнадан артык яшәдек. Мин моны зур бер бәйрәмем дип саныйм.

Без, кара-каршы утырып, чәй эчәбез. Хәсән абый юлга чәйнең «индийский», «цейлонский» дигәннәрен алып чыккан, ул чәйне бик ярата, чәйдән башка тора алмый икән. Бөртек чәйне ул тутырып ала да шуны учында уа: алай итсәң, яхшырак чыга, янәсе. Аннары кайнап кына чыккан суга сала да чәйнекнең өстенә мендәр яки тастымал каплап, чирек сәгатьләр чамасы тота.

Без хуш исле куе чәй эчәргә утырабыз. Башкорт әйтмешли, «тастымалны сыкканчы, самавырны екканчы» эчәбез. Чәй янында Хәсән абый күңеленә килгән яңа шигырьләрен яки язылачак шигырьләренең образларын сөйли.

Факеллар нурына болытлар җыела...

— дип башлый ул. Мин аның гап-гади, чамадан тыш гади сүзләр белән шул тикле дә тирән мәгънәне бирә алуына хәйран калып утырам. Факелларны мин дә күрдем, инде ничә еллар күреп йөрим, болытларны мин бала чактан ук күреп киләм. Минем күңелемдә нигә соң факеллар белән болытлар бергә кушылмадылар? Өстәвенә бит әле болытларның факелга җыелганы юк, әмма шагыйрь әйткәч, шул ышандыра, ышандыра гына түгел, өр-яңа дөнья тудыра. «Язучы тудырган дөнья реаль дөньядан чынрак», — дип Паустовский юкка гына әйтмәгән, күрәсең.

Утыра торгач, Хәсән абый, миңа иң яшерен, иң газиз хисләрен әйткән сыман:

— Беләсеңме, туганым, миңа ул факелларда Тукайлар, Җәлилләр йөрәге янадыр кебек тоела, — ди.

Күңелемә Мостай Кәримнең бер очрашуда әйткән сүзләре килә:

— Татар Тукай, татар Такташ, татар Туфан яшәгәндә, татар поэзиясе яши, татар халкы яши, — дигән иде ул.

Актүбәдә унбиш көн яшәгән чагында, Хәсән абый миңа үзенең Себер якларында үткәргән тормышыннан мәңге онытылмаслык истәлекләр сөйләде. Ул аны үзе язып чыгар дип бигүк ышанып бетмим, ник дисәң — әсәрләрен бастыру, туплау ягына бик тә оешмаган кеше, аның хәтта беренче китабын, үзе Урта Азиядә йөргәндә, безнең тәнкыйтьчеләр бастырып чыгаралар һәм ул аны Ташкентта күреп шакката. Аның Себер истәлекләрен теркәп куярга кирәк, юкса онытылыр...

Кабатлап әйтәм — Хәсән Туфан — Әлмәттә бүлек ачылуга иң башлап сөенгән шагыйрь. Ул яшьләргә киңәшләрен әйтеп, аларның шигырьләрен редакцияләп, нәшрият өчен эчке рецензияләр язып, конкрет ярдәм күрсәтте. Шулай да Әлмәт әдипләренә аның иң зур ярдәме — тормыштагы мисалы, оптимистлыгы, иҗаттагы фанатиклыгы булды. Зур язучы һәм зур шәхес янында без үзебезне дә кирәкле кешеләр итеп сиздек.

Әлмәт яшьләренең өченче остазы — Сибгат Хәким. Ул безнең әсәрләрне, шагыйрьме син, прозаикмы, әллә драматургмы, — һәммәсен укып барды. Мин аның яңа әсәрләргә сөенә һәм яшь авторларны илһамландыра белүен иң әйбәт сыйфаты дип саныйм.

1961 елның көзе иде. Лениногорскидагы әдәби хәрәкәтне җанландыру, андагы берләшмәнең эшенә җан өрү, абруен күтәрү өчен без семинарны нефтьчеләр каласы Әлмәттә түгел, нефтьчеләр каласы Лениногорскида үткәрергә булдык. Шамил Бикчуринның бик тә канатланып, дәртләнеп йөргән чагы, Лениногорскидагы әдәби көчләрне бергә туплап йөргән, «Каты токым» романының беренче битләрен язарга керешкән заманы. Семинарны Лениногорскида үткәрүебезне ул ялынып сорады.

Нефть төбәгендәге яшьләрне, партиянең Лениногорск райкомы белән алдан киңәшеп, Ромашкино нефтенә җыйдык. Лениногорскига Әлмәттән, Баулыдан, Азнакайдан, Бөгелмәдән һәм Лениногорскиның үзеннән утыздан артык яшь һәм башлап язучы килде. Семинар үткәрергә, үзебезнең Әлмәт әдәби берләшмәсе җитәкчеләреннән тыш, Хәсән Туфан, Риза Ишморат, Газиз Мөхәммәтшин, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Рәшит Гәрәй махсус чакырылдылар. Ике көн рәттән шигырь укыдык, пьеса укыдык, хикәя укыдык. Сөйләшү зур һәм мәгънәле булды.

Сибгат абый семинарның барышын бик тыныч, хәтта бу эштә катнашы да юк кебек, күзәтеп-тыңлап кына утырды. Күзләрендә вакытвакыт очкыннар кабынудан, ара-тирә, сагышы бар кеше сыман, уйчанланып калуыннан гына, әлеге семинарның аның күңеле аша узганын, әлеге семинарга аның үтә дә җитди караганлыгын белеп була иде.

Сөйләр сүзен ул башта өстәл буена утырган килеш сөйләде, аннары кинәт тирләп чыккан маңгаен кульяулыгы белән сөртә-сөртә, бик пөхтәләп, дүрт почмаклап төреп салган кульяулыгын сүтмичә, маңгаена, гүя авырткан җиргә куйгандай, сак кына тидереп ала-ала сөйләде. Ниһаять, шагыйрь җаны түзмәде, ул торып басты.

— Мин үзем иҗатыма карата тәнкыйть сүзе ишетмәсәм дә, мине гел мактап кыдсәләр дә, тәнкыйтьне кирәк дип карыйм. Тәнкыйтьне минем яманлау мәгънәсендә аңлыйсым килми. Акыллы киңәш мәгънәсендә аңлыйсым килә. Шигырь — кешенең халәте. Ул сулыш кебек табигый булырга тиеш. Без бит сулаганыбызны сизмибез. Мин, үзебез белән бергә юлга чыккан бик тә сәләтле кешеләрнең вакытсыз һәм урынсыз мактаудан башлары әйләнеп, әдәбияттан төшеп калуларын беләм. Талантлы кешенең әдәбияттан төшеп калуы кызганыч. Болай да сафлары Бөек Ватан сугышында сирәкләнеп калган, Мусаларын, Фатихларын, Кутуйларын югалткан поэзиягә яңа талантларны югалту мәгънәсезлек булыр иде. Дан артыннан куу иҗат кешесен үтерә. Максим Горький нәрсә дип әйткән? Дан болганчык су кебек төссез, әчкелтем бер нәрсә, дигән. Ул ныгып җитмәгән яшьләргә начар тәэсир итә, дигән. Дан дигән даруны бик сак кына кулланырга куша Горький, елына бер бал кашыгы гына. Күп итеп кулланса, дан дигән дарудан йөрәкне май баса, тәнгә масаю шеше чыга, иптәшләреңне санга сукмау, үзеңне бүтәнннәрдән өстен кую чире башлана, дигән. Сездә андый чир тамыр җәйгән дип әйтүем түгел, шулай була күрмәсен дип алдан иптәшләрчә кисәтеп куюым. Пожарны сүндерүгә караганда булдырмау яхшырак. Әлмәт яклары, Лениногорск яклары шагыйрьләргә ярлы түгел. Саҗидә бар, Гәрәй Рәхим күзгә күренә, Клара, Энҗе; Әдип инде — поэмалар авторы. Бүген сезгә Туфан олы башын кече итеп килгән икән, поэзия өмет итеп килгән, поэзия булганга килгән....

Сибгат Хәким сөйләгән сүзләрдән мин үземнең көндәлегемә шул кадәресен язып өлгергәнмен. Балаларын кайгырткан әтиләр әйткән сүз төсле, ягымлы, мәгънәле сүзләр.

Әнә шундый кайгырту, Әлмәт ягы яшьләренең әдәби язмышлары өчен борчылу безне гел канатландырып торды.

Оештыру эшләрен беренче көннәребездә Гали Хуҗи алып барды. Ул Язучылар союзының әдәби консультанты иде. Әле Баулыга, әле Әлмәткә, әле Азнакайга килеп чыга, үзен ифрат гади, тыйнак һәм кешелекле тота һәм без аның әледән-әле җибәреп торган хатларын алырга бик тә күнеккән идек. Андый хатлар Әдип Маликовта да, миндә дә саклана. Аларны матбугатта игълан итү илленче ел азакларында һәм алтмышынчы ел башларында яшьләр белән эшләүне күрсәтү ягыннан бик тә файдалы булыр иде.

## Әлмәт кояшы үзенә тарта

Уйламаган-көтмәгән җирдән Рафаил Төхфәтуллин Әлмәткә күчәргә теләге барлыгын белдерде. Бу 1959 елның башлары иде, ул чакта Рафаил Мәскәүдә, әдәбият институтының югары курсларында укый иде. Без, Әлмәтләр, башта моңа бик ышанып җитмәдек. Чыннан да, ничек инде Рафаил шәһәргә күчсен? Утыз ел гомерен авылда — Кенәрдә үткәргән егет, бөтен иҗатында авыл һавасын сулап торган, авылның телен, гореф-гадәтләрен биш бармагы кебек белгән язучы күчәр микән? Ләкин, икенче яктан, аны үзебезгә күчерәсе килү теләге бик зур, аның нәфис-лирик художник икәнен һәм исләр киткеч тыйнак, басынкы кеше икәнен беләбез. Күчсен иде. Мин моңа иплэп кенә хат яздым, син, янәсе, кил, үз күзең белән күр, безнең тормышларны карап кит. Ошаса — баш өсте. Квартир алу мәсьәләләренә калса — эш аңарга терәлмәс. Булышырбыз. Әлмәтнең шәһәр советы да, партиянең шәһәр комитеты да язучыларга якты күз белән карый, дүрт-биш айдан квартир бирә иде.

Коры, кояшлы сентябрь башларында Рафаил безгә килеп төште. Кочаклашып күрештек дисәм, ялган булыр, андый артык нечкәлеккә бара торган егет түгел ул. Аннары — ул әле өянәге килеп (каһәр төшкән сугыш зәхмәте!) егылган да билен сындырган, бик зур каучук корсет киеп йөри иде. Ничек булса булды, бездә шатлык — Рафаил килеп төште. Шул мәлне үк Казаннан, Язучылар союзыннан Зәки Нури телеграмма да бирде: Әлмәттән Рафаил белән мин Лениногорскига — татар һәм башкорт нефтьчеләренең дуслык кичәсенә барырга тиеш икәнбез.

Нефть якларында Рафаилнең бер мәртәбә булганы бар. Ялгышмасам, 1951 елларда ул «Яшь сталинчы» газетасында махсус хәбәрче булып эшләп алды. Әнә шул чакта аны яшьләр газетасы Баулыга, «кара алтын» фонтаннарын карап кайтырга һәм, билгеле инде, бер көлтә очерк язып кайтырга җибәрә. Рафаил «кара алтын» иленә килә, кешеләрен дә күрә, ләкин җүнле-рәтле очерк яза алмый. Авыл малаеның җаны, күрәсең, тимер-томыр дөньясына, әнә шул салкын тимерләргә җан өрүче, аларны гөрелдәтеп җибәрүче кешеләрнең күңеленә тоташа алмый әле. Бүген аның Лениногорскига барасы килә, үзе беренче мәртәбә күргәннән бирле фонтаннарның кай якка таба үскәннәрен белергә тели. Озак кына урын өстендә ятканнан соң юллар да сагындыргандыр инде.

Соңгы автобуска утырып, Лениногорскига киттек.

Без гостиница янына килеп җиткәндә сәгать төнге уннар тирәсе иде.

— Гостиницада тамак ялгарлык бер нәрсә дә булмас. Әйдә, колбаса-мазар булса да алып калыйк, — диде Рафаил.

Без утын пуләне чаклы колбаса һәм, гостиницаларда мондый чакта кайнар чәй дә булмавын искә алып, бер «акбашлыны» да чирттек.

Гостиницага инде Ибраһим Гази белән әле генә институт тәмамлаган бер яшь егет — скульптор Василь Маликов урнашканнар иде. Без бик яхшы беләбез: Ибраһим абый аракы-тәмәкеише нәрсәләрне яратмый, ләкин ул, башка «картлачлар» кебек, бу мәсьәләдә мыгырданмый, үзенең нык ышанган коралын — ачы һәм астыртын көлүен файдалана иде.

— Василь, шахмат уйныйсыңмы? — дидек без.

Василь уңайсызланып кына Ибраһим агайга күз сирпеп алды.

— Уйна, Василь, уйна,— диде Ибраһим абый, мәгънәле итеп.

Без урнашкан бүлмәдә Куйбышевтан килгән нефтьче егет бар иде. Аны да чакырдык. Стакан төбенә салып, берәрне генә каплавыбыз булды, ишектә —Ибраһим абыйның башы:

— Гариф, кемгә мат бирдең? — дип күзлек пыялаларын елтыратып карап тора.

— Эшләр әле шах тирәсендә генә, Ибраһим абый... — дидем мин.

— Ярар, уйнап бетергәч керермен. — Тавышында шул ук киная ишетелә иде.

Икенче мәртәбә стакан төпләрен чылатып алуга, ул кереп тә житте. Өстәл янына килеп утыруы булды, шешәгә күз сирпеп алуы булды.

— Нәрсә бу, егетләр?

Мин аның ишектән керә башлавын күргәч үк, шешәнең этикетлы ягын әйләндереп куйган идем: без дә шаярта беләбез, янәсе.

— Ботка бу, Ибраһим абый.

Теге — ялт! — шешәнең язулы ягын әйләндерде.

— Юк, водка дигән монда.

Без, дүртебез берьюлы, шаркылдап көлеп жибәрдек.

Үзләренең бүлмәсенә кайткач, ул әлеге «шахмат уены» турында шактый үтемле бер вәгазь сөйләп алды.

— Менә сез эчмәдек дисез инде? Дүрт кешегә бер ярты нәрсә дисез инде? Йөз егерме биш грамм. Ну бит аның исе килә...

— Сез моны Афзал абыйга кайтып әйтәсез инде? (Афзал Шамов— председатель иде).

— Ә син әйтмәсең дип әйтәсең инде?..

...Иртәгесен без Лениногорск горкомына юнәлдек. Шәһәр әле салынып кына ята. Бер якта ак таштан салынган, барысы бер төсле, ап-ак йортлар, икенче якта — колонналы, өч катлы горком бинасы япаялгызы басып тора, шәһәр белән горком бинасы арасында казылып ташланган жир, кантар-кантар балчыклар. Әнә шуларга абына-сөртенә бара торгач, без шәһәр комитетында очрашуга соңга кала яздык.

— Сәгатегез ничә, Ибраһим абый?

— Ун туларга чирек.

— Дөрес йөриме?

— Бик дөрес йөри, хәтта соңга да кала,— диде ул, житди итеп.

Шәһәр комитетында сөйләшәсе сүзләрне сөйләшеп, бүгенге кичәнең планын да ачыклап, тагын урамга чыктык. Дуслык бәйрәме төштән соң, ял паркында, ачык һавада буласы икән. Безнең әле ике сәгатьтән артык вакытыбыз бар иде — китап кибетләрен, нефтьчеләрнең китапханәләрен карап йөрдек.

Өстенә ялтыравык кара атластан теккән халат кигән, караңгы чырайлы китапханәче хатын шушы көннәрдә генә бер китапханәче штатын кыскартуларын сөйләп торды. Китап шүрлекләре арасында актарынып, күзлеге астыннан сүзсез генә китап битләренә күз салгалап йөргән Ибраһим Гази — һы, һы! — дип куйгалады.

Бәйрәм оркестрлар, концертлар белән булса да, артык кызыклы узмады. Октябрьскидан килгән Тимер Арслан, таза, базык гәүдәле шагыйрь, кулларын бутап, дуслык турындагы шигырен укыды, Казан артистлары жырладылар, биеделәр, без — Рафаил, Василь Маликов һәм мин — халык арасында, жиргә беркетеп ясалган агач эскәмияләрдә утырып тордык. Безнең барыбыз өчен ачы телле, күзлекле, язучылык стажы Рафаил белән икебезнекен бергә кушканда да берике мәртәбә артып китә торган Ибраһим Гази сөйләде. Без аңардан күбрәк нәрсә өмет иткән идек, ләкин аның сүзе нигәдер шактый сүлпән һәм тоныкк булып чыкты. (Язучылар жыелышында ул үткенрәк, кыскарак һәм мәгънәлерәк сөйли торган иде). Бу сүлпәнлекнең мәгънәсен без соңыннанрак аңладык.

Нефтьчеләр, бүгенге бәйрәм хөрмәтенә, елга буендагы аулак бер бакчада, ашханәнең зур залында мәҗлес оештырганнар, өстәлләрдә— жаның ни тели шул бар иде. Ачык һавадагы, парктагы очрашуга караганда бу очрашу жанлырак та, табигыйрәк тә булып чыкты.

Бераз гөрләшеп утырганнан соң, нефтьчеләр сәнгать вәкилләренең сүз сөйләвен үтенделәр. Артистлар җырлады, гөнаһларына керер хәлем юк, рәсми очрашудагыга караганда, күп өлеш әйбәтрәк җырладылар, хәтта үз җырларыннан үзләре үк канәгать булып калдылар бугай. Аларның мәҗлескә җан кертүләре белән канатланып киткән нефтьче егетләр язучыларның да сүз әйтүен таләп итә башладылар. Мондый чакта Рафаилгә өмет баглау — өметсезлек. Сөйләми ул, сөйли дә белми.

Китапларында шундый да җылы, җанга ятышлы сүзне каян табадыр — сөйли белмәве, ыкы-мыкы килүе белән чагыштырганда, аның алай оста яза белүе хәтта минем өчен серле, тылсымлы бер дөнья булып кала килә. Мин — азмы-күпме сөйли алам, ләкин оста барда телең тый дигән мәкальне истә тотып, дәшми утырам. Чират тагын Ибраһим абыйга килеп терәлде. Ул мәҗлестә, үз гадәтенә туры калып, бер генә йотым да эчми утырган иде. «Сөйләр микән?» — дип без шикләнә калдык.

Ибраһим Гази урыныннан торды. Күзлеген салып, кулъяулыгы белән озаклап сөртте, киде. Үзенә таба башларын борган чибәр, таза, яшь егетләргә, яшь кызларга күзлек астыннан бер караш ташлап, залны авыр гына сөзеп алгач, рюмкадагы кызыл аракының яртысын стаканга салды, яртысына «Нарзан» кушты да, сүзсез-нисез эчеп җибәрде. Аннары сөйли башлады:

— Күреп торам, бик акыллы, бик эшлекле кешеләр сез, хәзерге яшьләр. Илгә алтын бирәсез. Нинди машиналарны хәрәкәткә китерәсез. Бу әйбәт. Мин моны мактап әйтәм. Ләкин бер ярамаган эш эшләгәнсез. Сезнең борын төбегездә китапханәче штатын кыскартканнар. Монысын инде мин мактап әйтмим. Китапханәче штатын кыскартырга батырчылык иткән кешене мин атарга боерам!

Зал тынды. Һәм байтак вакыт сүзсез утырдык. Көндезге очрашуда ул сөйләгән котлау сүзе, бәлки, берәүнең дә исендә калмас, ә менә бу тост, образлы сүз, мәзәк сүз таләп иткән «әйбәт, эшлекле» кешеләрнең күзенә карап әйткән кыска һәм усал сүзне, мин берничә ел узганнан соң да, нефтьчеләр авызыннан берничә мәртәбә ишеттем.

Икенче көнне Рафаил самолет белән Казанга кайтып китте. Без Ибраһим абый белән Әлмәткә юнәлдек. Гостиницада урын юк иде. Ул аңа кайгырмады, хәтта сөенде дә бугай.

— Әйдә, Әлмәттә ниләр кырасың? Берәр яңа әсәреңнән өзек укырсың, — диде. Минем өчен бу сөенечле хәл иде. Үзенә һәм бүтәннәр иҗатына гаять таләпчән бу язучының үзе теләп минем яңа әсәремне тыңларга алынуы мине дулкынландырып җибәрде.

Мин безнең квартирага кайтып керү белән өстәл астыннан язмаларымны чыгара башладым.

— Тукта, ашыкма. Әсәр уку — бәйрәм ул, — диде Ибраһим абый. Башта ул безнең бүлмәләрне карап чыкты. Шәһиднең хуҗалыгы белән танышып, гөлләрен барлап йөрде. Розаларга исе китмәде, зур яфраклы фикус гөле янында туктап та тормады, кухня тәрәзәсе төбендә, иң аулак урында ялгызы гына посып утырган исле гөл янына туктап, аны башта җиңелчә селеккәләде, аннары гөл арасына чәчсез башы белән күмелеп, рәхәтләнеп иснәде дә, кечкенә генә бер тармагын өзеп алып, түш кесәсенә кыстырып куйды. Тик шуннан соң гына минем эш бүлмәсенә килеп керде.

— Я, укы. Мин диванга кырын төшеп тыңлыйм әле, — дип диванга, чыннан да, кырын сузылды.

Әлмәткә килгәч яза башлаган «Хәзинә» романының бер бүлеген укыдым. Укып бетергәч, каушап, аның хөкемен көттем.

— Тагын бармы?

— Бар.

— Укы — булса.

Мин тагын бер бүлек укыдым.

Ул диваннан торып утырды.

— Беләсең инде — мин мактауга саран кеше. Ләкин мин моны мактыйм. Яңа бу, чын. Әлмәткә килүең, болай булгач, бушка китмәгән, егет, — диде.

Икенче көнне өйләгә чаклы шәһәрне карап йөргәннән соң ул кайтып китте. Мин аны такси белән Бөгелмәгә чаклы озатмакчы идем, ул якын да килмәде, сары саквояжын култык астына кыстырып, шәһәр автобусына менеп утырды.

— Бар кайт, язуыңнан бүленмә. Хатының тагын минем белән баш төзәтеп йөри икән дип уйлар, — дип күзлек астыннан гына елмаеп куйды.

Ул, нидер исенә төшеп, автобустан кире чыкты.

— Төхфәтуллин Әлмәткә күчәмени?

— Әйе. Квартир бирергә булдылар.

— Син котырттыңмы?

— Юк ла. Үз теләге белән. Мәскәүдән үк хат язган иде.

— Алайса ярый, — саквояжын култык астына кыстырган килеш, тагын автобус баскычына сикерде. Борылды.

— Караны, үзе теләсә генә! Рафаил — авыл язучысы. Күчереп утырткан гөл бар туфракта да үсми...

Шулай да Рафаил, «ияләнгән туфрагыннан» аерылып, Әлмәткә килде. 1959 елның декабрь ахырларында шәһәр советы биргән өч бүлмәле зур якты квартирга инглиз йозагы куеп, ачкычын аның кулына тапшырдык:

— Әйдә, дус, төкле аягың белән!

Әлмәттә яшәве Төхфәтуллинга файдасыз булмады, минемчә. Монда ул «Йолдызым», «Тамчылар ни сөйли?» повестьларын һәм «Гашыйклар урамы» пьесасын язды. Биш ел эчендә байтак кына яңа хикәяләр дә бастырды. Эш шартлары әйбәт иде аның. Ләкин ул нефтьчеләр турында зурдан кубып сөйләрлек, вакыйга булырлык әсәр яза алмады. Күрәсең, «гөл ияләнгән туфрагында әйбәт үсә».

Кемгә ничектер, мин үзем Рафаил Төхфәтуллинны бүгенге колхоз авылының сихерен белгән, аның әрәмәле тугайларын, биек зәңгәр һаваларын, барыннан да бигрәк кешеләрен — гади һәм шул ук вакытта олы җанлы кешеләрен — йомшак тыныч табигатенә бөтенләе белән сеңдергән язучы дип саныйм. Шулай булмаганда, ат караучы гап-гади Нәбиләр, колхоз тугаеннан үз сыерына бер арба печән чапканга җаныын кая куярга белми интеккән Фазылҗан картлар, гомер буе үз йолдызын эзләүче Гөлзифалар безне ничек дулкынландыра алсын ди соң!

Әлеге ихлас күңелле танышларыбыз янына менә тагын бер яңа кеше өстәлде. Беренче саф мәхәббәте белән, очучы булырга омтылган яшьлек хыяллары белән, бер караганда язгы гөрләвекләр кебек шаулап, икенче караганда инде моңсуланып, тормышның кырыс рәхимсезлеге белән очрашкач, берьюлы олыгаеп китеп, авыл юлыннан Ильяс килде! Бу инде Нәбиләр, Фазылҗан картлар, Гөлзифалар гына түгел, бу — зуррак канатлы, киңрәк колачлы егет. Дөрес, бу да Әлмәт ягы кешесе түгел, Казан арты, Тукайлар ягы баласы, Рафаилнең күңеленә Кырлай урманнары белән кергән егет, ләкин ул аны Әлмәткә килгәч иҗат итте, кем белә, бәлки, туган-үскән яклар ерактан әйбәтрәк күренә, ныграк сагындырадыр, яз ясаучы «тамчыларның» берсе булган Ильяс, ихтимал, шуңа да аеруча җылы, күңелгә якын. Ләкин, ни генә булмасын, ул Гөлзифалардан зуррак, киңрәк колачлы булып туды. Аның колачы киңлегенә Әлмәт якларында башланган гигант эшләрнең колачы да кушылмадымы икән? — дип уйлыйм мин.

## Хәзинәләр эзләү заманы

Әлмәткә күченеп килгән чагында минем күңелдә «Байлангар» исемле роман язу фикере тәмам оешып житкән иде инде. Шәрәф Мөдәррис белән бергә илленче еллар башында Кукмара районында һәм Нократ якларында йөреп кайту, авыл тормышыннан байтак кына очерклар язып бастыру, шулар янына үземнең дә авылда туып-үсүем, табигатьнең күңелгә сеңеп кала торган, кешене нәфис-садә, беркатлы-ихлас итә торган хасиятләрен җаным-тәнем белән тоеп яшәгән булуым миндә авыл кешеләренең матур сыйфатларын сәнгатьчә сурәтләп бирү теләген уяткан иде. Тормышта әле һаман да очрый торган икейөзлелекне, ялганны, вак җанлылыкны авыл малаеның сафлыгына контраст итеп куймакчы идем. Тора-бара, авыл романы өчен болар гына җитмәс кебек тоела башлады. Бу ниятем — әсәрнең нигезен тәшкил итәчәк төп фикерем — ничектер тенденциоз кебек, ак җеп белән тегелгән кебек күренде. Өстәвенә ил күләмендә барган зур вакыйгалар, сугыш җимергән хуҗалыкны аякка бастыру кебек зур хәлләр янында бу кечерәк бер сукмак кына булыр иде. Шуннан соң инде мин авыл малаен авылда гына калдырмыйча, шәһәргә алып килергә, аны укытырга, галим итәргә, кыскасы — аның үз күңеле, үз башы аша ил күләмендә барган вакыйгаларны, социаль үзгәрешләрне сурәтләп бирергә ниятләндем. Романда әнә шундый фикер үткәрү инде мине дулкынландыра, күңелемне җылыта, мин аның укучыга алып килә торган иҗади йөге белән дә килешә идем.

Тик... минем авыл малаем кайсы шәһәргә килер? Нинди эш белән шөгыльләнер? Әнә шул уй мине туктаусыз борчып тора. Нефть якларына күченеп килү бу борчылуларга да ачыклык кертте. Авыл малаеның шөгыльләнә торган эше нефть чыгару икән ләбаса! Күңел тәмам утырды, һәм мин яңа роман өчен ашкынып-җилкенеп материал җыя башладым. Гомәр ага Бәширов миңа Казанда чакта ук язылачак әсәрләрем өчен «амбар кенәгәсе» ачарга кирәклеген әйткән иде. Укучыларның нәрсә ул амбар кенәгәсе дип аптырап калулары мөмкин. Шуңа күрә алдан ук аңлатып бирим. Суыштан соңгы чорда кибетләрдә калын дәфтәрләр юк иде, тышына «Амбар кенәгәсе» дип язган, китап кебек итеп төпләнгән кенәгәләр бар иде. Гадәттә алар канцелярия ихтыяҗлары өчен чыгарылалар иде. Гомәр ага әнә шундый кенәгәне очраган чакта күпләп алырга, язачак романның, повестьның, яки хикәяләрнең төп фикерен, геройларын, кызыклы сүзләрен, вакыйгаларын, сюжет-композициясен, күңелгә килгән уйларын шуңа теркәп барырга кушты. Үзе «Намус» романын язар алдыннан башкарган эшләрен әнә шул амбар кенәгәсеннән күрсәтеп бирде. Мин өлкән язучыбызның миңа өйрәткән бу эшен ифрат файдалы дип саныйм һәм әле генә әдәбият дөньясына аяк баскан яшьләргә бу ысул белән эшләүне тәкъдим итәм. Бәлки, «амбар кенәгәсендә» язганнар ул хәлендә әсәргә килеп тә кермәс, әмма ул әдәбиятчыда күзәтүчәнлек, тормышка актив караш тудыру ягыннан бик тә әһәмиятле.

Минем «амбар кенәгәмдә», мәсәлән, мондый юллар бар:

**ФИКЕРЛӘР:**

«Казан — совет шәрыгының культура үзәге. Заманында Казан каласы аркылы казакъ даласына рус прогрессив әдәбиятының якты нурлары үтеп торган. Рус әдәбиятын үзенең хәзрәте дип санаган бөек Тукай казакъларны Пушкин, Лермонтов, Кольцовлар белән тоташтырган», — бу сүзләрне казакъ язучысы Г. Мөсрепов Татарстан язучыларының III съездында сөйләде.

30 июнь, 1954.

## ЯҢА ШӘҺӘР КҮРЕНЕШЛӘРЕ:

«...Әлмәттә бөтен нәрсә яшь, агачлар, биләүсәдәге сабыйлар кебек, бил тиңентен уратып алынганнар.

**1 март, 1958.**

...Яңа шәһәр яшь урман кебек була икән. Әлмәттә әле күгәрченнәр юк. Казанда алар чат саен иде.

...Төн. Ленин урамында яңа йорт өлгереп килә. Тәрәзә саен кәкре торба чыгарып куйганнар. Лампочкалы кран муенын борган чакта, өйнең күләгәсе шуып урман аша чыга да икенче өй белән тоташа.

**2 март, 1958.**

...Шәһәрдә бөтен нәрсә яңадан төзелә: йорты, мунчасы, келәте, кибете. Һәр чатта таш ватыклары, балчык-ком өеме — моңа берәүнең бер исе китми. Бөтен шәһәр, төп йорттан аерылып, башка чыккан яшь хуҗаларны хәтерләтә. Анда да бит чүпчарга, йомычкага берәүнең дә исе китми торган була. Яшь хуҗа, төзелеш чүпләренә борчылудан бигрәк, яңа салынган каралты-курасына сөенә.

**3 март, 1958.**

...Әлмәттә салкыннар башланды. 40—45 градус. Әйләнә-тирәдәге күренеш бөтенләй үзгәрде. Кичләрен шәһәр өстен әллә нинди кара томан баса. Багана башындагы фонарь утлары сары булып күренәләр, фонарьларның әйләнәсендә тонык бер шәүлә кыршавы барлыкка килде. Моңарчы, җылы-аяз төннәрдә, күкне иңләп янган факел утлары хәзер, кылыч кебек, прожектор уты кебек, туп-туры күккә сузылалар. Моңарчы урамда үзләренең барлыгын сиздермәгән яшь куаклар кинәт калкып чыктылар: аларның өстенә калын булып сыкы утырды. Урамнардан барганда хәзер үзеңне чыршы бәйрәмнәре өчен юрамалый бизәп куйган парк эченнән узгандай хис итәсең, синең баш өстеңдә беләк юанлыгы ак арканнар эленеп тора — болары бәс сарган телефон чыбыклары. Кыскасы, Әлмәт урамнары кичләрен реальлекләрен югалтып, аклы-сарылы утлар, ясалма агачлар белән бизәлгән сәхнә декорацияләренә охшап калдылар.

Бу сәхнәнең үзенчәлекле музыкасы да барлыкка килде — радиаторы туңып калудан курыкмаган машиналар урамнан узган чакта, дистәләгән атлы олау урман юлыннан узган кебек, кар каты шыгырдый, шыгырдау тавышы урамның бер башыннан бер башына ишетелеп тора.

**24—25—26 декабрь, 1958».**

## СӨЙЛӘШҮ РӘВЕШЕ, ҮТКЕН СҮЗЛӘР

— Кулым тынса, җаным тынмый, шушыларга бер эш кушсаң.
— Бала табу — бер кыен, бала багу — мең кыен.
— Ул сөенгән чакта йөзендәге һәр җыерчык көлә.
— Кем белән кара булсаң, шуның белән ак бул.
— И-и-и, әле бик иртә, спутник әле генә узып китте.
— Әйбәт ие директорыбыз, эшләгән кешегә якты күз белән карый белә торганые.
— Аның гомер буе шулай булды: ачка койрык кадап йөрде.
— Арбаны тоткан дегет, хатынны тоткан егет.
— Кеше өлеше түгел, көшел өсте.
— Исәп йомры, уч төбе буш.
— Аты-чабы чыкмады.
— Семьяга бәйләнгән кешенең тормышын әйтмә инде: чыпта арасына эләккән тавык кебек, чыгып та китеп булмый, чабып та китә алмыйсың, гомерең буе чыпта тартып барырга тиешле син.
— Ирсәкнең җиде чикмәне булыр, алтысы кешедә булыр.
— Ничекләр торасың дип сорыйлар. Кули кәк торабыз. Колагымны саңгыраулатып, күземне сукырайтып, ишетәсен ишетми, күрәсен күрми яшим.
— Таптанма әле, никрут түгел, иртәгә солдатка китмисең. Идән юам мин хәзер.
— И-и-и, карлар кебек эрисең, чыклар кебек кибәсең икән ул картайгач.
— Уникенче числода Хәлим абзый гүр иясе булды, каберен зиярат кылыйк дисәгез, килеп китегез.
— Ярый инде: гарип-гораба булмаса, дүрт гамәле дөрес булса...
— Минуты белән бар, минуты белән юк.
— Табаннан азгандыр инде синең телең: бу хәтле дә әшәке булмасые.
— Мөнә генә йокыга китә, әлли сыртым дип, мөнә генә тагын уяна.
— И гыйбрәтсезләнде, и гыйбрәтсезләнде!
— Хатыным Васильевода ял итеп кайтты, аңар нарат исе, ылыс исе сеңгән.
— Улым әйтә башламый торып, мин машина маркаларын белми идем, ул сораша башлау белән өйрәндем, аңа белмим дип әйтеп булмый бит инде.

— Улымдыр шул, алмамдыр шул инде.
— Инде дә мин бәхетсез дисәң, алла орыр үзеңне!
— Менә шушы тиле әйткәнне дибәйтеп әйтерсең, ул чагында соң булыр.
— Нәсел чертеп йөрисең.
— Кайнана белән кандалага дару юк.
— Мәхәббәт кешенең эчен-тышын яңарта.
— Тымытыклар күп нефть эшендә. Алар чыпчыкка җон чыккан чакны сизеп калдылар (Акча күп төшкән чакны мәгънәсендә — Г. А.).
— Балчыктан чана сөйрәп йөри торган көй бит ул.
— Табыласы мал тау кадәр.
— Дуңгыз кылыннан киез итек басып буламы?
— Моннан кыякларга исәп.
— Уйласам уелып китәм, йөрсәм генә йөрәгем тынычлана.
— Әйттем мин аңар, казык башында булган икән башың, дидем.
— Яшь әле, катын чырае күрмәгән.
— Мин аңа шоколад алып килдем. Алмады. Мондыйны, ди, соядан ясаганны, ди, Кавказ ягында ишәккә генә ашаталар, ди.
— Бераүгә үлем хастасы тигән. «Үлүе читенме?» — дип сораганнар. «Бала караудан читен түгел әле», — дип әйткән ди.
— Бала багучы карчык — өйдә алтын канат.
— Аның эчендәгесе тышында, синең тышыңдагысы да эчеңдә.
— Кешене ике нәрсә күтәрә ала: берсе — хыял, икенчесе — мәхәббәт.
— Телемнең тупсасы юк, сөйләмә туктасы юк.
— Яшәү культурный, ашау культурный: өстәлдә ипи тормый.
— Минем матурлыгым ямьсезлегем белән генә беленми.
— Кайтыр дисеңме? Сукыр мүгез урнына чын мүгез үссә, кайтыр.
— Шөкерлек килмәсә дә, көферлек килә.
— Мулла кебек син: сәламне үзең бирмисең, җыеп кына йөрисең.
— Талымчан кеше түгел мин: каймак булса, катык димим, ит булса, сөт димим, кыз булса, катын димим.
— Юньсезгә майлап бирсәң, юеш дип әйтер, ди.
— Собрание белән нәзәр, собрание белән басалар, сөлге буе протокол язалар.
— Коры җиргә цемент ябышмый, чиста кешегә гайбәт ябышмый.
— Хәзер инде кесә саен закон.
— Мич астында да бала, мич өстендә дә бала, күпме икәнен белсә катын беләдер.
— Куянны этсез куып булмый.
— Әй уңгыры, бер башың мең булгыры!
— И картаеплар да карады соң: бите бөрешкән алма кебек булып калды.
— И җаным, күз буяу дигәннәре бар әле. «Техника безнең заманда могҗизалар эшли» дигән метр буе хәрефләр белән язган плакат эленеп тора, шуның янында ук биш-алты кеше ах-ух килеп машина этеп яталар.
— Өрдем тоймас кеше ул.
— Эшең артыңнан сөенеп калсын.

## КЕШЕ ХАРАКТЕРЛАРЫ, ПОРТРЕТЛАР

«Университет физиологы Ибраһим Вәлидов — кыеграк күзле, түгәрәк битле, турыга бәреп сөйләшә торган юморист. Мәҗлесләрдә ул:
Алларын да алмадың, гөлләрен дә сайладың,
Түшең киерен йөргән идең, әллә кемгә бармадың,
— дип җырлый. Докторлык диссертациясен коточкыч хезмәт куеп, бер меңнән артык бака ярып яза. 50 яше тулган көнендә аңа икенче бер физиолог, доктор Усман Курмаев, дусларча шарж ясап алып килгән: зур гына яшел бака, Вәлидов әнә шул бакага атланып бара. Ә бер читтә, ат абзары янында, атның йөгән тезгененнән тотып, әтисе моңаеп тора: атка атланыр дип көткән нем, булмады, бакага атланып китте, янәсе».

Мин моны Ибраһим ага Вәлидовның юбилеенда булганнан соң, 1956 елда язып куйганмын. Ә бит ул соңыннан минем «Чулпы җыры» пьесамда хәрби врач, фәннәр докторы Зыя образын язганда, нигез материал булып хезмәт итте.

Менә, Гомәр ага Бәширов киңәш иткәннән соң, егерме биш ел буена төрле кызык хәлләрне, кеше мөнәсәбәтләрен, портретларны, үткен сүз һәм сөйләшү рәвешләрен өзлексез теркәп барган «амбар кенәгәсеннән» мин сезгә берничә, бары тик берничә генә битне ачып күрсәттем.

Без, әдәбият кешеләре, тормышка чамадан тыш актив мөнәсәбәттә булырга күнеккәнбез, ахрысы. Миңа кайвакыт, хатын-кызларга артык төбәлеп торуым сәбәпле, кыен хәлләргә калырга да туры килгәләде. Кайбер яшь ханымнар, минем, кирәк булыр әле дип, төбәлеп каравымны, гашыйк булуга санаганнары бар. Яки икенче бер очрак. Туганым Тукаев миңа бер мәлне озаклап зарын сөйләде. Ул сөйләп бетергәннән соң да әле мин, керфек тә какмый, һаман аңа карап торам икән. Моның өчен ул миңа рәнҗеде.

— Мин сиңа кеше итеп кайгымны сөйлим, ә син кешемени, язучы гына бит син, берәр әсәремә ярап куяр әле дип кенә тыңлыйсың, — диде.

Украин язучысы Михаил Коцюбинскийның «Алмагачлар чәчәк ата» дигән хикәясен укыганда, шуңа охшаш бер хәл очраттым мин. Язучы үлгән кызын карарга өйгә керә һәм, ихтыярсыз, язучылык һөнәре буенча, кирәге чыгар әле дип, өстәл өстендә сузылып яткан кызының халәтен күңеленә сеңдерә башлый. Менә ул күренеш:

«Нинди икән ул хәзер минем бәләкәчем? Юк, уйларга кирәкми, ул юк бит инде. Юк. Аны кая салдылар икән? Хәзер нинди икән ул? Миңа моны белү кызык. Мин шау чәчәкле алмагачның чәчәк тәлгәшләрен сындырып, кочагым тулганчы җыям, мин аларны өйгә алып керәм. Мин сабыемның, бәләкәч кызымның кайда икәнен, аны кая салганнарын белмим — беренче бүлмәдә, кунак бүлмәсендә үк, минем каршыма өстәл килеп чыга, ә өстәл өстендә...

Мондамыни син, кызыкаем? Син нинди зурайгансың, үсеп киткәнсең, әйтерсең, сиңа өч яшь түгел, алты яшь...

Мин аның янына алмагач чәчәгенең тәлгәшләрен тезеп чыгам, чәчәк таҗларын аның өстенә сибәм, алар шундый нәфис, шундый саф, минем сабыем төсле.

Күземне алмый кызыма карап торам.

Ул, кулларын як-якка куеп, чамадан тыш тураеп ята, балавыз курчак төсле. Аның өстендә кыска ак күлмәк, аягында — мин күптән түгел генә алып биргән сары башмаклар. И сөенгән иде дә соң ул аңа...

Аның баш очында шәм яна. Көпә-көндез янган шәм утының яктысы юк, ул табигый түгел, әллә нинди төссез, үлек ут. Ут шәүләсе, калтыранып, бәләкәчемнең яңакларында бии.

Мин балавыз гәүдәгә карыйм, мине сәер бер тойгы биләп ала. Мин бу гәүдәнең үзем өчен чит икәнен, минем тере гәүдәм белән бернинди бәйләнеше юк икәнен тоям, минем тәнемдә кайнар кан ага, мин бу балавыз гәүдәне түгел, минем хәтеремдә алтын очкын булып сакланган тере гәүдәне яратам, исән кызым өчен сагышланам.

Ә минем зиһенем, үземнән бер генә мизгелдә дә калмый йөри торган секретарем, бу тынсыз, үле гәүдәне, аның алмагач чәчәкләренә күмелеп ятуын, күгелҗем төскә керә башлаган биттәге шәм яктысының шәүләсен һәм минем сәер тойгыларымны терки...

И каһәр төшкән зиһен, синең боларны нигә теркәгәчеңне беләм мин. Кирәге чыгар әле, дисең... кайчан да булса... язганда материал булыр...»

Адәм баласының иң фаҗигале чагында да, бар нәрсәдән кадерле кызын югалткан мизгелдә дә, язучы аңы, язучы зиһене эшеннән туктамый. Рус телендә призвание дигән сүз бар. Бу чын язучыларга, чын рәссамнарга, чын галимнәргә карата әйтелә. Язучылык призваниесе булган кешеләр бер генә көн дә язмый тора алмыйлар. Язучылыкны кәсепләре итеп кенә алган кешеләр, сүз белән сүзне ялгап, рифма гына чыгара торган суык тимерчеләр, язмый да тора алалар, акча өчен кирәк булса, бик аз вакыт эчендә кәгазь таулары да өеп куялар...

«Хәзинә»гә әйләнеп кайтыйк. Шушы роман өчен дип ачкан «амбар кенәгәсендә» дүрт ел эчендә бик күп материал җыелган. Романдагы геройларның тормыштагы биографияләре, кызыклы хәлләре, аларга бәйле вакыйгалар, аларның социал йөзен, җирлеген билгели торган фикерләр теркәп куелган. Арслан Гобәйдуллин образын язар өчен мин нефть якларыннан өч кешене өйрәндем. Аның берсе — Әсгать Абдуллин. Баулы якларында туып үскән, шушы якларда мәйдан тоткан, сабан туе батыры булып калган егет. Ул — илленче елларның иң алдынгы бораулаучысы, Татарстан АССРның Верховный Советы депутаты иде. Икенчесе — бораулау мастеры, соңыннан инженер, зерә дә акыллы һәм бик оялчан егет Тәлгать Бикчурин. Өченчесе — Әлмәттә туып-үскән, сугыш юлын узган, «Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән, искиткеч чибәр йөзле, җор сүзле, зирәк һәм тапкыр табигатьле, сөйләсә әйләнә-тирәне авызына каратып тота ала торган Үзбәк Саттаров. Ләкин «Хәзинә» романын язу уе Арслан Гобәйдуллиннан да, баш әйләнгеч рекордлар куеп, соңыннан фаҗигале рәвештә һәлак булган Кәрим Тимбиковның портретын табудан да башланмады, гап-гади бер кеше Заһир Гариповтан башланды. Заһир агай, мин Әлмәткә килгәндә, илле яшьләрендә иде, ул миңа бик өлкән кеше булып күренде. Бу мастерның егерме биш ел буе нефть эшендә эшләп, җир борау-

лап, Баку, Грозный, Сызрань, Куйбышевларны әйләнеп кайткан булуы, җир йөзендә ул бораулаган бер йөздән артык нефть скважинасының фонтан атып торуы аның өлкәнлеген тагын да арттыра төшә иде. Әлмәткә килгән беренче елларны мин айлар буе Заһир агай буровоенда кунып-төнеп яттым. Алдарак әйткәнемчә, мине аның белән журналист Фазыл Мостафин таныштырды. Заһир агай тәбәнәк буйлы, җирән чәчле, шушы Әлмәт якларында туып-үскән, акыллы, сабыр кеше иде. Аның сигезме-тугызмы баласы бар, рәхәтләнеп, чыркылдап көлә торган Сәрби атлы хатыны бар, әнә шул Сәрбиҗамалттәй, инәгә тагылган җеп кебек, илнең буеннан буена иренә тагылып йөри, иренең көен көйли, аңа бер көтү бала табып, аларны багып үстерә, өйләренә йомыш белән килсәң, сине үтә дә алчакланып каршылый, түр башына утырта. Минем бик күп гаиләләрне күргәнем булды, әмма Заһир агай белән Сәрбиҗамалттәй кебек тату, табигый тормыш белән яшәгән һәм халкыбызның иң матур сыйфатларын үзләрендә туплаган гаиләне күргәнем булмады. Хәзер инде Заһир агай да, Сәрбиҗамалттәй дә исән түгел, алар берничә ел элек дөнья куйдылар, җир йөзендә аларның үсеп җиткән балалары яши, Заһир агай бораулаган бик күп скважиналар фонтан атып утыра. Адәм баласы дөньядан киткәндә җир йөзендә эзе калганны белеп үлсә, ул — иң бәхетле кешедер, мөгаен. Лотфулла белән Тәүфика түтинең прототиплары булган Заһир агай белән Сәрби түти шундый кешеләр иде.

Мине Заһир агайның Татарстан җиренә мастер булып, дөнья гизеп кайтуы кызыктырды. Әнә бит бәхет аяк астында гына икән, татарлар аны эзләп кайларга гына юл тотмаганнар!

Лотфулла агай белән Тәүфика түти янына яшь кенә килеш сугыш юлы узган, белемгә, зур эшләргә омтылган Арслан Гобәйдуллин килеп кушылды. Монысы заманның яңалыгын, буыннар алмашынуын бирү өчен кирәк иде. Ләкин әле бу вакытта романның конфликтын тәшкил иткән герой Кәрим Тимбиков табылмаган иде. Мин аны атаклы бораулау остасы, даны ил күләменә чыккан, баш әйләнгеч рекордлар куйган, исеме СССР Министрлар Советы председателе докладларында телгә алынган Михаил Белоглазовның фаҗигале үлеменнән соң таптым. Хикмәт шунда ки, Белоглазов һәлак булганнан соң миңа Мәскәүнең калын бер журналыннан өч-дүрт табаклы әдәби очерк язарга заказ бирделәр. Киттем мәрхүмнең бригадасына. Барсам, шул ук егетләр, заманында рекордка шатланган, көрәп акча алган егетләр, балталары суга төшкән төсле, боек утыралар, өстәвенә миңа берни сөйләргә теләмиләр. Аларның тел ачкычларын тапканчы, буровойга атна буена йөрергә туры килде. Ниһаять, алар ачылдылар. Белоглазовның производство новаторы, талантлы оештыручы булуы белән беррәттән, байтак кына «утын да ватканлыгын», ягъни, рекорд артыннан куган чакта, берничә кешегә травма ясаганын, әйтик, бораулаучы Петр Карповның аягын сындырганлыгын сөйләп бирделәр. Сөйләүчеләрдән шул аңлашыла: Михаил Белоглазов, утыз яшьлек таза-чибәр, яшь кеше, меңәр сумлап алган премияләрдән, бүләккә бирелгән берничә җиңел машинадан соң азына, иптәшләрен санга сукмый, иминлек кагыйдәләрен саклауны уйлап та карамый башлый. Аның өчен контор директоры да, инженерлар да «непочем!». Менә шуннан китә дөнья куласасы әйләнеп. Коллектив белән санашмау Михаил Белоглазовны һәлакәткә китерә.

Күңелдә борчылу туды. Уй туды. Нефтьне без «кара алтын» дибез, «хәзинә» дибез, ә бит ул кара алтын хәзинәсе кеше дигән хәзинәбез исән булса гына ике мең метр тирәнлектән җир өстенә күтәрелә ала. Димәк, беренче хәзинәне, кеше дигән хәзинәне ныграк сакларга, аның тормышын, аның иминлеген өзлексез кайгыртып торырга кирәк. Бу — минем замыслым, котмәгәндә юлыккан бәхетле табышым.

Хәзер шул уй мине җылытып торачак, шул уй миңа романның сюжетын, композициясен төзәргә ярдәм итәчәк.

«Хәзинә» романын мин 1957—1961 елларда яздым. Дүрт ел вакытымны алды ул минем. Бер караганда бу бик күп, икенче караганда аз. Мин бит бер дә белмәгән материалга тотындым. Миңа мая туплаларга, нефть эшенең серенә төшенергә кирәк иде. Әмма миңа шул ук вакытта «Байлангар» романы өчен, ягъни үзәгендә авыл малае булган зур әсәр өчен материал җыйган булуым ярдәмгә килде. Лотфулла Дияров та, Арслан Гобәйдуллин да, Кәрим Тимбиков та, Мөнәвәрә белән Фәйрүзә дә — авыл кешеләре, аларның табигатендә авыл холкы яши, шул ук вакытта хәзер алар нефть фонтаннары ата башлау белән, шәһәр шартларына күчәләр. Унҗиде ел буе бер тоташтан авылда яшәгәнлектән, мин авылны ярыйсы ук яхшы белә идем, ә шәһәрне, Әлмәт авылының шәһәргә әйләнүен, мин дүрт ел буена күзәттем, үзем шул процесска катнашып яшәдем.

Минем өчен иң авыры әсәрнең стилен, алымын табу булды. Гаять зур тизлек белән яши торган заман иде ул. Кайчандыр нефть скважинасын ел буе бораулаганнар. Аннары ярты ел бораулый башлаганнар. Белоглазов өч айга, ай ярымга, кырык көнгә калдырды аны. Әнә нинди баш әйләнгеч тизлекләр китте. Миңа тыгыз итеп язу алымын сайларга, татар прозасының йөз елдан артыкка сузылган традициясен дә исәпкә алырга кирәк иде. Дөресрәге, Ш. Камал, Г. Ибраһимов алымнары миңа ошый, совет чоры язучыларыннан минем күңелемне Гомәр Бәшировның «Намус» романындагы алым, — сүзнең кадерен белү, Галимҗан Ибраһимовтан, Шәриф Камалдан, Фатих Әмирханнан җыйнап, иң кирәклесен генә сайлап алган алым ошый, тик Гомәр агай, холкына хас булганча, бу җыйналган алымны тагын да сабырлата төшә иде. Девон фонтаннары аткан чорга бу алым ятышып бетми иде шул. Эзләнә торгач, мин Михаил Шолоховка тукталдым. «Хәзинә»не язган чорда «Тын Дон» романы белән «саташкан» идем. Аны тәрҗемә итәргә дә ниятем юк түгел иде. «Тын Дон» эпопеясендәге вакыйгаларны язу алымының тыгызлыгы, аз сүз белән катлаулы вакыйга, җитди-зур портрет тудыра алу, сугыш күренешләрен җанландыру, кинофильмдагы төсле, аермачык итеп күз алдына бастыра алу сәләте мине тәмам әсир итте. Мин Шолоховның тормышын, яшәү рәвешен, язу алымындагы үзенчәлекләрне кәгазь-каләм алып өйрәнә башладым. Сүз уңаеннан әйтим, «Хәзинә» басылып чыккач, минем романнан Шолохов алымын күп эзләделәр, болында печән чабу күренешләрен һәм башкаларны тәнкыйтьчеләр миңа турыдан-туры сыларга тырыштылар, ләкин мәсьәләне болай кую бик примитив булыр иде. Мин аерым күренешләрне күчермәдем, мин Шолохов алымының рухын, тыгызлый белү сәләтен өйрәндем, ул тыгызлауның татарчага якын да килә алмавын күрдем. Шолоховтан өйрәнү миңа Шолоховтан ерак китү мөмкинлеген тудырды.

Тагын бер нәрсәгә игътибарны юнәлтми булмый. Бездә язучыларның индивидуаль стиле шушы көнгә кадәр өйрәнелмәгән өлкә булып кала бирә. Шул сәбәпле бездә осталык мәктәбе яшь һәм башлап язучыларга тапшырылмый, өйрәтелми.

Атаклы рус язучылары әдәбиятта, формаль яктан караганда, ике төрле алым барлыгын әйтәләр. Берсе — тоташы белән кеше күңелен язу, вакыйгаларга, информацияләргә игътибар итмәү. Татар әдәбиятында моның иң ачык мисалы — Әмирхан Еники. Икенчесе — күбрәк вакыйгалар язу, вакыйгаларга мөнәсәбәттә характер тудыру. Моның ачык мисалы — Габдрахман Әпсәләмов. Бу алымда информация күбрәк, кешенең күңел хәрәкәтеннән бигрәк, физик хәрәкәте, гамәле өстенлек ала. Болар икесе дә әдәбиятта яшәргә хаклы алымнар һәм аларның яшәргә хаклы икәнен тормыш үзе күрсәтте. Г. Әпсәләмовның үз укучысы, Ә. Еникинең үз укучысы бар. Рус әдәбиятында

моның мисаллары итеп Константин Симонов һәм Леонид Леонов иҗатларын китерергә мөмкин. Әмма, минем карашымча, кешенең күңел хәрәкәте белән физик хәрәкәтен бергә куша алган язучы — иң бәхетле һәм иң халыкчан язучы. Моңа мисал итеп мин Михаил Шолоховны алам. Шолохов шундый язучыдыр ки, ул уч төбе хәтле кәгазьдә кешенең күңел тибрәнешен һәм физик хәрәкәтен гаять зур көч белән сурәтләп бирә ала. Егерменче гасырның утызынчы еллардан соң башланган проза әдәбиятында, минемчә, Михаил Александрович Шолохов белән тиңләшердәй язучы гомумән юк һәм, ихтимал, тиз генә булмас та.

Кешенең физик хәрәкәтенә Шолохов аның күңел тойгысын да куша белә. Менә бер мисал: Аксинья иренә хыянәт иткән. Ире Степан солдат уеныннан, җәйге лагерьдан кайта. Аксинья аны тәрәзәдән күрә. Шолохов бу күренешне «Аксинья борчылды, кайгырды, ут йотты» дип язмый.

«Урамда кинәт арба көпчәкләре дөберди башлады. Атлар кешнәп җибәрде, Аксинья, чиләгән куеп, тәрәзәгә килеп капланды.

Бер кулы белән кылычын тоткан килеш, ян капкадан Степан кереп килә... Аксинья, алъяпкыч итәген йомарлап, сәке читенә утырды. Дөп-дөп итеп баскычтан менгән тавыш ишетелде. Аяк тавышы чоланга керде... Ишек төбенә килеп җитте...» (Яхья Халитов тәрҗемәсе).

Игътибар иттегезме, дөп-дөп баскан аяк тавышларыннан безнең, укучыларның йөрәге дөп-дөп кага башлый һәм, ни буласын көтеп, йөрәгебез бугаз төбенә менеп җитә. Аксиньяның рухи халәте әнә шул аяк тавышларында бирелгән.

Шолохов алымы белән мавыгу, аның тыгызлыгына ирешергә омтылу миндә алтмышынчы ел башында бик күп күңел газаплары, иҗат газаплары, вакыт-вакыт, хәтта гомумән дә, язуны ташлау фикере дә уята язып калды. Халык тормышының массовый күренешләрен бирү төссез чыккан чакларда, геройларның күңел газапларын, җанда ташыганча бирелеп булмаганда, утырып җылыйсылар килә иде.

Ничек булса булды, алтмыш беренче елны мин романны язып бетердем. Халык хөкеменә, дөресрәге, иң элек каләмдәшләрем хөкеменә тапшырдым.

Әлмәт бүлегендә Рафаилләр, Әдипләр, Фазыллар, романны укып чыккач, булган бу, дигән фикер әйттеләр, төзәтәсе, көчәйтәсе урыннарын күрсәттеләр. Мин роман язганда аның һәр битен күздән кичереп барган талантлы яшь художник һәм яшь прозаик Рәшит Зиятдинов бик күп вак детальләргә бәйләнде. Әйтик, буровойда эшләгәндә, төнлә, юеш кар яуганны, буран икәнне әйтәсең, карның юеш икәне миңа, укучыга тоелмый, диде. Арсланның акыллы булуына, үз сүзле булуына яңадан-яңа детальләр өстәтте. Кульязманы тоташ укып чыккач, беренче булып әсәргә ул сөенде. «Казан язучыларына тапшыр инде, зур казанда кайнасын бу, Гариф абый!» — диде.

Романның кульязмасын мин ике данәдә, бик пөхтәләп төреп, «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә илтеп бирдем дә чиксез бер дулкынлану белән җавап көтә башладым.

Җавап килми бик озак торды.

Түзмәдем, Казанга үзем киттем.

Миңа редакциядән кульязманың редколлегия члены Фатих Хөснигә тапшырылганын әйттеләр. Фатих агайга шалтыраттым.

— Иртәгә әбәттән соң мин Дом печатькә барам, шунда очрашырбыз, Гариф, яме. Иркенләп бер сөйләшербез. Бүген, чорт возьми, башым да авырткалап тора, Мәрфуга апаң да тиргәп ташлады әле, ачуым да бер килмәгәе... — диде һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Көч-хәл белән мин иртәгесе көнне көтеп алдым.

Бу — 1961 елның 30 ноябре иде.

Фатих абый иртәгесен Матбугат йорты коридорында минем белән

бик артык җәелеп китмичә генә исәнләште. Журналның ул чорда бер-ике генә бүлмәсе бар иде, әдәби хезмәткәрләр ул бүлмәләргә мичкәгә тутырылган кыяр кебек шыплап тутырылган иде. Бүлмә эзләп йөри-йөри аптырап беткәч, кичке сәгать бишләрдә без, ниһаять, язучыларның Тукай клубына, аның буш сәхнәсенә, президиум өстәле янына менеп чүмәштек.

Салкын иде. Бу минем бүгенгедәй хәтеремдә. Өсләрне салмадык, Фатих абый, президиум өстәленә түше белән ята төшеп, кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарды. Кәгазьнең ике ягы да бик пөхтәләп, энҗе кебек вак итеп язылган иде.

— Башым да авыртып тора, кәефем дә юк, Гариф, син гаеп итмә, кәгазьгә язганны укып бирим инде мин, яме, — диде.

Ул укый башлады. Аның язганнары биш пункттан тора иде. Беренче пунктта ул әсәрне игътибарга лаек дип саный, калган пунктларда бөтенләй юкка чыгара иде.

Фатих абый фикеренчә, әсәр нефть эшенә багышланган булса да, андагы хәл-әхвәлләрнең күпчелек өлеше семья-көнкүреш низагларыннан тора. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалардан һәм язмышлардан логик рәвештә ямьсез бер нәрсә — семьяда тотрыксызлыкны, хыянәтне яклау кебегрәк бер нәрсә килеп чыга. Авторның бик тә уңай кеше итеп күрсәтергә тырышып сурәтләгән бик көчле Арслангалие мыштым гына кеше хатыны артыннан, ике бала анасы артыннан сөйрәлсә, Шәвәли агайның кызы Фәйрүзә кайчандыр үзенә «бала ясап качкан» Булатны, югалып йөргән Булатны, теге өйләнеп кайтканнан соң, әллә ни талымлап тормыйча, яңадан үзенең кочагына бик рәхәтләнеп кабул итә. Кайда монда боларның кешелек горурлыгы? Кайда монда башкаларга тәрбия дигән нәрсә? Әйдә, ничек теләсә шулай ярый, тик «изге урын гына» буш тормасын! Шулмы мораль?

Фатих абый, шул рәвешчә үзен ярсыта-ярсыта, минем романны кичерелмәс гөнаһларда гаепләде.

Әдип өчен, бигрәк тә тәҗрибәсез яшь әдип өчен, дөньяда аның әсәреннән дә кадерлерәк берни дә юктыр. Ул — аның баласы. Ул — аның күңел газаплары, йокысыз төннәре. Ниһаять, ул аның өмете, язучы була аламмы-юкмы дип ут йотып йөргән заманнары бит. Бөркет үзенең баласын нинди ярсып якласа, яшь автор да үзенең әсәрен җил-давыллардан, бәла-казалардан җаны-тәне белән якларга әзер була.

Фатих абый минем романга карата хөкем карарын бер битлек кулъязмасыннан укыган чакта, мин йөрәгемнең бугаз төбенә менеп җиткәнен тойдым, умыртка сөяге турысында нәрсәнеңдер, чүкеч белән суккандай, сулкылдап бәрә башлавын тойдым...

Укып бетергәч, Фатих абый миңа күтәрелеп карады да, куркынып:

— Сиңа ни булды, Гариф? — диде. Күрәсең, минем чыраем көл кебек агаргандыр.

— Берни дә булмады, — дидем мин, үземне көч-хәл белән кулга алып. — Сезнең «Хәзинә»дә булмаганнарны сөйләвегез, акны кара дип ышандырырга тырышуыгызны ишетү бик авыр булды, Фатих абый.

— Син ни сөйлисең, исәр баш. Кайда монда акны кара дип сөйләү?

— Сез әйтәсез: «Бала ясап качкан» Булатны әллә ни талымлап тормыйча, яңадан үзенең кочагына бик рәхәтләнеп кабул итә, — дисез. Алай түгел бит. Һич тә алай түгел! Булатны Фәйрүзә аркасына төя-төя чыгара өеннән! Булат баскычтан дөбердәп егылып төшә, мәтәлчекләр атып барып төшә, төшкәннән соң, үзенең сәер хәленнән шаркылдап көлә башлый һәм, көлеп туктагач: «Төн үткәрергә генә түгел, гомер итәргә дә ярый икән бит бу башкисәр!» — дип үкенеп

уйлый. Ә сез әйтәсез, бик ансат кына, хәтта әле «рәхәтләнеп кочагына ала», — дисез. Кайда монда кочагына алу?

Фатих абыйның чырае бозылды. Ул маңгай турысындагы бер юл ак чәчен, алга чуалып төшкән чәчен, кулы белән артка чөеп җибәрде дә:

— Синең белән сүз көрәштереп утырырга бер дә теләк юк минем, Гариф. Мә, дустым, син моны үзең белән алып кайт та, суынгач, тагын бер мәртәбә тыныч кына укып чык. Ә хәзер кайтышыйк, юкса талашып китүебез ихтимал, — диде һәм, үтә дә тапкыр сүз әйткән сыман, көлеп җибәрде.

Мин гостиница бүлмәсенә кайттым, бер укыдым, ике укыдым, һич кенә дә тынычлана алмадым. Фатих Хөсни, мин бала чакта хикәяләрен яратып укыган Фатих абый, мин язганнардан чыгып түгел, үзе уйлаганнардан чыгып, романга бәя бирә. Алай дөрес буламы соң ул? Арслан белән Мөнәвәрәнең саф тойгыларын юрамалый каралту булып чыга түгелме? Әнә шул хис мине бик нык рәнҗетте.

Үзем дөньяга тудырган геройларымны яклап, Фатих абый белән күңелемнән бәхәсләшеп, гостиница номерында бик озак утырдым. Бу миңа гаделсезлек булып тоелды. Әйе, гаделсезлек булып. Ник дисәң — ул өлкән кеше, тәҗрибәле, абруйлы. Ул әйткәнгә ышанырлар, ә мине баласытып карарлар... Ул чагында бит әсәрнең басылмый калуы да ихтимал. Я, мин үземнең хаклы икәнемне ничек исбат итә алам?..

Бер көн узды. Ике көн узды. Күңелгә моңсу уйлар килә башлады. Мин изге итеп уйлаганнарны бозык итеп чыгарганы, Арслан белән Мөнәвәрәнең хисләрен ямьсезләгәне өчен, мин Фатих абыйга үпкәләдем.

Өченче көнне мин бераз суына төштем. Тел кимчелекләренә карата Фатих абый кәгазь битендә билгеләгән тамгаларны карап чыктым. Алары белән килештем. Укыган уңайга төзәтә дә бардым. Алар минем иҗат принципларыма туры килә, әмма — ни мәхәббәт, ни производство турындагы фикерләр мине тынычландырмый, мин алар белән бөтенләй дә килешмим. Шуңа күрә, кайнарланып ялгышмыйммы, файдалы фикерләрне кире какмыйммы дигән уй белән мин әсәремне Габдрахман ага Әпсәләмовка илтеп бирдем. Ул бик теләп алды. Ике көннән укып килергә вәгъдә итте.

Габдрахман абыйның тиз эшләвенә, әйткән сүзендә нык торуына мин «Совет әдәбияты» журналында эшләгән чакта ук ышанган идем. Редакциягә килгән кульязмаларның ул барысын диярлек укый, бик тиз җавап бирә, публицистик мәкалә язуын үтенсәң, хәтта бер табаклы мәкаләне дә бер атна эчендә өлгертеп китерә иде.

Чамадан тыш авырлык белән мин ике көнне көтеп алдым.

Габдрахман абый, әйткән сүзенә турылыклы булып, нәкъ ике көннән, көндезге сәгать икедә редакциягә килде. Проза бүлегендә ул чагында Вакыйф Нуруллин эшли иде. Безнең сөйләшүне ул да тыңлап утырды.

— Әсәрегез булган. Мин моны басарга тәкъдим итәм. Ну, әдәбиятның зур таләпләреннән чыгып караганда, аннары үземнең әзме-күпме эш тәҗрибәмнән дә чыгып, кайбер теләкләр әйтәсем килә.

Уң кулын маңгаена куеп, әле алдында яткан кульязмага, әле миңа күз төшергәләп, сөйли башлады. Ул инде дүрт романның, берничә повестьның, дистәләгән хикәя һәм очеркның авторы иде, студент чакта без аның «Алтын йолдыз» романын төннәр йокламый укый идек.

— Сез, Гариф, романның кульязмасын алдыгызга куегыз да тагын бер тапкыр ашыкмый гына укып чыгыгыз. Юк, тоташ укымагыз, бары тик баш геройның линиясен генә укыгыз. Мин үзем шулай эш-

лим. Әйтик, Арслан Гобәйдуллин белән Кәрим Тимбиковка караган бүлекләрне укып чыгыгыз. Алар үзләре бер хикәя төсле булып, сюжет җепләре өзелмичә барса, ул чагында сезнең әсәрне матур әдәбият ятратучылар һичбер ялыкмыйча укып чыгарлар. Мин, шул ният белән, исәпләп карадым, минемчә, «Хәзинә»дә әле баш геройлар линиясендә өзелгән урыннар бар. Төшендегезме?

— Төшендем, Габдрахман абый, рәхмәт.

— Аннары болай эшләгез. Геройларның үзара мөнәсәбәтен тикшереп чыгыгыз. Менә, мәсәлән, карт мастер Лотфулла Дияров белән Шәвәли картның үзара мөнәсәбәтләре ничек үсә? Шәвәли бит Дияровны бер дә өнәмичә, яратмыйча, аңардан көнләшеп каршы алган иде. Ул аның җиргә каты басып йөрүен яратмаган иде бит. Ул, Лотфулла өйдә юк чагында, аның буш торган йортыннан хәтта сайгаклар да алып чыккан иде бит. Менә хәзер Булат, Лотфулланың олы малае, Фәйрүзәгә өйләнде. Фәйрүзә — Шәвәли кызы. Болар, димәк, көтмәгәндә туганлаштылар. Шәвәли моңа ничек карый? Лотфулла моңа ничек карый? Лотфуллага коммуналь йорттан фатир бирделәр. Булат белән Фәйрүзәгә дә фатир бирделәр. Лотфулла йорты торып кала бит әле. Ә Шәвәлинең йорты аварга тора. Әгәр Лотфулла, кадровый эшче, үзенең кодасына шул йортны бүшлай бирсә, ә? Бу — Лотфулланы потомственный эшче буларак күтәрер иде, ә Шәвәли моңа ничек карар?

Мин, сөенечемнән нишләргә белмичә:

— Искиткеч! Валлаһидыр, искиткеч бу, Габдрахман абый! Шәвәли бит гарьлегеннән шартлаячак. Ул бит Лотфулла мастерның бүләген алмый маташачак әле! — дидем мин.

— Менә, күрдегезме? Лотфулла да образ буларак үсәр, Шәвәли картның да характеры ачыклана төшәр, шулай эшләсәгез. Сез мин әйткәннәргә рәнҗемәгез, барыбызны да шулай өйрәттеләр. Читтән күренәрәк төшә ул. Әнә бит сез минем хикәяләр китабына карата «Совет Татарстаны»нда мәкалә язып чыктыгыз. Кимчелеген дә күрсәткәнсез. Дөрес күрсәткәнсез. Мин кабул иттем аларны...

Без Габдрахман абый белән ике сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Мин аның Мөнәвәрәгә, Арсланга, Тимбиковка карата фикерен сорадым. Семья-көнкүреш мәсьәләсе белән производствоның бергә үрелгәнме-юкмы икәнен белергә теләп тә сораулар бирдем. Ул аларның барысы дөрес, барысы ышандыра, диде, тик шуларны драматигрәк итәргә, сюжет җебенең өзелмәгәнме икәнен тикшереп чыгарга кирәк, диде.

Мин телемнән генә түгел, күңелемнән дә Габдрахман абыйга рәхмәт әйтеп, аны урамга кадәр озата чыктым. Аксыл озын плащтан, аксыл кепкадан ул урам буйлап кызу-кызу атлап барды; бераз баргач, чатка җитәрәк, минем белән саубуллашты, аннары чаттан борылды, борылган чакта да иплә кенә түгел, гадәтенчә янтая төшеп, бик кызулап борылды һәм минут эчендә күздән югалды.

Мин, тора-тора, аңа рәхмәтләр укыдым. Ул мине аңлаган. Мин Әлмәткә киткәч, хәерле юл теләп, мәкалә язып чыгуы да чын күңелдән булган икән. Әлеге сөйләшүдә дә аның «Хәзинә» өчен сөенгәне күренде, тик ул аны педагогик такт белән генә кычкырып әйтмәде.

Минем кульязманы бераздан Сибгат Хәкимгә бирделәр. Моны Абдулла ага Гомәр таләп итте. Аның принцибы — редколлегия членнарыннан күбрәк укыту иде. Мин каршы килмәдем. Әлмәткә күчкәч, «Чулпы җыры» драмасын язган чакта, Сибгат абый миңа бик булышты. Ул аңа бик матур җыр тексты язып җибәрде, әсәргә карата үзенең фикерләрен әйтте.

Сибгат Хәкимнең кульязманы укып чыкканын көтеп торырга вакыт

юк иде, мин Әлмәткә кайтып киттем. Габдрахман абый белән сөйләшкәннән соң минем күңелгә тынычлык иңгән иде инде. Тагын да язасы килү, язганыңны дөрес аңлаучылар барлыгын тоеп яшәү җанга рәхәт икән ул, көч уята икән.

Озакламый Сибгат Хәкимнән дә романны хуплаган хат килеп төште. Ул Кәрим Тимбиковны, Арсланны, аның иң яраткан кешесе Лотфулла Дияровны, алардан кала Мөнәвәрә белән Фәйрүзәне яратуын әйткән, **аларны халыкның үз эченнән табылган чын, ихлас, саф күңелле кешеләр** дигән иде. Сибгат Хәким хатында мине сөендергәне тагын бер нәрсә булды. Ул «Хәзинә»дәге табигать күренешләрен хуплаган, аларның геройлар психологиясен ачып бирүдә ярдәм итүләрен әйткән, пейзажның кабатланмаган пейзаж, нәкъ менә нефть якларындагы пейзаж булуын басым ясап күрсәткән иде.

Хатка төбәлеп мин озак утырдым. Өстемнән гүя авыр бер тау төште...

Ниһаять, романны мина үзем теләгәнчә, Әлмәт әдипләре, Габдрахман Әпсәләмов, Сибгат Хәкимнәр әйткән фикерләр буенча төзәтү, камилләштерү мөмкинлеге туды. Ул ике ай чамасы вакытны алды. Шул чорда мин, иҗат принципларыма каршы килмичә, акны кара дип әйтмичә, вөҗдан газаплары кичермичә, кулъязмамны яңадан карап чыктым.

Тагын бер-ике айдан нәшрият редакторы Хисам Камалдан хат алдым. Ул роман өчен ифрат та сөенеп: «Син — җиңүче!» — дип язган иде.

Бу инде 1962 елның башы иде.



## Язучылар бүлек даулый

1962 елның башларында Казанда ил күләмендәге киңәшмә уздырырга, әдәби тәрҗемә мәсьәләләре хакында сөйләшеп алырга уйладылар. Моны күптән түгел оешкан РСФСР Язучылар союзы идарәсе кузгатты.

РСФСР Язучылар союзы идарәсе, аның председателе Леонид Сергеевич Соболев ул елларны күчмә пленумнар үткәрүне матур бер яңалык итеп кертте. Шундый киңәшмәләр Уфада, Алтайда, Россиянең көньяк өлкәләрендә булып узды.

Инде менә безгә чират.

Моңа әзерләнергә, моның өчен көне-төне чабарга, киңәшмәнең бинасын, акчасын, кунакларны йөртү өчен машиналарын, торыр өчен кунак йортын табарга кирәк иде.

Казан язучыларының оештыру эшенә бик авырдан кузгалуын күреп торган Зәки Нури, ул чагында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, тынгысыз җанлы, партизан Зәки 1961 елның азакларында ук мине Казанга, Язучылар союзында вакытлыча эшләп торырга чакырды. Әдәби консультант булып. Нияте, әлбәттә, мине киңәшмә эшенә җигү иде.

Мин моны аның телефоннан сөйләшүеннән үк аңладым.

— Син, брат, язасың да язасың. Нефтяниклар турында инде эпопея сочинять иткәнсең дип ишеттем, — диде ул, шаяртып. — Давай, Казанга килеп, ике-өч ай эшләп ал. Правление члены була торып бернинди җаваплы җәмәгать эше башкарганың юк, понимаешь. Оят түгелме сиңа?

— Нишләп булмасын?! Нишләп булмасын башкарганым? Биш ел буена Әлмәтнең әдәби берләшмәсендә кем чиләнә? Сез, җылы, әйбәт фатирларда түшәмгә төкереп ятканда, буровой юлларында яңгырга

чыланып, тездән пычрак ерып кем йөри? Рәхмәт әйткәнегез бармы?— дип, яшьлеккә хас кайнарлык, беркатлылык белән ябырылдым мин аңа.

Зәки минем сүзләремнән рәхәтләнеп бер көлде.

— Җил тегермәне корып ятма син, Гарифҗан. Җәмәгать эше өчен бу дөньяда берәүнең дә рәхмәт әйткәне юк әле, акча алып эшләгән эшкә генә рәхмәт әйтәләр бездә... — Аның кемгәдер, янындагы берәүгә, сүз кушып, шаркылдап көлгәне ишетелде.— Менә шулай, брат. Шәһидә ханымга мәсьәләне бик ныгытып аңлат та, сәгате-минуты белән Казанга килеп җит.

Мин уйга калдым.

Зәки Нуриның ике сөйләшә торган гадәте юк. Вәгъдә бирдеме— үти, эш куштымы — синнән дә үтәвеңне таләп итә. Барырга кирәктер Казанга. Бер яктан — бу минем үземә дә файдалы: романны «Совет әдәбияты» журналына әзерләргә кирәк. Икенчедән, без — Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин һәм мин — Әлмәттә Язучылар союзының бүлеген ачарга хыялланып йөрибез. Безнеңчә, моңа ныклы нигез бар. Нефть якларында әдәби хәрәкәт үсә. Әлмәтнең «Хезмәт байрагы» һәм «Знамя труда» газеталарында атна саен диярлек әдәби сәхифә бастырабыз, Техника йортында, М. Горький культура сараенда, нефтьчеләр клубында, кызыл почмакларда, мәктәпләрдә көн аралаш укучылар белән очрашабыз. Шуның янына Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләрендә, Азнакай, Актүбә, Баулы, Карабаш эшчеләр поселокларындагы очрашуларны да китереп кушсаң—безнең чыгышлар елына 180ешәр мәртәбәгә җыела! Галимҗан Ибраһимовка, Кәрим Тинчуринга, Такташка багышлап әдәби кичәләр үткәрдек. Шәһәргә Казаннан Тукай бюстын алып кайтып куйдык. Афзал абый Шамов, ул чагындагы Язучылар союзы председателе, безгә аны бик теләп биреп җибәрде.

Техника йортында безгә нефтьчеләр бүләк иткән аерым бүлмә бар. Аңа Казаннан Фатих Кәрим, Шәриф Камал, Абдулла Алиш портретларын алып кайтып элдек.

Безнең җыелыр урыныбыз бар. Башлап язучыларның шигырьләрен, хикәяләрен эзлекле рәвештә, атна саен тикшерәбез. Казандагы газета-журналларда Әлмәт әдипләренең әсәрләрен теләбрәк баса башладылар.

Киңәшмә, җыелыш, съезд трибуналарыннан без үз хакыбызны даулыйбыз. Сафларыбыз ел саен арта. Әдип Маликов белән Шамил Бикчурин янына Саҗидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова союз членнары булып кушылдылар. Шуларга тагын Рафаил Төхфәтуллин белән мине дә китереп кушсаң, без — союз членнары — алтау, СССР Язучылар союзының уставында бүлек ачу өчен алты язучы булу җитә, диелгән.

Без тавышны бөердән чыгарып сөйләшәбез. Әдип ел саен поэма иҗат итә, Саҗидә янача язылган үзенчәлекле лирик шигырьләре белән танылды. Клара Булатова шигырьне коеп кына тора! Энҗе Мөэминованың «Әткәм чүкеченең тавышы» һәм «Ефәк яулыгым» кебек күләмле әсәрләре басылып чыкты. Боларга янә дә ай саен диярлек республика газеталары игълан иткән әдәби битләребезне китереп кушарга кирәк. Фазыл Мостафинның ике зур очеркын «Совет әдәбияты» журналы бастырып чыгарды, Шамил Бикчурин, Чупай тауны актарып, хикәяләр китабы иҗат итте, Сәет Кальметовның усал телле, үткен фабулалы пьесаларын Әлмәт театры ел саен тамашачыга күрсәтеп тора, яшь язучылардан Рәшит Зыятдинов, Марсель Зарипов, Мәхмүт Газизов, Азат Ганиев, Мөдәррис Ибраһимов берләшмә утырышларында әле шигырь, әле хикәя күтәреп килләр; Иван Винокуров, Дмитрий Матвеев, Владимир Мальцевларның шигырьләре, балалар өчен язган мәзәк-такмазалары, хикәяләре басыла башлады. Җыелышларыбызны без башлап язучылар белән инде союз членнары булганнарны берг

чакырып уткәрәбез. Җыелышта өйрәтү, өстән торып сөйләү юк — кем ни уйлый, шуны сөйли, рәхәтләнеп бәхәсләшәбез, фикер әйтешәбез, яңа, оригинал әсәр туса, бергәләп сөенәбез. Кайнап, гөрләп, язгы ташкын суларыдай ташып, ашкынулы, тулы тормыш белән яшибез.

Әдәби түгәрәктән әдәби берләшмәгә күчкән идек. Инде әдәби берләшмәдән Язучылар союзы бүлегенә күчү кирәк. Бик тә кирәк. Моментны ычкындырсак, бүлексез калачакбыз.

Каләмдәш дуслар белән сөйләштем дә Казанга китеп бардым. РСФСР Язучылар союзы идарәсе үткәргән киңәшмә вакытында миңа Бүлек таләп итәргә, дөресрәге, Әлмәттә шундый Бүлек ачылырга яраклы әдәби көчләр барлыгын Соболевка, Сартаковка, Мәскәүнең бүтән язучыларына башта җай гына аңлатырга, аннары Бүлек ачтыруны аяк терәп таләп итәргә кирәк.

Мине заманында Әлмәткә күчәргә димләгән өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов хәзер РСФСР Язучылар союзында секретарь булып эшли, ул Әлмәттә бүлек ачарга кирәк икәнен бик яхшы белә, ул безнең эштә зур бер терәк булачак.

Мин — Казанда. Зәки Нури мине бик җитди каршылады. Язучылар союзының әдәби консультанты Гали ага Хуҗи үз теләге белән иҗади эшкә күчкәч, ярты ел эчендә тау чаклы булып җыелган хатны минем алга китереп аударды.

— Менә, Гарифҗан, сиңа монда, брат, көне-төне тырышсаң да, башлап язучыларга ай буе хат язарлык эш бар, — диде ул. — Яза барырсың, миңа докладывать итә барырсың. Ә хәзер барып ашап килик, мин сине үз исәбемә бер сыйлыйм бүген.

«Казан» ресторанының бизәкләп, чуарлап, бик матур итеп буялган якты зур залында, тәрәзә буендагы өстәл янына утырып, аш көткән арада Зәки Нури, кесәсеннән чыгарган блокнотыннан ертып алган кәгазь битләре белән өстәл өстен тутырып, аларга мин эшлисе эшләрнең планнарын, үзе әйтмешли, «памяткаларын» яза барып, авызында озак әвәләүдән инде мундштугы чыланып беткән «Казбек» папиросын иренен бер читеннән икенчесенә күчерә-күчерә, мин эшлисе эшләрнең тәртибен аңлатып бирде.

Бая, Союзда чакта китереп аударган хатларны, кулъязмаларны мин укып чыгарга һәм авторларына җавап язарга тиешмен. Шулар өстәвенә мин Казандагы әдәби берләшмәләрне йөреп чыгарга тиеш икәнмен әле. Университетта, пединститутта, заводлар каршында, яшьләр газеталары янында әдәби берләшмәләр оешкан, аларның утырышларында булырга, аларга практик ярдәм күрсәтергә, ниһаять, әдәбиятка бүген нинди яшьләр килә, алар нинди уй-тойгылар белән яши, нәрсәләр таләп итә — шуны мин идарәгә хәбәр итәргә тиешмен. Боларны минем Язучылар союзы түли торган хезмәт хакына эшлисе эшләрем. Шулар янына тагын озакламый үткәреләчәк тәрҗемәчеләр киңәшмәсен әзерләү дә Зәки Нури белән миңа йөкләнә булып чыкты.

Дөресен әйтергә кирәк, табигать биргән үткен акыллы, юмарт табигатьле, оештыру мәсьәләләрендә исләр киткеч сәләтле бу каләмдәшемнән (ул миннән дүрт яшькә генә өлкәнрәк) мин күп нәрсәгә өйрәндем. Өскә йөкләнгән вазифаны төгәл һәм нәтиҗәле итеп үтәргә, блокноттан ничек файдаланырга, рәсми кәгазьләрне ничек язарга икәнен өйрәтте миңа Зәки Нури.

Бер-ике ай вакыт эчендә консультация өстәле кулъязмалардан арынып, җиңеләеп калды. Зәки эшне тикшерә торган чакларда мин, юри эш тапкан булып, буш өстәл тартмаларын ачып-яба идем. Зәки моңа сөенеп көлә торган иде. Без шул ике ай эчендә берничә яшь язучы белән индивидуаль семинар да үткәрергә өлгердек. Мин бу эшкә шактый батыр тотындым. Ник дисәң — Әлмәт тәҗрибәсе җитәрлек иде миндә. Бик үзенчәлекле балалар шигырьләре язган Хәкимҗан Халиков (Ке-

нәр), прозаик Радик Фәизов (Магнитогорск) өлкән агайлардан файдалы киңәшләр алып киттеләр. Озакламый аларның әсәрләре аерым китап булып та басылды.

Ул арада киңәшмә көне дә якынлашты.

Язучылар союзы штатында эшләүчеләргә, шул исәптән миңа да, киңәшмәдә катнашачак 87 кешене каршылау, гостиницага урнаштыру, гомумән, аларны кайгырту эше йөкләнде. Зәки миңа язучыларның зурларын тапшырды: Леонид Соболев, Сергей Сартаков, Алим Кешоков— РСФСР Язучылар союзының җитәкчеләре!

Беренче мәлгә мин курка калдым. Булмас дип баш тартмакчы булдым. Зәки, гадәтенчә, рәхәтләнеп бер көлде.

— Син бик селтәнмә әле, брат. Әлмәттә Язучылар союзы бүлеге ачасыгыз бармы? Нәрсә, әллә петиция язып кына ачыла дип беләсеңме син аны? Менә син Мәскәүгә барасың, ди, Соболев сине тиз генә кабул итми әле, җанкисәгем, атна буе бик әйбәтләп ишек төбендә тота. Җүләр, монда сиңа ул үзе килә. Җитмәсә әле — синең карамакта, сиңа буйсынган кеше булып. Давай, жми! Нәрсәгә сәләтле икәненне күрсәт, брат. Бүлек ачтыруга ирешсәң — нефтьчеләр һәйкәл куяр үзеңә.

Киңәшмә ачылырга ике көн калгач, Казанга Сергей Сартаков килеп төште. Мин аны каршы алырга бик нык әзерләнеп, әйтәсе сүзне ничек әйтергә икәнен артистларча репетиция ясап куйган идем.

Зәки алдан өйрәткәнчә, бик шәпләп гостиницага урнаштыргач, «Социалистик Татарстан» газетасыннан корреспондент китертеп, аңардан интервью алгач, батырлыгымны җыеп:

— Сергей Венедиктович, мине сезгә беркеттеләр. Сизәсездер? Кая алып барыйм сезне: кызлар янынамы, ресторангамы, әллә театргамы? — дип ярып салдым.

Сартаков, чәче такыр итеп алдырылган, интеллигентча нәфис чырайлы, әмма саескан шыкырдаган төсле, шыкырдап чыга торган тавышлы, ул чакларда иллеләр тирәсендәге абзый, миңа бер дә гаҗәпләнмичә, йөзенә гримаса чыгармыйча:

— Кызлар янына барырга карт инде мин, коллега. Коньякны мин гомумән дә эчмим. Милли театрга алып барсаң, рәхмәттән башка сүзем булмас, — диде.

Театрга икән — театрга!

Мин опера театрына чаптым. Администратор янына кереп билет белештем. Бер дә юньле урын бирергә чамаламыйлар. Кул селтәдем дә чыгып киттем.

Дөресен әйткәндә, Зәкичә кыланырга булдым! Юмарт! Бардым кассага, партерның алтынчы рәтендәге ике шәп урынны сатып алдым да кайтып та киттем. Әйдә, мәнсез администраторның эче көйсен әле. Минем бәхеткә — билет булып торуын кара син аның!

Кичен без, Сергей Венедиктович белән икәүләп, иң шәп урынга җәелеп утырып, «Шүрәле» балетын карадык.

Сартаков безнең опера театрының Мәскәүдәгечә салынган булуына бер сокланса, спектакль бара башлагач, тамашаның башкала тамашасыннан ким булмавына икенче сөенде.

Чыннан да, артистлар әйбәт уйный, Яруллинның халыкчан моңлы музыкасы җанга сары май булып ягыла иде. Тәнәфескә чыккач, кунагым, бик тә кәефе килеп, спектакльне тагын бер мәртәбә мактады һәм миңа бирегә алып килгәнем өчен рәхмәт әйтте.

Сөйләшеп киттек.

— Сез үзегез кайсы жанрдан: хикәячеме, шагыйрьме, әллә драматургмы? — диде.

— Мин сезнең коллега, Сергей Венедиктович: прозаик. Тик мин Казанда яшәмим бит.

— Шулаймыни? Кайда яшисез?

— Әлмәттә. Нефть якларының башкаласы ул. Казаннан өч йөз чакрым ары. Анда хәзер алты кеше — Язучылар союзы члены, — дип тезеп киттем мин. — Безнең исәп — Әлмәттә бүлек ачу. Язучылар союзы бүлеге. Юкса, язучыларны оешма булмаган җирдә кызыксындырып асрап булмый.

Сартаков минем сүзләрне кызыксынып тыңлады. Минем белән янәшә, театр фойесыннан атлый-атлый, фойеның биеклегенә, стена-түшәмнәргә ябыштырылган орнаментларның матурлыгына соклана-соклана барган җиреннән, кисәк кенә туктады да:

— Леонид Сергеевичка әйтергә кирәк. Беләсезме? Леонид Сергеевич безнең — нечкә күңелле кеше, ул сезне аңлар. Әйе, әйе, һичшиксез әйтергә кирәк. Мин моны үзем әйтермен. Тормышның үзәгендә, эшчеләр арасында алты союз члены яшәү — бу уен түгел. Анда бит әле яшь язучылар да бардыр?

— Иллелән артык, — дидем мин.

— Яхшы. Бик яхшы! Әйтәбез. Үзем әйтәм, — дип кабатлады Сартаков һәм, ниһаять, бу юлы мин аның дулкынлана ук башлавын күреп, күңелемнән сөендем. Борчак пешә болай булгач. Казанда ике-өч ай яту бушка китмәде.

Мин Әдипләрне, Фазылларны, Рафаилләрне күз алдыма китердем, минем күз алдымда аларның сөенечле йөзләре пәйда булды.

Тагын бер көннән соң Казанга Мәскәү язучылары килеп төште. Бер йөзгә якын кеше. Казанның ул хәтле язучыны сугыш елында, эвакуация вакытында гына күргәне булгандыр. Бу безне, киңәшмәне оештыручыларны, хәтта каушатып та җибәрде. Әмма мин, өстемә йөкләнгән бурычны искә төшергәч, күңелемнең ныгый төшүен сиздем. Минем карамакта бүген — Соболев белән Кешоков. Мин аларны урнаштырырга, аларны тәрбия итәргә, алар өчен җавап бирергә тиеш. Кешоков, кабардин князьләре кебек, олысымак кыяфәтле, чибәр йөзле һәм аз сүзле кеше икән. Соболев исә бик тә «кампанийский мужик» булып чыкты. Мин аңар, моннан ике көн элек Сартаковка әйткән сүзләрне әйткәч, ул, ике дә уйлап тормастан:

— Башта без тамак ялгап алыйк, аннары калганын сөйләшербез, — диде.

Тамак ялгарга «Казан» гостиницасының кафесына кердек. Татарча пешергән өчпочмак, чәй янына чәк-чәк, кош теле китерделәр. Кунакларның моңа күңеле булды.

Леонид Соболев — баһадир гәүдәле, гади, ачык йөзле икән, гөбедән чыккандай калын тавышы белән сөйләшә, уен-көлке әйтеп көлдерергә ярата иде.

Көлке тынып торган арада ул безнең барыбызга да — Сартаковка, Кешоковка, безнең янга килеп җиткән Гомәр абыйга — берьюлы сорау бирде:

— Монда, кайдадыр Әлмәт дигән шәһәр бар, диләр. Дөресме?

— Дөрес, — дидем мин, форсатны ычкындырмаска тырышып. — Мин булам аның вәкиле.

— Нәрсә, анда язучылар бармы?

— Анда язучылар бар. Берәү генә дә түгел, алтау. Нефтьчеләр тормышыннан повестьлар, хикәяләр, шигырь-поэмалар язып бастырдылар инде...

— Менә монысы шәп! Без эзләгән җанвар монысы! — диде Леонид Сергеевич, калын тавыш белән гөлдерәп кенә көлеп алды. — Миңа ул хакта Сартаков әйтеп өлгерде инде. Ул шундый тынгысыз кеше. Бер яңалык ишеттеме — аны шунда ук миңа җиткерүне үз вазифасы дип саный. Бик шәп. Син, яшь дустым, бер төркем язучыны Әлмәткә барырга күндер. Бер төркемне. Талантлыларын. Аңладыңмы?

— Аңладым, Леонид Сергеевич.

— Барырбыз Әлмәткә, күрербез нефтьчеләрне. Сартаков әйтте миңа, анда Язучылар союзы бүлеге ачарга кирәк, диде. Мин риза, бүлек ачарга риза мин Әлмәттә. Тик башта барып күрергә кирәк.

Минем түбәм җиде кат күк артында иде бу минутларда. Леонид Сергеевич Соболев үзе әйтеп тора бит боларны! Бүлекнең язмышы аның кулында булган кеше.

Мин ул әйткән язучылар төркемен оештырырга керештем. Соболев ул хакта үзенең уң кулы булган кешегә — Василий Шкаевка да әйтеп куйган булып чыкты. Шкаев — РСФСР Язучылар союзының оештыру эшләре секретаре. Китте безнең эшләр хутка! Соболев үзе бара дигәч, Әлмәткә барырга унбишләп язучы, исемнәре илгә билгеле булган күренекле язучылар язылды. Без Василий Васильевич Шкаев белән командировканы кайгыртырга тотындык. Обком белән, Әлмәт горкомы белән, нефтьчеләр белән сөйләштек. Бар да риза. Хәбәр иттек — Әлмәт әдипләре канат какты.

Әмма безнең сөенечкә озакламый кырау төште. Хикмәт шундадыр ки, Леонид Сергеевич Соболев көне буе кинәшмәне үзе алып барып, кичләрен татар язучыларының өендә кунакта булып, кунактан соң мине, чечен шагыйрәсе Рәйсә Ахматованы, тагын берничә үзенә якын кешене гостиница номерына чакырып, Америкага, Европа илләренә сәяхәте турында сөйли торгач, бик нык арыды, йончыды. Өстәвенә ул елны февральдә көннәре дә суык иде, суык та тидерде. Без самолет билетларын алып, командировка кәгазьләрен яздырып, Әлмәттә аудиторияләрне әзерләп бетергәч кенә, Василий Шкаев миңа көннәрдән бер көнне әйтте:

— Леонид Сергеевич Әлмәткә бара алмый. Башка кешене сайла җитәкче итеп,— диде.

Минем үләр чиккә җитеп кәефем кырылды.

— Ул чакта бару өзелә, — дидем мин.

— Ник? — диде Шкаев.

— Соболевның бармавын белүгә күренекле язучылар шунда ук качып бетәчәк.

— Бетсә соң, икенче төркемне җыярсың.

— Икенче төркемдә калдык-постык булачак. Алары безгә кирәкми, — дидем мин, киреләнеп. Юри тупас итеп әйттем.

— Бар, алайса, Леонид Сергеевич белән үзең сөйләш.

Киттем мин сөйләшергә.

Кап-кара костюмнан, колач җитмәс киң күкрәгенә орден-медаль колодкаларын тезеп чыккан Соболев фойеда басып тора.

Килдем янына, исәнләштем. Шкаев әйткәннәрне әйтеп бирдем.

— Әйе, мин бара алмыйм, — диде Соболев. Кулын, гафу үтенгәндәй, күкрәгенә куйды. Мин бик хәтәр әтәчләнеп барган идем, аның шундый мөлаем мөнәсәбәтен күргәч, темпераментны кимәтә төштем.

— Кадерле Леонид Сергеевич, менә үзегез уйлап карагыз: укучыга бик шәп китап вәгъдә иттеләр, ди. Ул тыны-көне бетеп сөенде, ди. Аңа ул китапны бер атнадан алырсың дип әйттеләр, ди. Бер атна узып китте, ди. Аннары әйттеләр, ди: китап юк, дип. Сезнеңчә ничек, яратырмы укучы, риза булырмы?

Мин аның җан бәгыренә кагылдым, ахрысы. Ул балаларча нәумиз тавыш белән акланырга тотынды:

— Авырыйм бит мин, братец. Күрмисеңмени, салкын тидердем, авызларым чабырып чыкты, — дип бармакларын ирен тирәсендә йөртеп алды. — Син башка группа төзе, алып бар, күрсәт Әлмәтне, күрсәт язучыларны...

— Бармыйм, күрсәтмим.

— Ник?

— Сез бармагач, анда баручы калмый, барысы да качып бетә.

— Син бик дөрес әйтәсең, туганым. Качалар, ике дә уйламый качалар, шельмалар. Ярый, син миңа үпкәләмә, мин сиңа җәйгә чыккач, компетентный комиссия җибәрермен. Әнә шул комиссия карап кайтыр сезне, бер дә шикләнмә, бүлек ачабыз без Әлмәттә. Дингезче анты белән ант итеп әйтәм, ачабыз бүлек! — Ул ничектер яктырып китте, чыраена, калын иреннәренә нур йөгерде һәм гадәти бер кызык сөйләү һөнәреннән тыела алмыйча әйтеп куйды: — Дингезче дигәч искә төште, быел январьда Молдавиягә бардым мин. Емельян Буков белән очрашуга чыктык. Халык алдына. Емельян мине халыкка тәкъдим итте: «Сейчас перед вами выступит морская туша». «Морская душа» диясенә «туша» диде. Халык егылып көләргә тотынды. Чыннан да, мин алар алдында аю чаклы булып басып торам бит...

Мин дә, Соболев мәзәген тыңларга җыелган башка язучылар да рәхәтләнеп көлеп җибәрдек. Соболев, авыру икәнен онытып, үзе дә безгә кушылып көлде.

Мин аның сабыйлык ягымлылыгы китеп бетмәгән чыраена, тау хәтле зур гәүдәсенә, баһадирлыгына карап: «Юк, бу алдый торган кеше түгел. Ихласлыгы өчен яратканнар аны Мәскәү язучылары. Үзләренең башлыгы итеп юкка гына сайламаганнар. Сүзендә торачак бу», — дип уйладым.

Чыннан да, ул сүзендә торды.

1962 елның июль аенда «Литература и жизнь» газетасында РСФСР Язучылар союзы идарәсенең секретариат утырышы булуы, анда төрле мәсьәләләр каралуы әйтелгән һәм соңыннан Татарстанның Әлмәт шәһәрендә Язучылар союзы бүлеге ачылуы хәбәр ителгән иде.

1963 елның башында безгә бүлек ачу өчен кирәкле штат расписаниесе килде.

Казаннан Гомәр ага Бәширов, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев килеп, Әлмәт язучыларының җыелышын үткәрделәр. Бүлекнең бюросына Әдип Маликовны, Рафаил Төхфәтуллинны һәм мине сайладылар.

Әдип белән Рафаил минем җитәкче булуымны үтенделәр.

Моңарчы җәмәгать эше тәртибендә алып барган эшне мин түләүле эш итеп башкара башладым. Әлмәт язучылары бүлек эшенә теләп, ярата булыштылар.

Нефть якларындагы әдәби хәрәкәтнең колачын тагын да ныграк җәеп җибәрдек. Язучыларның Әлмәт бүлегенә багышлап «Правда» газетасы махсус әдәби бит чыгарды.

## Тормышның фаҗигале яклары

Ул елларны шатлык белән кайгы гел аралашып торды.

1962 елның азакларында «Совет әдәбияты» журналында «Хәзинә» романы, ниһаять, басылып чыкты һәм аны шул ук елны Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшрияты өчен русчага тәрҗемә итә башладылар. Шул ук елны мин «Тын Дон» романының икенче китабын татарчага тәрҗемә итәргә керештем. (Беренче китабын Яхъя Халитов тәрҗемә итте). Болар барысы шатлык, әйтеп бетергесез зур шатлык иде. Минем әдәби эшемне язучылар җәмәгатьчелегенең дә, укучыларның да тануы иде.

Әмма шул 1963 елны минем өскә зур гына бер бәхетсезлек тә ябырылды. Әлмәткә өченче июнь көнне ифрат та кыска, төгәл һәм, әйтергә кирәк, шигъри бер телеграмма килде: «Второго июня час ночи дом сгорел остались голые приезжай Сажида».

Йорт яну мине ул хәтле үк борчуга салмады. «Час ночи» дигән сүз хафага төшерде. Анда бит җитмеш яшьлек әни бар, ул ничек котыла алды икән, чыкканда зыян-зәвер күрмәдеме икән?

Партиянең Әлмәт шәһәр комитеты аркылы Бөгелмәгә шалтыратып, билет юнәттем дә самолет белән Казанга очтым. Казаннан Арчага кайтып киттем. Мин кайтканда төн иде инде. Арчада минем әле әниләр яшәгән төп йорттан тыш сеңлем Саҗидә яшәгән йорт та бар. Әниләр, мөгаен, алардадыр. Әмма мин станцадан менешли, юл өстендәге Саҗидәләргә кермәдем, янган йорт нигезен карап кайтырга булдым.

Йорт януның хәбәрен ишетү бер хәл, үз күзең белән күрү бөтенләй икенче хәл икән. Урыс капкалы, кара-каршы йортлы абзар-куралы хуҗалык урынында кап-кара ике-өч багана да, кап-кара мич кенә торып калган. Кисәү исе аңкый. Фашистлар яндырган авылдан бер дә ким түгел.

Көл өеме янында мин озак кына басып тордым. Әллә ниләр килде күңелгә. Кулаклар үтергән эти килде. Бу йортның беренче нигезен ул салган бит. Өчиле, — минем ятим бала чагым, — яшен кебек, җаннан сызылып узды. Әнинең беренче баласы янып үлгән — алар искә төште. Барысы бергә күңелдә кайнар бер төен булып төйнәлделәр дә, әнинең шушы пожар эченнән чыкканлыгы искә төшкәч, керфек төпләрем җылынып, күзгә бөялгән яшьне сөртмичә, сеңлем Саҗидәләргә йөгердем.

Капкалары ачык иде. Кердем. Өйдә ут бар. Түзмәдем, башта тәрәзәгә килдем. Әни караватта ята. Гайшә апа өстәл янында утырып тора. Бер читтәрәк үсмер егет, минем энем Ризуан урындыкка чүмәшкән. Саҗидә дә, аның ире — сугымчы Әһли дә — берсе дә өйдә юк.

Тәрәзә каккан тавышка өйдә кузгалдылар, каушап булса кирәк, ыгы-зыгы килә, бутала башладылар. Караватыннан төшкән әни ишек ачарга килә башлады. Мин аның чолан ишеге артыннан:

— Улым, син кайттыңмы әллә? — дигән миңа бик тә таныш, әмма бу юлы хәлсез тавышын ишеттем.

— Мин бу, әни. Ач әле ишекне, — дидем.

Ишек ачылды. Караңгыда мин, әнигә ияреп, өйгә кердем. Ут яктысында күзем төште: әнинең бите марля белән уратып алынган иде.

— Битеңә ни булды, әни?

— Уттан көчкә чыгып котылдым әле, балам. Төн уртасында, йоклап ятканда, яна башладык бит. Киявем Әһли күтәреп алып чыкмаса, эшләр харап иде.

— И игелекле дә кеше булды инде ул Әһли кияү, — дидем мин, сүз таба алмыйча, бераз дәшми тордым. — Йорт урынын менеп карадым. Кара баганалар гына тырпаеп тора, — дидем. Тавышыма берниндә үкенү дә, кызгану да кертмәскә, мөмкин кадәр тыныч булырга, пожарга кайгырмаска тырыштым.

— Йорт янып бетте, — диде Гайшә апа. — Көл булды йорт. Кеше бусагаларында йөрербезме инде? — дип мышык-мышык борын тарта башлады.

Әни бер тамчы да күз яше чыгармады.

— Йорты булыр. Үлемтегемә дигән әйберләрем янды. Менә шунысы үкенечле...

— И абый, йортын салырбыз. Гармун янды әле менә. Көмеш телле гармуным янды. Бер атнадан сабан туе... —диде энем, үсмер егет.

И катлаулы да син, кеше күңеле! Без еллар буе тырышып салган өй көл өеме булган. Аның өчен сыкрау-елау юк. Үлемтеккә дигән әйберләр янган да гармун янган. Зиһенем минем боларны теркәп бара. Кирәге чыгар... материал булыр... Әнинең, бөкрәеп хәлсезләнеп калган әнинең әнә шул сүзләрен хәтергә сеңдерергә телим. Онытмаска телим. Ул этинең үлемен күтәрде, ул беренче баласының, багалмасыдай кызы Таһирәсенең утта янып үлүен кичергән. Ачлы-туклы яшәгән сугыш еллары аны миңгерәүләтте. Ул өйне түгел, үлемен кайгырта. Я, дөнья... Аналар образын сурәтләгәндә кирәге булыр. Аның психологиясе... Үсмер егет психологиясе. Күңелгә беркетеп калырга кирәк...

...Төнне без сөйләшеп үткәрдек. Иртәгесен кайгы уртаклашырга кешеләр килә башлады.

Бер-ике пар чокыр, чынаяк алып киләләр. Чүмеч, коштабак ише савыт-саба китерәләр. Пожарның ничек чыкканын энәсеннән җебенә тикле сорашалар.

Башта бу миңа кызык тоелды. Минем язучылык һөнәрем адәм балаларының кайгы килгән чакта бер-беренә булышу кебек әйбәт гадәтләрен күңелгә сендерә барды. Ул көнне мин, сөйләшүләргә колак салasala, халыкның нечкә күңеллелеген, ярдәмчеллеген раслый торган байтак фактны күз алдымнан кичердем.

Ерак юлга чыгасы булса яки йорт-җир булдыру эшенә керешсә, халык ятим балага яки гарип-горабага бирәр нәрсә бирергә дип нәзер әйтә. Сабан туенда иң азаккы булып килгән атны халык сөлге белән күмә.

Әнә шундый йоланы күргән бер дусыбыз, Мәскәүнең «Современник» нәшрияты редакторы, фәннәр кандидаты Елена Корнеева, күңеле нечкәреп, елап җибәргән иде һәм башындагы бик матур косынкасын бүләк итәргә дип, әбиләр белән бергә, азаккы ат янына йөгергән иде...

Әйе, матур йолалары бар безнең халыкның, акыллы йолалары. Тик аларны да гел кабатлап тору туйдыра икән. Кичкә таба әни дә, Гайшә апа да кызганып килүчеләрдән арыдылар. Пожарның ничек килеп чыгуын, әнине ничек төн уртасында уттан алып чыгуларын сөйләүдән туйдылар. Чөнки алар артист түгел, алар моны, яттан өйрәнгән сүзне сөйләгән кебек, кабатлап кына утыра алмыйлар, сөйләгән саен янгын фаҗигасен күңелләрендә тергезәләр, шунлыктан туктаусыз җан газабы кичереп торалар иде.

Мин аларны кызгандым.

Сеңлем Сәҗидәгә һәм киявебез Әһлигә әйттем:

— Кызганып килүчеләрне бүтән кертмәгез. Алар әнине гүргә кертеп куймагайлары. Мин хәзер Казанга китәм, госстрахка кереп, иректә рәвештә түләгән страховой акчагызны кайгыртам. Ә эшне башлап җибәрү өчен китап нәшриятыннан акча алып бирермен. Анда минем «Хәзинә» романы басылып ята. Договор буенча бераз акча бирергә тиешләр.

Энем Ризуанны алып, мин Казанга китеп бардым. Нәшриятка кердем. Аның директоры Салих ага Вәлидигә кыска гына гариза яздым. Ул миңа чыгачак роман исәбенә мул гына аванс бирергә дип гаризага резолюция салды. Мин аңа рәхмәт әйтеп чыгып киттем.

И күп очрады да соң минем юлымда әйбәт кешеләр. Алар булмаса, миннән язучы чыкмас, тормышта мин үз дигәнемә ирешә алмый торган бер мәми авыз булып калган булыр идем.

Салих абый Вәлиди мине «Совет әдәбияты»на эшкә алдырган кеше, бу юлы да хәлемә керде. Нәшриятның акчасы юк иде. Ул миңа башка оешмалардан алып булса да акча табып бирергә боерды, бухгалтерлар аның әмерен үтәми булдыра алмадылар.

Ризуан белән икәүләп, аңа сабан туена кап-кара костюм, кара кепка, туфли, ап-ак күлмәк алдык. Гармунны ул иптәш малайларыннан алып торырга булды.

Шулай итеп, энекәш ягын көйләдек.

Казанга киткән чакта Шәһидә миңа:

— Акча вәгъдә итеп кайтма, булса биреп кайт, — дигән иде. Нәшрияттан алган акчаны мин әниләргә кайтарып бирдем. Бер көн кичекми, хәзер үк мари ягыннан бура эзли башларга куштым.

Булдыклы киявебез Әһли, аның иптәшләре һәм Ризуан бер атна дигәндә, маридан бура, абзар-кура алып кайтып, эшкә керештеләр. Яндык-көйдек дип елап-сыктап утырулар булмады. Иректә страхова-

нигә дә дәүләт мул гына акча түләде, Арчаның райбашкармасы бүрәнәгә язу бирде.
Өч ай дигәндә, энеләр сап-сары бүрәнәдән салган кара-каршы ике өйле йортка кереп тә утырдылар.
Моны минем язучылык зиһенем кабат та теркәп куйды: элекке заман булса, нишләрләр иде болар? Дүрт балалы тол хатын урамда торып калыр иде. Булмаганмыни янган тәртә башын күрсәтеп, авыл саен хәер эстәп йөрүләр?!

БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

# КАҺАРМАННАР ЭЗЛӘГӘНДӘ

## Роман язу авыр

1961 елның көзендә «Хәзинә»не язып бетергәч, гомерем булса, романга бүтән тотынмас идем, дип ант иттем. Бик тә арыган идем.
Роман язу авыр, коточкыч авыр. Роман ул — шәһәр һәм авыллар, диңгез һәм елгалар, кырлар һәм күк йөзе. Роман ул, барыннан да элек, кешеләр, аларның язмышы, гади генә язмышы да түгел, тарихның кискен борылышларындагы язмышы, революция, кан коелу, гаделлек даулары...
Мин моны роман язганчы да белә идем — университетның акыл ияләре аны безгә бик ныгытып тукыганнар иде. Ләкин үзем язып карагач, аның авырлыгын ныграк тойдым, үз җанымда, үз җилкәмдә, үз йокысыз төннәремдә тойдым. Шуңа күрә, романга бүтән тотынмам, дип ант иттем дә.
Ләкин Казанда күргән бер вакыйга мине кабат романга тотынырга мәҗбүр итте.
Июнь иде, көн чалт аяз иде, Бауман урамы тулы халык иде. Чәчләре агарган, яланбашлы бер абзый урамның урта бер җиреннән бара һәм кычкырып елый иде.
Урам уртасына кереп, абзыйны иплэп кенә култыклап алдым да читкә алып чыктым, юкса аның машина астына ялгыш эләгүе мөмкин иде.
Бераздан ул тынычланды, үзен өенә тикле озатып куюымны сорады. Теләгеп үтәдем, саубуллашкан чакта, иплэп кенә, бик нык гафу үтенеп, нигә елавының сәбәбен сорадым.
Озак сөйләде ул аны миңа. Роман язарлык материал сөйләде. Ике сүз белән генә әйткәндә, ул болай. Аны партиядән чыгарган булганнар, егерме елдан соң кабат партия сафына кайтарганнар. Аның егерме еллык гаепсез газаплары, җанында ташыган бүгенге куанычы, күз яшьләре булып, тышка бәреп чыккан икән.
Абзый берничә ел минем күңелемнән китмәде. Ниһаять, 1962 елның январенда мин амбар кенәгәсенә яңа романның «Юлдаш» дигән исемен һәм төп фикерен язып куйдым. Еллар узгач, ул «Идел кызы» дигән исемне алды һәм әнә шуннан башлап, ягъни азаккы исеме табылганнан бирле, миңа тынгылык бирми башлады.
Баштарак мин роман егерме еллык вакытны эченә алыр дип уйлаган идем, тора-бара ул киңәйде, җәелде, утыз елга да, илле елга да сыймый башлады.
Хикмәт шундадыр ки, егерме ел дип исәпләгәндә, мин партиядән чыгарылган кешене һәм шул дәвер эчендә аның ялгыш чыгарылган бу-

луын аңлап, аңар иң авыр чагында турылыклы юлдаш булып калган хатынын бирмәкче идем. Уйлый торгач, бу хатын гади бер юлдаш булудан узып китте, мин аның аша егерменче гасырдагы татар хатынкызлары образын бирергә теләдем. Димәк, мин татар халкының тормышын егерменче гасыр башыннан ук өйрәнә башларга тиеш булып чыктым. Ә бу 1905 елгы Беренче рус революциясе, беренче Бөтендөнья сугышы, Февраль революциясе, Октябрь давыллары...

Әсәрнең урыны итеп башта мин Әгерҗе төбәген генә алган идем, герой белән героиняның прототиплары табылгач, вакыйга Кама буена гына сыймый башлады, Казанга, Ижевскига, Мәскәүгә күчте, Идел-Чулман буйларын тоташы белән иңләп алды.

Кешеләрнең шәхси тормыш биографияләрен чагыштырмача тиз таптым мин, миңа революцион вакыйгаларның, гражданнар сугышының Идел-Камадагы сурәтен табарга, шуның өстәвенә революцион ситуацияләрнең җирлеген, мәгънәсен ачыкларга кирәк иде. Озын сүзнең кыскасы — мин архивларда утырмый булдыра алмый идем хәзер.

Минем бәхеткә, 1965 елның башында нәкъ шундый мөмкинлек туды. Каләмдәшем Рафаил Төхфәтуллин, 1965 елның январенда Малеевка иҗат йортында ял итеп кайткач, миңа сөенечле хәбәр әйтте:

— Гариф дус, Мәскәүдә Әдәбият институты каршында ике айлык югары әдәбият курслары ачыла. Революцион темага язучылар өчен. Мине бит институтта яхшы беләләр. Сездән кем килә ала дигәч, мин сине яздырдым. «Идел кызы»на революция чоры кирәк дигән идең ич. Казаннан Атилла абый Расих та барачак. Син ризамы?

— Риза булмаган кая! Бу бит гел дә минем өчен юри эшләгән кебек. Рәхмәт сиңа. Кайчан барасы?

— Апрельдән. Әзерлән. Вакыт аз калды.

28 мартта, төянеп, Мәскәүгә китеп бардым. Әдәбият институты тулай торагыннан аерым бүлмә бирделәр. Тумбочка каршысындагы стенага Шәһидәнең улым белән кызымны кочаклап төшкән рәсемен кнопка белән беркетеп куйдым да «дүртәүләп» яши башладык.

Мәскәүгә килеп төшкән көннән башлап, бер генә минутны да әрәм итмичә, эшкә тотынырга кирәк иде. Эшлисе эш, укыйсы китап мин уйлаганнан күбрәк икән. Архивтан мин менә нәрсәләр табарга тиеш булып чыктым:

«Мусульманская газета» (1912—1914 еллар).
«Камско-Волжская речь» газетасы (1914—1917 еллар).
«Рабочий» газетасы (1907—1917 еллар).
«Знамя революции» газетасы (1918—1921 еллар).
«Урал» — татар телендәге беренче большевистик газета (1906 ел).
«Октябрьская революция и Советская власть в документах» (1917—1920 еллар) китабы — 1920 елда басылган.

Моңардан тыш тагын 18 китап. Аларны Казанда табуы кыен.

Боларны укырга миңа Вәзих Исхаков киңәш итте. Озын буйлы, грузиннарга охшаш кәкре борынлы, үткен егет. Уфадан. Аның язганы — гел революционерлар турында. Бик беркатлы, ихлас кеше күренә. Дуслашырбыздыр, ахрысы...

2 апрель көнне бүгенге драматургия турында бик шәп доклад тыңладык. 3 апрель көнне революция музеен карап кайттык. Тәэсир бик зур, «Идел кызы»н язу теләге арта төште. Анда экспонатларның, документларның күп булуы гына түгел, булмаганнары да кузгатты күңелне. Музейда барлык халыкларның революционерлары бар, безнең Мулланур Вахитов та, Хөсәен Ямашев та юк. «Ник?» — дип сорадым директорыннан. Гади генә җавап бирде:

— Безгә алар хакында Татарстаннан материал килгәне юк.

Менә бит ул ничек? Югары әдәби курсларда булмасам, мин әле боларны белмәс идем...

Революция музеен карау, гомумән, көндәлдә бик күп тойгылар һәм аек уйлар кузгатты.

... Мин бирегә килүемә сөенеп йөрим.

«Идел кызы» өчен кирәкле материал көннән-көн ишәя. Совет Армиясе һәм Октябрь революциясе архивларында булдык. Документлар бик кызык.

... Адмирал Колчак армиясе 1919 елның апрель-май айларында Алабугада, Минзәләдә, Кама буеның башка калаларында булган.

... 9 мартта Минзәләдә, 12 мартта Алабугада, 31 мартта Бөгелмәдә ревкомнар төзелгән.

... Апрель-май айларында Беренче укчы татар бригадасы оешып, Колчак армиясенең көньяк флангысын җимергән, Хөсәен Мәүлетов, Якуб Чанышев, Галиулла Касыймов шул чорда, иң беренче полководецлар белән беррәттән, Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгәннәр, ул чорда бу бердәнбер орден булган.

... 1919 елның 2 маенда Казанга «Октябрь революциясе» дигән агитпоездда Михаил Иванович Калинин килгән, Ирек мәйданында митингта чыгыш ясаган.

... 29 майда Колчак гаскәрләре Алабугадан бәреп чыгарылган.

... 1915 елны Кама елгасында Мулланур Вахитов елга төбен чистарту партиясендә эшләгән.

Боларны романда бик әйбәт файдаланырга мөмкин. Бигрәк тә Мулланурның Камада эшләвен, «Идел кызы»ның баш герое Солтан Айдаровны Мулланур белән очраштырып була, нәкъ шул елны Солтан, абыйсы Шәяхмәт белән бергә, Кама елгасы буйлап Чистайга кадәр сал куып төшә. Димәк, сюжет ныграк үрелә, Мулланур Вахитов романга табигый рәвештә килеп керә ала...

Күңелдә хыяллар уйный башлады.

Әдәби курсларда без алган мәгълүмат моның белән генә бетмәде әле. Революция музеенда, Ленин квартирында, Ленин яшәгән урыннарда булдык, революцион Мәскәү буйлап автобус сәяхәте ясадык. Третьяков галереясын карадык, Ясная Полянага барып кайттык.

Шул хәтле күп музей һәм архивлардан без бөтен нәрсәне дә алып бетердек дисәм, дөрес булмас. Галимнәр бер архивта гына да еллар буе утыралар. Безгә алай озаклап утыру насыйп булмады. Әмма боларны барлап чыгу гына да минем өчен ифрат файдалы булды. Музей һәм архивлардан үземә кирәклесен алдым мин. Ул — дәвернең атмосферасы. Мин үземне революция елларында яшәгән, шуларны үз күзем белән күргән кебек тоя башладым.

Ә бу — әсәр язгандагы иң мөһим шарт бит.

Шуның өстәвенә әле мин Мәскәү партоешмасы һәм гражданнар сугышы архивында Шәймәрдән Ибраһимов дигән ифрат кызыклы шәхескә юлыктым.

16 яшеннән — коммунист, 17 яшеннән — патша төрмәсендә, Кронштадтны фетнәчеләрдән азат итүдә катнашып, Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән. Тухачевский армиясендә мобилизация бүлеге начальнигы булып, ике йөз меңнән артык кешене совет гаскәрләре сафына җыйган.

Шәймәрдән Ибраһимовның җеп очыннан барып, мин аның Мәскәүдәге туганнарын һәм хатынын эзләп таптым. Алар миңа Шәймәрдәннең үз кулы белән язган автобиографиясеннән күчермә алып бирделәр.

Шәймәрдән революциядән соң Партия Үзәк Комитетында эшләгән, Бөек Ватан сугышында политрук булып катнашкан, янә дә орден-медальләр белән бүләкләнгән. 1957 елны үлгән. Ә 1958 елны ул яшәгән Мочальский урамына Ибраһимов урамы дип исем кушканнар.

Бу табышка мин чиксез шатландым. Моның өчен архивта ике ай гына түгел, ел буе утырсаң да урынлы. Чөнки бу татар халкының революция һәм гражданнар сугышы тарихына яңа сәхифә өсти.

Әдәбият институты каршындагы ике айлык югары әдәби курсларда уку архивлар, музейлар белән генә чикләнмәде. Анда әле бүгенге көн мәсьәләләре дә зур итеп куелды.

Без анда, мәсәлән, илнең экономикасы турында алты сәгатьлек бик шәп лекция тыңладык. Аның шәплеге шунда, промышленность ничек үсә, авыл хуҗалыгы ничек үсә, илдә сәүдә эше нинди югарылыкта, нинди кимчелекләр бар, алар ни рәвешле бетерелергә тиеш — шуларны мисалы-ние белән күрсәтеп бирделәр. Илнең сулышын без тулаем, колачлы итеп күз алдына китерә алдык. Менә шул чакта мин нефтьчеләр турындагы икенче романымда («Хуҗалар»да) уйлый һәм фикер йөртә белә торган геройларны тасвирларга кирәк дигән нәтиҗәгә килдем. Ул чорда «Идел кызы» белән янәшә «Хуҗалар» романы да күңелдә яши иде.

Бу урында мин бер нәрсәгә ачыклык кертүне кирәк саныйм. Кайбер язучылар бер әсәргә тотынса, — язылamы ул, язылмыймы, — еллар буе шуның белән чиләнә. Кайберәүләр берничә әсәрне берьюлы язалар. Мин, күрәсең, икенчеләр рәтенә керәмдер.

Югары әдәби курсларда укыган чакта минем яртылаш язылган «Хуҗалар» романым бар, «Идел кызы»на мин материал җыеп ятам, «Утлар яна учакта» исемле драмамны Әлмәт театры сәхнәгә куярга әзерли иде.

Спектакль май бәйрәме алдыннан чыгарга тиеш иде. Каләмдәш дуслар Әдип белән Рафаил, репетициянең ничек баруын әйтеп, миңа хәбәр итеп тордылар. Режиссер Габдулла ага Юсупов мине премьерага чакырып хат язды. Хатының азагында, шаяртып: «Кайтмасаң, репетицияне сүтәм, әнә академнар куйсын!» — дип язган иде.

Аның «академнар куйсын» дип әйтүе юкка түгел. «Җир куенында» пьесасы кебек үк, «Утлар яна учакта»ны да мин Академия театры коллективына барып укыдым, анда миңа: «Автор сәхнәне белми, нефтьчеләр тормышын белми», — дип бәйләнделәр. Алар арасында иң агрессивы һәм калын тавышлысы артист Туфан Миңнуллин иде. Мин артистларга:

— Сез Габдулла Юсуповны ихтирам итәсезме? — дигән сорау бирдем. Чөнки, театрга тәкъдим иткәнче, мин пьесаны Габдулла абый белән эшләп чыккан идем инде.

Ветераннар дәшмәде.

Габдулла Юсупов Академия театрында баш режиссер булып эшләгән заманда театрдан чыгарылган, әмма местком катнашы белән янә кире кайтарылган бер яшь артист:

— Юк, без Юсуповны ихтирам итмибез! — диде.

Бу сүз минем йөрәк бәгыремә килеп кадалды. Чөнки сәхнә әсәре язган авторларның һәммәсе бер авыздан: «Драматурглар белән эшләүдә Габдулла Юсуповка җиткән берәү дә юк», — диләр иде. Үз тәҗрибәмдә дә мин моңа ышанган идем.

Яшь артист репликасыннан соң мин, кәгазьләрне җыеп алдым да, папканы култык астыма кыстырып, ишеккә юнәлдем. Мине туктаттылар. Ни өчен чыгып баруымны сорадылар.

— Габдулла ага Юсупов сездә егерме ел режиссер булып эшләгән. Сез шуның хезмәтен ихтирам итмисезмени? Начар, иптәшләр. Бик начар. Бу сезне бизәми. Нәсел-нәсәбегезне таный алырлык имамнар булгач, бер-берегезне ихтирам итәргә өйрәнгәч, мин сезгә пьеса укырга килермен. Хәзергә сау булыгыз, — дип чыгып киттем.

Мин моны бигүк акыллы эшләнгән эш дип исәпләмим, ләкин минем башка чарам юк иде, Академда мине икенче мәртәбә мыскыл итүләре иде.

Озакламый Габдулла ага Юсуповны Әлмәт театрының баш режис-

серы итеп билгеләделәр. Әнә шул чагында ул минем «Утлар яна учакта»ны сорап алды да бик теләп куярга тотынды...

Беренче Май бәйрәменә биш көн кала Әлмәткә кайтып төштем. Габдулла абый мин кайтканга сөенде, шунда ук эш тә тапты, пьесаның финалы аңа ошамый, өч битне мин кабат язарга тиеш булып чыктым.

Ул көннәрдә Габдулла абый ике пьесаны берьюлы сәхнәгә куя иде.

— Төштән соң икенче группа репетициясе, Туфан Миңнуллинның «Очканда, кагынганда» пьесасын сәхнәдә уйнап карыйбыз, керәсең килсә, кер, — диде.

Мин бу әсәрне, кулъязмада укып, яраткан идем. Сәхнәдә ул ниндирәк буласы икән, карыйк әле.

Кердем. Зал караңгы, беркем юк. Сәхнәдә якты — артистлар уйный.

Беренче пәрдәнең ахырына җитәрәк, гөбедән чыккан төсле калын көчле тавыш зал түреннән ишетелде:

— Курчак уены бит соң бу!!!

Тавышның көчлелегеннән һәм кинәтлегеннән мин Туфан Миңнуллинның залда утыруын аңладым.

Пәрдә ябылды. Туфан сүзенә каршы бер генә сүз дә әйтелмәде.

Бәйрәмгә «Утлар яна учакта»ны чыгардылар. Халык, аеруча нефтьчеләр, бик яхшы кабул итте. Спектакль Уфада, Казанда күрсәтелгән чакта да яхшы бәя алды. Партиянең Татарстан өлкә комитетында үткәрелгән драматурглар һәм театр сәнгате эшлеклеләре киңәшмәсендә ул 1965 елның иң яхшы спектакле дип табылды.

Мин моңардан үзем өчен мөһим бер нәтиҗә ясадым: сәхнә әсәре язган автор иң әүвәл үз режиссерын табарга, ә ул режиссер аның иҗат принципларын таный торган, аны ихтирам итә торган кеше, авторның фикердәше булырга тиеш икән.

Инде берничә повестьның, хәтта романның авторы булсам да, «Утлар яна учакта» спектакленнән соң мин беренче әсәрен дөньяга чыгарган яшь автор кебек сөендем. Әлмәт театрының артистларын, режиссерын, рәссамын гына түгел, кием тегүче, гриммчы, машина йөртүчеләренә кадәр кунакка чакырдым. Безнең квартирга, Әлмәт язучыларын да кушсаң, берьюлы җитмеш кеше кереп тулды.

Минем эти, сөенеч килсә, дөнья бетереп сөенә торган булган, бәйрәмгә әйләнә-тирәне җыйган. Мин дә шулай кыландым.

Бәйрәм зур, бәйрәм тантаналы булды.

Халыкта: «И гыйшык, гыйшык, нигә синең бер кырыең кыйшык?» дигән гыйбрәтле сүз бар.

Туфан Миңнуллинның «Очканда, кагынганда»сы бик әллә ни булып чыкмады. Моның шулай булуын сизгән Габдулла абый Юсупов премьераны Әлмәттә түгел, Тайсуган авылында күрсәтте.

Халык спектакльне бик әллә ни исе китеп карамады. Яшь автор, премьераны билгеләп узу өчен дип, бәләкәй генә бер чемодан ише нәрсәгә тегесен-монысын да салып килгән иде. Габдулла Юсупов «премьераны юу» дигәнгә кул гына селекте (авторның «Курчак уены бит соң бу!!!» — дип кычкырган репликасы хәтерен калдырган булса кирәк). Ул бәйрәм итмәгәч, артистлар да, теләкләре никадәр зур булса да, табынга якын килергә базмадылар. Әгәр мин дә килмәсәм, яшь авторга кычкырып еларга гына кала иде.

Туфан белән без икәү — аңа утыз, миңа кырык яшь! — аның беренче сәхнә уңышсызлыгын юдык. Хәзер Җәлил, Тукай, Станиславский премияләре лауреаты, республиканың иң күренекле драматургы булган Туфан Миңнуллинның сәхнә юлы әнә шулай башланды.

Иң башлап мин аның зурлыгын түгел, хурлыгын күрдем.

Унбиш еллык тырыш хезмәт, принципиаль таләпчәнлек аны бүген илебезнең алдынгы драматурглары сафына китереп куйды.

Хәер, ул чакта ук мин аның нык булуына ышанган идем. Борын салындырмады, берәүгә дә үпкәсен белдермәде, сабыр гына Казанга кайтып китте. «Менә моңардан драматург чыгачак», — дип уйладым мин.— Ныклык бар моңарда, үз-үзенә ышану бар! Ә мин беренче пьесамнан үпкәләп йөрдем, миннән драматург чыкмады. Күрәсең, ныклык җитмәгәнгә чыкмагандыр...

## Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр

Югары әдәби курсларда 35 кеше укыды. Илебезнең төрле якларыннан килгән язучылар. Алар арасында Таҗикстанның күренекле өлкән әдибе Җәлал Икрамидән башлап, Кыргызстанның яшь шагыйрәсе Майрамханга хәтле бар иде. Төрле характер кешеләре иде алар. Атилла абый, мәсәлән, аз сүзле, Вәзих Исхаков, киресенчә, күп сүзле һәм шаян иде.

Атилла агай кичке тугыздан ук ятып йоклый да, иртән, алты да тулмас борын, безне уятып җанга тия. Чөнки әле без уникедә яки бердә генә йоклап киткән булабыз. Чөнки Вәзих миңа татар һәм башкорт революционерлары турында ярсып-ярсып сөйләгән, ә мин авыз ачып тыңлаган булам, мөмкин кадәр күбрәк ишетергә, күбрәк белергә ниятләнәм.

Миннән яшьрәк булса да, әдәбият эшенә миннән соңрак тотынган булса да, Вәзих революционерларга булган гаять зур ихтирамын, бу темага фанатикларча бирелүен миңа да йоктыра алды. Чыннан да, башкорт һәм татар әдәбиятында Вәзих Исхаков кебек бу теманы белүче, бу темага аңардан да күбрәк язучы юктыр. Вахитов, Мәүлетов, Чанышев, Бәхтизиннар турында ул роман-повестьлар язып бастырды.

Чынлап әйткәндә, «Идел кызы»н язарга кирәклегенә мине бөтән беркем дә түгел, Вәзих Исхаков ныклап ышандырды, юкса инде, язаргамы, юкмы дип икеләнә башлаган заманнар да булган иде.

Вәзихнең бер кызык ягы бар: ул бер генә нәрсәдә дә чама хисен белми. Таза, күкрәк киереп торган яшь, армиядә менә дигән офицер булган, русча да, татарча да, башкортча да бердәй тигез матур сөйли ала, кич буе табын янында утыра ала — эһ тә итми. Мин алай булдыра алмыйм. Табын янында озак утыру минем хәлне ала. Вәзих, чамадан тыш ихлас беркатлылыгы аркасында, мине кайгыртырга, дәваларга кирәклеген әйтеп, Әлмәткә, Шәһидәгә хат язган, хат, мин спектакль карарга кайткач, килеп төшмәсенме!

Җир йөзендә әле бер генә хатынның да аның эшенә читтән кисәтү ясаганны күтәрә алганы юк.

Мин спектакль премьерасыннан афишалар күтәреп кайтып төшкәч, йөзем дә айның унбишенче кичәсе төсле балкыгач, Вәзих түзмәде, гадәтенчә, чамасыз беркатлылыгы белән алдан ук сөенергә тотынды:

— Күрәм, юллар уңган Ахун хәзрәтнең. Нәмәгә икәнен дә беләм, иреңне кайгырт дип Шәһидә ханыма хат язган идем, яраткан, болай булгач, бисәкәй безнең хатны. Әйт әле, хакмы?

— Хак, хак, бик тә яратты, әллә ул революционер Исхаковыгызның кеше гаиләсенә тыгылмаса бөтән бер эше дә юкмы, диде.

Вәзихнең озын зур борыны салынып төште.

— Әнә гел шулай инде мин: беркатлылыгым аркасында янам да торам. Армиядә, лейтенант чагымда, мин бер мәлне чит-ят кешеләрдә яшәдем. Кайтсам, ире бер заманны хатынын уңлы-суллы яңаклап ятмасынмы. Гомердә мин күргән хәл түгел, әти белән әни минем — сугышу кая ул! — бер-берсенә авыр сүз дә әйтмәделәр.

Яшь чак гайрәтле чак дигәндәй, арслан киектәй килеп кердем болар

арасына, икесен ике якка чөеп аттым. Аның белән генә туктамадым, ирен битәрләргә тотындым.

— Ничек оят түгел сиңа, мин әйтәм, безнең совет заманында хатын-кызга кул күтәрәсең, фәлән дә фәсмәтән...

Хатыны инде хәл җыеп өлгергән иде, баласын яклаган бөркеттәй, миңа ташланды. Урал бөркетләренең кыятаудагы ояларын туздырганда-гы кыланышын күргәнем бар, бер дә яман-хәтәр, якын килерлек түгел. Авызы-борыны канаган Маруся түти, әнә шул бөркет төсле, миңа очып куна.

— Ни хакың бар синең, ди, борын астың кипмәгән молокосос, ди, ир белән хатын арасына керергә, ди.

Перәме буынсыз калдым, әй. Башыма күсәк белән китереп ордылармыни!

— Туктагыз әле, мин әйтәм, мин арага кермәсәм, ирегез сезне кыйнап үтерә иде бит, сездән юеш урын гына кала иде бит, — дим.

— Калсын! — ди Маруся түти. — Синең анда эшең юк, ди. — Татарча әйткәндә юашрак чыга ул, Маруся түти: «Не твое собачье дело!» — дип җиффәрә! — Эт талашыр, тиресе ертылмас, — ди.

Шундый хәтерем калды, шундый хәтерем калды, бер минут тормый чыгып киттем мин болардан. Икенче көнне, бераз суынгач, Маруся түти мине «миленький» дип чакыра да килде, бармадым — минем дә үз горурлыгым үзем белән.

— Бу сүз Шәһидәгә дә кагыламы инде?

— Кагылмый ни соң! Мин бит аңа әйттем, Ахунов әдәбиятка кирәк, сакла, дидем. Ә ул әнә кабул күрмәде, дисең.

— Так точно, революционер Исхаков, кабул күрмәде. Бигайбә.

— Ярар... — диде Вәзих моңсу гына. — Югары курслардан соң сентябрьдә Әлмәткә барырмын дигән идем, синең кырык еллыгыңа! Бармыйм инде, болай булгач.

— Син, революционер Исхаков, колак белән калакны бутама, килерсең, күрешербез, әле синең белән сөйләшәсе дә, киңәшәсе дә сүз күп минем... — дидем.

Афишаларны чемоданнан чыгарып, стенага элдем. Премьераның ничек узганын әйттем.

— Әйдә, курсташларны чакырабыз, шатлыкны үзеңдә генә калдыру әйбәт эш түгел, — диде беркатлы Вәзих.

— Ярармы соң алай? Бу бит минем уңыш түгел, режиссер уңышы,— дидем мин икеләнеп. — Ул тырышмаса, спектакльнең монысы да җимерелә иде...

— Юкны сөйләп торма, — диде Вәзих. — Бер режиссерның да драматург өчен пьеса язганы юк әле.

Ул «ә» дигәнче өстәл әзерләде. Ял көне иде. Моңаешып коридорларда йөргән «студент халкы»—язучылар безнең бүлмәгә кереп тулды.

Вәзих минем шатлыкны әйтүне үз өстенә алды. Алай әдәплерәк була, диде.

Әрмән язучысы, ифрат тапкыр сүзле һәм ифрат чибәр, бөдрә чәчле кара егет, Сурен Айвазян, минем афиша каршысына басып:

— Елга өстен боз каплый, әмма боз астында тормыш бар. Бу — афишаның хуҗасы Гарифҗан боз астындагы тормыш кебек, безнең арада шыпырт кына яшәде дә инде менә афиша күтәреп килгән. Яратам талантлы кешеләрне, чөнки мин үзем дә талантлы! — диде.

Гөр килеп бер көлдек. Сурен Айвазян да, безгә кушылып, рәхәтләнеп көлде.

Ул көнне без, төрле халыкларның балалары, рәхәтләнеп бәйрәм иттек. Мин дә онытылдым, афиша да күзгә күренмәс булды. 9 май иде бу. Илебезнең Җиңү бәйрәме хөрмәтенә каяндыр баян табылды. Әдәбият институтында укучы шагыйрәләр килде. Танцалар, халык биюләре башланды...

Иртәгесен иртүк Вәзих белән мине Атилла абзый уятты.
— Торыгыз, чукынчыклар! Йоклап ятмагыз. Бу ниткән ялкаулык?! Торыгыз, дим, торыгыз...
Күзләрне тырмап ачып тордык, бүтән йоклап булмады. Әмма тагын бер көннән соң Атилла абзыйдан моның «үчен алдык».
Төнге өчкә кадәр, сүз берләшеп, язып утырдык та, нәкъ өч тулгач, барып, Атилла абзыйның ишеген шакыдык.
Күзләрен уа-уа, Атилла абзый ишекне ачты. Безне күргәч, аптырап:
— Нишләп йөрисез, чукынчыклар? — диде.
Без түбәнчелек белән гафу үтенгән булдык. Вәзих портфеленнән бер төргәк чыгарды.
— Менә моны сезгә Җәлал ага үзе җибәрде.
— Нинди Җәлал?
— Соң тажик язучысын белмәскә?! Җәлал ага Икрами. Атилла туганга илтеп бирегез, миннән күчтәнәч булсын, мин аның Муллануր турында, Хөсәен турында роман язганын белдем. Ул — җөдә яхшы кеше,— диде.
Атилла абзыйның йокысы ачылды, каушады, ни дип әйтергә белми, трусиктан безнең каршыда басып тора, аптырагач, бүлмәсенә чакыра башлады.
Олы кешегә каршы килеп булмый — кердек.
— Нәрсә соң бу? — диде Атилла абзый, төргәкне сүтеп. Аннан бик матур бальзам шешәсе һәм кипкән йөзем килеп чыкты.
— Сыйлыйм дип әйтер идем, инде вакыт бик соң... — дип башлады Атилла абзый.
— Юк, юк, — дидек без. — Мәшәкатьләнә күрмәгез. Шулай соң уятып йөргәнгә гафу итегез. Үзегезгә мәгълүм, без икебез дә төгәллекне яратабыз. Икрами агайда кунакта булдык, ул сезгә менә шушы бальзамны җибәрде, нинди соң булса да кертеп бирми калмагыз, мин аны бик ихтирам итәм, ул менә дигән язучы, диде.
Шуны әйтү белән без бүлмәдән чыгып ычкындык. Атилла абзый иртәгесен дәрескә килә алмый йоклап калды, шуннан соң безне беркайчан да «торыгыз, чукынчыклар!» дип таң тишегеннән уятып йөрмәде.
Бальзамны Икрами агай түгел, без алганны аңладымы икән ул? Хәер, аңламавы да мөмкин. Мактау сүзенең бигрәк зурысын әйттек шул без аңа. Ул ике атна рәттән баш күтәрми эшләде, Икрами аганың «җөдә яхшы кеше» дигәнен аклыйсы килде бугай.
Ә бит чыннан да, әйбәт язучы ул безнең Атилла абзый. Андый тырыш, андый галим язучыны көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың.
Без байтак вакыт Икрами агайдан шүрләп йөрдек. Атилла Расихның аны күрүе, бальзам өчен рәхмәт әйтүе, тегесенең аптырап калуы мөмкин иде.
Без ул хакта Икрами агайны кисәтеп куярга да ниятләгән идек, ул атна буе өйдә булмады, аннары, көтмәгәндә, Вәзих белән икебезне кунакка чакырды.
Без, кыенсынып, баш тарта башлаган идек, ул елмая биреп:
— Минем генерал Чанышев белән күрешәсем килә. Бохараны азат иткән кеше бит ул. Алып килегез әле аны миңа, — диде.
Болай булгач инде, баш тартып булмый.
Шимбә көнне Икрами агай әйткән вакытка, сәгать нәкъ икегә, генерал Чанышевны да алып, аның бүлмәсенә килеп кердек. Вәзих аның хакында китап яза, Якуб агай белән бик дус иде.
Алтын погонлы генерал, аның белән бергә татар әдипләре килеп кергәндә, без инде хуш исле тажик пылавы, авыздан сулар китерер, өстәлдә торыр дип исәпләгән идек. Ялгышканбыз.
Без килгәндә, Икрами агай һәм аның якташы Шәмси Каюмов, диванга чүмәшеп утырганнар да, газета кәгазенә дөге ярмасын таратып ташлап, аның чирле-чинкесен, каралган-мазарын берәмтекләп чүплиләр иде.

«Ник алай?» — дип соравы уңайсыз. Пылауның пешкәнен ике сәгать көтеп утырдык. Өстәлгә бик зур тәлинкә белән пылау, икенче бер коштабакка коньяк җимешләре өелеп куелды.

Җиңнәрне сызганып, озаклап кул югач, хуҗалар өстәл янына килеп утырдылар.

Икрами агай уймак чаклы гына рюмкаларга, һәркемнең теләгенә карап, аракы яки коньяк салып чыкты, уймак рюмканы кулына тотып әйтте:

— Сез ишектән килеп кергәч, бәлки, аптырап калгансыздыр. Икегә чакырылдык, ә пылау пешмәгән. Таҗикның гадәте шулай, туганнар. Ул бар нәрсәне кунакка күрсәтеп эшли. Аның алдында дөгене чүп-чарыннан аралый, аның алдында пешерә, аның алдында кул юа. Мин татар халкының бик пөхтә, бик кунакчыл халык икәнен, аш-суны бик мул әзерләвен беләм. Мин татар халкының ифрат та ярдәмчел халык икәнен беләм. Күпме татар мөгаллиме Урта Азиягә белем бирде. Күпме татар солдаты Урта Азиядә революция ясашты. Ә бу бик мөһим иде, дини фанатизм котырган заманда бөек акыл иясе Ленин Урта Азиядә революция казанышларын сакларга татар сугышчыларын чакырды. Менә безнең алда Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, татар халкының батыр улы генерал Чанышев утыра. Ул узган юл — шанлы совет гаскәрләре узган юл. Бохараны контрреволюциядән коткарышкан генерал олы хөрмәткә лаек. Совет халыкларының иң бөек хәзинәсе өчен, дуслык-туганлык өчен, Якуб ага Чанышевның саулыгы өчен тост тәкъдим итәм.

Бохара турында, Төркестан турында, өч китаплы романы турында җай гына сөйләде Икрами агай. Аның, инде алты дистәне тутырган кешенең, йөзе ифрат чибәр, кашлары куе, калын һәм кара, чәче дә кара әле, тик маңгай турысы гына пеләшләнеп, ялтырап калган иде. Ә илле яшьлек Шәмси Каюмов гел дә егетләргә биргесез иде.

Пылауны алар икесе дә кашык белән түгел, кул белән ашадылар. Урта Азиядә пылауны әле дә кул белән ашыйлар дигәнгә аптырабрак йөри идек, үз күзебез белән күргәч, аптырау бетте. Алар икесе дә, биш бармакны бергә җыеп, пылауны бик оста эләктереп алалар да, бер генә ярмасын да түкмичә, авызларына озаталар, бу шундый чиста-пөхтә килеп чыга, изге бер эш эшләгән кебек тоела иде.

Мин үзем, алар ашаганда, авыл карчыкларының искиткеч ихтирам белән ашъяулыктагы ипи валчыгын чүпләүләрен искә төшердем.

Без ул көнне бик иркенләп утырдык, пылауны кыстатмый-нитми ашадык, пылаудан соң бирелгән яшел чәйне рәхәтләнеп эчтек.

Хәтта пылау пешерүнең рецептларын да язып алдык. Вәзих белән икәү, икенче көнне бик батыраеп, Атилла абзыйны шаккаттыру нияте белән, зур бер кастрюльдә таҗик пылавы пешерергә керештек. Бөтенесен Икрами агай әйткәнчә эшләдек: дөгене чүп-чарыннан араладык, симез сарык итен һәм суганны көнбагыш маенда кыздырдык, бер кило дөгегә ике кило ит салдык, тиешенчә су өстәдек, ярманы тутырдык та әкрен утка куйдык. Ярма өстендәге су беткәч, сөлге белән, мендәр белән бөркәп, иркенләп тәнәттек пылауны. Әмма безнең пылау таҗик пылавы булып чыкмады. Бердән, һәр бөртеге аерым торырга тиешле, таралып торырга тиешле дөге изелгән, шуның өстенә ярманың яртысы көйгән иде.

«Өй салуның ние бар, чутлыйсы да мүклисе», — дип көлештек без.

Безнең пылауның ниге таҗикча килеп чыкмавын институтта, дәрескә җыелгач, Икрами агайдан сорадык. Ул бездән ит, ярма, май суган салу нормаларын белешкәч:

— Кәстрүлегез эмаль идеме? — дип сорады.

— Әйе, әйе, эмаль иде! — дип бик батыр җавап бирдек без.

— Эмаль кәстрүл ярамый, көйдерә, калай кәстрүл кирәк — диде Икрами агай тыныч кына.

— Без сездә бик озак кунак булдык,— диде Вәзих. — Сезнең кәефне алмадыкмы?
— Яхшы кеше мәҗлестә матурлана, яман кеше мәҗлестә ямանлана. Сез яхшы кешеләр, җөдә матур утырдыгыз, рәхмәт сезгә, — диде Җәлал Икрами.
Аңардагы ягымлылык һәм зирәклек безне таң калдырды.



## Ак төннәр

Майның икенче яртысында Ленинградта ак төннәр башлана, диделәр. Без, югары курста укучылар, нәкъ шул вакытта Ленинградка барырга, Ленин яшәгән урыннарны күрергә тиеш икәнбез. Бу безне бик сөендерде. Мин шунда ук өйгә хат язып салдым, Ленинградка Шәһидәне һәм бишенче класста укыган улыбыз Рәшитне чакырдым. Шәһидәне чакыруымның сәбәбе шул: без аның белән өйләнешкән чакта, Ленин мавзолеең, Ленин яшәгән урыннарны икәү бергә карарбыз, аерым-аерым карамабыз дип сүз куешкан идек. Өйләнешкәнебезгә инде ундүрт ел узса да, Мәскәүдә миңа ничәмә-ничә мәртәбә булырга туры килсә дә, вәгъдәмә турылыклы булганга, Ленин мавзолеена кергәнем юк иде әле.
Менә хәзер керербез инде. Ленинградны да бергәләп карарбыз. Ленин бабай йөргән юллардан бергәләп йөрербез.
Рәшит рәсем мәктәбендә укый, минем аңа легендар Ленинградны, Петергофтагы фонтаннарны, Эрмитажны, барыннан да бигрәк, Ленин шалашын, Смольныйны, Кронштадтны күрсәтәсем килә иде.
Килдек Ленинградка, «Россия» гостиницасыннан бик әйбәт люкс бирделәр. Яши башладык. Көндезләрен экскурсия, Петергофтагы фонтаннар, Пулково кырындагы һәйкәлләр, һәлак булганнарның истәлеге, Пушкин укыган лицейны карау белән уза, кичен театрларга йөрибез. Пушкин театрында, мәсәлән, «Күтәрелгән чирәм» спектаклен карау безнең өчен зур бәйрәм булды.
Баштарак Рәшит, сорау-мазарлары белән теңкәгә тиярме, дип курыккан идек, ул безнең кулга да эләкмәде. Вәзих абыйсы аны шул хәтле дә үз итте, тәмле теле, дусларча мөнәсәбәте белән бездән тартты да алды. Аннары Вәзихнең революция турында күбрәк белүе дә Рәшитне аңа якынайтты булса кирәк, кыскасы — берничә көн эчендә алар аерылмас дуска әйләнделәр. Шул заманның фоторәсемнәрен карап утырганда, игътибар иттем: Рәшит — гел Вәзих абыйсы янында, алар гел дә абыйлы-энеле кебек басып торалар.
Эрмитажны караган чакта, улыбызның хисләрен белү өчен, без аны ялынып диярлек үз яныбызда алып калдык. Әмма ярты сәгать уздымы икән, ник алып калганыбызга үкенә башладык. Кайсыдыр бер картина белән без озаграк мавыкканбыз, гид һәм язучылар төркеме китеп барган, эзли башладык, табар гына хәл юк. Эрмитажның никадәрле зур икәнен әнә шунда аңладык.
Ә Рәшит, гидтан һәм Вәзих абыйсыннан аерылып калганга үпкәләп, елап ук җибәрде. Башка көннәрне инде ул безгә якын да килмәде, гел Вәзих абыйсы белән генә йөрде. Улыбыз Ленинградта һәйкәлләр, каеннар, йорт рәсемнәре ясады. Дөресен әйткәндә, аңа аларны мин көчләп диярлек ясаттым. Малайда рәсем кайгысы түгел, аның җаны хис белән, сокланулар белән тулы иде.
Төнге Ленинград көмеш яктылыкта коена. Аяк астыннан әнә табарлык. Без, ак төннәрне беркайчан да күрмәгән кешеләр, мондый хәлгә хәйран калып төнге икеләргә хәтле урамда йөрибез.
Шушы тойгыларга яр буенда торган «Аврора» крейсеры килеп кушыла. Кая ул Рәшит кенә, без, олылар, крейсерны күрүгә йөгерә үк башлыйбыз, онытылмас шул көннәрнең истәлеге итеп рәсемгә төшәбез.

Ленин шалашы янында озак юандык. Инде ничәмә-ничә мәртәбә китаплардан укыган булсак та, шалаш безне әсир итте. Шушында дөньяның даһи кешесе яшәгән, печән чапкан, ашаган, йоклаган, кыскасы, гади кеше ни эшләсә, шуның барысын да эшләгән, әмма шуларның барысына өстәмә итеп, дөнья язмышын, хезмәт ияләренең бәхетен кайгырткан, булачак революциянең барлык детальләрен берәмтекләп, җентекләп күңеленнән уздырган.

Советлар иленең көчле ныгытмасы булган Кронштадтта безне чамадан тыш зур булуы белән бер чиркәү таң калдырды. Бирегә өч мең солдат берьюлы дога кыла торган булган. Әнә нинди фанатизм богавында тоткан патша үзенең сакчыларын. Әмма Ленин акылы богауларны, төрмә-зинданнарны, дин фанатизмын җиңгән, Ленин даһие халыкны һәм гаскәрне үз артыннан алып киткән.

Миңа боларны белү, боларны күңелем аркылы үткәрү бик мөһим иде. Ленинградтан мин Ленин башлаган эшнең бөеклегенә иман яңартып кайттым.

Мәскәүгә кайткач, өчәүләп Ленин мавзолеена кердек. Чыккач, хисләрне бүлешмәдек. Тел белән генә әйтеп бетерерлек түгел иде тойгылар. Гостиницада Шәһидә әйтте:

— Рәхмәт сиңа, этисе. Безгә Ленинградны бүләк иттең. Әйдә, барысының бер бәйрәме итеп, такси белән Мәскәүне дә әйләнеп кайтыйк инде, — диде.

Мәскәү буйлап без озак йөрдек. Илнең зурлыгын, колачын, төзелеш куәтен янә бер мәртәбә башкалабыз мисалында да күрдек. Балаларның сөекле язучысы Аркадий Гайдар сүзләре күңелдә яңарды.

«...Дөньяда иң зур, иң матур кала бар. Ул, әлбәттә, Мәскәү...»

## Хуҗалар

«Идел кызы» романына яңадан-яңа материаллар туплауны дәвам иттергән хәлдә, мин «Хәзинә» романының икенче китабын ныклап язарга керештем. Исемен «Хуҗалар» дип билгеләдем. Бу исемнең мәгънәсе болай: илдә төрле хуҗа бар, берсе үз ихатасын, үз кесәсен кайгырта, икенчесе — өзлексез, туктаусыз ил кайгысы белән яши.

Алтмышынчы елларда Әлмәт тирәләрендә газ факеллары бик күп яна иде. Нефть якларына аз гына вакытка килеп чыккан шагыйрьләр аларга сокланып, поэтик образ итеп кулланалар, очеркистлар исә моны, нефть якларының билгесе итеп, язмаларын шуның белән башлап җибәрәләр иде.

Ә чынында исә бер факелда гына да меңләгән сумлык байлык күккә оча, Әлмәт тирәсендәге авылларда көн күргән нефтьчеләр өйләрен җылытырга утын таба алмый интегә, хатын-кыз газсыз тилмерә иде.

«Хуҗалар» романында мин әнә шуны зур бер проблема итеп алдым. Арслан Гобәйдуллинны, «Хәзинә» дән үк килгән баш геройны ил кайгысын кайгырту кебек зур эшкә җигәргә ниятләндем.

Арслан промыселлардан газны җыеп алу өчен компрессор заводы салу идеясе белән янып яши. Главкага, министрлыкларга житә, исбатлый андый завод кирәклеген, салдыра андый заводны, шунда, авария вакытында аның хатыны Сәгыйдә һәлак була. Романда шулай ук «Хәзинә»дәге Лотфулла Дияров, Нәҗип Корбанов, Шәвәли картлар сызыгы да бара, Арсланның беренче мәхәббәте Мөнәвәрә тормышы да дәвам иттерелә.

Мин бик күп нәрсә уйлап чыгара алам, әмма әсәрләремдә үзем күргәнне теләбрәк һәм ышаныбрак язам. Компрессор заводын салганны минем күргәнем булмады, аларны соңрак сала башладылар һәм алар, завод дип түгел, «Компрессор станцасы» дип аталды. Үз күзем белән күр-

мәгән заводны мин язучылык фантазиясе белән тудырырга тиеш идем. Шунлыктан «Хуҗалар»ны язу «Хәзинә»не язуга караганда авыррак булды миңа. Главкаларның, министрлыкларның эшен, андагы җитәкчеләрнең холкын өйрәнергә кирәк иде.

Роман 1968 елны «Казан утлары»нда басылып чыкты, ә 1969 елны, Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта Фатих ага Хөсни, бер өйрәнгән гадәте буенча, аны бик матур итеп сүтеп атты.

Мине яклап берәү дә сүз кузгатмады.

Төне буе утырып, мин җавап сүзе яздым. Җыелыш әле икенче көнне дә дәвам итәчәк иде. Ләкин сөйлисе сүземне Шәһидәгә укып күрсәткәч, ул тыныч кына әйтте:

— Кирәкми, әтисе. Үз әсәрен үзе яклаган кешенең уңышка ирешкәне юк әле. Аннары бит син романыңны сөттән ак, судан пакь дип әйтергә җыенмыйсыңдыр. Компрессор заводы салуны күрмәдең, шулай булгач, дәшми калуың яхшырак булыр, — диде.

Ул чакта инде без Әлмәттән Казанга күчкән идек. Мин Язучылар союзында җаваплы секретарь булып эшли идем.

Ибраһим Гази — Язучылар союзы идарәсе председателе — минем җыелышта чыкмый калуымны хуплады, әлеге тәнкыйтькә яңа бер әсәр белән җавап бирергә кирәк булыр, диде. Димәк, «Хуҗалар»ны ул да җитлекмәгән әсәр дип саный.

Мин, тешемне кысып, «Идел кызы»на тотындым. 1970 елның җәендә, романның Кама буена караган өлешләрен тагын да ныграк ачыклау өчен Әгерҗегә китеп бардым. Миңа Колчак гаскәрләренең Салагышка керүе, үтерелгән активистлар, Әгерҗе депосындагы эшчеләр дружинасы, ул чордагы ревкомнар, гомумән, Әгерҗе—Красный Бор төбәгендәге революцион вакыйгаларның конкрет кешеләре кирәк иде.

Әгерҗегә килеп төшүгә, вокзалда ук, милиция капитаны очрады. Озын буйлы, зәңгәр күзле, аксыл чәчле, сүзне өзеп сөйләшә торган нык холыклы кеше. Ул безне ай-ваебызга карамый үзләренә алып китте. Баксаң-күрсәң, ул Шәһидәнең туганына өйләнгән икән, чәй янында мин аның тормышын сораштым. Этенеп-төртенеп тормады, тыйнаклык саклап та азапланмады, ул миңа сугыш ветераны булуын, азактан югары хуҗалык мәктәбен, юридик институтны тәмамлавын, Волга-Балтика каналында эшләвен, Әлмәтнең нигезен салуын, ниһаять, утызмеңче булып, артта калган бер колхозны күтәрүен, инде менә тагын төп эшенә — милиция эшенә кайтуын сөйләп бирде.

Бу миңа шундый да кызыклы материал булып тоелды, бүген, бер минут кичекми, утырып язасы килде. Ләкин бит мин — «Идел кызы»на материал җыярга чыккан кеше, буш кул белән кайту романга хыянәт итү булыр иде.

Әгерҗе районының Балтач авылында без ике атна яшәдек. Гаҗәеп киң күңелле кешеләр булып чыкты безнең хуҗалар, Җамалттәй белән Миңлегали абзый. Алар безгә авыл хәлләрен сөйләделәр, кичләрен яшь чакларын сагынып искә алдылар. Мине үземә кирәкле авыл атмосферасына алып керделәр. Мин, Балтачтан ерак түгел Кырынды авылына барып, Фоат Садыйков белән очраштым. Әгерҗе төбәген биш бармагы кебек белгән әлеге укытучы миңа Кама буйларының революция тарихын сөйләде. Аннары мин Салагышта крестьян даулары турында сәмруг кош мөһере сугылган, ике гасыр моннан элек язылган сургучлы кәгазь таптым. Салагышның атаклы Янчуриннар нәселе табып бирде миңа ул кадерле кәгазьне.

«Идел кызы» романына яңа материаллар табуыма, җитмәсә, әле бүгенге заман повестена юлыгуыма бик тә шатланып, Казанга кайтып төштем дә... хезмәт вазифаларына күмелдем.

Әйе, әйе, үземне дулкынландырган кыска повестьны язасы урында, мин җыелышлар җыйдым, идарә утырышлары үткәрдем, директив ор-

ганнарга белешмәләр яздым; шуның белән нәкъ ярты ел искән жилдәй узып та китте, повестьның мине дулкынландырган эчке пружинасы ычкынды, бары тик коры кысасы гына торып калды.

Хәзер Язучылар союзында председатель, аның ике урынбасары, секретаре бар. Ул чорда председатель белән секретарь гына иде. Хикмәти хода, председатель булып сайлануга Ибраһим абыйга нindидер чирләр каныкты, минем эш аны больницага илтү, больницадан алып кайту иде. Өстәвенә ул елларны, ике ел рәттән, Казанда әзербәйҗан, үзбәк әдәбияты һәм сәнгате атналыклары үткәрелде. Биш йөзләгән кешене каршылау, урнаштыру, аларга тарихи урыннарны күрсәтү, газеталарда әдәби битләр оештыру, шулар өстенә Язучылар союзының агымдагы эшләрен алып бару бик авырга килде. Миңа кунакларны гостиницага урнаштырудан башлап, үзәк газеталарга мәкалә язуга кадәрле, әдәби кичәләрне ачу һәм алып баруга кадәрле, күп төрле эш йөкләнде. Ибраһим абый боларны аңлый, түз инде, Гариф, түз инде, яшь чакта барыбыз да шулай эшләдек, дип мине юата иде. Юата белә иде Ибраһим абый.

Әдәби атналыкларны уздырырга өлгермәдек, Казанга монгол язучылары делегациясе килеп төште. Аннары озак та тормый, Италиянең атаклы балалар язучысы Джанни Родари, хатыны, кызы һәм тәрҗемәчесе белән килеп житте. Кыскасы — «Идел кызы»на да, әлегә исеме табылмаган лирик повестька да вакыт калмады.

Күп төрле очрашулардан минем аеруча хәтеремдә калганы Джанни Родари булды. Мин аңа Казанны күрсәттем, Ленинның беренче мәртәбә сөргендә булган урыны Кокушкиноны күрсәттем. Тәбәнәк буйлы, базык гәүдәле, шомырт кара күзле һәм шомырт кара чәчле Джанни үзен бик гади тота, кулында аның блокнот, аркасында бәләкәй генә рюкзак булыр. Сөйләгәнне ул тоташ язып бара. Кайчагында унбиш яшьлек үсмер кызы яки хатыны аны алҗыта, аңа бәйләнә башласа, тыныч күңел, сабыр холык белән чәчләреннән генә сыйпап куя иде. Джаннидагы идеал сабырлык мине таң калдырды.

Урамда исереп егылган бер кеше ята. «Әнә шундый хәлләр дә була дөньяда», — дим мин, уңайсызланып.

«Борчылмагыз, мин сезнең илне барлык кимчелекләре белән яратам», — ди Джанни. Һәм бу кылтаеп яки рияланып әйтелгән сүз түгел. Джанни Родариның дөньяга танылуы безнең илдән башланды.

Язучылар союзындагы очрашуда аңа татарча чыккан «Чипполино маҗаралары»н һәм тагын кайсыдыр бер китабын бүләк иттеләр, автограф язуын үтенделәр.

Уйланып тормады Джанни, болай дип язды (итальянча язды, тәрҗемәче безгә тәрҗемә итте):

«Казанда мин күп кенә дуслар һәм үз китабымны очраттым. Китабымнан көнләшәм, чөнки ул татарча сөйләшә белә, ә мин белмим. Хәер, бер сүз беләм икән, рәхмәт».

Ленино-Кокушкино музеенда безне фотограф Әсрар Шакирҗанов рәсемгә төшерде. Ни генә кыланмады ул: утырып та, чүгәләп тә, аркасына ятып та төшерде.

— Кара инде: безне тарихка калдырыр өчен адәм баласы ничекләр тырыша, — дидем мин, шаяртып.

— Тир белән тапкан ипи тәмлерәк була, — диде Родари. Хезмәт кешеләренә ихтирамы чиксез иде аның.

Татар ашлары йортында без Джанни семьясын чүлмәктә пешергән итле бәрәңге белән, чәк-чәк белән сыйладык.

— Сезгә ошыймы? — дип сорадым.

— Күрмисезмени, чүлмәк тә, тәлинкә дә буш. Итальянны, әгәр ризык ошамый икән, аркасына мылтык терәп тә ашата алмыйсың.

Казанда Родари өч көн торды, өч көн эчендә утыздан артык татар сүзе отты. Иртән «исәнмесез!» дип күрешә, кичен «хушыгыз, сау булыгыз!» дип озата, рәхмәтне, ак тешләрен балкытып, адым саен әйтә иде.

СССРда балалар язучыларына булган ихтирам аның күңеленә хуш килә икән. Җае чыккан саен ул моны әйтә, бездә балалар язучыларының әсәрләренә икеләтә ким түлиләр, ди.

Мин аңа татарча чыккан «Канатлар кая илтә?» дигән китабымны бүләк иттем. «Сез, Джанни, Казанга килеп дөрес эшләгәнсез. Чөнки Пушкиннан башлап барлык бөек язучылар бездә булды», — дип яздым. Тәрҗемәче кыз моны итальянчага тәрҗемә итеп биргәч, Родари бик озак тынычлана алмыйча:

— О, о, о! — дип торды.

Миңа ул почтальон кыз рәсеме төшерелгән китабын бүләк итте. Автографы: «Гариф, бу кыз сиңа миннән хат китерә, ә хатта син Италиягә килергә, минем кунагым булырга тиешлек әйтелгән. Рәхмәт сиңа».

Джанни миңа шул хәтле ияләнде, өченче көнне гаиләңне күрсәтә алмассыңмы, диде.

Шәһидә һәм унбиш яшьлек улым Рәшит белән бергә мин аларны халыкара яшьләр лагерена алып бардым, су коендырдым, яшьләргә ашата торган ризыклар белән сыйладым.

— Бәхетле сездә яшьләр. Алар өчен нинди шартлар тудырылган. Сәнгать әсәре бит бу! — диде Джанни, кулларын җәеп җибәреп, әкият стилендәге йортларга күрсәтте. Аннары, көтмәгәндә:

— Ничә яшьтә өйләндегез? — диде.

— Егерме алтыда, — дидем мин һәм соңрак өйләнүемә уңайсызланып, акланырга керештем: — Әтисез үстем мин. Башта эшлисе, аннары университет бетерәсе булды.

— Ә мин утыз биштә өйләндем.

— Ник?

— Бездә башта квартир булдыралар, мебель алалар. Квартиры юк кешегә бездә берәү дә кияүгә чыкмый.

Джанни Родари Татарстанга Ленинның йөз еллыгына китап язар өчен килгән иде. Китәр көнне ул шактый моңсу булды. сөйләшмәде диярлек, өч палубалы ап-ак теплоходның салонында, бу юлы аркасына рюкзакның зуррагын аскан көе, унбиш минутлап басып торды. (Кайсыдыр бер мәгънәсезе аркасында каюталарны ачмый интектерделәр). Мин борчылып, гаепләне эзләргә чапмакчы идем инде — Джанни мине туктатты.

— Кирәкми. Теплоход кузгалгач, каюта үзеннән-үзе ачыла ул, — диде...

Ульяновскидан ул миңа ихтирам һәм рәхмәт хисе белән тулы телеграмма җибәрде.

Джанни Родари белән очрашу, аңардагы ныклык һәм чамасыз сабырлык мине иң кыен хәлләрдә калганда да тыенкырак булырга, гасабиланмаска өйрәтте. «Яхшы кешеләр белән булганда, мин үземне дә яхшырып киткәндәй сизәм», — дип Толстой әйткән бугай.

## Киңәш

Шулай итеп, минем язарга утыру вакытым сузылды да сузылды. Ибраһим абый, 1970 елны йөрәгенә микроинфаркт булып, әллә ике, әллә өч ай больницада ятып чыкты. Больницадан ул кыска хикәяләр язып алып чыккан иде. Минем тәнкыйтьчелегемне таныганга күрә (аның иҗаты хакында мин «Таләпчән художник» дигән бер табаклы мәкалә бастырган идем), миңа укырга бирде. Хикәяләр югары сәнгать законнарына таянып язылган, бер генә сүзе дә артык түгел иде. Гомумән, гомеренең соңгы елларында Ибраһим Гази «Тургай да картаямы?», «Алсу томаннар артында», «Сарбай — сары эт» кебек, татар әдәбиятының

гына түгел, гомумән совет прозасының җәүһәре булырдай хикәяләр иҗат итте.

Больницадан соң, әз генә тернәкләнә төшкәч: аңа өч бүлмәле бик шәп квартира бирделәр. Бер көнне машинада икәү бергә утырып кайттык та, мин саубуллаша башлагач:

— Әйдә, бераз урам йөрик әле, китсен бу машина, — диде.

Риза булдым. Үземнең дә андый теләк бар иде, тик әле «сыткый сагыз» дип әйтмәгәе дип шикләнүдән генә аңа ияререгә теләвемне әйтми тора идем.

Зур язучылар да мактауга, җылы сүзгә мохтаҗ була. Бу хакыйкатьне миңа моннан ун еллар элек Малеевка иҗат йортында ял иткәндә Мостай Кәрим әйтте. «Күңелеңдә җылы сүзең булса, кемнең кем булуына карамый әйт», — диде ул.

— Ялагай дип әйтмәсләрме соң?

— Зур кеше ялагайлык белән ихласлыкны аера белә.

Менә хәзер шуны искә төшереп:

— Ибраһим абый, хикәяләрегезне укыдым. Сез соңгы елларда татар хикәясенең дәрәҗәсен бик күтәрдегез бит, — дидем.

— Син алай бик зурдан кубып сөйләшмә, Гариф. Дөрес, мин ярыйсы гына хикәяләр яздым. Үземнең дә күңел булды... Ләкин әле эшлисе эш, ай-һай-һай!

— Минем дә язасы килә бит, Ибраһим абый.

— Син әле яшь, язарсың. Миннән инде булмас.

— Нигә алай дисез, Ибраһим абый?

— Сизәм мин, гомер калмады. Какшады сәламәтлек. Ятимлек-мәхрүмлекләр өскә чыкты...

Күңелгә кинәт бик моңсу булып китте.

Мин инде ел буе ял итмәгән идем. Ике айга ял алып, язуга утырырга иде исәп. Сүз болайга киткәч, ничек инде ял сорыйсың?

Искиткеч сизгер кеше — Ибраһим абый. Күзлек пыялаларын елтыратып, астан-өскә таба минем буй-сынны үлчәп алды да:

— Син инде байтак интектең, Гариф. Ел буе союз эше белән чаптың. Давай, ялга чыгып кер инде, аннары мин чыгармын, — диде.

— Юк, — дип каршы төштем мин. — Башта сез чыгыгыз, Ибраһим абый, больницадан соң сезгә санаторий кирәк. Мин сездән соң ял сорармын.

— Ихлас әйтәсеңме?

— Рияланçам, шушы кояшның чыраен күрмим.

— Ярый алайса, мин барып кайтыйм әнә шул санга туры дигән җирләренә, — диде ул, «санаторий»ны үзенчә бозып. Теләсә кайсы чит сүздән ул кызык итеп татар сүзе ясый ала иде.

Бервакыт кибеттә «Геркулес» алган чагында, ул болай диде:

— Чибәркәй, әнә шул герле күзеңне биреп җибәрче миңа.

Кызый аның шаяртканын аңламады.

— И абый, әйтә дә белмисең икән әле, герле күз түгел, геркулес бит ул.

— И ярамаган безгә, карт кешегә, бир инде, бир шул герле күзеңне.

Тик шуннан соң гына кызый аның йөзенә күтәрелеп карады:

— Бәлеш! Ибрай Гази дигән язучы түгелме соң сез?

— Шул инде шул: бер ай казый, ике ай казымый, — диде Ибраһим абый, һаман да шаяртып.

Кибеттән чыккач, ул миңа әйтте:

— Күрдеңме, кызлар мине шаярта, димәк, әле арбадан төшеп калган тукмак түгел мин, әйеме?

— Сез әле егетләр төсле, Ибраһим абый.

Кыяфәте аның чыннан да егетләр төсле. Гәүдәгә төз, куллары нык, урманда йөргәндә, берәр агач ботагы күрсә, сикереп ябыша да, турник-

та уйнаган төсле атына башлый иде. Тәмәке тартканын, аракы эчкәнен белмим мин аның. Чамадан тыш пөхтә иде ул. Кул юмыйча ашарга утырмый иде.

Бервакыт мин аңардан сорадым:

— Ибраһим абый, сезнең хакта бер мәзәк йөри. Имеш, сез базарда карбыз сатучыдан: «Бу карбызның суы кайнаганмы?» — дип сорагансыз. Дөресме шул хәл?

— И усал телләр этләшәләр инде! — диде ул, кул селтәп.

Санаторийдан ул матурланып, битләре алсуланып кайтты. Ул инде СССР Верховный Советы депутаты, партиянең XXIV съездына делегат булып сайланган иде.

Санаторийдан кайткач, без аның белән тагын бер мәртәбә очраштык. Минем ялга китәр вакыт житкән иде. Мин утыра торган бәләкәй бүлмәгә үзе килеп керде.

— Син бер атнага сабыр ит инде, Гариф, кайбер эшләрне ачыклап бетерик әле. Воронковка хат яздыңмы?

— Яздым. Менә җавабы да килде. Йөз мең акчаны быел бирә алмыйбыз, ике-өч елдан соң күз күрер, дигән.

Константин Васильевич Воронков — СССР Язучылар союзының оештыру эшләре буенча секретаре иде, бер йөз мең акча безгә язучыларга йорт салдыру, дөресрәге, берәрсе төзи торган йортка пайга керү өчен кирәк иде. Ибраһим абый җаваптан канәгать булмады. Шунда ук үзе утырып хат язды. Хат бик кыска, рәсми хатларга охшамаган иде:

«Иптәш Воронков! Хатыгызны алдык. Сез безгә йөз мең сумны туксан тугыз ел узганнан соң бирергә вәгъдә итәсез. Ләкин бит кызыл күкәй пасха көнендә кадерле».

Бер атнадан соң безгә шундый ук кыска язылган хат килде. «Это — недружелюбно» диелгән иде анда, әмма йөз мең сумның лимиты-ние белән, Татарстан Язучылар союзына күчерелүе әйтелгән иде.

— Минем Воронков белән күз бәйләш сукыр тәкә уйныйсым юк, акчаны җибәргәнме, шул җиткән безгә, — диде Ибраһим абый.

Бер башлагач әйтеп бетерим, рәсмилекнең, кәгазь волокитасының кан дошманы иде ул.

Әлмәттән Казанга күчкән чагында, миңа квартир бирми аптыраттылар. Дөресрәге, якыннан бирми теңкәгә тиделәр.

Ибраһим абый шәһәр Советына шалтырата, секретарь кыз, председатель өйдә юк, җыелышта, киңәшмәдә, тагын кайларда дип кенә җавап биреп тора. Ярый, хуш, андый җаваптан арыды Ибраһим абый.

— Нишлибез? — диде, гаҗиз калып.

— Горсоветка барыйк.

— Юк диләр бит.

— Әйтәләр генә, шунда ул.

— Киттек.

Барып кердек. Ибраһим абый, кабинет ягына ымлап:

— Андамы? — дип сорады.

— Анда,— диде секретарь кыз.

— Ә нигә сез әтиегез булырдай кешене алдап йөртәсез?

Кыз ык-мык килә башлады, кызарды.

Ул арада Ибраһим абый Бондаренко бүлмәсенә кереп тә китте. Мин дә иярдем.

— Исәнмесез. Квартир мәсьәләсендә килдек.

— Кемгә?

— Язучылар союзы секретарена.

— Танкодромнан рәхим итегез.

— Булмый. Ерак. Секретарь Язучылар союзына якын булырга, теләсә кайчан союзга килә алырлык, кунаклар каршылый алырлык булырга тиеш.

— Кайдан сорыйсыз?

— Новаторлар урамыннан. Тимер юлчылар больницасы янынннан. Бондаренко дәшмәде, Ибраһим абыйга каш астыннан карап утыра башлады.

— Сез, Александр Иванович, миңа каш астыннан карамагыз. Мин сезнең әбиегезне үтермәдем. Хәер сорашырга да килмәдек без сезгә. Тиешлесен сорарга килдек. Менә бу егетнең Әлмәттә бик яхшы квартиры бар иде. Без аны Казанга китердек. Сентябрьдә, тагын ун көннән, аның балалары мәктәптә укый башларга тиеш. Ярдәмчеләрегезгә боерык бирегез дә без киттек.

Александр Иванович ниндидер кәгазьгә шатырдатып кул куйды һәм мин бер атнадан семьямны Әлмәттән Казанга, яңа квартирга күчерә алдым.

Әнә шундый иде безнең Ибраһим абый. Һәм ул шундый туры сүзле, принципиаль кеше, таләпчән язучы булып күңелгә кереп калды.

Мин аның үземнән алда ялга чыгуына азактан сөендем. Югыйсә, үзем алдан китеп, ул ялсыз калса, гомерлек үкенеч булыр иде. Мин ялга чыгып, егерме көн узуга, аның кинәт, йөрәк авыруыннан үлгәнлеген хәбәр иттеләр.

Ул кылтаюны белми иде, урам йөргән чакларда гомеренең озак калмавын әйтүе дә, яшь чагында, көчле чагында яз, бернинди тинтерәтүләргә дә, ыгы-зыгыга да карама, актыктан эшләде дип әйтмәсләр, язмады дип кенә әйтерләр, дип киңәш бирүе дә ихлас булган, чын булган икән.

Хәзер мин үзем дә шул фикердә торам. Ыгы-зыгы күп дөньяда, гомер кыска, Толстой әйтмешли, язучы язарга тиеш.

## Чикләвек төше

Әгерҗедән алып кайткан кайнар дулкын дүрт-биш ай эчендә сүнде, сүрелде. Хисләрне кабат яңартырга, коймак пешерү өчен табаны кабат кыздырып алырга кирәк иде.

Янә дә Әгерҗегә киттем. Анда милиция капитанын эзләп таптым. Аның башлыгыннан рөхсәт сорап, капитанны өч көнгә үзем белән гостиницага чакырдым.

Без өч көн, өч төн йокламый диярлек сөйләштек. Ул сөйләде, мин яздым. Калын дәфтәргә мин аның тормыш юлын, уй-тойгыларын, сөйләшү рәвешен теркәдем. Җанда янә дә кайнар дулкын уянды, ашкынып язасы килә башлады. Әгерҗедә чакта ук повестьның «Чикләвек төше» дигән исеме дә табылды.

— Повестьны сиңа багышлыйммы? — дидем мин капитанга.

— Кирәкми, син бит аны барыбер мин сөйләгәнчә генә язмыйсың, язучылык фантазиясе белән өр-яңа дөнья тудырасың бит син, — диде капитан. — Ярый, хәерле юл сиңа, эшләрең уңышлы булсын.

Казанга кайтуга язу өстәленә беректем. Иртәнге алтыдан көндезге уникегә чаклы язам да, җиңелчә тамак ялгап, чаңгы белән Казанка буена чыгып китәм. Кайткач, ванна кереп, бер сәгать йоклыйм, көндезге икедән кичке сигезгә кадәр тагын язу өстәле янына чүмәшәм.

Повестьны мин тиз яздым, чын мәгънәсендә илһамланып, дөньямны онытып яздым.

Безнең, язучы халкының, беренче тәнкыйтьчеләре — машинисткалар.

Әгәр күңелләренә ошаса, алар син килеп керешкә:

— И әйбәт тә соң, малай! Кайлардан уйлап чыгардың моны?.. — дип сөенечләрен әйтергә ашыгалар.

Әсәр уртача булса, сүлпән генә:

— Ярый бу, ярый, — диләр.

Әгәр әсәр начар булса:

— И җаным, аңламадым әле мин моны, наданлыгым да көчледер инде, — дип үзләренә яла ягарга керешәләр.

«Әнә шул «аңламадым»ны гына әйтә күрмәсеннәр», — дип куркып килгән идем, мине көтеп зарыккан машинистка шелтә яудыра башлады:

— И Гариф абый, нигә шул тамаша елатырлык итеп яздың инде? Күзләрем кызарып бетте бит минә. Аерыла алмыйм, көне буе, төне буе бастым, — диде.

Бу — минем өчен иң югары бәя иде. Инде журналда чыгару мәсьәләсе. Редакторлар кабул күрерме, яратырмы, теләп бастырырмы?

Повестьта мин капма-каршы холыклы ике кеше алдым.

Берсе — коллективист, кешеләр өчен җанын бирергә әзер торган коммунист. Аның өчен алгы планда — илдәге тәртип, илнең иминлеге. Монысы герой, ә героиня — мещанка, аның өчен беренче планда үз рәхәте. Ике полюстагы көчләр тартышы.

Язу алымы итеп мин эпик сурәтләүне түгел, беренче заттан сөйләтү алымын сайладым. Гомер буе иреннән аерылырга теләгән, әмма аерыла алмаган хатынның вакыйгаларны үзе сөйләве, минем уемча, сюжетны тагын да кызыклырак итәргә тиеш иде.

Повестьны бастыру мәсьәләсен кайгыртып йөргән чакта, бая әйткәнемчә, Ибраһим абый кинәт үлеп китте, аның урынына Язучылар союзы председателе булып Зәки Нури сайланды. Ул «Казан утлары»ның баш редакторы иде, ул Язучылар союзына күчкәч, журнал хуҗасыз калды. Зәки Нури үзенең секретарена, ягъни миңа, «Казан утлары» өчен баш редактор табу бурычын йөкләде. Мин моның эчке мәгънәсен аңладым. Журналга ул минем күчүемне тели иде.

Партия өлкә комитетында да миңа шуны әйттеләр. Ә бу — минем яраткан эшем, мин бит анда Әлмәткә киткәнче биш елдан артык эшләдем.

Озакламый мине «Казан утлары»ның баш редакторы итеп билгеләделәр. Редколлегия членнары «Чикләвек төше»нә уңай бәя бирде һәм ул 1972 елның башында басылып чыкты.

Мин хәзер, каушап һәм дулкынланып, укучылар хөкемен көтә башладым. Минем чамасыз гаҗәпләнүемә каршы, иң беренче булып мине Фатих абый Хөсни котлады:

— Чукынчык малай, бик шәп повесть язгансың бит син, дивана, — диде ул миңа. — Котлыйм, энекәем, котлыйм, Гариф, төкле аягы белән булсын!

«Күңел алмак — бер калҗа, күңел калмак — бер калҗа», — дип юкка гына әйтмәгән, ахрысы, халык. Мин Фатих абыйга «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» өчен рәнҗеп йөргәннәремне шунда ук онытып, аны кочаклап үбәргә әзер идем.

Икенче хатны Свердловскидан бер татар хатыны язган, «тормышның барлык авырлыгы белән, ясамыйча-бизәмичә сурәтләгән өчен» рәхмәт белдергән. Өченче хатны Ташкенттан 81 яшьлек карт язып җибәрде. Хатының кыскача эчтәлеге болай: моңарчы ул Гомәр Бәшировны, Әмирхан Еникине, Фатих Хөснине язучы дип таныган. Ахунов дигән кешенең дөньяда яшәвен башына да китермәгән. Инде менә «Чикләвек төше» журналда басылган, укый башлаган, врачлар аңа бер сәгатьтән артык укырга кушмаганнар, ә ул төне буе укыган һәм Ахунов дигән язучы барлыгын да таныган.

1973 елның февраль башында минем сабакташым Нурихан Фәттах әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта, Габдулла Тукай клубында, чикләвекнең төше бик сыек әле, мактарга ашыкмыйк, дип йөз илле язучы җыелган залга кычкырып әйтте.

Шуның артыннан ук Мостай Кәримнән хат килеп төште. Ул мине

ихлас күңелдән иҗат уңышым белән котлаган, син яңа повесть язып кына калмагансың, яңача повесть язгансың, дигән иде.

Котлау белән тиргәү әнә шулай аралашып торды.

Язучылар союзы кушуы буенча «Волга» журналына повестьның подстрочнигын (сүзгә сүз тәрҗемәсен) җибәргән идек, әсәр басарлык түгел дип борып кайтардылар. Әдәби әсәрне аңламый торган кеше түгел, бик нечкә зәвыклы художник, «Боланнар илендә» романының авторы Николай Шундик шулай дип язган иде.

Бу мине беркадәр гаҗәпләндерде, ләкин каушатмады. Яңа әсәр беркайчан да тапталган юлдан бармый, аның эчке мәгънәсен, сәнгатьчәлеген аңлаганчы һәм башкаларга аңлатып биргәнче, байтак вакыт уза, аңларлар әле дип юаттым мин үземне.

Әмма күп тә узмый, журнал редакциясенә бер мәкалә керде, мәкаләнең авторы, минем сабакташым, күренекле тәнкыйтьче, «Чикләвек төше»н урланган әсәр дип язган. Моңа мисал итеп, А. Макаренконың «Педагогик поэма»сындагы баш геройның сукбай малайны тотып яңаклавы белән минем колхоз председателе Халик Саматовның «практичный» Мөбәрәкшәне баскычтан тибеп төшерүен параллель китергән иде. Бу гаепләүдә бернинди логика да юк, әлбәттә. Педагог сукбай малайга, балалар колониясендә тәрбияләнүчегә, соңгы чиккә җиткәч, шашынган нервысын тыя алмыйча суга, ә минем Саматов үзенә лом белән ташланган карак крестьяннан саклану өчен аңа тибеп җибәрә. Хөрмәтле галим моны белә, әмма ул авторның ачуын китерер өчен юрамалый, гаделсез рәвештә аны плагиатлыкта гаепли.

Мәкаләне укыганда, мин бер нәрсәне аермачык күз алдына китердем. «Менә син — баш редактор, синең әсәреңне иң яман чирдә гаеплиләр, беләм — син моны уздырмыйсың, ә менә үз кулларың белән минем мәкаләне сызып утыру синең җаныңны таласын әле», — дип кулларын уа тәнкыйтьче.

Ә мин мәкаләнең бер юлына, хәтта бер хәрефенә дә кагылмадым. «Басарга!» — дип кул куйдым да типографиягә озаттым.

Хәтта үзебезнең редакция егетләре дә, түзмичә, мине үгетләргә кереп карадылар, якын да килмәдем — бар нәрсәне тәнкыйтьченең үз намусына калдырдым.

Мәкалә басылып чыкты.

Нәкъ шул дәвердә минем «Чикләвек төше» повесте белән «Хәзинә» романына Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирү хакында газеталарда партия өлкә комитетының һәм Министрлар Советының карары басылды.

Иртәгесен минем янга әлеге тәнкыйтьче, сабакташым керде. Чыраенда сөенеч юк иде шикелле. Ул ничектер ифрат та уңайсызланып:

— Сине котларга минем хакым юк, әлбәттә, — дип башлады сүзен. — Шулай да мин сине котлыйм. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегеннән беренче лауреат булуың белән котлыйм...

Әсәрләргә бәя бирүдә гадел булмасаң, әнә шулай әйләнгеч юллар белән котларга да мәҗбүр буласың икән....

Мин бу гыйбрәтле хәлне ни өчен сөйләдем?

**Беренчесе.** Әсәрләребезгә ашык-пошык бирелгән бәяләрдән беренче нәүбәттә без, әдипләр үзебез, каушап калмаска тиешбез. Китапларыбызның беренче тәнкыйтьчесе, контролеры безнең намусыбыз булырга тиеш.

**Икенчесе.** Әдәбиятка бәя бирү кебек гаять җаваплы вазифаны өсләренә алган кешеләр, ягъни әдәби тәнкыйтьчеләр, кристаллдай саф күңелле, чамадан тыш намуслы булырга, әдәбиятта үзләрен түгел, әсәрләрне яратырга тиешләр.

Шул чакта, бары тик шул чакта гына тәнкыйтьче әдәбиятның үсешенә йогынты ясый ала.

# ЯЗМЫШЛАР КУШЫЛГАНДА



## Чакыру

1978 елның беренче декабре көнне Зур Кремль сараеннан ашкынып чыгып барган халык арасында Чыңгыз Айтматовны очраттым. Баһадир гәүдә, ташып торган куе кара чәч. Кырысрак чырай. Әйе, чырае аның һигәдер гел уйчан — рәсемдә дә, тормышта да. Әллә ничә мәртәбә уйлаганым бар: нигә уйчан икән аның чырае? Бик яшьли ул этисез калган, сугышка кадәрле үк һәлак булган аның әтисе, обком секретаре. Әллә шул ятимлек аның чыраена кырыслык, үз эченә бикләнгәнлек салып калдырганмы? Алай дисәң, аннан соң да кырык елдан артык вакыт узып киткән бит инде. Чыңгыз үзе әти кеше хәзер, ике малай атасы, язганнары буенча фикер йөртсәң, ил агасы булып килә. Әллә аны үз уйларына күмелеп йөрергә шул мәҗбүр итәме? Ни генә булмасын, Айтматов гел җитди — кырыс чырайлы. Без аның белән язучылар җыелышында, СССР Верховный Советы сессияләрендә, Тышкы эшләр комиссиясендә әледән-әле очрашып торабыз. Очрашканда сизелер-сизелмәс кенә яктырып китәр, бер-ике сүз белән генә хәл-әхвәлеңне сорашыр, аннары тагын үз эченә бикләнер...

Бу юлы ул минем янга кояш кебек балкып килде. Мин, аңардагы үзгәрешне ни дип юрарга да белмичә, аптырабрак калдым. Аның иреннәре калын икән ләбаса, өстәвенә алар елмая беләләр икән: гаҗәеп бер җылы — бераз гына серле дә дип әйтимме — елмаю куна икән аларга. Күзләре аның коңгырт, һәм шул коңгырт күзләр кап-кара җәенке каш астыннан нурланып-чаткыланып кабына беләләр икән; шушы елмаюлы күзләргә, елмаюлы иреннәргә кушылып, аның зур таза борыны да гомуми тәэсир белән яши, — кыскасы, минем каршымда кырыс чырайлы Чыңгыз түгел, ягымлы чырайлы Чыңгыз басып тора! Мин аның күкрәгендә СССР Верховный Советы значогы белән янәшә җемелдәп балкыган Алтын Йолдыз медален күрдем. Беренче мәртәбә!

— Татарстан язучылары исеменнән безнең котлауны кабул ит, Чыңгыз! — дим мин.

— Котлауларыгызны алдым, Гарифҗан, — ди Чыңгыз, минем кулны җибәрмичә, зур авыр кулында тотып тора. — Рәхмәт, Татарстаннан килгән котлау минем өчен бик тә кадерле. Карале, юлдашым, 12 декабрьда минем юбилей бит. Телеграмм ебәреш кирәк. Киләсеңме?

Мин бер генә мизгелгә икеләнеп калам. 12 декабрь, нәкъ менә уникенче декабрь көнне Казанда иҗат союзларының берләштерелгән пленумы. Мин анда доклад ясарга тиешмен. Шулай булгач, юбилейга барам дип вәгъдә биреп буламыни? Ләкин бу минем дә, Чыңгызның да гомерендә бер генә килә торган бәйрәм. Бармыйм дип әйтү белән мин аның кәефен кырып салам бит. Чыңгыз мине Гариф Ахунов дигән язучы итеп кенә түгел, Татарстан язучыларының тулы вәкаләтле бер илчесе итеп, аның әнисе — татар хатыны Нәгыймә апаның да кан кардәше итеп чакыра бит. Мин башны кискен генә чайкап алам да:

— Ярый, Чыңгыз, килермен, — дим.

Аның миңа төбәлеп уйчанлана башлаган чыраена яктылык иңә, калын йомшак иреннәре елмая, күзләре чаткыланып нур бөрки. Мин калган ягын төпченеп-сорашып торырга теләмим. Без кул кысышып аерылабыз.

Шул сәгатьтән башлап мин Чыңгыз бәйрәменә бару уе белән яшим. Ничек итеп мин аның юбилеена өлгерәм соң әле? Әйтик, 12 декабрьда иртәнге сәгать уннар тирәсендә докладны ясасам, биш-алты кеше чыгып сөйләгәннән соң, уникеләр тирәсендә самолет белән Фрунзега очып китә алсам, бәлки кичкә кадәр барып та җитәрмен... Ләкин... Фрунзега бездән, ягъни Казаннан турыга оча торган самолет бармы?

Белештем. Турыга оча торган самолет юк икән.

Минем барулар шулай итеп киселер микәнни? Мондый чакта, үзегез беләсез, иҗат җене кагылган кешенең фантазиясе әллә кайларга, тау түбәләренә менеп җитә торган була.

Чыңгызның миңа түгел, халкыбызга булган үпкәсен шундый да зур итеп күз алдыма китердем, әллә кайчангы очрашулар, күрешүләр, Чыңгызның «Җәмилә»сендәге, «Хуш, Гөлсарат»ындагы, «Беренче мөгаллим»ендәге каһарманнарның үпкәләп йөрүләре хыялымнан уза башлады. Ул да түгел, моннан биш-алты еллар элек, Чыңгыз Айтматовның кыргыз язучылары делегациясе белән Казанга, әдәби атналыкка килгән чаклары, хатыны Кәрәз белән бергәләп, татар язучылары алдына басып, бик моңсу кыяфәттә әйткән сүзләре искә төште:

— Кадерле туганнар, татар кардәшләрем, миңа әнием Нәгыймә әйтте: «Улым Чыңгыз, мин авыруым сәбәпле туган якларыма кайта алмадым, туган туфрагыма баш ора алмадым, минем өчен син кайт, син минем Иделләремне, Казаннарымны күреп кил, минем туган туфрагыма баш орып кил...» — диде. Мин аңа биргән вәгъдәмне үтәп, сезнең якларга, мине дөньяга яраткан әнием җиренә, «анам кырына» кайттым. Сез, татар язучылары, минем әсәрләремне әниемнең телендә халыкка җиткердегез, сезгә шуның өчен җиргә тикле башымны иеп, иң зур рәхмәт тойгыларымны белдерәм.

Әнә шулай дигән иде Терекол улы Чыңгыз! Беркайчан да алдашмаган, алдаша да белми торган, зур хакыйкатьне гади һәм ихлас итеп әйтеп бирә белә торган ир-егетнең сүзләре халыкта һәм язучыларда аңа карата ихтирам хисе уяткан иде. Инде хәзер аның бәйрәменә, үзе өзелеп чакырып торганда, гомерлек кырыс чыраена таң яктысыдай елмаю балкытып әйтеп биргән чакта, бармый калыргамыни?!

Бәйрәмнәргә катнашу мәсьәләсендә минем әле беркайчан да болай аптырашта калганым юк иде.

Мин, бердән, иҗат союзларының пленумына доклад язу мәшәкате белән йөрсәм, икенчедән, Чыңгыз бәйрәменә бара алырлык кеше эзләп баш вата башладым. Яшьләр, әлбәттә, анда бара алыр иде, әмма аларны Чыңгыз үзе ничек кабул итәр?! Картлар, аксакаллар, алар белән эш кыенрак шул: юл йөрүләр аларны бик авырыксындыра шикелле. Ә монда, — аз да түгел, күп тә түгел, — барып кайтуы җиде мең чакрым.

Фрунзега барырга ашкынып торучы табылмады, бар өмет җимерелеп төште. Мин уникенче декабрьда булачак пленумга доклад язарга утырдым. Иҗат кешесенең бер бәхетле ягы бар — язарга утырдымы, аның күзенә ак-кара күренми, аның шул үзе яза торган әсәреннән башка дөньяда берни дә калмый. Әйе, бу шулай. Бу шулай бер кайда да эшләмәгән ирекле художник өчен. Минем кебек Язучылар союзында эшләгән кешене теләсә кайчан, теләсә кая чакырып алулары ихтимал. Чынында ул шулай булып чыкты да. Мине СССР Язучылар союзының үзбәк әдәбиятын тикшерүгә багышланган пленумына чакырып алдылар. Ул жиденче декабрьда булырга тиеш, без анда — Зәки Нури белән икәү — алтынчы декабрьда ук барып җитәргә, өстәвенә мин үзбәк әдәбияты хакында сүз сөйләргә тиеш булып чыктым. Хәер, сүз сөйләү мәсьәләсендә мин әллә ни кайгырмадым, ник дисәң, үзбәк әдәбиятын тикшерәчәкләре миңа октябрьда ук билгеле иде, СССР Язучылар союзы секретаре тәнкыйтьче Юрий Иванович Суровцев минем чыгыш ясавымны Казанда уздырылган бөтенсоюз конференциясе вакытында ук

бик үтенеп сорап киткән иде. Минем турыдан-туры үзбәкчәне укый алуым аңа ошый, ул моны үзбәк дуслар да яратыр дип уйлый иде. Мин Нәзир Сәфәровның «Кайгылы һәм каргышлы көн» повестен, Әсгать Мохтарның «Чинар» романын татарча басылганыннан, Шәраф Рәшидов романнарын русча һәм татарчадан, шуның өстәвенә Үткер Хашимовның «Яктылык һәм күләгә», Мирмухсинның «Чаткал юлбарысы» романнарын «Шәрыкъ йолдызы» журналыннан үзбәкчә укып чыккан идем. Үзебезнең пленумда булачак докладны хәзергә төреп куеп, мин үзбәк әдәбиятына чумдым. Үзбәк әдәбияты — борынгы гасырлардан ук килгән Алишер Нәваиләры, бүгенге заманның Гафур Голәмнәре булган зур әдәбият. Тик гаҗәп хәл; бүгенге прозаларында мин аларның озын-озакка сузып сөйләү-аңлату алымы күрдем. Иң матур милли характерлар, заман билгеләре әнә шул озынга сузу, төссез итеп сөйләү аркасында тоныкланып калалар иде.

Мин моны җайлап кына, үзбәк прозаикларының барлык уңай сыйфатларын әйтеп бетергәннән соң гына әйтергә тиешмен.

Үзбәк әдәбияты турындагы зур сөйләшүгә әзерләнү, беренче карашка, Чыңгыз Айтматов бәйрәменә киртә булып төшә кебек тоела иде, ләкин, чынлабрак уйлагач, мин аның үзем өчен файдалы икәнен аңладым. Ул миңа Чыңгыз иҗатын тагын бер мәртәбә акыл җәтмәсеннән үткәреп, башка әдәбиятлар белән чагыштырып карарга мөмкинлек бирде. Мин Айтматовның кыска-җыйнак повестьларында безнең күбебезгә җитмәгән камиллекне, сәнгатьчә төгәллекне күрдем. Мәскәүдә мин үзбәк язучылары белән, таҗик, кыргыз, казакъ, төрекмән һәм тагын башка байтак әдәбиятның вәкилләре белән кара-каршы утырып сөйләштем, алар миңа чыгышымны әзерләп бетерергә, төпле бер фикергә килергә ярдәм иттеләр.

Шундый зур ярдәмне миңа бик тә акыллы, балаларча шат күңелле язучы, күптәнге дустым, казакъ язучыларының җитәкчесе Әнуәр Алимҗанов эшләде. Ул казакъларда соңгы ун ел эчендә бер дистәгә якын гаять талантлы, заманча тыгыз яза белән торган язучы тууын әйтте. Саин Муратбеков, Абиш Кекильбаев, Сатимҗан Санбаев шундыйларга керә икән. Мин моңа шунда ук ышандым, чөнки татарчага тәрҗемә итеп чыгарырга әзерләгән бер томлыкта «Хатынгол балладасы», «Ак дөя» кебек повестьларның бай эчтәлеккә һәм эмоциональ көчкә ия икәнлекләрен күргән идем. Бу очраклы гына хәлме, әллә алардагы проза үсеше законлы күренешме, дип уйлана да башлаган идем. Димәк, законлы күренеш. Бу миндә үзебезнең татар прозасы өчен борчылу, гамьсез йөрүебезгә беркадәр үкенү хисе дә уятты.

Хисләр минем бик кайнарланган, уйлар башка сыймастай булып тыгызлана башлаган иде ул көнне, мин аларның барысын ак кәгазьгә чәчеп ташладым. Иртәгесен пленумда сөйләячәк сүземне милли әдәбиятларыбыз алдында торган бурычларыбыз итеп күз алдына китердем, озын-озак сөйләүләрдән арынырга, сәнгатьчә төгәл сурәтләп бирә белү осталыгына омтылырга кирәк безгә. Шулар янына күптәннән җанымны борчып торган бер мәсьәләне көн тәртибенә кичектергесез бурыч итеп куйдым. Анысы — әдәби тәрҗемә, СССР Язучылар союзы дәүләт күләменә күтәрергә тиешле мөһим мәсьәлә. Юкса нәрсә килеп чыга? Кем терсәкне киереп, этешә-төртешә алга чыга — шуның әсәре басыла. Чын талант иясе үз әсәрен бастырырга бик ашкынып тормый бит ул, нәшриятлар тирәсендә буталуны вакыт уздыру дип карый. Шунлыктан, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләр ил күләмендә яңгырый алмый, бөтенсоюз укучысына барып җитә алмый аптырыйлар.

Пленумда миңа, һич көтмәгәндә, икенче итеп сүз бирделәр. Моның сере бераздан аңлашылды. Мин Мәскәүдә Язучылар союзы пленумында йөргән арада өйгә СССР Верховный Советыннан телеграмма килеп төшкән: мин Тышкы эшләр комиссиясендә чыгыш ясарга тиеш икән-

мен. Ул хакта Язучылар союзына да хәбәр иткәннәр. Димәк, минем бүгенге пленумда мөмкин хәтле тизрәк сөйләвем хәерле. Беренчедән, озаклап, зарыгып көтеп утырасы булмаганга, икенчедән, язган уй-тойгыларым әле күңелдә кайнар килеш саклангачга күрә, мин сүземне дәртләнеп сөйләдем.

Язучыларга бик тә хәерхаһ секретарь Юрий Верченко мине шундук Кремльгә озатып җибәрде.

СССР Верховный Советына, секретариатка кереп, чыгыш ясар өчен кирәкле материалларны алдым. Чит ил багланышлары бүлегендә эшләүче Гурьянов, озын буйлы, якты чырайлы, иллеләрне узган абзый, минем алдыма материалларны китереп куйды, биш минутлык чыгыш әзерләгез, әзерләнү өчен бер сәгать вакыт бирелә, диде. Үземә кирәген сайлап, СССР—Вьетнам дуслыгын, хезмәттәшлеген хуплап, телмәр (речь) яздым. Александр Константиновичка күрсәттем. Булган бу, диде, тик Договорны ратификацияләү тәкъдимен дә сез кертерсез, диде. Килешеп кайтып киттем.

Утырышта миңа, Тышкы эшләр министры урынбасарының докладыннан соң, иң беренче итеп сүз бирделәр. КПСС Үзәк Комитеты секретаре һәм Политбюро члены Михаил Андреевич Суслов алып барган киңәшмәдә сүз сөйләү җаваплы, дулкынландыргыч иде. Мин киңәшмә башлану белән: «договор» дип, басымны беренче иҗеккә төшерергәме, әллә икенче иҗеккә куеп әйтү дөрес булырмы, дип икеләнә башладым. Министр урынбасары беренче иҗеккә төшереп сөйләгәч, мин дә шул беренче иҗек вариантына тукталырга булдым. Тик дөресе — соңгы иҗеккә төшерү икән, миннән соң барысы да шулай сөйләделәр. Бу минем күңелемдә бәләкәй генә уңайсызлану тудырып алды, тик, бәхеткә каршы, уңайсызлану тиз узды. Чөнки киңәшмәдән таралган чакта минем белән бергә чыккан язучылар Георгий Марков белән Камил Яшен минем комиссиядә беренче булып чыгыш ясавымны яхшыга юрадылар, сиңа ышаныч белдерелде, диделәр.

Бу миңа азмы-күпме тынычлык китерде, әмма икенче зуррак тынычлык китергәне, алай гына да түгел, юаныч һәм шатлык китергәне, ике язучының икесенең берьюлы язучылар пленумындагы чыгышымны хуплаулары булды.

— Җөдә зур рәхмәт сиңа, Арыпҗан, үзбәк әдәбияты турында укып-белеп сөйләдең! — диде Камил ага Яшен. — Бу минем фикерем генә түгел, барлык иптәшләр, үзбәк язучыларының фикере, алар сиңа рәхмәт әйтергә куштылар.

— Әйе, дөрес, әйбәт сөйләдегез, — диде Георгий Мокеевич Марков. — Ышандыргыч итеп, белеп сөйләвегез, зур проблема күтәрүегез белән сез пленумга тон бирдегез... — Ул беркавым дәшми барды. Без Кремль ишегалдыннан атлый идек. Бераздан ул тукталды, минем җилкәмә дусларча кул салып: — Менә, нәрсә, Гариф Ахунович, мин хәзер эш белән бу якка китәм. Ләкин аерылыр алдыннан әйтеп каласым килә: мин татар әдипләрен, татар әдәбиятын бик яратам. Сезнең әдәбият беркайчан да ташлама сорамый. Байтак язучыларыгыз белән бергә фронтта булдым. Сезнең пленумда берәүгә дә ярарга тырышмавыгыз, яхшыны яхшы, начарны начар дип әйтүегез татар әдәбиятының әле һаман да җитди зур юлда икәнен әйтеп тора.

Миңа кинәт кыюлык кереп китте.

— Гафу итегез, Георгий Мокеевич, минем дә сездән сорыйсы бер сүзем бар иде, мөмкинме? — дидем.

— Сорагыз, — диде Марков, гади генә итеп. Мин аның тавышында ягымлылык барын сиздем.

— Сез, Георгий Мокеевич, әле әдәби атналыкта, әле пленумда, әле чит илдә... Язу эшенә ничек вакыт табасыз?

— Вакыт юк, — диде Марков кинәт. — Изеп куйган романым кабарып утыра, кәгазьләргә кагыла башласам, үзәкләр өзелеп китә. Юк

вакыт, юк! Михаил Андреевич Суслов өч кенә елга дип Себердән, Иркутскидан чакыртып алган иде, инде менә Язучылар союзы йөген егерме өч ел буе тартам, әле һаман чиге күренми. Ә сезнең хәлләр ничек?

— Мин дә Язучылар союзы системасында 28 ел эшлим. Киләсе елга язучылар съезды, китәргә исәп. Трилогиямне тәмамларга кирәк.

Марков кискен генә баш чайкады, түгәрәк тыныч йөзе үзгәреп китте.

— Белмә-ә-әәм. Коллективка намуслы, булдыклы оештыручылар кирәк. Рәхәтләнеп өйдә генә язып утыру тәтер микән сезгә? Белмә-ә-әәм, — диде тагын бер тапкыр...

Аңардан аерылгач, минем күңелгә кинәт бер уй килде. Әгәр мин иҗат союзлары пленумына докладны язып кына бирсәм? Минем өчен аны икенче бер кеше укыса? Ул чагында мин бит Айтматов бәйрәменә үзем бара алам. Билләһи, яңалык бу, тупиктан чыгу юлы.

Була менә шундый вакытлар: күңел гел ашкынып, ярсынып тора башлый. Күңел кушканны эшләмәсәң, башка барлык эшләрен җимерелеп төшәр сыман тоела. Мин Фрунзега барырга, җитәкче иптәшләрне шуңа күндерергә дигән ныклы карарга килдем.

Ләкин миңа берәүне дә күндереп йөрергә туры килмәде. Иҗат союзларының берләштерелгән пленумына доклад язып утырган чакта, Фрунзедан икенче бер телеграмма килеп төште. Анда акка кара белән: Чыңгыз Айтматовның илле еллыгы уникенче декабрьдан унөченче декабрьга күчерелә, диелгән иде.

Булды болай булгач. Аэропорт кассасына барып, аннан Ташкент аша Фрунзега билет алып кайттым. Ташкентка кичке самолет сәгать тугызда, аэропорт кагыйдәләре белән әйтсәк, 21 сәгатьтә оча. Димәк, мин җыелыштан соң тыныч кына очып китәм дә, 13 декабрь көнне Фрунзега барып җитә алам. Һавалар аяз булсын да самолеты гына вакытында оча күрсен.

Докладны мин тәмам тынычланып, Фрунзега үзем барырга күңелемне беркетеп, иркенләп яздым.

## Уйлар

...Адәм баласы туа, үсә, балигъ була. Шул дәвердә ул укый, профессиональ күнекмәләр ала, аягына нык басып торырга өйрәнә. Әнә шуннан соң аңа җәмгыять вазифалар йөкли. Кешенең кешелек дәрәҗәсен үлчи торган беренче вазифасы — аның хезмәткә һәм үзе эшләгән коллективка мөнәсәбәте.

Болар безгә дә, иҗат кешеләренә дә кагыла.

Безнең иҗат эшебезне алга әйди, безне дулкынландырып яшәтә торган гаҗәеп бер тойгы бар: роман тәмамлагач, картина язгач, симфоник музыка иҗат иткәч яки республикабыз башкаласын гасырлар буе бизәп торырга яраклы җәмәгать бинасының архитектура проектын сызгач, сәхнәдә меңләгән кешене җәлеп итәрлек характер тудыргач, иҗат кешесе хезмәтенең нәтиҗәсе белән горурлана, аның кешеләргә файда китерәчәген аңлап, күңеленә рәхәтлек таба.

Сүз остасы булу, заманның тәртипсез авазлары эченнән иң кирәкләләрен сайлап алып, дулкынландыргыч ритм тудыру, полотнода таң калып торырлык кеше сурәтен ясау — болар барысы бәхет. Бәхет, чөнки иҗат кешесенә табигать аерым сәләт биргән. Кеше җанындагы тибрәнеш-үзгәрешләрне ул барлык кешедән дә алдарак күреп ала, халыкның мең еллар буена җыелган рухи хәзинәсен үз күңеле аша үткәреп, алмазны шомартып бриллиант ясаган кебек, янә дә халыкның үзенә кайтарып бирә. Әнә шундый сәләте булган кешене халык бәхетле кеше, ди. Китаплар укый-укый каләм йөртергә, пумала белән буйый-буйый ниндидер сурәт китереп чыгарырга, сәхнәдән автор сүзен ятлап кычкырып кына йөрергә өйрәнгән кешеләрне халык бәхетле

кеше дими, кәсепче, ди, үз рәхәте хакына сәнгать белән сату-алу итүче, ди. Кызганычка каршы, бездә әле андый кәсепчеләр дә бар, алар барлык талант иялəренə караганда да күбрәк кычкыралар, әдәбият-сәнгать мәйданында үзләренә урын даулыйлар, алар җил кай яктан иссә, шул тарафка борылырга әзер торалар. Аларның сәнгатькә гомерне багышлау, соңгы сулышларына кадәр сәнгать камиллеген эзләү кебек тойгылары юк, булачак та түгел. Мондый кешеләрнең әдәбият һәм сәнгать өчен иң куркыныч кешеләр икәнен 1963 елны, Әлмәттә Язучылар союзы бүлеге ачкан чакта, атаклы рус язучысы, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе Леонид Сергеевич Соболев әйткән иде миңа. Әдәбият тирәсенә сырышкан әрсез эшкуарларны берүк союзга член итеп ала күрмәгез, алар берләшәләр, талантлы кешеләргә каршы көрәшеп, аларны кысрыклап чыгару җаен эзли башлыйлар, дигән иде.

...Әдәбиятта ике дистә елдан артык эшләү дәверемдә мин бер нәрсәгә ачык төшендем: халык героизмын, ил язмышын сурәтләүдән дә отышлырак бер ни дә юк. Мин бик җылы язылган хикәяләрне, лирик повестьларны беләм, әмма алган темалары вак булу, сай булу сәбәпле алар онытылдылар, алар халык хәтереннән төшеп калдылар. Ил язмышының киеренке дәверләрен сурәтләгән әсәрләр яши. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» яши, Фатих Кәримнең окопларда мылтык түтәсенә куеп язган, ут сулап торган җырлары яши, сугыштан соңгы чорда Татарстаннан Европага җылылык трассасы сузган тол хатын Халидә яши; ил хуҗалыгын аякка бастыру елларында, вулкан кебек кабынып китеп, берничә ел эчендә биш-алты поэма яза алган Әнвәр Давыдов иҗаты яши. Тик бу талантлы әсәрләр тирәсенә алга таба тәнкыйтьчеләребез игътибарны күбрәк тупларга, әдәби хуҗалыкны ефәк иләк аша үткәзеп, аларның зурысын, көчлесен, ил язмышына лаеклысын алгарак чыгарып куярга тиешләрдер дип беләм.

Рухи байлыкларыбыз, сәнгать хәзинәләребез үссен дисәк, аның киләчәге турында, аның магистраль юллары турында, аның проблемалары турында өзлексез уйларга, кайгыртып торырга кирәк икән.

Мин әнә шундый уйлар белән безнең гасырның акыл иясе һәм каләм остасы Чыңгыз Айтматов юбилеена юнәлдем.

## Фрунзе каласында

Самолет безне Казаннан кичке тугызда алып чыгып китте, төнге бердә Ташкентка илтеп җиткерде. Без киткәндә, Казанда температура 20 градус суык булса, Ташкентта 15 градус җылы иде. Болар берсе дә мине борчымады, мин озак еллар юл йөргән гадәтем буенча, салкынга да, җылыга да яраклык итеп киенгән идем. Мине борчыган нәрсә, әлеге дә баягы, шул: мин Чыңгыз бәйрәменә өлгерә аламмы, юкмы? Өлгерә алмасам, минем меңнәрчә чакрым араны самолетта очып йөрүләрем бушка гына булып чыга ич.

Депутатлар бүлмәсендә миңа: самолет Фрунзега көндезге унда гына оча, без сезне шул вакытка гына утыртып җибәрә алабыз, диделәр.

— Юлда күпме оча? — дидем мин ашыгып.

— Бер сәгать тә унбиш минут.

— Шуннан да алдарак самолет юкмы?

— Тугызда бар. Ләкин аның оча алуына ышаныч бик аз. Кечкенә самолет ул. Очмый калуы да ихтимал.

Мин күңелдән исәпләп чыгардым: әгәр дә самолет, әйтик, әзерлекләре-ниләре белән сәгать ярым очса, мин уникенче яртыда Фрунзеда булам. Анда Мәскәү вакыты белән нәкъ өч сәгать аерма. Димәк, мин

өченче яртыда гына булам әле Фрунзе аэропортында. Тантаналы җыелыш кичке биштә башлана. Аэропорттан бер сәгать шәһәргә барасы булса, минем карамакта сәгать ярымнар вакыт кала. Нибарысы! Әә бит әле самолетның очуын кичектерүләре мөмкин, ә бит әле минем Язучылар союзына барасым, кунак йортын эзләп табасым, урнашасым, өс-башны алыштырасым бар. Тагын борчу билән алды. Шушы хәлемдә мин тугыз сәгать буе депутатлар бүлмәсендә утырып тора алмыйм бит инде. Самолетта черем иткәләп алуны исәпләмәгәндә, мин әле бөтенләй диярлек йокламаган. Йокламаган килеш сүз сөйләүләре — айһай! Беренче эш итеп, аэропортның кунак йортына керергә рөхсәт язуы алдым. Икенче эш итеп номерга килдем дә шундук ятып йокладым. Теләсә нинди шартларда, теләсә кайсы вакытта мин үземне йоклап китәргә күнектергән идем. Журналистлар һәм язучылар өчен мин андый күнекмәләрне ифрат дәрәҗәдә кирәк дип саныйм. Ул безнен эше гасабилы халыкның эшләү сәләтен бик арттыра. Эштән бүленеп унбиш минут черем итеп алырга җай чыга икән, аны да эшләргә кирәк. Моңа мине укытучы Гази ага Кашшаф өйрәтте.

Сигезләр тирәсендә мине уята күрегез дип дежурный абыстайны кисәтеп куйган идем, ул да әйбәт булып чыкты. Самолетка кадәр юынып-киенеп, тамак ялгап алырга өлгердем. Ташкент аэропортында иртәнге сәгатьләрдә үк кайнар аш булу, җиләк-җимеш күп булу мине сөендерде.

Самолетка мине депутатлар бүлмәсеннән ярты сәгать алдан чыгарып утырттылар. Самолетның экипажы — озын буйлы, шәрык кешеләренә хас кинчәрәк битле, кояшта тигез булып янган каракучкыл чырайлы кыргыз егетләре — Фрунзедан булып чыктылар. Монысы да сөенечле хәл, ник дисәң, адәм баласы үз өенә дәртләнебрәк кайта. Шәт, вакытында барып җитәрбез...

Стюардесса, үзбәк кызы, унсигез яшьләрендәге, дөньяның бер чибәре, кашлары чем-кара булып сызылып киткәне һәм борын турысына килеп кушылганы — пассажирлар утыра башлаганчы ярты сәгать вакыт булудан файдаланып, минем яндагы утыргычта утырып горды, кайдан килүемне, Фрунзега ник баруымны сораштырды. Мин яшереп-нитеп тормастан: Чыңгыз Айтматов бәйрәменә барам, дидем. Кызның шомырт кара күзләре зуррак ачылды, шоколад төсле булып кояшта янган хәтфәдәй йомшак битенә елмаю кунды, ул үзалдына сөйләнгәндәй: «Бар дөньяда бәхетле кешеләр!» — дип әйтеп куйды. Мин аның тал чыбыгыдай нәфис буй-сынына, бик тә килешле зәңгәр аэрофлот киеменә, җиңенә һәм беретына кунган очкыч сурәтенә үз итеп, яратып карадым, шушы заманча киемнәрне аның заманча булмаган калын кара чәч толымнары бизәп, калку күкрәкләре өстендә ятып тора иде.

Чыңгыз Айтматов турында башланган сүз безнең күңелләрне бергә бәйләде. Эшчеләр гаиләсендә туып-үскән Зөлфия (мин аның исемен атаклы үзбәк шагыйрәсе Зөлфиядән исемдә калдырдым) — кечкенәдән үк эш ярата торган булып үскән, самолетта көннәр, атналар, айлар буе кеше озатып йөрү аның өчен рәхәт бер эш икән.

Моның коры сүз генә түгел икәненә мин үз күзем белән күреп ышандым. Халыкны самолетка ул бернинди этеш-төртешсез, шау-шусыз, дәгъва-мазарсыз утыртты, һәркайсына үзенчә ягымлы сүз таба белде, җайлады, көйләде. Мин боларны күңелемә беркеттем, безнен профессиядәге кешеләр өчен андый детальләр ифрат кирәк.

Салонда тынлык урнашкач, Зөлфия сеңлебез пассажирларны котлады, экипажның кемнәрдән гыйбарәт икәнен әйтте һәм без, җирдән аерылып, Фрунзе ягына очып киттек.

Гаҗәеп нәрсә бу кеше мөнәсәбәте! Эшче гаиләсеннән чыккан унсигез яшьлек кызый, әти-әнисе аңарда тәрбияләгән күңел матурлыгы аркасында, үзе беренче мәртәбә очраткан кешеләрне җылытып, бергә

укмаштырып, бөтен бер коллектив итеп Фрунзега алып бара.

Мин Зөлфиянең әдәби образын күңелемдә зуррак итеп ясый башлаган идем инде, шуңа күрә ни өчен юлга чыкканымны да, самолетта барганымны да онытып җибәргән идем. Стюардесса яңгыравыклы яшь тавышы белән Кыргызстанның башкаласы Фрунзены мактый башлагач, айнып киткәндәй булдым.

...Фрунзе башта Пишпет исемле булган, аның төзелүенә йөз ел икән. Менә бит, меңәр еллык тарихлары белән горурланган Кавказ калалары янында йөз яшьлек калалар да бар икән әле! Халкы инде ярты миллионны узып киткән. Әнә шул ярты миллионлы яшь калада, Кыргызстанның данлы әдибе Айтматов яши.

Самолет җай гына төшеп утырды, туктады: кешеләр берсе бер өтәләнмичә, Зөлфия туташның әмеренә буйсынып, самолеттан чыктылар, аңа ягымлы сүзләрен әйтеп, исәнлек-саулык теләп аерылдылар.

Җиргә төшү белән минем һушны алган нәрсә — Ала тау булды. Түбәсеннән итәгенә кадәр актан киенгән мәһабәт тау ала-кола булып, өскә авардай булып күренә, күңелдә моңарчы уянмаган әллә нинди сәер, ашкындыргыч хисләр уята иде...

Биредә дә җылы, күк йөзе зәңгәр, аяз, Ала тау зәңгәр фонда тагын да аграк булып, күзләрне камаштырып җемелди. Машинага кереп утыргач, мин аның матурлыгына тагын бер мәртәбә сокланып, борылып карамый булдыра алмадым.

Аэропорт, безнең Казандагы кебек, шәһәргә терәлеп кенә тора икән. Ун-унбиш минут та узмагандыр, без пирамидаль тупыллы, күкрәп үскән өянке-тирәкле, икешәр-өчәр катлы йортлары тезелеп киткән зур бер шәһәр урамына килеп кердек.

— Чыңгыз Айтматовның бәйрәм кичәсе кайда үткәрелә? Сәгать ничәдә? — дип сорадым мин машина йөртүчедән.

— Опера театрында, сәгать биштә, — диде шофер.

— Алайса аңа бит бер сәгать калып бара, без туп-туры Язучылар союзына барыйк әле, туганым.

Джинси костюмлы кыргыз егете мине Язучылар союзына — аланда аерым утырган ялгыз ак бина янына китереп туктатты.

Калганы баш әйләнгеч тизлек белән эшләнде. Союзда дежур егет белән дежур машина гына калган, башкалары бәйрәмгә китеп беткән иде инде.

Дежур егет минем Казаннан килгәнемне белгәч:

— Без сезне каршы алырга ике мәртәбә барып кайттык инде аэропортка, кичә дә, бүген дә бардык. Әйдәгез, мин сезне кунак йортына илтим, анда озак мавыгырга туры килмәс, әйберләрегезне куярсыз да театрга китәрбез! — диде.

Өр-яңа стильдә, заманча итеп салынган пыяла-бетон бинада, «Пишпет» гостиницасында, мине өч бүлмәле люкска китереп керттеләр дә шундук алып та чыгып киттеләр. Гостиница алдына килеп чыгуга күптәнге танышлар-дуслар Кайсын Кулиев, Давид Кугелтинов, Имран Касыймов, Әбдиҗәмил Нурпәисовлар уртасында торып калдым. Мәскәүдән, Кавказдан, Урта Азия республикаларыннан килгән кунаклар шактый күп булып җыелып өлгергән иде.

Ул да түгел, аксыл пальтодан, көрән каракүл очлы бүректән Чыңгыз үзе килеп җитте. Йөзенә тыенкы елмаю чыккан, сабыр-олысымаклык аны бизәп тора, кунаклар белән ул баш кагып исәнләште (кичә үк күрешкәннәр булса кирәк), минем белән кочаклашып күреште һәм үтә дә гади, туганнарча якын итеп:

— Килеп яхшы иткәнсең, Гарифҗан, рәхмәт! — диде.

Мин аңа Казан сәламнәрен җиткездем, әле генә яңа әсәре басылган «Казан утлары» журналын күрсәттем, ул ифрат зур игътибар белән, ләкин бигүк җәелеп китмичә, журналны карады.

— Рәхмәт. Портфелеңдә алып бар инде алайса, минем монда салырга бер нәрсәм дә юк, — диде.

Гостиница каршысына җиңел машиналар, автобуслар килеп тулган иде. Казакъ язучысы Нурпәисов мине үз машинасына алып китте. Алар бәйрәмгә зур бер делегация булып килгәннәр, барысы да үз машинасында килгән, Алма-Ата белән Фрунзе арасы нибары өч йөз чакрым икән.

Опера театры яңы халык белән тулган. Билет сорыйлар. Бина эченә кердек. Чишендек. Президиум бүлмәсенә өстәл тутырып ризык, җиләк-җимеш, су-мазар куйганнар. Беркем дә ризыкка кагылмый, беркем дә артыгын сөйләми, кунак табыны башланыр алдыннан булганча, олысымак бер тынычлык, сабырлык, яңа киемнәрдән тартыну кебегрәк бер тойгы күңелләрне биләп тора иде.

Ниһаять, сәхнә артыннан президиумга уздык. Утырдык. Залга күз салдым: шыплап тутырылган. Өстә балконнар җимерелеп төшәрлек булып тулган халык. Күбесе басып тора. Меңнәрчә шәм нур чәчә, кызыл комачлар, алтын путаллар, орнамент бизәкләре балкый.

Президиум Кыргызстан компартиясе Үзәк Комитетының бюро членнары, хөкүмәт башлыклары, кунаклар белән тулды.

Үзәк комитет секретаре Кулматов кыскача кереш сүз белән кичәне ачты. Кыргыз язучылары башлыгы Тендик Әскәров унбиш минутлык доклад сөйләде. Аннары котлаулар башланды. Әлбәттә, башта союздаш республикаларга сүз бирелде, бу инде гадәткә кереп киткән иде. Тик алар арасында илнең атаклы язучылары Кайсын Кулиев белән Давид Көгелтиновка гына бүлеп сүз бирделәр.

Миңа сүз биргәндә, мактыйсы макталып, барлык бизәкле эпитет, чачаклы-чуклы сүз әйтелеп беткән иде инде.

Күп еллардан бирле илнең төрле почмакларында әдәби атналыкларда катнашып килгәнлектән, ораторлык осталыгының кайбер серләренә төшенә башлаган идем инде мин. Әлбәттә, иң беренче булып чыгу файдалы, чөнки син берәү дә әле телгә алмаган сүзне әйтәсең. Уртадарак сүз бирсәләр, синә темпераментыңны, артистлык сәләтеңне җигәргә туры килә. Азакны булып сөйләүченең хәле мөшкел. Беренче таушалмаган сүзне инде әйтеп бетергән булалар. Бүген андый сүзне илебезнең барлык язучылары исеменнән Юрий Верченко — СССР Язучылар союзы секретаре әйтте. Аңар Ленин һәм Дәүләт премияләре комитетының гыйльми секретаре Игорь Васильев, кинематографлар исеменнән атаклы артист Евгений Матвеев кушылдылар, Германия Демократик Республикасының Сәнгать Академиясеннән Конрад Вольф юбилярның дөнья күләмендәге әһәмиятен озаклап сөйләп, аның күкрәгенә ГДР Сәнгать Академиясе члены медален такты. Кайсын Кулиев белән Давид Көгелтинов утлар чәчеп торган кайнар телмәр (речь) сөйләделәр. Калган барлык әйбәт сүзне казакъ, төрекмән, әзербәйҗан, үзбәк, таҗик язучылары әйтеп бетерде. Бу сүзләрнең, кайнар котлауларның барысын җыйсаң — Чыңгыз Терекол улы Айтматов бүгенге, егерменче гасырның, бөек язучысы дигән зур һәм тирән эчтәлекле бер мәгънә килеп чыга иде. Җәмәгатьчелек шуның белән килеште. Чыңгыз Айтматов зурлыгында үзенең дә зурлыгын күреп, бик теләп, яратып, хуплап кул чапты.

Шуннан соң да яңарак сүзнең, халыкны кабыза торган сүзнең табылуы мөмкин түгел иде. Ә минем бер дә сынатасым килми, ник дисәң, минем Кыргызстанга беренче тапкыр килүем, шулай булгач, табигыйдыр ки, минем сөйләвем бер минем үзем өчен генә кирәк түгел, монда җыелганнарның хәтерендә мин татар халкының вәкиле булып калачакмын.

Өстәвенә — Чыңгыз Айтматовның әнисе татар булуы миңа әйтеп бетергесез зур җаваплылык өсти иде.

Мин, әнә шул җаваплылыкны җаным-тәнем белән тойган хәлдә, трибунага чыктым һәм ораторлык осталыгының өченче ысулын — хәйләкәрлек юлын сайлап алдым.

— Биредә, бу гаять зур вәкаләтле мәҗлестә, Чыңгыз Айтматовка карата әйтеләсе барлык әйбәт сүз әйтелеп бетте, миңа бер сүз дә калмады, — дип әкрен генә, хәтта беркадәр уңайсызланып сүземне башлап җибәрдем. Залның тын алуыннан сиздем, алар мине тыңларга ниятләнә. — Мин, иптәшләр, шулай булгачыннан, мактау сүзе сөйләп тормаска, шушы зур җаваплы трибунадан Чыңгыз Айтматов иҗаты хакында докторлык диссертациясе якларга булдым. — Залда җиңелчә көлешү ыш-ыш-ыш килеп узып китте. — Әйе, вакытны күп алсам алам, мин аны эшлим... — Шуннан соң мин кызурак темпка күчеп, тавышыма дәрт өстәдем. — Безнең илнең язучысы кайсы гына республикада тумасын, ул бәхетле язучы, чөнки аның язар өчен бик әйбәт материалы, бик рәхмәтле укучысы бар. Әмма мин үзем безнең илнең аеруча бәхетле язучылары дип кояшлы Кыргызстанда һәм кояшлы Татарстанда туып-үскән язучыларны саныйсым килә. — Әкрен генә көлешеп алдылар. — Илнең иң зур елгасы, бөек дуслык елгасы Идел кайда ага? Минем Татарстанымда. Ул гынамы? Мул сулы Чулман-Кама, җитез Вятка, башкорт чибәре Агыйдел кайда ага? Минем Татарстанымда. Башкортлар Агыйделләрен Татарстанга нигә җибәргәннәр? Татарстанның матурлыгын күреп чык та, шул хакта кыргыз дусларга сөйлә дип җибәргәннәр. Ә дөньяның иң матур тавы, бер карау белән башлар әйләнеп китә, йөрәкне чаптар аттай тыпырдата ала торган Ала тау кайда яши? Кояшлы Кыргызстанда. Бүген барлык ораторлар бер тавыштан егерменче гасырның бөек язучысы дип атаган Чыңгыз Айтматов кайда туып үскән? Кыргызстанда дип авыз тутырып әйтәбез. Чыңгызның китапларын иң яратып укучылар кайда? Татарстанда. — Шаулатып, рәхәтләнеп, ышанып кул чаптылар. — Мин Фрунзега килгәч, үзем өчен бер ачыш ясадым: Айтматовны, бактың исә, Татарстанда гына түгел, Кыргызстанда да яраталар икән. — Зал шаулап көлде, мин сүземнең икенче өлешенә күчтем. — Безгә бүләкне хәзер бирмәскә кушканнар иде. Кайсын Кулиев кинҗал бирде, төрекмән Ходайназаров чапан кидертте. ГДРдан килгән дус медаль такты, шулай булгач, нигә мин генә авыз күтәреп торырга тиеш әле? Ләкин миңа бүләк итәр өчен нәрсә кала?— Залдан: «Кыз!» дип кычкырдылар. — Рәхмәт, сез минем хәлне аңладыгыз. Мин Казанның чеканка осталары иҗат иткән татар кызы портретын алып килдем. Моның ике сәбәбе бар: берсе — безнең татар язучылары иҗатында хатын-кыз образы иң алдан йөри, чөнки төрки телләрдә сөйләшүче халыкларда революциягә хәтле иң каты изелгән зат хатын-кыз булган, икенчедән, Чыңгызның әнисе Нәгыймә апаның татар халкы кызы булуы миңа бу бүләкне тапшырырга хокук бирә. — Монысына да яратып кул чаптылар. — Чыңгыз, — дидем мин,— синең барлык әсәрләрең татар телендә басылды, пьесаларың Академия, Минзәлә һәм Әлмәт театрларында куелды, менә мин сиңа «Казан утлары»ның унберенче санын алып килдем, әле бары тик кыргызча гына басылып чыккан «Әйләнеп кошлар кайтканчы» романыңнан өзекне юбилееңа бастырып өлгерттек. Җылы кулдан кабул итеп ал. Соңгы сүзем шул сиңа: хәзерге заманның акыл иясе әйткәнчә, тау ике өлештән тора. Аның нигезе һәм күз камаштыргыч биек түбәсе бар. Әгәр Ала тауның нигезен кыргыз халкы дип санасак, биек түбәсен кыргыз халкының интеллигенциясе дип фикер йөртсәк, кыскача болай булып чыга: яшәсен тауның нигезе — кыргыз халкы! Яшәсен тауның түбәсе — халыкның талантлы икәнен исбат иткән зыялылары, шул исәптән бүгенге заманның бөек язучысы Чыңгыз Айтматов!

Мин бераз хәйләләп, бераз юмор кушып сөйләгән сүз ул хәтле үк халыкка тәэсир итәр дип уйламаган идем, әмма мин көткәннән артыграк булып чыкты. Кичен кунак йортында да, иртәгесен урамда да ми-

на бөтенләй таныш булмаган кешеләр рәхмәт әйттеләр, хәтта — бераз алгарак сикереп әйтәм — самолетта Мәскәүгә очкан чакта, безнең экипажның командиры, кыргыз егете салонга кереп, мине эзләп тапты да сөйләгән сүзем өчен рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Көтелмәгән шундый «эстрадный» уңыштан мин аптырабрак калдым. Юрий Николаевич Верченкодан, моның хикмәте нәрсәдә соң, дип сорарга мәҗбүр булдым.

Юрий Николаевич — искиткеч игътибарлы, йомшак сүзле, әдәп кагыйдәләрен үтә дә ихтирам итә торган кеше, миңа таба борылып:

— Кадерлем Гариф, кешеләр яңа сүзгә мохтаҗ. Алар безнең риторикадан, адым саен бер үк сүзне ишетүдән туеп беткәннәр. Синең сөйләвең, шәрык әдәбиятындагыча бизәкле, нык логикалы, конкрет булды. Шуңа күрә кешеләр сиңа тартылдылар. Бу — бик табигый хәл. Чыңгызның үз иҗаты да шундый бит. Ул заманның бик зур проблемаларын алып, кешелеклелек, гуманлылык кебек, адәм баласы гомер буе җавап эзләгән проблемаларны алып, кыргыз материалында ачып бирә. Ә бу исә ахыр чиктә безнең социализм җәмгыятенең әдәбият нормаларын, әдәбият кануннарын гаять үтемле итеп дөнья халыкларына җиткезү дигән сүз. Әнә шуңа күрә яши Чыңгыз иҗаты, яшәячәк тә!..

— Әйе, — дидем мин, аның белән килешеп. — Чыңгыз кабатланмаган талант. Ул, миңа калса, кыргызларның матур әдәбиятын гына түгел, барлык төр сәнгатьләрен уятып җибәргән кеше икән бит.

Мин моны кичә концертта күргәнемнән чыгып әйттем. Чыннан да, юбилейның концерт бүлеге безнең барыбызны да таң калдырды. Башта үзенең колачы белән. Концертта җиде йөздән артык кеше, бер сүз белән әйткәндә, республиканың төп сәнгать көчләре катнашты. Мондый да зур концертны, бер язучыны шул хәтле дә зурлауны әле күргәнем юк иде. Җыр-бию ансамбле, халык уен кораллары ансамбле, симфоник оркестр, бер йөз кешелек балалар хоры, шулар өстәвенә опера һәм балет театры, драмтеатр коллективлары, филармония артистлары, кино артистлары — барысы, барысы бар иде.

Болар Айтматов сәнгатенең кыргыз сәнгатенә тулаем йогынты ясаганын әйтеп торсалар, аның барлык өлкәләренә яңарыш-кузгалыш алып килсәләр (Кыргызстан кино сәнгатен ил күләменә алып чыгуы гына да ни тора!), шул ук вакытта республиканың барлык төр сәнгать вәкилләре бу иҗатны тирәнтен ышанып, барлык талантларын, йөрәк кайнарлыкларын салып пропагандалыйлар иде.

«Ак пароход» повесте тоташ әкияттән тора кебек. Мондагы илаһи дөньяны конкрет кеше рәвешендә сурәтләп булмастыр кебек иде. Ник дисәң, андый югары сфераны китаптан укып, акыл һәм күңел байлыгы белән үзең хыялый җанында гына тудырып буладыр кебек иде, ә менә кыргыз сәхнәсендә җиде-сигез яшьлек малай безне повестьның үзендәге хәтле үк зурлык, эмоциональлек белән дулкынландырды. «Анам кыры» повестендагы Толганайның да сәхнәдәге сурәте белән безнең күңелдәге сурәте бергә кушыла алды. Гасырлар буе бикләнеп яткан сәнгатьнең, җанны тутырырдай зур сихри дөньяның барлык бикләрен алып ташларга мәҗбүр итә, ахрысы, Чыңгыз иҗаты, кеше күңелендәге бөек көчләрне кузгатып җибәрә, ахрысы.

Әнә шуны республика җитәкчеләренең аңлавы, Айтматов талантына иркен юл ачуы республиканы, кыргыз халкын тулаем күтәрә.

Бу минем өчен ачыш иде.

Шундый ачыш ясавыма мин сөендем. Чөнки бу, Айтматовны кыргызларга талант кирәк булганга гына күтәрәләр, дигән тар карашларны чәлпәрәмә китереп ватып ташлый, бу зур сәнгать, олы сәнгать файдасына сөйли иде. Бу безнең дәвердә талант иясенең хезмәтенә һәйкәл кую кебек иде.

Айтматов сәнгатен олылауны икенче көнне тагын бер урында күрергә туры килде.

Мин, баштарак әйткәнемчә, Фрунзега юбилей кичәсе менә-менә башлана дип торган чакта гына килеп төштем, шунлыктан, табигыйдыр ки, бәйрәм алдыннан үткәрелгән чараларның кайберләрендә катнаша алмадым. Чыңгыз Айтматовка багышланган фильмны һәм юбилярның күргәзмәсен карарга өлгермәдем.

Бәхетем — минем кебек соңгарак калган кешеләр тагын бар булып чыкты. Иртәгесен тамак ялгап, тугызлар тирәсендә урамга чыгуга, Чыңгыз үзе килеп җитте. Аксыл көзге пальтодан, аксыл костюмнан, кара туфлидән, җитди дә, тыенкы-ягымлы да чырай белән килде ул. Кунак йорты алдында җыелып торган язучылар белән берәм-берәм күрешеп чыкты, бик җәелеп китми генә, хәл-әхвәлләрне сорашты, тирәякны угыз сөте кебек куе-аксыл томан баскан иде, таулар ягына бер күз сирпеп алгач:

— Ягез, кадерле кунаклар, сезгә тагын күпме томан җибәрим? — диде, матур итеп, калын иреннәрен җәеп елмайды. Аннары җитдиләнде. — Бүген сезне Кыргызстан компартиясе Үзәк Комитеты кичке бишләрдә кабул мәҗлесенә чакыра, шуңарчы әле вакытыгыз бар, күрми калганнар фильм карый ала, күргәзмә залына бара ала, — диде.

Казакълардан Калтай Мөхәммәтҗанов күргәзмәгә бармаган икән, ул барырга теләген белдерде. Уртача буйлы, очлы соры каракүл бүрекле, илле яше быел тулган Калтай, гаҗәеп ягымлы, әллә ниткән йомшак нур бөркелеп торган чырайлы, кара тут йөзле кеше, драматург, «Фудзиямага менү» дигән драманы Чыңгыз Айтматов белән бергә язып, дөньяга чыгарган кеше:

— Гарифҗан, син кичә әйбәт сөйләдең, минем сиңа күңелем төште, әйдә, барып карыйк Чыңгызның күргәзмәсен. Менә бу минем хатыным Фәридә абыстай булыр — врач, — дип үзе төсле үк ягымлы, чибәр, үзеннән буйлырак күренгән ханым белән таныштырды.

Шул минуттан башлап без Калтайның машинасына күчтек. Күргәзмә залларына барып җиткәнче укучыга бер хикмәтне әйтеп алыйм. Казакълар Чыңгызны үз уллары кебек якын күрәләр, аның белән горурланалар, барлык газеталарын тутырып аның хакында материал бастырганнар, бүләккә чаптар ат, чапан, XVII гасырның көмеш билбавын, агачтан ясалган сәнгать әйберләре, савыт-саба, тагын әллә ниткән бүләкләр төяп килгәннәр иде. Юбилей башланыр алдыннан булган бер каушауны әйтеп көлдереп алды Калтай мине:

— Чыңгызның олы улы Санҗәр әтисе янына опера театрына йөгереп керә дә: «Әти, казакълар аргамак алып килгәннәр, нишләтик?» ди. «Опера театрының капкасына бәйләп куегыз!» — ди Чыңгыз. «Алай ярамас бит», — ди улы. «Ярамаса, безнең дача капкасына бәйләгез»,— ди Чыңгыз. Нәкъ шулай эшлиләр. Ә икенче көнне чаптар җиде чакрым гына ераклыктагы бер совхозга тапшырыла. «Нишләтергә исәпли икән аны Айтматов?» — дип баш ватучылар бар. Берәүләр: суеп ашар, диләр. Икенчеләре ярсынып каршы төшә: ничек суеп ашасын, ул чагында бит Айтматов үзенең «Ак пароход»ындагы явыз Орозкулдан кай ягы белән аерыла соң? Бәхәсләшә торгач, уртак бер фикергә киләләр: «Чыңгыз, казакълар бүләк иткән чаптарга атланып, халык арасына чыгачак, болын тугайларына, тауларга барачак. Чаптар Чыңгызның аерылмас юлдашы булачак. Толстойның да җандай газиз күргән аты булган...»

Күргәзмә залына килеп керәбез. Башта бик зур фоторәсемнәр күзгә ташлана. Аларны берәр метр биеклектәге планшетларга куйганнар. Чыңгыз — аксакаллар янында. Чыңгыз — Мәскәүдә. Чыңгыз — респуб-

ликаларда. Чыңгыз — чит илләрдә. Тәэсир итәрлек, зәвыклы. Масштаблы.

Аннары — китаплар. Безнең ил халыкларының барлык телләрендә диярлек чыккан китаплар пыяла астына пөхтәләп тезеп куелган. Шулар арасында мин үзебезнең Татарстан китап нәшрияты чыгарган ике калын китапны да күрәм — җанга рәхәт булып китә. Чит илләрдә без Чыңгыз Айтматовның бер йөздән артык телдә чыкканын белә идек, кичәгенәк ул хакта докладчы Тендик Әскәров та әйтеп киткән иде. Ишетү бер нәрсә, үз күзең белән күрү — икенче. Дөньяның бер йөз телендә чыккан китап диңгезе каршыда җәелеп ята. Илле яшендә кемгә эләккән бәхет бу? Бары тик Шолоховка гына! Ә китапларның тиражы күпме, тиражы?! 15 миллион данә!

Алга узабыз. Чыңгыз китапларына ясаган иллюстрацияләр, графика, линогравюра, майлы буяулы картиналар, Чыңгызның атаклы скульптор Кербель койган бюсты, төрле рәссамнар ясаган портретлары. Болар таң калдыра дип әйтү шаблонрак булыр иде. Син ничектер тынып каласың. Һәрбер картинаны, эстампны, сынны килеп карыйсың, ашыкмый гына язуын укыйсың, күргәзмәне карап бетергән чакта, янә бер мәртәбә Айтматов иҗатының бөеклеге, аның кыргыз сәнгатен тулаем күтәрүе хакында уйлыйсың. Уйларың, аның сәнгате кебек, олысымак булып, талгын гына агыла. Олы сәнгать белән очрашу синең үзеңне дә сафландыра, җаныңа олылык иңдерә...

Чыңгыз Айтматовка багышланган фильмны караган чакта, күңелдә Чыңгызның акыллы булуы, зирәклеге беренче планга чыга.

Фильмдагы күренешләрне Чыңгыз үзе аңлата, аларга үзе бәя бирә. Аз гына да мактанчыклык, кәпрәю юк фильмда. Тоташы белән Чыңгыз сурәтеннән торса да, ул Чыңгыз Айтматов хакындагы фильм гына булып чыкмаган, художник һәм халык дигән темага эпопея булып чыккан.

Болай өстән караганда, фильм икегә бүленә: бар аның төсле өлеше, бар аның ак-кара белән эшләнгән өлеше. Әгәр ул тоташ төследән генә торса, бәлки ул хәтле үк тәэсир итә алмас иде. Чөнки аның төсле өлеше бүгенгене, ил һәм дөнья таныган Чыңгызны төшергән. Ә ак-кара белән эшләнгәне — Айтматовның бала чагы, үсмер чагы, әтисе Терекол, әнисе Нәгыймә, бу бәхетле гаиләнең сугышка тикле яшәеше. Аннары сугыш, аннары солдатлар, фронт эпизодлары. Экраннан йөзләрчә чырай, йөз, нурлы күзләр карый, аларның өметләрен, яшәүгә булган ышанычларының олылыгын, чынлыгын раслаган ат көтүләре, кичке тын дала, мәһабәт таулар, таулар аркылы чабаннар алып барган сарык көтүләре. Болар барысы ак-кара, болар барысы күптән булган хәлләр. Боларның барысын сугыш кырып сала, боларның барысы Чыңгыз иҗатына «моңлы бер җыр» булып керә. Шинель кигән, мылтык тоткан солдатлар, товарняклар, фронтка китеп баручы кыргыз егетләре, башка милләт уллары, ил иминлеген сакларга баскан соры шинельле совет халкы. Әнә шул иксез-чиксез ак-кара кадрлар янына төсле кадрлар саркып кына кереп тора. Чыңгыз Айтматов әле тын күл буена, әле чабаннар яккан учак янына килеп чыга, шушы кадрларга бәя биреп, тормышның олылыгын, дошманның явызлыгын, халыкның каһарманлыгын сөйли. Киемнәре аның халык киеп йөргәнчә гади, үзүзен тотышы халыкча җитди, хәтта кырыс. Чыңгызның сөйләвенә аның китаплары буенча төшерелгән фильм эпизодлары килеп кушылып, кинәт барлык күренешләрне бергә җыя, үткән белән бүгенгене бергә ялгый. «Беренче мөгаллим»нән, аның баш герое Дүйшенның кара көчләргә, иске дөньяга каршы көрәшеннән, кыргыз иленә мәгърифәт нуры алып кергән чактагы аяусыз көчләр белән тартышыннан, яңгын күренешләреннән, аның яшь бер кыргыз кызын уттан коткаруыннан башлана. Шуның янына «Хуш, Гөлсарат» повестендагы атлар серен, алар-

ның моң-зарын белгән Танабай килеп кушыла. Гомумән, атлар, аларның ял иткән чагы, аларның су эчәнә кергән чагы, төнге ат көтүләре, ат печтергән һәм шуның белән Гөлсаратның дөньясын җимергән мизгелләр, яхшылык белән явызлыкның көрәше булып, халык тормышы булып буйдан-буйга сузыла. Бу күренешләрнең чынлыгын, уйлап чыгарудан бигрәк тормышның үзеннән алынган икәнлеген, әмма Айтматов дигән художникның шәхесе, җаны аша үткәрелеп, тагын да биегрәккә, поэтик югарылыкка күтәрелүен Чыңгызның сөйләп торуы баета. Әйе, ул гел халык арасында: ул яшүсмер килеш атта чаба, ул яшүсмер килеш терлек-туар арасында йөри, сарык көтүләрен Ала тау аша куа — болар барысы чын кадрлар, ак-кара белән төшерелгән кадрлар, шунысы белән алар кыйммәтле дә. Күңелдән уй уза: Чыңгыз-малай, Чыңгыз-үсмер, Чыңгыз ир-егет барлык кинокадрларда бар, әйтерсең, язмыш аның зур язучы булып җитешәсен белгән, әйтерсең, кыргызлар шуны алдан ук сизеп, аның һәр адымын: ветеринария техникумында укыган чорын да, авыл хуҗалыгы институты студенты чагын да, Мәскәүнең әдәбият институты каршындагы югары әдәби курслардагы елларын да — барысын, барысын тарихка яза барганнар, кинога төшерә барганнар. Күңелдә уй туа. Безнең дәвер — искиткеч зур тизлекләр дәвере, машина заманы, бездә кино дигән мөмкинлек бар, әмма без шуны тулысынча, сәнгатебезгә кирәкле юнәлештә файдалана алабызмы? Мин бу сорауны зур итеп, кычкырып куям. Киностудияләрдә, телевидениедә эшләгән яшь белгечләр ишетсен дип кычкырам. Инде сиксәннәргә җиткән Туфаннар, Исәнбәтләр мәңгелек түгел бит. Яшь буыннар, киләчәк буыннар соңыннан безгә үпкәләмәсләрме? Безнең оешмаганыбызны, безнең ялкаулыгыбызны тиргәп йөрмәсләрме? Муса Җәлилне сугышка кадәр гадәти шагыйрь итеп белгәннәр, аның «Алтынчәч»е дә, «Хат ташучы» дигән искиткеч халыкчан поэмасы да, аның халыклашкан җырлары да аңа кино камерасын төбәргә, аның җанлы чыраен төшереп калырга өндәмәгән. Муса турында документаль фильм әзерли башлагач, аның шәһәр Советына сайланган чакта эләгеп калган бердәнбер кадрын таптылар киночылар. Әйтик, ул чагында киноның безнең республикага килеп кенә кергән чагы, телевидениенең исе дә булмаган чагы, ул чакны беркадәр, анда да «беркадәр генә» аклап була. Бүген безнең республикада киностудия бар чагында, телевидение гөрләп эшләп торганда, йоклап ятуыбызны, кирәкле моментларны кулдан ычкындыруыбызны киләчәк буыннар аңламаслар, без каргалган адәмнәр булып калырбыз...

Күңелгә әнә шундый уйлар да килә. Чыңгыз Айтматовка багышланган фильм ул аерым шәхес фильмы булып кына калмый, нәкъ менә халык һәм художник язмышына багышланган эпопеяга әйләнә.

Кинофильм караганнан соң, кичке сәгать биштә, без, кунаклар, Кыргызстан компартиясе Үзәк Комитетына кабул мәҗлесенә җыелдык.

Анда да Чыңгыз Айтматов исеменә тәбрик сүзләре әйтелде: Чыңгыз иҗатының ил күләмендәге, дөнья күләмендәге әһәмиятен кунаклар кат-кат, басым ясап әйттеләр. Минем үземә, мәсәлән, бизәкле, образлы, ялкынлы телмәрләрдән атаклы кино артисткасы Людмила Гурченко сүзе бик ошады.

Озын зифа буйлы, чибәр йөзле, бөтен барлыгы нервы төененнән торган бу артистка үзен алга чыгарып куярга, кемгәдер охшарга тырышмады. Әйтәсе сүзен ул хәтта тост итеп тә әйтмәде. Артист Евгений Матвеевның бик тәмләп, төеп-төеп әйткән сүзенә бәләкәй генә кушымта, Кавказ ягында йөргән термины белән әйтсәң, «аллабирды» итеп кенә әйтте. Ул кайсыдыр бер культура сараена, тамашачылар белән очрашуга ашыга иде. Мәҗлеснең тәмам өлгереп, пешеп җиткән чагында аңа чыгып китәргә кирәк иде.

Людмила чиксез дулкынланып урыныннан торды да:

— Мин тост әйтмим. Вакыт юк. Әмма сүземне әйтми дә китә алмыйм,— дип, тамак төбенә килеп бөялгән тавыш белән сүз башлады. Аның чамасыз дулкынлануы инде шаулаша һәм беркемне дә тыңламый башлаган мәҗлесне тынып калырга мәҗбүр итте.— Мин, кадерле дуслар, бүген төне буе Чыңгыз Айтматов белән әңгәмә корып чыктым. Хәтерегездәдер, «Ак пароход» повесте җиде яшьлек малайга карата әйтелгән кыска-кыска өч җөмлә белән башлана: «Аның ике әкияте бар иде. Берсе — үзенеке, анысын берәү дә белми, икенчесе — бабасыннан ишеткәне. Хәзер инде аның бер әкияте дә калмады». Шушы өч җөмлә аша мин алдыма котылгысыз зур фаҗига басканны сизәм. Әнә шул җидесе тулып, сигезенче яшь белән барган малайның фаҗигасе безнең барыбызны, дөньяның барлык халыкларын тетрәтте. Бу малай гаделлек, изгелек, сафлык-садәлек байрагын күтәреп бара иде. Мөгезле ана болан фаҗигасеннән соң ул ауды, байрак аның кулыннан төште. Ул байракны автор үзе күтәреп алып китте...

Башка бер генә сүз дә әйтмәде Гурченко, теләкләр дә теләмәде, Матвеев белән бергә, очрашуга китеп барды. Әмма аның сүзләре мәҗлестә дә, мәҗлес беткәннән соң да минем күңелемдә яшәде.

«Ник шулай соң?» — дип, мин үз-үземә сорау бирдем. Уйлый торгач, аның мәгънәсенә төшенгәндәй булдым.

Җиде яшьлек малай — ятим. Аның әтисе дә, әнисе дә юк, аның бабасы бар да, бабасыннан ишеткән мөгезле боланы бар. Болан гүя аның әти-әнисен, тудыручысын, нәсел башы ролен уйный. Бабасының әкияте белән малай күңеленә ул әнә шулай сеңгән. Шул боланны үтерделәр. Бабасы да моңа каршы килә алмады. Әкияте сүнде малайның. Димәк, явызлык һәм изгелек турында Чыңгыз илләрне, халыкларны кузгатырлык әсәр иҗат итте, яңа бер дөнья, без белгәннән зуррак, моңлырак, драматиграк дөнья иҗат итте.

Минем Гурченко белән икәүдән икәү генә әнә шул хакыйкать турында сөйләшәсем килде. Миңа ул бәхет элəкте. Без Мәскәүгә очасы самолет, томан булу сәбәпле, Фрунзе аэропортында шактый вакыт тоткарланды.

Шунда мин Гурченко янына килдем.

— Людмила ханым, сез кабул мәҗлесендә бик зур сүз әйттегез. Мин, сезне очратканчыга тикле, артистларга әсәрнең мәгънәсен режиссерлар төшендереп бирә дип йөри идем...

— Ә хәзер?

— Үзегез барып җитәсез икән дигән фикергә килдем.

— Рәхмәт,—диде Гурченко.—Режиссерлар көчләп икенче бер идея такмаса, әсәрнең асылына без үзебез дә бик әйбәт барып җитәбез. Айтматов — минем өчен өр-яңа ачыш. Әйтик, дөньяның иң зур хакыйкатен аның бала образы аркылы әйтеп бирүе әсәрне көчәйтә. Аның язу алымына карата да үз фикерем бар минем. Чыңгызның беренче әсәре «Җәмилә»не русчага тәрҗемә иткәннәр. Икенче әсәрләрендә автор үзе һәм тәрҗемәче исеме күренә. Бераздан тәрҗемәче булып автор үзе генә кала. Инде менә соңгы бер-ике әсәрендә тәрҗемәче дигән сүз бөтенләй дә юк. Димәк, автор үзе турыдан-туры русча язган. Мин аларны бик төпченеп укыдым, төпле бер нәтиҗәгә килдем: үз милли культурасы традицияләрендә тәрбияләнгән кеше, русча язган чагында, рус теле стихиясенә гаҗәеп бер яңа агым, яңа аромат алып керә. Димәк, безне алда яңа ачышлар, яңа зур эстетик кыйммәтләр көтә. Тик шуны истән чыгарырга ярамый, андый кыйммәтләрне Чыңгыз Айтматов кебек, үз язмышын ил язмышы белән куша алган, халыкларның рухи байлыкларын тирәнтен үзләштергән олы шәхесләр генә бирә алачак...

Людмила Гурченко тынып калды, аннары урыныннан торып, бүлмә буйлап йөреп килде, янә дә кәнәфигә килеп утыргач, әйтеп бетермәгән сүзе калган шикелле, уйчан һәм үтә сизгер йөзен миңа якын ук китереп, сер бүлешкәндәй әйтте:

— Чыңгыз — бөек язучы. Сиздегезме, бу көннәрдә ул тоташ безнең белән яшәде кебек: ягымлы, кайгыртучан булды. Ә бит ул шул ук вакытта үз эченә бикләнеп яшәде, күңеле тулы уй бит аның. Беләсезме, безнең өчен, халык өчен ул күптән өлгергән шәхес, ә үзе өчен өлгермәгән әле. Шуңа уйчан ул, шуңа кырыс. Ул әле безнең һушыбызны алырдай әсәрләр иҗат итәчәк. Исән генә булсын, өлгереп кенә житсен... Мин үземне аның замандашы булуым белән бәхетле санийм, аның фильмында роль уйнаячак көнемне хыялымда якынайтам.

ЖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

# ХЕЗМӘТ ҺӘМ ХӨРМӘТ

## Принцип

Уфага мин беренче мәртәбә 1963 елны барган идем. Ул чакта миңа утыз сигез яшь иде, минем әле «Яшьлек яме» белән «Юллар чатында»-дан башка китабым да юк иде.

Без, башкорт язучылары съездына баручылар, күп идек ул чакта. Хәсән Туфан, Риза Ишморат һәм Рәисә Ишморатова, Гали Хуҗи һәм аның хатыны Гайшә апа, Әлмәттән мин идем.

Партиянең Татарстан өлкә комитетыннан килгән Мансур Хәсәнов бу зур делегацияне житәкли иде.

Мостай Кәрим съездга килгән татар язучыларының барысын да кунакка чакырды, тик мине генә аерып калдырды. Моның сәбәбен кунакта булган язучылар болай дип аңлаттылар: Мостай Кәримнең күптәннән килә торган бер принцибы бар — үзе якыннан белмәгән кешене ул беркайчан да кунакка чакырмый.

Шушы хәлләрдән соң сигез ел вакыт узгач, 1969 елның октябрендә, үзенең илле еллык юбилеенда, Мостай Кәрим мине кунакка чакырып кына калмады, хәтта өендә үткәрелгән табынны алып баруны да миңа ышанып тапшырды.

Мондый кискен үзгәреш каян килеп чыкты соң?

Мостай Кәрим минем остазым Гази ага Кашшафны бик үз итә, аны гаилә дусты дип саный иде. Күрәсең, минем хакта беренче жылы сүзне аңа Гази абый әйткәндер.

Аннары без аның белән Мәскәү киңәшмәләрендә, пленумнарда, РСФСР Язучылар союзы секретариатында очраша башладык. Очрашкан чакларда ул минем белән бик җылы күрешә, хәлләрне сораша, үзенең дә ни эшләр бетерүен сөйли иде.

Талантлы әдипләрне беләм мин, әмма аларның кайберләре тормышта үз-үзләрен тотулары белән бик күпләрнең гайрәтен чигерәләр. Мостай Кәрим, бу яктан караганда, бәхетле кеше. Табигать аңа шагыйрьлек, драматурглык, прозаик һәм публицист талантын биреп кенә калмаган, шуларның барысына өстәмә итеп, акыл, ягымлылык, шәфкатьлелекне дә биргән. Аның әнә шул сыйфатлары беренче очрашуда ук аны яраттыра, кешеләр аның белән дус булуны үзләре өчен бәхет санийлар.

Мин дә аның үземә карата кайгыртучан-мәрхәмәтле карашын сиздем һәм, табигый, корыч магнитка тартылган кебек, аңа тартылдым.

1965 елны, әдәбият институты каршындагы ике айлык югары курсларда укыган чакта, Мостай Кәрим Мәскәүгә килде. Муса Галине, Вәзих Исхаковны, мине ресторанда тамак ялгап алырга чакырды.

Безнең өчен бу бик тә мөһим иде, мин егетләргә әйттем:

— Дуслар, Мостай ага безне кунакка чакырган икән, җиренә җиткереп сыйлаячак. Аның юмартлыгын бөтен ил белә. Ләкин минем һич кенә дә аңардан түләтәсем килми. «Авторлар хокукы» оешмасыннан мин бераз акча алдым, рөхсәт итегез миңа түләргә, — дидем.

Муса Гали идеяне хуплады. Тик түләү өчебездән дә тигез булсын һәм моны матур итеп эшләргә кирәк, диде.

Ресторанда без, студент-язучылар, тәмле ризыклар ашап, коньякмазар да капкалап, сөйләшеп утырдык. Мостай ага сыйны мул алды, кәефе аның шәп күренә, әйдәгез әле, шәкертләр, минем исәпкә бер рәхәт чигеп калыгыз әле, — дип шаярткалап та куя иде.

Ләкин без аңардан хәйләкәррәк булып чыктык. Папирос алу сылтавы белән мин акчаны түләп тә килдем.

Мостай ага, без ашап туйгач, кулларын җәеп җибәреп:

— Я, чибәркәй, бездән акча көрәп ал әле, — дигән иде, официант кыз, матур гына елмайды да:

— Уже все! — диде.

Мостай Кәрим каушады, гомердә булмаганча югалып калды. Әйтергә бүтән сүз таба алмагач:

— Кайсыгызның этлеге бу, сабакылар? — диде.

Муса Гали, арада иң итагатьле кеше, йомшак кына итеп көлеп куйды:

— Барыбызныкы берьюлы.

— Ни арада өлгердегез соң сез?

— Революцион курсларда укыйк та, «подпольщиклар» булыйк та, шуны да эшли алмагач... — дип тезеп китте Вәзих.

— Алайса, тагын бераз утырыйк инде, юкса, мин сыйлыйм дип алып кердем дә тәки ялганчы булып калам бит, — диде Мостай Кәрим.

— Давай, — дидек без бертавыштан.

Акча түләр вакыт җиткәч, матур кыз тагын бер мәртәбә ягымлы елмаеп:

— Уже все! — диде.

Әнә шуның белән җиңдек без акыл иясен. Рестораннан без аны гостиницага кадәр озата бардык. Саубуллашкан чакта ул, безгә моңсу гына карап, башын кырын салды:

— Зерә дә кызык якларыгыз ачылып китте бит әле бүген сезнең, бер да аерыласы килми бит әле сездән, сабакылар,— дип, бит урталарын чокырайтып, матур итеп көлеп куйды, аннары җаннарны җылытырдай үтә дә ихлас тавыш белән, — әллә миңа кереп шигырь тыңлыйсызмы? — диде.

— Давай, — дидек без һәм кич буе дөньябызны онытып шигырь тыңладык. Төн уртасы җиткәндә генә аерылыштык.

— Бик зур рәхмәт сезгә, туганнарым. Бик күптән шулай рәхәтләнеп сөйләшкән юк иде. Әллә ничә айга җитәрлек җылы иңдердегез җаныма, — диде Мостай ага.

...Бу очрашу Мәскәүдән Әлмәткә кайткач та күңелне гел җылытып торды; күрәсең, шул тәэсир беләндер, мин Мостай Кәримгә уй-тойгыларымны әйтеп, беренче мәртәбә хат язып салырга җөрьәт иттем.

Хат озак көттермәде. Мостай Кәрим миңа туганлык тойгылары өчен рәхмәт әйткән, безнең арада дуслык туып килүен сизәм, дигән иде.

Шуннан соң без аның белән РСФСР Язучылары съездында очраштык. Ул мине якын күреп, кочаклап күреште. Ләкин мин үземне тый-

нак тоттым, аны сүзем белән дә, аның янында булуым белән дә алҗытмадым. Халыкның әдәп кагыйдәләре миңа тыенкы булырга куша иде. Өстәвенә шул көннәрдә Әмирхан Еники белән булган сөйләшү мине тагын да сагая төшәргә мәҗбүр итте.

Ничектер шулай сүздән сүз чыгып, Әмирхан абый миңа Мостай белән очрашуын, аңарда кунакта булуын гыйбрәтле бер хәл итеп сөйләде. Мин дә яшьлегем-тәҗрибәсезлегем аркасында, Әмирхан абыйга Мостай Кәримне яратуымны әйтеп ташладым.

Чамадан тыш сак, шул ук вакытта шикләнүчән табигатьле Әмирхан абый минем җанны көйдерерлек сүз әйтте:

— Шулаен ул шулайдыр, ыһым, пнимаешь ли, син аны, допустим, ярата да торгансыңдыр. Ул бит әле, йие, ыһым, үзе бар... Яратуың бер яклы булып, сагызлану булып чыга күрмәсен...

Йөрәгем «жу-у» итте. Уфага ник хат язганыма үкенә башладым. Дөрес, ул миңа җавап хаты язды, ләкин бит аның әдәп саклап кына, яшь кешенең канатын сындырмыйм дип кенә язган булуы да ихтимал.

Борчу алды минем җанымны. Съезд вакытында мин биш-алты көн буена Мостай Кәримнең күзенә күренмәскә, мөмкин кадәр аны читләтеп узарга тырышып йөрдем. 8 Март көнне, ягъни съезд тәмамланып, кабул мәҗлесе җыелган көнне дә, Мостай Кәримгә күренмәс өчен, аулак бер почмакка кереп постым һәм, мәҗлес беткәнне дә көтмичә, чыгып ычкындым.

Иртәгесен иртүк мин Бөгелмә самолеты белән өйгә китәргә тиеш идем. «Балалар дөньясы» кибетенә кереп, улым белән кызыма күчтәнәчләр, үземә кирәк язу-сызу әйберләре алдым. Гостиницага кайтып, җыена торгач, төнге бер булды. Ә мин иртүк, сәгать алтыда ук, аэропортка китәргә тиеш. Мәскәүдән Бөгелмәгә туп-туры оча торган самолет бар иде. (Нефтьнең бездә гөрләгән чагы!)

Җыенып бетеп, урын өстенә сузылырга гына тора идем, телефон шалтырады. Алдым.

— Гариф, синме?

— Мин бу, Мостай ага.

— Син нигә миннән качып йөрисең?

— Нигә алай дисез?

— Иркенләп бер сөйләшкән дә юк бит. Хәзер үк минем номерга күтәрел!

— Анда кемнәр бар соң?

— Ул ни дигән сүз? Үзем генә мин. Синең белән сөйләшәсем килә.

Менә бу юлы инде эч «жу-у» итмәде, күңелгә җылы иңде, бер атналык газаплар кинәт юкка чыкты.

Чыннан да, Мостай ага үзе генә иде. Өстәлдә краб, кызыл икра ише деликатес ризыклар, әфлисун, лимон, башкорт балы бар иде.

Мостай ага рюмкаларга коньяк салды.

— Менә болай, Гарифҗан: яшь чагында дуслар күп була. Олыгая барам, олыгая барам, дусларны югалта барам, югалта барам. Син — минем олыгая төшкәч тапкан дустым. Җитез, булдыклы кеше син. Гадәттә булдыклы кешеләр әдәби яктан сәләтле булмый. Табигать сиңа икесен дә тигез биргән. Ләкин синең мин аеруча яраткан сыйфатың — ихласлык. Мин бүген, менә хәзер, тәрәзәдән ташлан, дисәм, ташлана торган кеше син. Дуслык, минем аңлавымча, әнә шундый булырга тиеш. Шундый булмаса, дуслашып йөрүнең мәгънәсе калмый. Синең саулыкка, Шәһидәң саулыгына, балаларың саулыгына, син корган оя бәхетле булсын өчен!

Без әкрен генә сөйләшеп утырабыз. Икәүдән икәү генә.

— Син кайчан китәсең әле? — Ул көлеп куйды.— Үзбәкләр моны

матуррак итеп әйтәләр: «Син безне, әкә, килеп шатландырган идең, кайчан кайгыга саласың?» — диләр.

— Бүген китәм, иртәнге самолет белән, — дидем.

— Гостиницадан кайчан кузгаласың?

— Алтыда.

— Вакыт азрак икән азрагын, ярай, борчылма, йокыны аны өйгә кайткач та йоклап бетереп була, самолетта да вакыт бар.

Әлмәт әдипләренең хәлен берәм-берәм сорашып чыкты, үземнең планнар белән кызыксынды, башкорт әдәбиятыннан мәгълүматларымны чамалап-барлап карады...

Сәгать төнге икеләр тирәсендә аның номерына бер төркем кеше ияртеп, Рәсүл Гамзатов килеп керде һәм бүлмәне шундук шау-шу белән тутырды.

Бераздан ул биредә кемнең иң яшь кеше булуын белергә теләде.

— Мөгаен, миндер, — дидем мин.

— Менә нәрсә, улым, — диде Рәсүл, миңа өстән карап. — Минем люкста Дагстан шәрабы бар. Чирекле шешәләрдә. Шуның берсен алып кил әле.

— Ачкыч бирегез.

Гамзатов номерына якынаюга берьюлы ике дежурный йөгереп килде. Мин аларга Язучылар союзы билетын күрсәттем.

— Кирегез, — диделәр.

Рәсүл Гамзатовның шаянлыгы-шуклыгы хәттин ашкан. Ул, мин алып кайткан чирекле шешәне күкрәгенә кысып, бер стакан шәраб салды да:

— Мин моны сезгә эчертә дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз. Мин моны үзем эчәм! — диде.

— Эчегез, сәламәтлегегез артсын! — дидем мин.

Икенче стаканны ул миңа сузды:

— Мә, улым, монысын син эч.

— Эчмим, — дидем мин.

Рәсүлнең күзләре зураеп китте.

— Ни өчен? — диде, дошманы өстенә ташланырга әзерләнгән тау бөркете төсле, канат-кулларын җәеп җибәрде.

Мин үземне бик тыныч тоттым.

— Сез, Рәсүл Гамзатович — тостлар мастеры. Минем халкымның мең еллык культурасы бар. Тост әйтсәгез, эчәм, әйтмисез икән — юк.

Бүлмә тып-тын булып калды.

Гамзатов аяк өсте басты. Чирек сәгатькә сузылган нотык сөйләде. «Йосыф» кыйссасыннан башлап, бүгенге көнгә хәтле татар әдәбиятының барлык җәүһәрләрен санап чыкты. Тукайга, Җәлилгә, Туфанга махсус тукталды. Сүзен ул болай дип очлады:

— Татар халкының саулыгы өчен, аның югары культурасы өчен тост тәкъдим итәм!

Мостай Кәрим мине кочаклап алды.

— Молодец, Гарифҗан! Халкыңны рәнҗетергә ирек бирмәдең. Мактаудан башлары әйләнгән Гамзатовларны әнә шулай акылга утыртырга кирәк, — диде һәм үзенең шаян сүзеннән үзе үк көлеп җибәрде.

## Олы бәйрәм

1968 елның декабрь аенда без язучыларның Малеевка иҗат йортында булдык. Башта без Рафаэль Сафин белән икәү идек. 5 декабрь көнне иҗат йортына Мостай Кәрим килде. Очраштык, күрештек. Бит урталарын чокырайтып, шундый матур елмаеп тора, бер елмаюына әллә ни бирерсең.

— Суырылгансың әле син, Гарифҗан, — диде, минем кыяфәткә карап алгач. — Бик каты эшләйсеңмени?

Өстәл янына утыртты безне, тормыш-көнкүрешне, гаилә хәлләрен сорашты.

— Сезнең өчен генә, бүген генә тоттым, — дип, көлә-көлә, Мәскәүдән алып килгән затлы балык белән сыйлады. — «Дружба народов» журналының утыз ел тулу бәйрәмендә катнаштым, кичкә калырга кушканнар иде, калмадым. Ахун да бар, Рафаэль дә монда дигәч, нишләп ятаем соң Мәскәүдә, үз дусларым янында булуга ни җитәр, дидем.

Мостай агай Мәскәүдә ай буе булган икән инде, туган якларының моңын сагынган, аның җыр тыңлыйсы килә иде. Ләкин күрше бүлмәдәге язучы тык та тык машинкада баса. Аңа комачауламаска, минем бүлмәгә барырга булдык.

Мин зур корпустан читтә, аерым коттеджда яши идем.

Бардык. Рафаэль «Колый кантунны» җырлады. Бик матур һәм тәэсирле итеп җырлады. Мостай Кәрим тын калып, бирелеп тыңлады. Рафаэльдән соң мин дә «Арча»ны җырламакчы булган идем, «ярай, бүгенгә бүтән җырламаек инде», — диде Мостай ага. Рафаэль җырыннан соң үзешчәннәр дәрәҗәсенә төшәсе килмәде бугай. Ләкин ул моны бик йомшак итеп, хәтер калдырмаслык итеп әйтте һәм безне урманга алып чыгып китте.

Башта сөйләшми генә йөрдек. Салкынча, тын. Агачларны бәс сарган. Рафаэль моны үзенчә «агачларны зәңгәр моң сарган» дип бәяләде. Мостай Кәрим:

Кайгыларым кайгырылмаганнар,
Шатлыкларга кул да тимәгән,

— дип шигырь сөйли башлады да, агачларга күз сирпеп алып, дәвам иттерде:

Агачларны салкын сихерләгән,
Алар йоклый төренеп бәсләргә.
Еллар җиле ботакларны кага,
Бәсләр очып куна чәчләргә...

Гади генә бер күренештән, урман бәсләреннән башланып киткән шигырьнең кинәт шундый зур гомумиләштерүләргә барып җитүенә мин хәйран калып барам. («Еллар җиле кага ботакларны, бәсләр очып куна чәчләргә».) Мин Мостай Кәримнең Хәсән Туфан поэзиясен яратуын белә идем, әмма ни өчен икәнен белеп бетерми идем, болай булгач, аңлашылды. Тирәнлек һәм халыкчанлык яраттыра икән аңа Туфан поэзиясен.

Дөнья бирде кирәкне,
Җыламаска өйрәтте.
Кайсыгызның кулы җылы,
бәйлисе бар йөрәкне?

— дигән юллардагы, Хәсән Туфан шигырендәге искиткеч гадилек һәм гаять зур гомумиләштерү көче барлыгын уйлап барам мин...

— Кичке аштан соң без Рафаэль Сафин бүлмәсендә аның русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен укыдык. Аларны үзләрендә, Уфада яшәүче Олег Сущевский дигән шагыйрь тәрҗемә иткән. Образларны саклаган, ритмы тигез, Рафаэльгә хас темпераменты да бар. Баштагы өчдүрт шигырьне әйбәт, әйбәт дип бардык. Аннары Мостай Кәрим әйтте:

— Кайбер тәрҗемәчеләр оригиналдагы шигъри образларны коеп калдыралар, шигырьне сөйләп чыгуга гына коралар. Монда образлар артык күбәйгән. Шунлыктан сулыш алуы тарайган кебек тоела. Шигырь юллары арасында иркенлек, бушлык та булырга тиеш бит. Ми-

сал өчен әйтик, йортларны бер-берсенә терәп салсаң, карап торырга да уңайсыз була, араларыннан җил дә йөрми. Яле, үзең теләгән бер шигырреңнән башкортчасын укып кара әле.

Рафаэль «Иөрәгемне көмеш кыңгырау итеп сине эзләдем» дигән шигырен укыды. Мостай Кәрим шигырьнең оригиналын ятратты.

— Кайчандыр миңа Зәйнәп апа Биишева: «Иөрәгем кайдадыр адашып йөри», — дигән иде. Безнең, шагыйрь халкының, гел шулай, йөрәкләребез кайдадыр адашып йөри, шул адашкан йөрәкне эзлибез. Югыйсә, без нәмәгә язып көчәнер идек. Син мена шуны оригиналда бик матур әйтә алгансың, русчасында ул авырайган, кыенлашкан...

Иртәнге аштан соң яки язып арыгач, өйләдән соң урманда йөрүгә без шундый күнегеп киттек, бер генә көн бергә чыкмый калсак та, үзебезне зур югалтуга дучар ителгән кешеләр кебек сизә башладык.

11 декабрь көнне Мостай ага миңа язылачак шигырьләренең фикерен сөйләп, аларны сынап-тикшереп карады.

...Бу чәчләрем минем картайганга гына ак түгел. Бу чәчләрем минем турысын әйтәсе урынга, ярашканга да ак. Бу чәчләрем минем бичәм алдында вак-төяккә алдашканга да ак. Начар кешене начар дип битенә бәреп әйтмәгәнгә, соңыннан үкенеп йөргәнгә дә ак...

Сыерчыклар бала очыра — сөенеп калабыз. Сандугачлар бала очыра — сөенеп калабыз. Саескан бала очыра, ул шыкырдап үткәндә, малайлар артыннан таш атып кала. Саескан да әни кеше бит, нигә бу дөньяда кеше белән кешегә тигез итеп карау юк?..

...Зур ак пароход узды, җиле белән, кузгаткан дулкыннары белән көймәне аударып китте. И адәм, син пароход булгансың икән (ягъни олы дәрәҗәгә ирешкәнсең икән), дөньяда көймәләр барын, бәләкәй кешеләр барын онытма. Синең саксыз гына бер җилең дә аларны һәлакәткә илтергә мөмкин...

... Бер малай бар иде дөньяда. Бөтен хыялы аккошны тоту иде. Канатына ярату сүзләре язып, сөйгәненә озату иде. Тота алмый интегә. Мәхәббәт ул — безгә тоттырмый торган аккош...

Әйбәт шигырьләр, мәгънәле шигырьләр, уйланырга мәҗбүр итә, дулкынландыра алырлык шигырьләр булачак болар. Ә бит без кайчагында рифмаларга, ритмнарга алданабыз, беренче чиратта шигырьнең образлы фикере булырга тиеш бит. Ритмсыз да, рифмасыз да дулкынландыралар икән ич алар андый чакта.

Мин Мостай абыйга күңелдә туган шул фикерләремне әйттем, ул алар белән килеште, үз нәүбәтендә, миннән:

— Гарифҗан, син нигә «Тихий Дон»ны тәрҗемә иттең? — дип сорады.

— Художниклыгы йокмасмы дип.

— Йоктымы соң?

— Һәрхәлдә, мин аңардан ясап язмаска, алдашмаска, әдәбиятта намуслы булырга өйрәндем.

— Молодец! Менә шул кирәк тә. «Тын Дон»ның күңелеңдә аеруча сакланган кай төшен беләсең?

Миңа 1917 елның сентябрендә фронттан казаклар кайткан өлеше бик ошый иде. Сөйли торгач, мин аны яттан өйрәнеп бетергән идем инде. Шолоховның тол калган хатынга булган мөнәсәбәтен әйтеп бирдем!

...«Җыла, җаным, кайгыдан сирәкләнеп калган чәчләреңне йолкы, канатканчы тешләгән иреннәреңне чәйнә, авыр эштән гарипләнеп беткән кулларыңны каер, буш йортыңның бусага төбендә үксеп ят! Юк синең хуҗаң, юк синең ирең, юк синең балаларыңның әтисе... Син икенче мәртәбә кияүгә чыга алмассың, ни өчен дисәң, авыр хезмәт, нужа, балаларың сине кибектереп, саргайтып бетерделәр. Синең ярым ялангач, маңкалы балаларыңның әтисе булмас; җелекләрең суырылганчы, көчәнә-көчәнә, суканны үзең сукаларсың, тырманы үзең тырмаларсың, өч җәплекәле агач сәнәк белән бодай чүмәләсен үзең күтәрерсең, шул чагында, касык астында нәрсәнеңдер өзелеп китүен сизәрсең дә иске-москыга төренеп, бөгәрләнеп, канга батып ятарсың...»

Моны тыңлагач, Мостай ага әйтте:

— Безнең заманда рецензентка гына түгел, редакторга гына түгел, халыкка да яраша башладылар. Шолоховның бөеклеге шунда, ирсез калган казачкага да яхшатланмый, ярашмый, аның трагедиясен ачып сала.

Әдәбиятта намуслы булу, хәтта халык белән дә ярашмау — язучыга куелырга тиешле иң беренче таләп. Тик бер ягы бар, без перспектива дигән нәрсәне дә онытмаска тиешбез. Дөнья даһилары гел караңгылыкны гына язмаганнар, хәтта кеше кол итеп яшәтелгән дәверләрдә дә кешенең бөеклеген җырлаганнар. Менә шушы ике сыйфат бергә кушылган чакта гына чын язучы, зур язучы була ала.

Бездә, Башкортстанда, талантлы шагыйрьләр күп. Шуларның берсе — Рәми Гарипов. 1937 елның трагедиясен язды. Кеше полюска очты, «Күтәрелгән чирәм» туды, шул ук елны «Тирән тамырлар»ны утка яктылар. Мин бу шигырьне якладым, китабында калдырырга куштым.

Рәми, сүз дә юк, әйбәт шагыйрь, Атнабай дә әйбәт шагыйрь. Назар Нәҗми — зур шагыйрь. Шушы әйбәт, чын шагыйрьләргә бер үпкәм бар — дөньяны аз күрәләр, аз йөриләр. Мин үзем Уфада озак утырсам, тарыга башлыйм. Кайларгадыр чыгып китәсе, кемнәрнедер күрәсе, җәяүләп йөрисе килә башлый. Әнә бит утызынчы елларда Такташ Донбасска барып чыккан, Шәриф Камал өзлексез йөргән, Туфан Себер якларын айкаган. Күрәсе килгән кешегә дөнья иркен хәзер: туристлык путевкасы белән илләрне айкап йөрергә була. Юкка-барга акча сарыф иткәнче, йөри бир рәхәтләнеп!

15 декабрь көнне урамда йөреп аргач, Мостай Кәрим безне үз бүлмәсенә чакырды. Гадәттәгечә, әдәбият мәсьәләләрен сөйләштек, Рафаэль дә, Мостай ага да шигырь укыдылар. Мин аларга Шәһидәдән килгән хатны укып күрсәттем. Миңа ул көнне берьюлы дүрт хат килде. Рафаэль аларны миңа зерә дә кызык итеп тапшырды. Башта Мәҗит Рафиков хатын, аннары Марсель Зарипов хатын, аннары кызым Наилә хатын, соңыннан гына Шәһидә хатын тапшырды. Шәһидә хатында гел төш күрүен әйткән һәм төшен шигырь белән аңлаткан иде.

Төшләрем ни әйтә?
Төшләрем шуны әйтә:
Йөрәгем ярылып,
Я мигә кан савып,
Үләргә калса миңа йокыда,
Төшемдә сине күреп,
Я үткән гомерем кереп,
Синең өчен ут йоткан мизгелдә
Чыгачак икән җаным.

Укып күрсәткәч, Мостай ага беркавым сүзсез утырды. Аннары әйтте:

— Карале, гаҗәп бу. Солдат хатлары кебек тә, бүгенгечә дә, теләсә ни әйтегез, монда зур эмоциональ фикер ята.

Сөйләшү безнең көннән-көн тирәнәя, җитдиләнә бара. Шәһидә ханыннан дулкынланып, кабынып киткән Мостай ага безгә «Ай тотылган төндә», «Айгөл илендә» пьесаларының беренче кулъязмаларын күрсәтте. Кара тышлы калын дәфтәрләргә вак кына итеп кулдан язган. Бик пөхтә, энҗе кебек тезелеп тора.

— «Ай тотылган төндә»не 1963 елны Малеевка иҗат йортында бер ай эчендә яздым. «Айгөл иле»н үзебездә, Уфада яздым, больницада, анысы озаграк язылды, — диде.

Бүгенге әдәбиятның үзәк мәсьәләләре, тоткан юлы турында сүз кузгаттык.

— Совет әдәбияты егерменче елларда халыкны сыйныфларга бүлү белән шөгыльләнде, — диде Мостай ага. — Павлик Морозовның әтисен үтертүне мактау — бернинди киртәгә дә сыймый торган хәл. Ханнар гына туганнарын үтергән. Туган туганны үтерү идеясен югары итеп күтәрү — дөнья әдәбиятына, кешелек дөньясы тудырган әдәбиятка ялган китереп кертү. Бөек художниклар чамасыз гаҗәпләнү белән язалар аны. Моның четерекле мәсьәлә икәнен тормыш практикасы да күрсәтте. Павлик Морозов турында кино төшереп карадылар, әмма халыкка чыгарыр көн килгәч, икеләнеп калдылар.

Чынбарлык — аяусыз. Революция чорында, гасырлар буена килгән традицияләр һәм канлы режимнар җимерелгән чорда, туган туганга каршы да барган. Зур художник Михаил Шолохов аларын да күрсәткән, катылык, рәхимсезлек, кансызлык күренешләре бу эпопеядә тулып ята.

Әмма бүген безнең совет әдәбиятында гуманизм, халыклар арасындагы дуслык, адәм баласының күңел матурлыгын җырлау төп тенденцияне алып бара. Чыңгыз Айтматовта моның бик әйбәт мисаллары бар.

...Мостай Кәрим безне Малеевка иҗат йортыннан ерак түгел Глуховка авылына алып барды. Анда минем ахирәт дус Вәкил Сабитов яши, ди.

Урам уртасында суелган дүрт әтәч күтәреп килүче бер хатын очрады.

— Чибәр апай, безгә бер әтәчеңне сат әле,— диде Мостай ага.

Дүрт әтәчнең дүртесен дә кулы белән тотып, күтәреп карады, берсен сайлап, акча түләде, Сабитовларга илтеп бирегез, йолкысыннар, пешерә торсыннар, — диде.

Хатын әтәчләрне күтәргән көе китеп баргач:

— Менә, егетләр, әтәчле дә булдык! — диде. Көлеп әйтте.

Сабитовларга барырга ашыкмадык. Әтәч пешкәнче, авыл башындагы елгага барып, боз өстендә бик озак йөрдек. Мостай ага, гел дә менә мәктәп балалары төсле тотты үзен боз өстендә. Ялт итеп торган көзге бозда, су туңган чакта, һава кереп калып, куыклар барлыкка килгән иде. Малай чакта, без әнә шул куыкларны магазин дип атый идек, бүлешә торган идек. Мостай ага да шул бала чак уенын башлап җибәрде. Без, магазиннарны бүлешә-бүлешә, дөньябызны онытып җибәргәнбез. Безне Сабитов җибәргән бер малай алып кайтып китте.

Вәкил Сабитов дигәннәре Малеевка иҗат йортында эшли торган, алтмыш яшьләрендәге бер чандыр гына агай булып чыкты. Мостай Кәрим белән ул кочаклашып күреште, Мостай ага аның балаларының үскәнлегенә хәйран калды.

Вәкил абзый әтәчне пешереп җиткергән, табын әзерләп куйган иде инде. Мостай ага белән Вәкил абзый тормыш мәшәкатьләре турында иплә кенә сөйләп утырдылар, без тыңлап утырдык.

Рафаэль белән мин, эсселәп китеп, һава алырга чыгып кердек. Керсәк, ни күрәбез, Мостай ага кара йон свитеры урынына зәңгәр бумази

күлмәк киеп алган. «Матурмы, матурмы?» — дип мактанып утыра. Баксаң-күрсәң, кыйбатлы свитерын Вәкил абзыйның бумази күлмәгенә алмашкан икән.

Юлда кайтышлый без аңардан, нишләп алай эшләдең, дип сорадык. Ул үзенә хас ягымлы елмаюы белән елмаеп:

— Вәкил абзыйның да матур күлмәк киясе килә бит, — диде.

— Бүләк иттеңмени?

— Әйе.

— Ник алайса, аның күлмәген алдың?

— Болай гына алмый бит ул күлмәкне. Алмаштык, шуңа риза булды.

Сүз тормышка, тормыштан тагын әдәбиятка кайтып төште.

Мостай ага әйтте, Салават турында трагедия язам әле, диде. Рафаэль бу хәлне белә икән инде, минем беренче ишетүем иде, сораша башладым. Мостай ага ялындырмый сөйләп бирде.

— Мин батырлыкны халык өчен борчылу дип аңлыйм. Пугач явында Салаваттан гаярь кешеләр дә була. Әйтик, Кинйә Арсланов, ләкин халыкка батырлык үрнәге булып Кинйә түгел, Салават кереп калган. Салават — халыкныкы. Ул халыкның уй-тойгыларын, акылын һәм теләкләрен аңлаучы. Трагедиям минем «Салаватның биш төше» дип атала.

**Беренче төш.** Салаватны кыйнарга камчылы кешеләрне китерә патша. Ләкин кешеләр камчыларын Салаватка сукмыйлар, үзләренә сугалар. Үзенә сугу инде ул — Салаватка сугу, чөнки Салават — халык. Җиңелү хурлыгыннан сугалар үзләренә. Трагедия шулай башлана.

**Икенче төш.** Салават диңгез ярында бик зур таш өемен әле бер якка ташып куя, әле икенче якка. Мәгънәсе: кирәксез эш эшләү — Салаватка иң зур җәза.

**Өченче төш.** Салават Екатерина янына керә һәм әйтә: «Әби патша, син миңа Суворовны юкка җибәргәнсең, Суворов — намуслы кеше, — ди.

**Дүртенче төш.** Салават бер кызга гашыйк була. Кызны (дөресрәге— халыкны, димәк, кызны да) Салават яныннан куалар. Мәгънәсе: шагыйрьне туфрагыннан, таяныр җиреннән аералар.

**Бишенче төш.** Монысы әле ачыкланып җитмәгән. Бәлки дүрт кенә төштән булыр, — диде Мостай ага.

Без аулак урман юлыннан атлыйбыз. Мин әдәби әсәрләрнең формасы хакында уйлап барам. Салават Юлаев хакында рус язучысы Степан Злобин атаклы роман язган иде бит инде. Аңардан соң тагын да эпик формага тотыну кабатлаудан башкага илтмәячәк иде. Мостай Кәримнең төш формасын сайлап алуы драматизмны көчәйтә, вакыт һәм пространство белән иркенрәк эш итәргә мөмкинлек тудыра.

— Күлмәкне Вәкил абзыйга биргәнгә үкенмисеңме? — диде Рафаэль.

— Үкенмим. Нигә кат-кат сорыйсыз? — диде Мостай Кәрим, бит урталарын чокырайтып, мөлаем елмайды. — Минем эти, бала чакта матур чана сорасаң, әйтә иде, чана ясаучы урыс үлгән бит, улым, дия иде. Әйбәт кеше иде эти, шаукымлы. Бервакыт авылны тузанга күмеп, арбаның алды белән генә кайтып керде. Артын өч көннән соң урманга барып таптык. Төп башына эләгеп калган. Өйдән тагын хат алмадыңмы әле? — дип сорап куйды ул, бераз тын баргач.

— Алдым, — дидем мин.

— Укып күрсәтмисеңме?

— Чынлап әйтәсезме?

— Чынлап.

— Укыйм алайса, тыңлагыз, — дидем мин, куен кесәсеннән төргәге

белән хатлар чыгарып, берсен сайлап алдым. «Нажарның шигырьләрен укып чыктым. Әйбәт шагыйрь, чын шагыйрь. Язуы белән генә түгел, бөтен барлыгы белән шагыйрь икәнен тоеп була. Китап тышындагы рәсемен торам да карыйм, торам да карыйм. Укыган саен карыйм, караган саен якынрак, мәгънәлерәк тоела бара. Рафаэльнең китабын, Әнгамнең китабын укыган идем инде — акыллы шагыйрьләре бар башкортларның; шигырьләрендә гел фикер, гел уйлану. Уйлану — именно шул. Шагыйрьнең бит әңгәмәсе дөнья белән. Дөнья белән әңгәмәгә кирәрлек фикерең булмагач, шигырь буламыни, аны язган шагыйрь буламыни — челтәр бәйләүче була, анысын да әле ни чыгарын белеп бәйләми, әллә сөлге башы, әллә салфетка, әллә нәрсә шунда; бәйләргә өйрәнгән дә төрледән төрле үрнәкләрне бәйли дә бәйли.

Мостай абыйның шигырьләрен укый башладым. Аның «Айгөл илендә» пьесасын укыган да идек, спектаклен дә караган идек, әйеме? Гомер иткән олы кешенең шундый чиста, хыялый әйбер язуына шаккаткан идек ул чакта. Баксаң, гомер буе Айгөл илендә яшәүчеләр дә бар бит. Үзебезнең дусларның күбесе Айгөл иле кешеләре бит...»

Мостай Кәрим хаттагы фикерләр белән килеште.

— Шәһидә — максималист кеше. Ул дөнья турында чиста итеп кенә уйлый. Чиста түгеллекне күрсә, дулый, протест белдерә. Аңа дөньяда яшәве шактый кыендыр... — дип нәтиҗә чыгарып куйды ул.

16 декабрьда без Мәскәүгә юл тоттык. Унсигезендә РСФСР Верховный Советының чираттагы сессиясе башланачак, Мостай Кәримгә регистрациягә керергә, эшләр белән танышырга кирәк. Аны алмага Мәскәүдән машина килде, форсаттан файдаланып, мин дә Мәскәүгә барып килергә булдым. Безгә юлдаш булып тәнкыйтьче Владимир Огнев та барды.

Юл мажарасыз булмый. Мостай Кәрим белән Владимир Огнев шоферга әйттеләр: без сине туры юлдан алып барабыз, син без әйткән юлдан гына бар, яме, без бу юлны биш бармагыбыз кебек беләбез, диделәр.

Шофер, алар өйрәткән юл белән генә барып, Тучково станцасы тирәсендә ярты сәгатьләр чамасы адашып йөргәч, юл салучылардан һәм каршыга очраган машиналарның шоферларыннан сорый-сорый, ниһаять, дөрес юлга, Минск шоссесына килеп чыкты.

Минск шоссесын мин шундук таныдым. Юл чатында, биек постаментта танк тора — авыр сугыш елларында безнең республика колхозчылары акча җыеп төзегән, фронт юлларын узган «Татарстан колхозчысы» дигән танк. «Канатлар кая илтә» дигән китабымда мин махсус ул хакта язган идем.

Мәскәүдә Мостай Кәрим биш көн торды. Биш көн эчендә без аны сагындык. Ни генә эшләсәк тә, кая гына барсак та, аның юклыгы гел сизелеп торды.

Бильярдчылар бүлмәсенә керәбез — тәмәке тартканнар. Мостай ага барында тартмыйлар, аңардан тартыналар иде. Яшьләр бүген шарны, осталыкларын күрсәтергә теләп, дөбердәтеп китереп сугалар, шарлар, ике якка атылып, идәнгә барып төшә. Әнә шул егетлек санала! Мостай аганың төзәгәнен дә күрмисең, сукканын да ишетми каласың, шар матур гына тәгәрәп бара да тиешле оясына кереп китә иде. Аннары Мостай ага, таягын кочаклап, башкалар уйнаганны сабыр гына көтеп тора, дөрес сугылган һәр шарга мөлаем гына елмая иде. Рәхәт аның белән бергә булулары, рәхәт аның белән сөйләшүләре, аның янында үзеңне язучы итеп, кеше итеп тоясың, дәрәҗәңне сакларга, азынмаска тырышасың.

Ашханәгә керәбез. Монда тагын ул искә төшә. Безнең өстәл — түрки теләндә сөйләшүчеләр өстәле. Мостай ага белән Рафаэль — Уфадан, Нил Юзиев белән мин — Казаннан, Хәлимәт Бәйрәмукова белән Киас Мәҗитов — Кавказдан.

Хәлимәт — илле яшьләрендәге, йончылганрак кыяфәтле ханым. Әйбәт шагыйрә. Мостай ага аны «Наша сердечная сестра» дип атады. Киас Мәҗитов — олы яшьтәге, әкрен сүзле агай; заманында аучы булган, хикәяләренең күбесен хайваннар тормышыннан яза. Бавыры авыртә аның, ул сөтле ризыклар гына ашый, сөтне дә җылытып китергәнне генә эчә. Мостай ага аны «Наш молочный брат» дип атады.

Без бүген өстәл янында уен-көлкесез генә ашыйбыз. Ашап бетерү белән кузгалабыз. Безнең янда Мостай Кәрим юк, безнең коллективны оештыручы юк.

Төштән соң Рафаэль белән урманга чыгып киттек. Чаңгыда йөрү сулышларны киңәйтә, хыялларны арттыра. Бүген безнең белән Мостай ага бармый, безне тыеп торучы юк. Малеевка урманына бик ерак кердек. Чыршы ботакларында мендәр-мендәр кар эленеп тора. Каен кәүсәләре, аланнар ап-ак. Нигәдер миңа ул каеннар кияүгә чыгарга әзерләнгән кызларны хәтерләтәләр: аклык күп аларда, пакьлек күп. Каен урманы, бигрәк тә кышкы, тын каен урманы күңелне нечкәртә, тирән итеп сулыш аласы, көрсенеп куясы килә.

Без йөри торган юлда көянтәләнеп бөгелгән каеннар очрый. Алар әкият капкалары кебек. Сыкы сарган ак тәлгәшләрен салындырып, тын гына каршы алалар, тын гына озаталар. Күңел отыры нечкәрә, тулыша, Мостай Кәрим булып, шигырь юлларын кабатлый:

Юкка гармунчы түгелмен,
Ярсып бер уйнар идем,
Ярсып бер уйнар идем дә
Үксеп бер җылар идем...

Кичне моңсу гына үткәрдек, вак-төяк шаяртышу, мәзәк сүз әйткәләдек. Бала-чагаларчарак чыга хәзер безнең шаярту, үзебезне олпат итеп, тыенкы итеп тотмыйбыз. Ә бит без Мостай ага бар чагында шаяртуны ваклаудан да курка идек.

Рафаэльне, Мостай аганы, Зәйнәп апаны Мәскәү университетында укыган бер башкорт егете якташлар җыелып үткәрә торган бер җыелышка чакырып киткән иде. Рафаэль шигырь китабын русча чыгару хәстәре белән ике мәртәбә Мәскәүгә барып кайтты инде. Без аны бу юлы анда җибәрмәскә булдык. Моны Мостай ага да белеп торсын дип, «Егерме берендә иртән кайтыгыз, без анда бара алмыйбыз», — дип телеграмма суктык. Тыныч күңел белән душ кереп, кичен Нил Юзиев бүлмәсендә сөйләшеп утыра идек (ул бездән ун көн соңрак килгән иде), төнге сәгать уникедә Мостай ага кайтып төште. Кулында телеграмма. «Иртән» дигән сүзне «кичен» дип төзәткән. Телеграмманы безгә сузып, авызын ачкан килеш, рәхәтләнеп елмаеп тора. Гел дә менә балалар кебек!

Малеевкада яза башлаган бер шигырен тәмамлаган. Шундук аны укырга кереште:

Әйләнә карусель, әйләнә,
корылган карусель хәйләгә...

Бу шигырьнең мәгънәсе: тулпарга атланган фил дә, шонкарга атланган тычкан да үзләрен тигез итеп сизәләр. Ягъни бу дөньяда тар акыллы бәләкәй кешеләр дә үзләрен акыл иясе белән янәшә итеп куялар. Әйләнә карусель, ара бик якын, әмма бер-беренне куып җитеп булмый.

Кыз бала белән ир бала карусельдән төшәләр, шагыйрь аларга әйтә: кулларыгызны ычкындырмагыз, ди. Чөнки:

Әйләнә бит, әйләнә җир, әйләнә,
ул да бит корылган хәйләгә...

Йокы качты безнең — Мостай ага кайтты, сөйләшәсе килә, шигырь тыңлыйсы килә, Мәскәү хәлләрен беләсе килә. Төнге бергә тикле урамда йөрибез; Мостай ага Язучылар союзындагы, журнал редакцияләрендәге яңалыкларны сөйли, иртәгә Арслан Мөбәраковка — СССР халык артистына 60 яшь тула, аңар телеграмма сугасы булыр, ди.

Без бергәләп телеграмма текстын төзибез.

«Без синең белән горурланабыз, чөнки син җилкәндә башкорт театр сәнгатен күтәреп барасың, көчле канатларында аның даныи еракларга илтәсең...»

— Сәнгать дөньясында кеше бик күп ул, дусларым, әмма аның данын алып баручылар бармак белән генә санарлык, — ди Мостай ага. — Һәр сәнгатьнең фидаи җаннары булырга тиеш. Сәнгатькә җаны тәне белән бирелгән кешеләре. Аларның бөек язучылар булуы, бөек артистлар булуы да мәҗбүри түгел. Әмма әнә шул фидаи җаннар халык күңелендә тормышка ышаныч тудыралар, чын сәнгатьне яклыйлар, аның үсүенә булышалар.

Фронт газетасында мин татар язучысы Мәхмүт Максуд агай кул астында эшләдем. Иҗат кешесен аңлый белә иде. Бер көнне әйтә бу миңа: «Мостафа, әнә теге урманны күрәсеңме, матурмы? Мин сине бер атнага эштән бушатып торам, бар әнә шунда, яз шигырьләреңне»,— ди.

Төнге бердә Малеевка урманында йөргәндә, без әнә шуларны сөйләштек. Фронтларда йөргән татар язучыларының, Җәлилнең, Фатих Кәримнең, тагын бик күпләрнең җанлы образлары күңелдә яңарды. Алар арасында, фронтта Мостай Кәрим дә булган, кыйпылчык аның күкрәген һәм комсомол билетын тишеп узган. Ул әле менә хәзер дә безнең арада йөри, шул авыр елларның истәлеген сөйли һәм, поэзия сөючеләрнең бәхетенә, татар һәм башкорт халыкларының бәхетенә исән калып, яңа шигырьләрен иҗат итә...

Малеевкада бергә үткәргән өч атнаны без **олы бәйрәм** дип атадык һәм шул бәйрәм әле дә безне җылытып, күңелләрне куандырып, җанда яши, уйлаган саен дулкынландыра, эшләгән эшләребез өчен җаваплылык хисен арттыра.

## Мөнәсәбәт

Әдипләрнең зурлыгы аларның үзләреннән элгәре иҗат иткән бөек затларга булган мөнәсәбәтләрендә дә ачык күренә.

Мостай Кәрим Татарстанга күп мәртәбәләр килде, ул безнең язучылар съездларында, әдәби бәйрәмнәребездә катнашты. Килгән саен, сүз чыккан саен, аның сокланган бер бөек заты бар.

Ул — Тукай.

Хаер, Мостай Кәримнең Тукайга соклануы бер Казанга килүе белән генә бәйләнмәгән. Кайда гына булмасын — Мәскәүдә я Уфадамы, киңәшмәдә я иҗат йортындамы — ул аның хакында сүз кузгатмый калмый, ул аның шигырьләренә, тормыштагы батырлыгына торып-торып соклана, Тукайны дөнья даһилары белән бер рәткә куя.

1976 елны безнең Татарстан Язучылар союзы идарәсе Тукайның тууына 90 ел тулу уңаеннан Бөтенсоюз комиссиясе алуга иреште. Тукайны илебезнең барлык республикаларында, барлык шәһәрләрендә

бәйрәм иттеләр, әдәби журналларда һәм газеталарда Тукай турында 150 дән артык мәкалә басылып чыкты.

Мостай Кәрим Тукай бәйрәменә Казанга килде, Тукай-Кырлайга барды, аның хакында күп еллар буе күңелендә йөрткән уйларын ул Тукайның шүрәлеле урманында әйтеп бирде һәм соңыннан «Социалистик Татарстан» газетасында аерым мәкалә итеп бастырды.

Әлеге мәкалә Мостай Кәримнең үзенең дә олылыгын, публицист буларак осталыгын һәм акылының тирәнлеген раслый. Мин аны укучыларыбызга тулысынча бирәм.

— Бер кеше һәм бер буын гомерендә Габдулла Тукай исемле бөек бер могҗизаны аңлап, ахырынача аңлатып бетереп булмый. Бу гаҗәеп шәхеснең иҗаты искиткеч. Аның бөтен асылына төшенеп җиттем дигәндә, синең алда яңа тирәнлекләр, яңа офыклар ачыла, яңа буяулар, яңа яклар балкый башлый. Яңара баручы заман югары күтәрелгән, рухи яшәешебез байый барган саен, Тукай тагын да зуррак биеклеккә ирешә — ул татарның әлегә тарих белгән иң бөеге. Фикере һәм эше белән заманны куып узган генийларның язмышы шундый — алар уннарча, йөзләрчә елдан соң да үзләренә киләчәктән юнәлгән нур белән яктыртыла. Нинди генә давыллар булып узмаган, нинди генә озын юллар, куркыныч борылышлар, текә кыялар артта калмаган! Ә Тукай гел алда!

Әйе, дөнья культурасының, безнең түгәрәк планетабызның кайсы гына җиреннән карасак та, һәрчак алда торган, безне сокландыргыч бер эндәшү белән чакырып торган биеклекләр, маяклар бар. Бу сүзләрне мин Данте, Шекспир, Гете, Пушкин, Тагор, Шевченко, Тукай кебек биеклекләр турында уйлап әйтәм.

Габдулла Тукай, безнең кайберләребез кебек, һәр адымында халыкны кайнар яратуы, аңа тугрылыгы турында антлар әйтеп йөрмәгән. Чөнки ул үзе үк халыкның яратуы да, анты да булган. Ә халык бары тик үзе белән тиң булып сөйләшкән, ярашу нияте белән генә җырламаган һәм еламаган, үзе алдында ялагайланмаган, кәпрәймәгән шагыйрьләрне генә үзенеке дип таный. Поэзиядә күпме уйсыз-җансыз сүз әйтүчеләр, күпме ялланган яшь түгүчеләр булган — алар онытылган. Ә Тукай калды! Чөнки ул, милләтнең җәрәхәтен җырда җырлап, аның өметләрен раслады, омтылышларын данлап, аның көчен раслады, сүзен җырлап, аның телен, рухын раслады һәм ныгытты.

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Ул гына да түгел, үзенең яшендәй кыска гомерендә милләтчеләр һәм милләтчелек белән көрәшеп, ул үзенең күпме хәсрәт кичергән, уянып, күтәрелеп килгән милләтен яклады, аны саклады, раслады. Шагыйрьнең социаль-иҗтимагый, эстетик һәм әхлакый идеаллары аның талантына вак гайбәтләр дә, татлы вәгъдәләр дә, куркыныч янаулар да көрәшче позициясеннән читкә этәрмәгән җитлеккәнлек һәм алдан күрә алучанлык бирде. Ул үз халкына хәзер һәм һәрвакыт кирәк нәрсәне яхшы белеп торды. Ул үзеннән — шагыйрьдән хәзер һәм һәрвакыт нәрсә кирәклеген яхшы аңлап торды.

«Үләбез!» дип елаган һәм үксегән милләтчеләр артта калды, милләт алга китте, Тукай — алда.

Төрки телләре дөньясында шулай тиз һәм нык итеп күпме халыкларның рухи тормышына кергән һәм халыкара хәзинә булып әверелгән башка шагыйрьне атавы кыен. Безгә, башкортларга килгәндә, Тукай әдәби күренеш кенә түгел; аның безнең милләтнең рухи яңаруы, үсүе,

үз-үзен тануындагы урыны һәм роле әйтеп бетергесез зур. Тукай моңы, Тукай әдәбе, Тукай иманы — безнең мәңгелек хәзинәбез. Тукай — безнең бик күбебезне кулыннан җитәкләп сихри поэзия дөньясына алып кергән милли шагыйребез, остазыбыз.

Әгәр дә без бу хакта бер генә мизгелгә булса да онытып торсак, без бөтен чирләрнең дә иң куркынычларыннан берсе булган хәтер югалту авыруы белән авырыр идек. Хәтер югалту — хыял югалту кебек үк куркыныч. Бу бигрәк тә анага һәм остазга карата булганда куркыныч. Көндәлек тормышыбызда да, тантана көннәрендә дә без Тукай истәлеге, аның бүгенгесе, үлемсезлеге алдында чиксез рәхмәтле, һәм без аның алдында ихтирам белән баш иябез...

Мостай Кәрим, шушы фикерләренә өстәп, Кырлай урманында, Габдулла Тукайның 90 еллык бәйрәмен үткәргән чакта, болай диде:

— Тукай халыкныкы. Бөтенләе белән. Ул татар халкының мең еллык тарихыннан, күңел хәзинәсеннән үсеп чыкты.

## Ил бәясе

Театр фойесының буеннан буена өстәлләр тезелеп киткән. Өстәлләрдә — китаплар, китаплар, китаплар. Күргәзмәнең бик төгәл билгеләнгән бүлекләре бар: Мостай Кәрим һәм проза, Мостай Кәрим һәм драматургия, Мостай Кәрим һәм публицистика, аннары — әлбәттә, поэзия.

Шагыйрьнең башкорт телендә, илебез халыклары телендә, ниһаять, чит ил телләрендә чыккан китаплары, зур бер диңгез булып, җәелеп ята...

Башкорт дуслар шагыйрьнең бәйрәмен — тууына 60 ел тулу һәм аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү тантанасын әлеге күргәзмәдән башлап бик дөрес эшләгәннәр. Күргәзмәгә бер күз сирпеп алу белән үк, Мостай Кәримнең иҗаты никадәр киң колачлы һәм күп яклы икәненә тагын бер тапкыр ышанасың.

1979 елның 26 октябрендә, Башкорт дәүләт опера һәм балет театрының тамаша залына кергәндә, без күргәзмәне күздән кичереп, Мостай Кәримнең кырык еллык илһамлы хезмәтенә сокландык.

Аның хакындагы сүзне юбилей кичәсендә партиянең Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре Мидхәт Закир улы Шакировның үзе әйтүе дә аның иҗатының зурлыгын, башкорт әдәбиятына яңа үрләр яулавын раслады. Илебезнең барлык республикаларыннан килгән утыздан артык язучы, артист, галим һәм фронтовик дусларының Мостай Кәримгә әйтер сүзе күп икән.

Бәйрәм тантанасы бер көнгә генә сыймады. Зур тантанадан соң, без Башкорт дәүләт университетында, шагыйрьнең туган авылы Кәләштә, Чишмә район үзәгендә булдык.

Мостай аганың иҗатын якыннан белгәнгә, аның үзе белән егерме ел буе аралашып, фикер алышып яшәгәнгә, төрле-төрле кешеләрнең аңа биргән бәясен ишетү миңа кызык булды, шагыйрьнең минем күңелемдә туган образы белән илнең аңа биргән бәясен чагыштырып карау мөмкинлеге туды.

Аңа карата, әйтелгән сүзләрне мин язып барырга тырыштым. Инде менә хәзер, Казанга кайтып, тынычрак шартларда укып карагач, әлеге коллектив бәянең никадәр дөрес, сәнгатьчә бизәкле һәм тирән мәгънәле булуын күрдем. Күңелдә хәтта бер генә мизгелгә үкенү хисләре уянды: безнең бит никадәрле кыйммәтле сүзләребез бәйрәмнәрдә, әйтелгән урыннарында югалып калалар, мәңге кире кайтмаслык булып онытылалар.

Шуңа күрә Уфада, Чишмәдә һәм Кәләштә язганнарымның кайберләрен укучылар карамагына тапшырам.

**М. З. Шакиров.** Мостай Кәрим сугыш яланнарында койган каны, солдат каһарманлыгы белән шагыйрь-коммунист дип аталу хокукына лаек булды һәм ул тормыштагы, иҗаттагы һәр адымын коммунистик әхлак һәм дөньяга коммунистик караш принциплары белән үлчи.

Мостай Кәрим иҗаты — совет әдәбиятының алга үсешендә тоташ бер чор. Ул сугышка чаклы, үнтугыз яшьлек егет чагында, тәүге шигырьләр җыентыгын чыгарганнан соң, менә инде кырык ел буе күп жанрлы әдәби иҗат юлыннан кыю рәвештә алга атлый. Ул башкорт әдәбиятыннан гомумсоюз һәм гомумкешелек әдәбиятына күпер салды, шуның белән туган халкының күңелен ныграк аңларга мөмкинлек тудырды.

**Чыңгыз Айтматов.** Мостай үзеннән-үзе генә туган шәхес түгел, тарихи зарурлыктан, халык йөрәгеннән туган шәхес. Рухи, әхлакый, эстетик кыйммәтләрне гәүдәләндерү бурычы — бик җаваплы бурыч. Мостай Кәримнең Башкортстан турында әйткән сүзе дөнья күләмендәге әһәмиятле сүз булып яңгырый.

**Сергей Михалков.** Иң яхшы аудитория — балалар бакчасы. Ә сез, студентлар, бераз олырак яшьтә. Без сезгә әйтәбез, без Мостайның юбилеен үткәрешергә килдек. Чыңгыз Айтматов — Азия һәм Африка илләре киносәнгате буенча чит илдә зур киңәшмә үткәрә иде, шуны бүлеп, Прага аша Мәскәүгә, Мәскәүдән Уфага килде, инде менә туган җиренә, Фрунзега кереп тә тормастан, тагын халыкара киңәшмәгә китә. Бу — Мостай Кәримнең зурлыгын сөйли торган факт.

Шагыйрьгә Алтын Йолдыз бирделәр. Юбилейдан соң, яңа-ялгызын калгач, күңелгә төрле уйлар килә. Иҗатың хакында да, гражданлык вазифаң хакында да уйлыйсың. Мин моны үземнән чыгып әйтәм.

Мин Мостайга карыйм, ул моңсу, күкрәгенә тотына.' Безгә тотын, без сиңа тотынырбыз.

**Әсгать Мохтар.** Мин башкортча белмәсәм дә, татарча ничава сукалыйм. Без, Зөлфия ханым белән икәү, Үзбәкстан иленнән Мостайга сагыну сәламнәрен һәм ихтирам хисен алып килдек. Шуны мин шигырьгә салдым. Укырга рөхсәт итегез.

Бүген хөрмәтеңә йолдызлы төннән
Мин илаһи тынлык теләдем.
Азиянең зәңгәр кырларында
Чәчелеп ята синең йөрәгең.
Чәчелеп яткан йөрәк чаткылары,
Сизәсеңме, кабалананлар.
Сиңа моңсу уйлар килде мәллә:
Бик сабырсызланып яналар.
Моңсу уйлар килсә килгәндер шул,
Безнең картлык шактый соңлады.
Шигырь бетмәгәнче ярсу басылмый бит,
Ә шигырьнең соңсыз моңнары.
Без үлмәбез, изге хыялларда
Соңсыз моңнар белән яшәрбез.
Мәңгелеккә бу көннәребезне
Шигъри моңнар белән дәшәрбез.

**Кайсын Кулиев.** Салкын кымыздан минем тамагым карлыкты. Әмма йөрәгем кайнар минем, Кавказ йөрәге. Миң бүген студентлар аудиториясендә Мостафаны күрүемә шатмын, чөнки шагыйрьләрнең студентлардан да зуррак дуслары юк. Фикердәшләрем минем, җир йөзендә студентлар бар чагында, без, шагыйрьләр, бер нәрсәдән дә курыкмыйбыз. Дөнья поэзиясе — иң борынгы шагыйрьләрдән башлап Мостай Кәримгә кадәр — фидакарьлек белән тулы.

**Михаил Дудин.** Кадерле Мостай, миңа алтмыш яшь тулган чакта, люстралар сүнде. Мин дустыма шалтыраттым, ул килеп люстраларны кабызды. Мин төньяк котыпка очтым, аннан кайткач, үземдә яшь ча-

гымдагы, инде онтылып бара торган көч сиздем. Котыпчылар миңа фронтовикларны хәтерләтте. Алар бер-берсе өчен теләсә кайчан үлемгә барырга әзерләр. Дөньяда шундый мөнәсәбәтләр барында, җан дустым Мостай, яшәве рәхәт.

**Давид Көгелтинов.** Мостай исеменә алкышлар ява бүген. Ләкин дөньяда моңсу кешеләр дә бар, хәсрәтле кешеләр. Җир йөзендәге хәсрәтле кешеләргә Мостайның талантлы якты поэзиясеннән нур төшсен, алар хәсрәтләрен онытып торсыннар иде...

**Әбү Сөрсенбаев.** Казакъ әйтә, үзең үргә күтәрелсәң, артыңа борыл, артта калганга кул бир, ди. Мостай элек тә шулай иде, хәзерге биеклегеннән дә шулай булып калыр дип ышанам.

**Мин сөйләгәннәре.** Кадерле дуслар, кадерле Мостай ага! Бу зур бәйрәмдә, без, татар язучылары, сезгә күптән билгеле булган бер хакыйкатьне әйтеп бирергә телибез. Егермедә егеткә көч кирә, утызда егетнең кулыннан эш килә, кырыкта егеткә аң килә, илледә егеткә дан килә, ә алтмышта... егеткә чаң кирә! Ягъни табигать биргән көчне, нәселең биргән сәләтне, халкың һәм җәмгыять биргән данны, дәвер биргән аңны син ничек гамәлгә ашырганны тикшерү-барлау сәгате суга. Син, Мостай ага, утны-суны, сугыш давылларын әйбәт уздың, халкың йөзенә кызыллык китермәдең. Шуның өчен рәхмәт сиңа.

Башкортстан белән Татарстан өстендә, куе зәңгәр күк йөзендә ике йолдыз балкып яна иде. Алар үзләренә лаек кешеләрне көттеләр. Берсе аның Муса Җәлилнең гражданлык батырлыгын, икенчесе Мостай Кәримнең шигъри батырлыгын сайлады.

Без, Татарстан язучылары, Мостай Кәрим белән горурланабыз һәм аңарда үзебезнең дә өлеш бар дип саныйбыз. Мостай Кәрим иң җаваплы очрашуларда, телевизион тапшыруларда һәм зур кичәләрдә шигъри осталык мәктәбенең башы итеп Тукайны күрсәтә. Бу аны безгә һәм хакыйкатькә туры килә. Тукайның бөеклеге — мең еллык шәрык поэзиясенең зирәк һәм сабыр акылын көнбатыш поэзиясенең революцион чакыру авазы белән куша белүендә. Тукай поэзиясендәге әнә шул төп сыйфатны яңа шартларда үстерә белүе, көчле поэтик таланты белән Мостай Кәрим безнең илнең төрки телләрендәге поэзиясен дөнья поэзиясенә китереп тоташтырды.

**Тамара Искәндәрова.** Мин Башкортстанның студент яшьләре исеменнән әйтәм. Мостай Кәримнең яшьлек рухы, оптимизм һәм халыкчанлык белән сугарылган иҗаты безгә һәрвакыт кадерле.

«Үз халкыңның сәнгатьчә эстетик тәҗрибәсен алу белән генә чикләнергә ярамый. Яки, киресенчә, башка халыклар тәҗрибәсен алып та, үз халкың тәҗрибәсен оныту яраган эш түгел. Үзеңне аңламый торып, башкаларны аңлап булмый, башкаларны өйрәнмәсәң, үзеңне аңлый алмыйсың», — Мостай Кәримнең бу сүзләре иҗат яшьләренә вәгазь булып ишетелә.

## Туган туфрак җылысы

Без Уфага килгәндә, урамда суык ике градустан артмый иде әле. Тагын бер көннән ул дүрт градуска, ә 28 октябрь көнне ун градуска җитте. Төнлә кар яуган, дөнья ап-ак иде. Илле урынлы автобус, уннап җиңел машина, зәңгәр һәм кызыл утлы милиция машиналары безне Мостай Кәримнең туган якларына алып киттеләр.

Мостай Кәрим үзе безнең белән автобуста барды, гид урынына утырып алып, микрофонны кулына тотып, сөйләде дә сөйләде. Гади иде ул хәзер, җир кешесе иде, яшьләреп искә төшерде, мәзәкләр сөйләп, туйганчы көлдерде һәм моңсуландырды.

Туган авылы Келәшкә җитәрәк, ул болай диде:

— Келәштә каланчага куялар иде безне: иген сакларга. Безне дигәнем — пионерларны. Иген саклау дигән сылтау белән җаваплылык хисе тәрбияләгәннәр, күрәсең...

Авылны чыккач, без бер түбәгә менәрбез, әллә ни зур түбә түгел ул. Келәш халкы ул хакта: «Дөньяда иң биек түбә — Келәш түбәсе, иң нык тәүбә — тукран тәүбәсе», — дип көлеп сөйли иде. Без өйләнешкәнче Рауза белән шул түбәгә килә идек...

Автобус кунакларны шул түбәгә алып менде. Түбәгә имән ботакларыннан шалаш ясап, ут якканнар: чатыр-чотыр яна. Мәхәббәт учагы дип аңлаттылар моны. Бәлки ул шагыйрь бәйрәменә килгән төрле милләт вәкилләренең дуслык учагыдыр.

Авылга кердек. Зур, күп йортлы. Байлыгы чекрәеп күзгә ташланмый. Салам түбәле лапаслар белән мунчалар да очрый. Түбәләр ак, урамнар ак. Аяк астында кар шыгырдый. Бер кое түбәсенә плакат элгәннәр. «Келәштә булучылар, Мостай Кәримнең поэзия чишмәсеннән авыз итми китмәгез!»

Мәктәп янында микрофон куйганнар. Түгәрәкләп мәйдан ясадык.

**Колхоз председателе.** Бәлки илдә Мостай Кәримнән дә зуррак шагыйрьләр бардыр. Әмма безнең өчен Мостай Кәримнән дә зур шагыйрь юк. Губернатор килгән безгә — онытылган, Мостай онытылмас.

**Мостай Кәрим.** Күңелем тулы рәхмәт сүзләре. Сез шундый матур, олы итеп каршылый беләсез. Күп илләрне күргәнем бар, сездән зуррак кешеләрне күргәнем юк. Минем эчкән суым, ашаган икмәгем, тамырым сездә, авылдашларым.

## Келәш һәм Чишмә табынында әйтелгән сүзләр

**Зөлфия.** Әсгать Мохтар белән мине бередә ак кар каршылады. Саф ак кар — үзбәк өчен могҗиза. Тау түбәсендә безне учак каршылады. Мостайның җаны халык җылысыннан җылынуын белсәк тә, символ булып кабынган учак дулкынландырды. Безнең үзбәкләрдә һәм таҗикларда киленне ишек алдында учак ягып каршы алалар.

**Сергей Михалков.** Тещаны утка аталар.

**Зөлфия.** Мин юмор аңламыйм. Сүземне дәвам итәм. Кияү балакай киленне өч мәртәбә учак тирәли әйләндереп алып чыга. Раузаның бүген яшь килен булганы өчен тост тәкъдим итәм.

**Нажар Нәҗми.** Мин әлерәк кенә Трускавецтан кайттым. Шифалы бер чишмәнең үз янына бер мең кешене җыйганын күрдем.

**Сергей Михалков.** Авыруларны.

**Нажар Нәҗми.** Әйе, авыруларны. Мостай Кәримнең шигъри чишмәсеннән шифалы су эчеп килгән без — авырулар ул чишмәнең озын гомерле булуын телик.

**Әхияр Хәкимов.** Мостай Кәрим Чишмәдә туган, мин — Дәүләкәндә.

**Мостай Кәрим.** Димнең суын сез болгатып җибәрәсез икән безгә.

**Әхияр Хәкимов.** Зөлфия апа, юморны аңламыйм, диде, мин аңлыйм. Без, Мостай ага, суны Димнән түгел, Өршәктән эчәбез. Әмма поэтик Чишмәбез — Мостай Кәрим. Әнә шул чишмәнең гел саф сулы булуын, кешеләрне гел үз янына чакырып торуын телим.

**Игорь Васильев.** Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре комитетының гыйльми секретаре буларак, әйтәм: Мостай СССР Дәүләт премиясен бер тавыштан алды. Инде хәзер шул комитетның члены буларак, намус белән, объектив эшли.

**Дмитрий Хренков.** Без Келәшкә килгәндә, түбәдә учак кабынды. Михалков анда тещаны ыргытырга кирәк, диде. Минемчә, учакка тәнкыйтьчеләрне ыргытырга кирәк. Без — тәнкыйтьчеләр — Мостай Кәрим хакында әле төп сүзне әйтмәдек. Пушкинның «Капитан кызы»нда тел-

сез башкорт бар. Символ. Башкорт хәзер телле. Тагын шушы түбәгә килергә, телле башкорт өчен сөенергә язсын.

**Туфан Миңнуллин.** Мин бәләкәй чакта Хуҗа Насретдин мәзәкләрен сөйлиләр иде. Мин бәләкәй чакта аны безнең авылныкы, үсә төшкәч, безнең районныкы, югары уку йортында белем алгач, бөтен илнеке дип белдем. Мостай Кәрим дә шулай.

**Сергей Михалков.** Нәрсә өчен тост күтәрәбез?

**Туфан Миңнуллин.** Әтиемне мин никадәр яратсам да, әти дим. Әниемне мин никадәр яратсам да, әни дим. Хатыныма мин никадәр яхшы мөнәсәбәттә булсам да: «Әй!» дим. Мостай Кәримне без никадәр зур итсәк тә, «Мостай абый» дибез, шуның белән бөтенесе дә әйтелеп бетте.

**Айвар Клявис.** Бу моментта мин латыш язучыларының рәсми вәкиле булудан туктыйм, Мостай Кәримнең миллион укучыларыннан берсе булып калам. Бу төндә җир өстенә ак кар яуды, мин Мостай Кәрим иҗатындагы аклык, сафлыкны яклыйм.

**Илгиз Кәримов.** Әтигә, Михаил Александрович Дудинга утызар яшь иде. Без Келәштә идек ул чакта, 1949 елны. Без Михаил Александрович белән төнлә балыкка бардык. Балык, әлбәттә, кермәде. Михаил Александрович әйтте: төнлә, вак шагыйрьләр кебек, вак балыклар гына йөри, ә вак балык ахмак була ул, зур җимне танымый, диде. Шул истә калды.

Бер мәлне Михаил Александрович югалды. Әтинең шигырьләрен тәрҗемә итә-итә арыды бугай. Өч көн торгач кына кайтты. Күкрәгенә тере тавык кыскан, ишек төбендә юаш кына басып тора. Әнигә әйтте: Рауза, мине ачуланма, мин начар кеше түгел, диде. Ул да истә калды.

Бер көнне шулай әни тәрәзә буена утырып тегү тегә. Үзе «Сарман буйкайларын» җырлый. Моңлы җыр, әллә ниткән хисләр уята. Яшь булган икән әни, моңлы булган икән, ул чагында аңламаганмын, хәзер генә аңладым.

Әти белән Михаил Александровичның шул елларны, моннан утыз ел элек, төшкән фотолары бар. Келәш базарында. Биш минутлык фотографиядә. Икесе дә явыз. Михаил Александрович — ябык, озын явыз, әти — юан, юаш явыз. Кулларында — кылыч, күзләрендә — ут. Яшь геройлар. Хәзер минә алар икесе дә герой. Олы, чын геройлар. Аларның яшьлеге өчен тост тәкъдим итәм.

**Сергей Михалков.** Мостайның дуслары сөйләде, каләмдәшләре сөйләде, улы сөйләде, ник хатыны сөйләми? Сөйләсен, азиятларның хатын-кызны кимсетә торган заманнары узды.

**Рауза ханым.** Мин Мостайның данына мөкиббән китеп яшәмим. Мине аның дуслары күп килү шатландыра. Кырык эшләрен кырык якка ташлап килүләре. Мин Мостайның авыр көннәрен күрдем. Әнә шул авыр көннәрендә мин аңар аз гына булса да ярдәм итә алган булсам, шушы көчсез җилкәләремә йөк күтәрә алган булсам, мин үземнең бурычымны үтәлгән дип саныйм. Әгәр миңа хәзер әйтсәләр, аның тормышында шундый-шундый авырлыклар була, аңа кияүгә чыгасыңмы, дисәләр, чыгам дияр идем.

**Сергей Михалков.** Социалистик Хезмәт Герое була дисәләр дә чыгар идегезме?

**Рауза ханым.** Күземне йомып булса да чыгар идем.

**Мостай Кәрим** (өч кичәдә һәм дүрт банкетта әйткән сүзен берләштереп бирәм). Бик җаваплы бер белдерү ясарга рөхсәт итегез. Хатын-кызлар, иң элек сезгә рәхмәтемне белдерәм. Сез иртүк торгансыз, парикмахерга чиратка баскансыз, минем бәйрәмемә чибәрләнеп килгәнсез. Мин моны үз чутыма кабул итәм: димәк, мин әле беткән баш түгел.

Мине үз йортым, Башкортстан Язучылар оешмасы үги итмәде. Шу-

шы туган коллективым мине тиешле югарылыкта торырга, вакланмаска өйрәтте. Партиянең Башкортстан өлкә комитеты минем бәйрәмемә үзенең шәхси эше итеп карады. Язучылар оешмасына, партия өлкә комитетына, Министрлар Советына рәхмәтемне белдерәм.

**Таһир Ахунжанов.** Мостафа Сафич юбилейны обкомның шәхси эше итеп караганлыгын әйтте. Без шуңа омтылдык, шуңа ирешүебезгә шатбыз. Без үзебезнең партоешмада тәрбияләнгән коммунист Кәримов белән горурланабыз.

**Мостай Кәрим.** Кадерле иптәшләр, дуслар! Моннан нәкъ ун ел элек мин шушы урында, трибуна янында басып тора идем. Сез нәкъ шул урында, залда, утырып тора идегез, берни дә үзгәрмәгән, сез һаман яшь, һаман чибәр. Рәхмәт сезгә ун елдан соң мине котларга килгәнегез өчен. Миңа карата бик күп олы сүзләр әйтелде. Мин бүген әйтелгән сүзләр төбәлгән кешегә охшарга бик теләр идем.

Безнең Башкортстаныбызга шундый күренекле язучылар килде — миңа бик рәхәт. Кайчандыр, моннан йөз ел элек, безнең авыл аша губернатор узган, аның хөрмәтенә бер урамны губернатор урамы дип атаганнар. Безнең теләсә кайсыбыз ул губернатордан ун баш, йөз баш югарырак.

Дуслык хакында бик җылы сүзләр булды. Дуслык ул — бер-береңне саклау. Биредә минем сугышчан дусларым, кыен чакларымны уртаклашкан коралдашларым утыра; биредә мине үлемнән йолып калган кеше, ул чагында гади бер врач, хәзер бөтен дөньяга билгеле академик, Ленин премиясе лауреаты Лев Александрович Богуш утыра. Минем аларга рәхмәтем чиксез.

Кадерле дуслар, мин сезне ышандырырга телим: миңа карата әйтелгән олы сүзләрне мин аралап кына кабул итәрмен. Артыгын алудан мин гел куркып яшәдем. Бер мәлне, үсмер чакта, беренче шигыремне язгач, мине үзебезнең авылның бер егете, укытучы, болай дип мактады: «Аны хәзер Келәш белә, аны хәзер Чишмә белә, аны хәзер бөтен Уфа белә!» Ул чакта әле мине берәү дә белми, минем ул шигырем басылмаган иде әле...

Иптәшләр, минем әдәбият өлкәсендәге кырык еллык хезмәтем нәтиҗәлары, бик югары бәяләнде. Тормышымның бик тә мөһим бер тукталышында мин бердәнбер антымны — Ватанга турылыклы булум хакындагы антымны кабатлыйм. Мин янә дә азаккы сулышыма тикле сезне яратырга, хәсрәт-кайгыларыгызны күтәрешергә вәгъдә итәм. Ярату һәм хәсрәт уртаклашу — минем эш, минем өлешемә чыккан көмешем, минем борчуларым...

Бәйрәм күкрәүләре узды. Без аның белән тагын Мәскәүдә, язучылар киңәшмәсендә очраштык. Ул көтмәгәндә, салкын тидереп, авырып китте. Мин аның койкасы янында утырып тордым. Безгә иркенләп бер сөйләшергә мөмкинлек булды.

Бәйрәмендәге уй-тойгыларымны сорашты ул минем. Үзен ничек тотуын, кешеләрне уңайсыз хәлгә куймаганмы икәнен сорашты. Аннары ифрат та якын итеп, миңа матур киенеп йөрергә, барлык яктан үрнәк булырга кушты. Мин матур киенүгә каршы төшкәч, күңелсезләнде, ул синең өчен түгел, халкың өчен кирәк, чөнки син хәзер бер әдип кенә түгел, халкыңның вәкиле, сиңа карап, халкың хакында фикер йөртәчәкләр, диде.

Ул миңа адым саен шаян сүз әйтмәскә, тыенкырак булырга кушты. Мин хәтта Рәсүл Гамзатов кебек кайнар темпераментлы Кавказ шагыйрен дә мәзәк сөйләүдән яртылаш тыйдым, диде.

Ул миңа киңәшмәләрдә бик зур игътибар белән тыңлап утырырга, сүземне уйлап җиткермәстән, ашык-пошык әйтмәскә кушты. Моны ул

үзенең ачы тәҗрибәсеннән, үкенүләреннән чыгып әйтүен белдерде.

Мин аның койкасы янында утырып тордым, аның сүзләрен тыңлый-тыңлый, үз уйларымны уйладым. Табигать аңа зирәклекне, мөлаемлыкны йөге белән өеп биргән. Талантлы шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы, публицист, зур дәүләт эшлеклесе Мостай Кәрим үзен ихтирам итә белгән кешеләргә ничәмә еллар инде йогынты ясап килә, һәм бу йогынтының көче елдан-ел үсә, арта бара.



# СӘНГАТЬНЕҢ КӨЧЕ

*Йомгаклау сүзе урнына*

Без олы сүз һәм акыллы фикерне күбесенчә китаплардан эзләргә күнеккәнбез. Ә андый сүз кайвакыт гап-гади бер әңгәмә вакытында да туа торган була.

1979 елның декабренда драматург Туфан Миңнуллинга һәм аның театрдагы коллегаларына К. Станиславский исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе бирелде. Без, әдипләр, моңа чиксез сөендек. Культурабызның ил күләмендә тагын бер мәртәбә бәя алуы күңелгә хуш килде. Димәк, халкыбызның талантлар чишмәсе әле кипмәгән, татар әдәбиятының әле ачылмаган мөмкинлекләре бар дигән сүз.

Шул уңай белән без Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү бүлегенә җыелдык та сүз куертып җибәрдек. Мәҗлескә җыелмадык. Күңелләр бик күтәренке, өйгә кайтып китәсе килми иде, шуңа күрә җыелдык. Газетчылар теле белән әйткәндә, түгәрәк өстәл янына җыелдык.

— Бәхетле кеше син, Туфан, биш ел эчендә өч премия, шуның өстенә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исемен алдың, — дидем мин. — Монда синең татар әдәбиятына керткән өлешең дә, шул ук вакытта сине чолгап алган тирәлекнең синең иҗатыңа карата ихтирамлы булуы да ярдәм итте. Синең үз-үзеңә таләпчән, бер генә пьесаңда да үзеңне кабатламавың халык алдында да, язучылар җәмгатьчелегендә дә сине күтәрде. Яшерен-батырын түгел, бездә әдәби иҗатка җиңелрәк караучылар да бар. Андый кешеләр көчләрен сәнгать әсәре тудыруга сарыф итәсе урында, терсәкне киереп, башкаларны этеп-төртеп, алгы сафка чыгарга омтыла башлыйлар. Көндәлек тормышта этешү-төртешү әрсез адәмнәргә бәлки уңыш та китерә торгандыр, әмма әдәбият-сәнгать дөньясында җитди уңышка табигый таланты, актив гражданлык позициясе, культура үсеше өчен җаваплылык хисе булган шәхесләр генә ирешә.

Барыбызга да мәгълүм: йолдызлар галәм тирәнлегеннән калка, талантлар халыкның гасырлар буена җыелган рухи хәзинәсеннән үсеп чыга.

Әдәбиятка сугыштан соң килгән буын вәкилләре: Рафаил Төхфәтуллин, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Хисам Камал, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Шәриф Хөсәенов, Юныс Әминов, Нурихан Фәттах, Хәсән Сарьян, Мөхәммәт Мәһдиев, Эдуард Касыймов һәм тагын башка байтак талантлы каләмдәшләребез тарихи зарурлыктан, халык күңеле байлыгыннан үсеп чыктылар. Мин моны «Йолдызлар калка» повестенда үзебезнең татар әдәбиятындагы өлкән буын әдипләр үрнәгендә, янә дә килеп, тугандаш әдәбиятлардагы Чыңгыз Айтматовлар, Мостай Кәримнәр үрнәгендә күрсәтеп бирергә тырыштым. Урта буынның иҗат тәҗрибәсен укучыга җиткерү әле минем өстә кала.

Сибгат Хәким — әдәби аңгәмәләрнең һәрвакыт уртасында була торган, культурабыз үсешенә гел дә игътибар итеп килгән әдип — бүген башта тыныч кына, табигатенә хас сабырлык белән генә тыңлап утырды. Аннары Туфан Миңнуллинга карап сүз башлады:

— Без хәзер, Туфан, синең белән тигез: икебез дә РСФСРның Дәүләт премияләре лауреаты. — Кысылып бетә язган күзләрендә шаян очкыннар биешеп алды. — Татар әдәбиятын күтәрдең син. Рәхмәт. Мена шушы, культурабыз үсешендәге күңелле бер дәвердә минем сезгә, егетләр, әйтәсе килгән сүзем бар. Муса Җәлилнең алтмыш еллыгы алдыннан Гази Кашшаф, мин, Әминә ханым — Мусаның хатыны — Берлинга бардык. Шәһәрләр дә, йортлар да күрдек. Берсе дә әллә ни тәэсир итмәде. Севастьян Бах каберен карадык, Бахның орган музыкасын тыңладык, күңелләр тетрәде. Ике Германия бергә кушылырга килә кебек күкри музыка. Гази Кашшаф җәлилчеләр һәм татар әдәбияты хакында Германия-Совет дуслыгы җәмгыятендә доклад ясады. Тәрҗемәче аның докладын немецчага тәрҗемә итеп барды. Әнә шул чагында ул, Тукай, Такташ исемнәрен әйтә алмый аптырап бетте. Әйттем Гази абыйга: ашыкма, ун кат әйтсеннәр, әйтергә өйрәнсеннәр Тукай белән Такташны, дидем, чөнки без Европаны саклап калдык. СССР халыклары саклап калды Европаны. Коллыктан, фашизм чирүеннән. Татар халкының да бу изге көрәшкә керткән өлеше зур. Ике йөздән артык Советлар Союзы Герое! Орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән татар сугышчылары житмеш меңнән артып китә! Европа үзен азат иткән совет халыкларының культурасын, мөкатдәс кешеләрен белергә тиеш!

Шушы уңай белән тагын бер нәрсәне әйтәсем килә: Германиягә барганда, поездда моңлы көй уйнап җибәрделәр. Күңелгә уй килде: әгәр мине шушында поездан төшереп калдырсалар, озата баручы бирмәсәләр, мин җәяүләп өйгә кайта алыр идемме? Кайтыр юлны таба алыр идемме? Озатучы бирмибез, сәнгать бирәбез, нәрсә сорыйсың, дисәләр, мин әйтер идем: бирегез миңа Сәйдәш моңын, мин шул моңга тотынып, туган җиремә кайтып китәм, дияр идем.

Илдар Юзеев тә әйтер сүзен Тукайга китереп ялгады:

— Беләсезме, — диде ул. — Үләр алдыннан Тукай туган авылы Кушлавычка кайткан. Хәле кыен. Тәрәзә буеннан урамны карап ята. Урамнан кышкы суыкта бер малай ялан аяк йөгереп бара. Тукай үзенең бердәнбер киез итеген әнә шул малайга чыгарып бирә. Әдәбиятта буыннар гел алмашып тора. Өлкәннәр үз тәҗрибәләрен, йөрәк жылыларын үзләреннән соң килгәннәргә бирәләр. Без, урта буын, Тукайлар, Такташлар мәктәбен уздык. Инде менә хәзер без үзебез өч дистә ел жыйган тәжрибәбезне яшьләргә бирергә, яшьләрне тәрбияләргә тиешбез. Тик шул чагында гына без тыныч күңел белән әдәбият һәм сәнгать дөньясында яңа йолдызлар калкуы, яңа талантлар үсеп чыгуы хакында сөйли алырбыз.

*Казан — Идел буе дачасы,*
*1979*

Рәдиф Гатауллин

# ФЕНИКС–ҮЛЕМСЕЗ КОШ

## Мәңгелек чаң

Бу чаң нигә яңгырый һаман? — дип сорама. Синең өчен яңгырый, синең рухка багышланган!

Джон Донн

— Юк, әйтегез,
кем рухына багышланган бу чаң?

Изге Павел соборында бүген
шагыйрь һәйкәленә карап, ник мин
уйга калдым әле шул сораудан?

— Джон Донн һәйкәле — изгеләрдән, —
ди гидыбыз һаман.—
Ничә кабат янган Лондон. Собор янган.
Ә бу һәйкәл исән калган!

Шагыйрь рухына аталганмы? —
Яңгырый һаман, яңгырый чаң!

Изге булмаган, юк... алдан күргән:
— Бер кыяны гына дулкын кыйсын —
материк кечерәя.
Европа тәнендә ул — зур яра, дигән.
Җирдә бер генә кеше үлсен —
кешелекне кайгы сара,— дигән.

— Даң-даң!
Димәк, барыбыз өчен яңгырый ул чаң?

Мин Лондонда. Изге Павел соборында...
Гамьсез турист түгелмен:
дөнья язмышын уйлыйм мин.
— Котыла алырсыңмы, Кешелек,
үзең үк тудырган фаҗигадән?
Сез ник тыныч, Париж, Нью-Йорк, Лондон?
Акылмы соң сездә уянмаган?
Ишетегез, сезнең өчен дә — чаң!
Хемингуэйга да ул шулай яңгыраган...

Бөек гасыр аңы
бәхет көтеп, кырыкка ярган

матдә-атомнардан
бомба ясарлармы һаман?

Әнә:
— Даң-даң!
Синең өчен, минем өчен бәлки?!

Булмасмы ул
Кешелек рухына ук багышланган
Җирдә соңгы зур чаң?
Әй, Джон Донн?!
Син дәшмисең. Дәшми — Лондон...

## Империя белән сөйләшү

Британия!
Әйе, арыслан син:
яраланган ләкин, нык картайган.
Сине усал диләр һаман.
Кайда сикерә аласың соң
бүген, «бөек» империя —
Британия!

Тарих агышы суытмаган, ахры,
синең зәңгәр канны?
Әллә сукыр горурлык гел кайнар, яшьме?
Нинди булыр синең соңгы язмыш?
Темза ярындагы
сфинкслар бу турыда дәшми.
(Алар — Мисырдан «трофей», Клеопатра сараеннан!)
Җавап көтим каян?

Англия!
«Кай диңгезгә» илтә синең юл?
Нәрсә яза яңа Киплингларың —
империянең каләм рыцарьләре?
— Дөньяны тотачак тик көчле, корыч кул.
Альбион, уян! — диләрме?!
Кайда ул борынгы көч?
Кайда «тимер» политиклар —
Чемберлен, Черчилльләр?
Англиягә нота язган Такташ, ишет:
мин — Темзада,
Тэтчер ханымга
ирешер бәлки минем шигъри сүзләр?!

Бәлки мин үзем дә «консерватор» —
«империя яклы» шагыйрь? —
ошый миңа шундый «агрессор» лар:
бар дөньяны яулап алган Шекспирлар,
«узурпатор»лар — Байрон, Шеллиләр,
мәңгегә таҗ һәм тәхетле ирләр.
Булса икән җирдә тик җыр- шигырь империяләре!
Күп синең шундый императорларың, Англия!
Менә кайда синең иң чын, югалмас дан.
Һәм син бөек — шул даныңны саклап калсаң.

Ишетәсеңме,
Британия-Англия-Альбион?!

## Шагыйрь тавышы

Шагыйрь тавышын—
бер кабат та ишетмәгән,
ләкин гүя иң якын танышым—
Такташ тавышын эзлим, эзлим һаман:
нинди җылы тембрларда,
аһәңнәрдә яңгыраган,
нинди моң белән ул хәтерләрдә калган?
Грамзаписьта юк.
Радиофондта, ни үкенеч! сакланмаган.
Ә бит, бүген һәр «озынчәч» кулындагы
магнитофоннар, сез,
ул исәндә булсагыз...
Тавышын шагыйрь һаман яңгыратыр иде!
Бүген тагын бер танышым:
— Такташ тавышы калмаган шул, — диде.
Такташ тавышы?
Ә соң шагыйрь яшәмиме бездә? Бүгенгедә?
Ул түгелме безнең җырлар,
симфонияләр, поэмаларда?
Ни уйлыйдыр бу турыда минем дустым—
сәер очрак!—
Такташ шигыренең ревизионисты!
Яңгырый, дәвам итә Такташ хәтта анда.
Ул — «Киләчәккә хатлар»да.
Сагынычлы тавышы, еллар белән
ачыклана, тик көчәя бара.
Гомерем буе аның тавышын тыңлыйм,
үлмәс шагыйрь тавышын!
Гел ишетербез —
йөрәкләр саңгырау булмаса:
ул — безнең арада!

●

Хәере белән!.. Җырның башы булсын —
язылды бу, бер юл...
...Июль. Тарих мең дә тугыз йөз дә
җитмеш җиденче ел.
Шәһри Болгар энесе ак Казан
тарафы —бер авыл...
(Үзе җиңел кебек бүген уйлар,
үзе шундый авыр).
Тауга мендем. Күрим, кемнәр ни дип
язганнар ташына?
Ничә сәгать утырам күз текәп
шушы тау башында.
Бәлки иң кирәкле сүзне бүген
таштан укып табам?
Бәлки шунда васыятен уйган
бер-бер оста, бабам?
Ташны еллар юган... Ә мин бары
кәгазьгә җыр язам.

Укырлармы эзләп васыятьләрне,
имин булырмы Җир?
Минем тауга алмаш, дәвамыммы,—
җилгә бирергәме язганымны —
кайсы оның килер?
...Шәһри Болгар дәвамы Казаным
тарафы — бер авыл.
Ташта тик «бисмилла» сүзе. Җырдан
ул иң беренче юл.
Ләкин җанда ул җыр!

●

*Фәрзәнә һәм Тәлгатька*

Туган яклардан искән җил
сәламсез исәмени?..
Чал Уралның курайлары,
Агыйдел сандугачлары
болай да истә минем.
Сандугачлар сайрап җанны
уяттылар җыр өчен.
Курайлар, бәгырьгә үтеп,
аңлаттылар моң көчен.
Авазлары күкрәк тулы,
еракта булсам да мин.
Уралтауның үзе рухта,
үзәндә торсам да мин.
Кем әйтер соң, туган туфрак
суынган дип хисендә?
Җырларымда чагылмыймы
Агыйделем төсе дә?
Җыр телен кайчан да булса
дан, «акча кискән»[1] мени?
...Уралның горур җырлары,
Агыйдел сандугачлары
мәңгегә истә минем!

●

Хатыңа салып җибәргән
Казан яфрагы исән.
Сагынган дип аңла, аны
күрешергә сузган кулдай
сак кына алдым, дисәм.
Сагынганда хисләр дә бит
яктырак, сафрак кебек...
Моң да бер яфрак гүяки —
көз кочагында тирбәлгән
Алтын бер яфрак кебек...
Ә кичен синең яфракны
мин баш астыма куям.
Төшлеге матур: гел яшел
туган җир рухын тоям.

[1] Акмулла шигыреннән.

Аңларсың, Казанга кайтып
синең кулларга сак кына
кагылдым бүген, дисәм.
Соңгы хатыңдагы саф моң
һәм яфрак — миндә, исән!

## Хәсән Сарьян истәлегенә

Яздың:
«Бер ананың биш улы»...—
Бәхеткәме, җиргә ник туды?
Язмышлары белән ни булды?
Кайда, нишли алар бу җирдә —
(Шатлык тулы анда, гамь тулы!)
бер ананың газиз биш улы!

Син — әнкәңнең бердәнбер улы —
үзең
Җир-ананың идең кайсы улы?
Нигә безнең күзләр яшь тулы?
Нигә кыен бүген? Ни булды?
Җирдән китте
әллә бер ананың бер улы,
әллә Җир-ананың бер улы?
Әллә «тирәк төптән киселде,
әллә тирәк кинәт егылды» [1]?
Моң тетрәтте күпме кыз-улны.
Бер югалту — күпме җан тулы!

## «Гамлет» истәлеге

— Кайда барыйк?
Үрәзмәттә клуб ябык — бүген ял бит.
Ә Әмәкәйдә — кино, — ди, — Әмәкәйдә — «Гамлет»!
... Без, дүрт егет, Шекспирга шашып гашыйк булган.
Алты чакырым ара ни ул? Чаптык кышкы юлдан.
Киче шундый: буран тузгый, бөтерелә карлар.
Җилгә каршы йөгерәбез — җан яшь безнең, кайнар...

Ике арада авыл — Буләк. Илдар Маннановны —
батыр егетне үстергән. Сәламлибез аны!
Йөгерәбез... Кем дә әйтми, «җитте, бераз ял!» дип.
Алда — утлар. Әмәкәйдер, анда — көтә «Гамлет».

Ашыгыгыз, әй малайлар, яшьлек, дәрт җилкетә.
Йөгерегез — алда шатлык, бәхет — барсы көтә.
Йөгер, Дәлфәт, утка кадәр байтак узасың бар.
Янып-пешеп җыр язасың, Зөлфәт буласың бар.
Үзе татлы, үзе ачы — иҗат шәраб кебек.
Ахыргача барырсың, син — яшьтән бунтарь егет.

---

[1] Фольклордан.

Йөгер, Фәрит, алда — Казан, Әлмәтең утлары,
Уйлыйсыңмы нефтьчеләр бирер повестьларны?
Яңа сюжетларны!

Йөгер, Роберт, Илдар абыең калышмаска өнди,
Маннанов син, тормышның син эченәрәк кер, ди.
Чаллы көтә сине... әле ул да аны белми.

Минем — кабул була, ахры, әнкәм теләкләре! —
Буран катыш җырлар туа — «Үрәзмәт дәфтәре»!
«Бәхетле булыйк, дуслар!» дим, я, кызулыйк әле!
Йөгерәбез. Алда утлар, алда — киләчәкләр.
Буран каплый бары... Алда — тере ак чәчәкләр.

Алда — Казан, шагыйрьләрнең бәхәсе, даулары.
Әле катгый басар алга Гамлет сораулары.
Әле ерак — җанның яшерен Офелиялары.
Әле уйда калкыр — батыр чорыбыз геройлары,
Монологлар, диалоглар...
Алда әле — бары!

Буран тынды. Менә авыл. Әмәкәй, кабул ит!
Үрәзмәттән килдек. Саумы, безнең яшьтәш, Гамлет!

## Әбелхарис һәм Әбугалисина турында

*Ибне Синаның 1000 еллыгына, кыйсса буенча*

Әйе, син — талантлы, шиксез,
син — кыйссадагы
«симия, кимия» белемле Әбелхарис.
Бөек Әбугали — туган сиңа...
Әйе, син дә мәшһүр,
әмма миңа
Әбугалисина кирәк, Әбугалисина!
Анда
Хәлвәфруш тагын тоткын була,
патша тормәсендә ярдәм көтә.
Аның күңел чәчәкләре тагын сула!
Сөюе — күңел чәчәкләре өчен генә
үлем яный аңа —
хәбәр итегез, әйтегез Әбугалисинага.

Әйе, син — сәләтле, шиксез,
син — «мәгарәдән укып чыккан» Әбелхарис!
Түгел син һөнәрсез:
салдың нинди матур мунча-хәммам.
Патша дусы саный сине тәмам.
Ләкин Хәлвәфруш һәлак була анда,
кайда Әбугалисина, кайда?!

Әйе, син — талантлы,
ләкин вәзир акылы синдә.
Бөек хәким түгел атың.
Горур фәйләсуфлар таҗын күрмәссең дә!
Ләкин сөен, нәни бәхетең бар ич.

Ә мин
бөек демократ жан —
Әбугалисина эзләреннән йөрим, эзлим...
Аны, аны сагына кешеләр, Тарих...

Сау бул, Әбелхарис!

## Олжас Сөләймановка

Олжас!
Кил Казанга,
Монда калган синең
истәлегең — исән.
Ышан:
заллар хәтерлиләр тавышыңны,
сагыналар, дисәм.

Олжас!
Монда синең якын кардәшләрең —
төрки моңнар яши.
Сагына сине — күреп бер яраткан,
Яки укып белгән җолдастарың,
сагына карты-яше.

Олжас!
Аңла, кил Казанга, тагын безгә
кил кунакка, дисәм:
яши синең матур хатирәләр!
Хатирәләр — исән...

## Феникс

Әй, Феникс, әкияти кош!
Күктә
өч әйлән дә кил, җиргә төш!
Янып көл бул,
үз көлеңнән янә терел.—
Синдә шундый зур сәләт, көч.
Әй, Феникс, тылсымлы кош!

Сөйлә, күпме мәдәният,
Күпме тел, җыр, әдәбият
(Әй, Көнбатыш!.. Син, Көнчыгыш!)
олы тарих дәвамында
юкка чыккан — алар кайда?

Ул халыклар үткәненнән —
үз көленнән!—
кабат терелеп, яралырмы?
Тагын алар җанланырмы?
Тарихта бар, бар яңарыш —
янып, янә чәчәк ату —
Ренессанс!

Син — шулардан тере сурәт.
Әй, Феникс! Безгә күрсәт:

яныл, терел бер каршыда,
хәтерләт — аң, җанны уят,
аннан.... башка җирләргә оч!
Әй, Феникс, үлемсез Кош!

## Җитмешенче еллар белән саубуллашу

Әйе, үттегез сез... Хушыгыз, мәңгелеккә...
Җитмешенче еллар!
Хушыгыз!
Әһле каләм, күңелләргә алыгыз:
бу еллардан
гыйбрәт булыр ни бар?
Тулы көчкә җиктекме без җанны,
яныл
эшләдекме эшне?
Акылны без хаклы яклый белдек,
тыймадыкмы хисне?
Шаулы ярсу шигырьләргә алмаш
безгә
шулай хуш килдеме?!—
Тыныч, тын булганга, әйбәт, дидек
түгелме шигырьне?
Җитмешенче еллар! Ә бит сездә иде
Чаллы, БАМнар рухы...
Сезгә аваздашмы безнең иҗат,
һәйкәл булырлыкмы?
Калырмы соң лаек истәлекләр
сездән — шедеврлар,
онытылмас җырлар?!
Киләчәктә әйтерләрме:
— Күрегез,
онытмагыз, кайтып өйрәнегез.

— Җитмешенче еллар!
Үттегез сез...
Эшләнмәгән эшләрне уйлап, бәлки
хәзер вөҗдан елар.
Бәлки хәзер соңдыр. Хушыгыз.
Әһле каләм, инде аң булыгыз, языгыз!
Ишек шакый
Сиксәненче еллар:
— Әй, саумысыз?!

Котлы булсын туар яңа җырлар!

1979—1980

## Аяз Гыйләҗев

# ҖОМГА КӨН, КИЧ БЕЛӘН...

ПОВЕСТЬ

Күпме уйласа да, кичәгене хәтерләсә дә, күңелендә ачы бер яра Бибинурның — игезәк сыңарың белән, бер карында яшәгән туганың белән уртак тел тапма инде!

Монда төп гаепле итеп Бибинур үзен саный иде. Әгәр Габдуллаҗанга кияүгә чыкмаса, Зөһрәбану алай зәһәрләнмәс иде... Әгәр зәһәрләнмәгән булса, мөгаен, ул да тиңен табар иде... Тиңен тапса, ул кадәрле үк сарыга сабышып аждаһага әйләнмәс иде...

Тормышта һәммәсе бер-беренә бәйләнгән шул!

Бүген сишәмбе. Почта машинасы кайтырга әле байтак вакыт бар. Бибинур бүген ераккарак, бакча түренәрәк кереп утырды. Буа тавышы моннан да ишетелә. Шаулый буа, арыктан су шарлап түбәнгә төшә, мең нурлы тамчы булып чәчри, күбекләнә, кайный, тавышлана...

Сишәмбе уйлары да аны яшьлегенә, тагын шул көннәргә, Габдуллаҗан янына алып кайтып киттеләр.

Ир — хатын-кызның җан таянычы, «Иделгә таянма, иргә ышанма», дип яшәү кадерен белмәгән кәнтәй күңелләр генә уйлап чыгарган. Иделгә таянганны ишеткәне дә, күргәне дә юк аның, әмма мең телдән мең тапкыр ишеткәне бар: «Утыз улың булганчы, у...к ирең булсачы!» дип кистереп куйган татар. Һәм шушы сүзен бер чакта да онытмаган. Нишләсен, талмуды юк, шәригать тә читтән килгән, гыйльми, фәлсәфи китаплары сакланмаган, бар булган тормыш фәлсәфәсе, яшәү кагыйдәләре, мәхәббәт-семья законнары, ачы тәҗрибә авазлары әнә шул кып-кыска мәкальләрдә генә сакланып кала алган. Йөз еллыгы да, мең еллыгы да шунда. Тегенди-мондыена утыз улны биргәнне, уңган ир күпмегә бәяләнә? Аның Габдуллаҗаны, Хәнифәнең Идрисе кебек ирләрнең бәясе ни хак?!

Иң элек Хәнифә сыгылып төште.

Ул һәр көн иртән Бибинурларга килеп житә, аның белән сыер саварга чыга, бәрәңге тәпкәләргә йөри, ияреп болынга да бара. Бибинур сава, тәпкәли, утый, печән чаба — Хәнифә боларның берсен дә

---

Ахыры. Башы 6 нчы санда.

эшли белми. Кәкре койрыклы эте «Марс»ны кочаклый да аның юеш борынын үбә-үбә көннәр буе елый.

Бармаклары нәп-нәзек аның, үтә күренмәле, сөякләре ап-ачык беленеп тора. Ботлары да нечкә, аягы да бәләкәй. Ничек сыер саусын да, ничек тәпке тотсын? Чалгыга киселермен дип, ул Бибинур чапканда әллә каян читтән генә карап тора.

Эшсез ничек яшәргә кирәк!..

Кирәк чагында тамак төбе белән җикеренеп тә ала торган, малайшалайны олы күзләре белән шүрләтеп торган мөдирме бу?! Районнан килгән хәтәр-хәтәр кешеләр белән күкрәк киереп, сүзне бөердән генә чыгарып сөйләшкән директор хатынымы бу?! Аюдай иреннән су ташыткан, төнге чүлмәген чыгарткан, идән юдырткан Хәнифәме бу?! Сүзе — ыңгырашу, адымы — чирле кешенеке, төсе — агарынган. Юка, шәмәхә иреннәрдән кан качкан. Этендә генә үзгәреш юк — былтыр да ләң-ләң өрә иде, быел да шулай, хак. Чыпчык күрсә дә сырт йонын уйнаткан була.

Хатын-кызга тотанак — ир ул!

Хәнифә Бибинурларда куна да кала. Чишенеп ташлый, күкрәкләре тавык йомыркасы хәтле генә, арты юп-юка, алты-җиде кат юбка кигәч кенә күзгә беленә башлый, аяклары чаңгы таягы сыман туп-туры, ә тәне ефәк кебек елкылдап, ялтырап тора. Аяк тырнаклары буялган, үкчәсе ап-ак, түгәрәк. Бөтен җиреннән тәмле ис килә.

— Түзә алмам, Бибинур, мин монда. Китәрмен дә барырмын. Укытырга кер, диләр. Фән биреләр. Идриснең дәресләрен ал, диләр.

— Ал, — дип үгетли Бибинур. — Паюк чыгар үзеңә, Хәнифә апа. Эшсез ничек яшәмәк кирәк? Ирләребезне бергә озаттык, бергә каршы да алырбыз. Сугыш мәңге бармас, ничек тә үткәреп җибәрербез. Кайта алар, кайта, алла боерса. Әйбәт төшләр дә керә.

Бибинурга, беркатлы, саф күңелле Аксыргак хатынына, тәмле-татлы төшләр кергән төннәрнең берсендә, таң алдыннан башланып киткән һөҗүм вакытында билгесез тауҹык янында имән кискән кебек Идрис Белов егылып үлде. Габдуллаҗан аның взводында иде. Яман хәбәрне ул ирештерде. «Мина төшеп взводыбыздан өч кеше, шул җөмләдән кадерле командирыбыз Идрис абыебыз да һәлак булды», дип язды. Бибинур «и аллам, пуля белән генә ега алмаганнар икән бахырны, мина дигәнне үк җибәргәннәр!» дип уйлады.

Хәнифә укытырга да керешкән иде, иренең үлгән хәбәрен алгач, ике көн, ике төн өеннән чыкмый ятты да, өченче көнне председательгә килеп ат сорады. «Китәм мин», диде. Ялынуның файдасы юклыгын председатель бер карауда аңлады, шәһәр кызы иде Хәнифә, авылны бер чакта да үз итә алмады.

Станцага кадәр олау белән аны Бибинур озатты.

Ирсез калган хатынның чын кичерешләрен ул шунда беренче тапкыр ап-ачык күрде. «Ир кадерен белгән хатыннар гына шулай бәргәләнә ала!» дип уйлады Бибинур. «Берүк Габдуллаҗаным исән булсын да гомер юлын бергә үтик», дип ходайга ялынды.

Вокзаллы шәһәр базарында алып барган маен сатты, Хәтимәгә яулык белән чуар күлмәклек, малайларның икесенә дә куян бүрек алып кайтты. «Ә үзеңә, әнкәй?» дип сорады Хәтимә. «Үземә?» — дип сорады Бибинур, «үземә менә сез, балалар!»

Кырык икенең февралендә аны ат карарга куйдылар.

Сиксән ат бар иде авылда. Ул — өлкән конюх. Аңа булышырга ике үсмерне җибәрделәр. Икесе дә елгыр гына малайлар, түбән очтан, егет булып киләләр явызлар, кызлар күрүгә авызлары ерыла. Салам-печәнне дә алар ташый, зур кабык чуман белән тиресне дә елга ярына алар чыгара. Бибинур камыт-ыңгырчак өчен җаваплы, тәртәсен дә ул каера, дуңгыз тиресе иләп чөелдерекне дә ул телә.

Март урталарында атларга азык бик койтыланды, Бибинур кунатөнә диярлек кардада ятты, кышын үзләре түккән тиресне тырмалар белән тарап салам-соламны бөртекләп дигәндәй җыеп ашаттылар. Сугыш чыккан елны гына ябылган мәктәп түбәсен ишеп төшерделәр.

Габдуллаҗаннан хатлар сирәк килә, хатларында һаман бер үк нәрсә кабатлана: иң башта бик күп итеп тезеп авылдашларына сәлам яза, аннан исәнлеген өстәп куя, тиздән күрешәчәкләренә өмет итеп, имзасын сырлый.

«Мин чыдармын, менә син анда балалар белән ничек яшисең?» дип бер сораса икән ичмасам! Аңа да рәнҗеми Бибинур, иренең хәле җиңел түгеллеген шул кыска хатлардан чамалый. Үз хәле хәлдер солдатның, шуңа сүзләре онытыла, шуңа хатлары кыска була.

Ул балаларның өчесен дә өстәл кырына тезеп утырта, хатны иҗекләп, сүзләрне кабатлап, һәр җөмләсенә басым ясап укый. Каш астыннан гына Хәтимәгә карап ала да «әнкәгезне тыңлагыз» аның сүзе өстен булсын, карышмагыз, аңа булышып кына торыгыз», дип укып китә. Апайлары белән төрткәләшеп утырган Хәтимә әнкәсенең керфекләренә кунып дерелдәгән энҗе яшьләрне күрми дә кала. Шулай да бер тапкыр ул хәйләне сизде, кинәт кенә хат битенә үрелеп карады да:

— Анда алай язылмаган! — дип чәрелдәп куйды.

Бибинур, көлмәк җиңе белән күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Язылмаса да бар ул сүзләр, бар. Әткәгез шул сүзләрне яза гына башлаган икән, фашистлар мина атарга керешкәннәр. Менә «сагынам» дигәне бармы? Бар. Тагын ике хәрефне сызганмы? Сызган. Шунда булган аның ул сүзләре, — дип аңлатып күрсәтә.

Балалар акрынлап исәя башлады, уртанчы малай да вак-төяккә ярый, йомыш-юлга чаба, Нәҗип тә кул арасына керә, олыларга ияреп утынлыктан йомычка җыеп керә, иске таска көл тутырып бакчага чыгара. Хәтимә энекәшләрен карый, малайлар аны апа, дип олылыйлар, тыңлыйлар. Тыңламый карасыннар, әнә ич, әткәләре хат саен: «Хәтимә апагызны олы итегез, малайлар, аңа укырга комачауламагыз, тырышсын», дип кисәтеп тора.

Хәтимә муенын сузып хатка карый, әмма чәрелдәми, чөнки әткәсе шушы сүзләрне язарга җыенганда гына фашистларның мина ата башлауларын белә. «Сагынам» дип тә язмый аның әткәсе, әнисе хаттагы буш урынны гына күрсәтте, ә ул барыбызны да бик ярата, барыбызны да бик сагына... Балалар йокларга яткач, Бибинур солдат иренә озаклап хат яза, эченнән генә сүзләрен кабатлый-кабатлый яза. Аннары калын чәчләрен ак мендәргә таратып йокларга ята, янагына Габдуллаҗаннан килгән хатны куя: «тәмле төшләр керсен!» Инде изрәп йокыга китәм дигәндә, зиһен, акыл йокы белән көрәшкәндә, аның кайнар иреннәреннән гел бер сүз чыга: «Сагынам дип язсаң ни була? Бер генә тапкыр шулай дип куйсаң ни була?!»

Иртәнгә бу зарыктырган сүз онытыла, яз-кыш, җәй-көз эш белән үтә аның көннәре. Конюх булса да аны башка эшләргә дә йөртәләр. Быел тары бик уңды, Кырынды өстенә кырык гектар чәчкәннәр иде, котырды гына, эре-эре башаклары карасу-зәңгәрләнеп чук-чук асылынып торды. Бибинур да конюх атын җигеп көлтә кертергә чыкты. «Атың шәп», дип аны басуның иң ерак түреннән ташырга куйдылар. Берсендә шулай, юан-юан саллы көлтәләрне чытыр арбага сыртлап төяде дә, бастырык булып үзе өскә менеп ятты. Көн җылы, җилсез, кыр такыр, һавада сузылып-сузылып көмеш тоҗымнар оча, арба өстендәге көлтәләрдә тәтәй кашыклар мыжлап йөри. Ат та үз бурычын аңлаган кебек җай гына бара, ара-тирә пошкырып та куя, юл аулак, алдарак, шактый еракта гына ике атлы күренә. Кайта-кайта Бибинур изрәп йокыга да китте. Төнлә дә рәтле ял күрмәгән керфекләр тыгызланып йомылдылар. Йокы аралаш ул нидер кыштырдаганны ишетте, ул арада

булмады дәү генә бер кул аның күлмәк изүенә керә башлады. Чын кул, йонлы беләкле ирләр кулы... Кул тәнгә үк кереп җитте. Бибинурның шалкан кебек тып-тыгыз, нәни күкрәген уа да башлады. Ул чәчрәп уянып кулны эләктереп алды һәм җан ачысы белән: «Нишлисең?» дип кычкырды. Күзен ныклап ачып караса янында ярдәмчесе — Түбән оч көчеге Ибрай ята, танау тишекләре киңәйгән, куыгы кабарган, иреннәре дер-дер килә.

— Нишлисең, малай актыгы?

— Чү, чү, Бибинур апа, мин болай гына, кулым ялгыш кына кереп китте.

Бибинур ике куллап малайны йөктән этеп төшерде, ат куркып тартылып алды, малай чак кына тәгәрмәч астына кермәде.

— Болай гына калдырмам, бел!

Әрсез малай арба артыннан тыр-тыр йөгерә башлады.

— Әй, Бибинур апа! Син бабайга чыккансың, сине кыз килеш калган диләр. Шул дөресме?!

Бибинур сыны катып йөк өстенә сыгылып төште.

Менә ни сөйлиләр икән аның турында! Тагын шул Зөһрәбану таратадыр инде? Шул кичне үк ул председательгә:

— Ибрайны кардадан алыгыз! Эзе булмасын, — диде.

— Нигә? — диде председатель борчылып.

— Шулай.

— Бел, Бибинур, койрык чәнчи торган чак түгел, артык кешем юк.

— Берүзем эшләрмен.

Үткән атнада гына армиягә җиде ат озаткан иде Бибинур, бу атнада тагын бишне әзерләргә боерык килде. Кыр эшләре беткәнне дә көтмиләр, дип уйлады ул.

Урак өстендә Аксыргакта район вәкиле булып райбашкарма рәисе урынбасары Сара апа торган иде. Бәрәңге алулар башлангач аны Казанга чакырып алдылар да вәкил булып райземотдел мөдире тәбәнәк кенә, камыт аяклы, түгәрәк корсаклы мәзәк кенә ир кеше килде. Кичен атын кардага төшергәндә Бибинур аны беренче мәртәбә күрде.

— Минем атны аерым кара,— диде ул, конюх хатынны ач күзе белән ашап. — Исемең кем була инде синең?

— Бибинур мин.

— Ирең солдаттамы?

— Кайда булсын инде?

— Балаларың да бармы?

— Өчәү.

Өчәү икәнне ишеткәч, вәкил Бибинурның кызларныкы кебек зифа, житез гәүдәсенә бер карады, ике карады, тузан кунган итекләренең кунычын гармунлап аска төшерде дә, шыгыр-шыгыр басып китте.

Икенче көнне дә атын кардага үзе төшерде мөдир һәм ялманып:

— Иртәнге бишкә җигеп китерерсең, — диде.

— Анысы булмас, абый, — диде Бибинур карышып. — Вакыт житкереп булмас. Миндә бер синең ат кына түгел. Бөтен карда минем өстә!..

— Вакыт табарсың!

Башка вәкилләр атны бер дә үзләре төшереп йөрми иде, малай-шалай китереп китә иде, бу камыт аяклы, чуен башлы Хөснетдинов тәки этләште бит. Атны үзе төшерә, иртән Бибинур үзе җигеп китергәнне таләп итә. Илтә Бибинур, Хөснетдинов зәңгәр галәфиләрен ике якка салындырып камыт аягын ерып аңа карап тора. Бер кичне ат тугарганнан соң Бибинурга ияреп ат караучылар йортына ук керде.

— Монда карарлык нәрсә юк, — диде уңайсызланып Бибинур.

— Син бит миңа ни кирәген белмисең. Ничек дидең әле? Бөтен карда минем өстә дидеңме? Хи-хи-хи.

«Моның ни көлкесе бар?» дип сорарга җыенгач кына мөдирнең тел төбендә оятсыз киная ятканын сизенеп тыелып калды. Стенадагы агач чөйдәге камытларны, киезләре тузган шыгырчакларны тотып карады мөдир, аркалыкларны тартып-тартып куйды, аннары кулын иснәде, бармакларын галәфиенә сөртте. Сәкедә Бибинурның ямаулы бәз бишмәте ята иде. Стенада әллә кайчан чыгарылган стена газетасы. Бер почмагын кемдер ерткан.

Хөснетдинов газетаны да караган булды, «яңасын чыгарырга вакыт» диде дә, кинәт кенә ишек келәсен элде һәм уң кулы белән Бибинурның сыгылмалы биленнән эләктереп алды. Бибинур аның кулын аерып атты.

— Җә, кыланма!

— Кагылма, Хөснетдинов абый, — диде Бибинур, тыныч булырга тырышып. Вәкил алай тиз бирешә торганнардан түгел иде ахрысы, ул үз көченә шул кадәр ышанган иде, мыскыллап бераз карап торды да, билне ике кул белән үк урап алды.

— Сине ирдән кыз килеш калган диләр. Дөресме шул? Әйдәле, тикшерик!

Бибинур аны этеп җибәрде, тәрәзәне тибеп коеп төшерде һәм карда эченә сикерде.

Хөснетдинов ап-ак булып катып калды.

— Мин сорадым гына ич! Кыланма, әй!

Бибинур колхоз айгырын йөгәнләп алып чыкты һәм җайдак кына чабып Зөһрәбану янына кайтты.

— Син таратасыңмы минем хакта кара гайбәтне?

— Гайбәт таратмыйм, дөресен сөйлим.

— Әйдә районга! Врач алдында ачып күрсәтәм!

Усал кешеләр тиешле отпор алганда җебеп калалар, бер мәлгә генә Зөһрәбану да аптырап калды, аннары тагын үз хәленә кайтты:

— Әлә-лә, теле! Оялмыйча! Әйтәм җирле, вәкил белән сиптерә диләр, рас икән, — дип тәтелдәде.

Хөснетдинов яңадан кардага аяк басмады, мәгәр аның аркасында Бибинур чак кына төрмәгә эләкми калды.

Армиягә байтак ат озатсалар да аксыргаклыларның ел да байтак колыннары туа торган иде. Бияләрне аерым күзәтү астына алды Бибинур, азыкны аларга мулрак та бирде, мөмкин булганча аларның тәнен саклады.

Айгырдан да уңдылар алар, гәүдәгә ул тиклем зурдан булмаса да, нык күкрәкле, нык аяклы, озын яллы кызыл айгыр юртак буларак үз эшләренә һич ал бирми торган иде. Бияләр белән дә эш пешә иде аның.

Икенче язда тагын шул Хөснетдинов вәкил булып килде.

— Башка юньлерәген тапмыйлармы әллә безгә? — дип зарланды Бибинур рәискә.

— Вәкилне сайлап алмыйлар, синең эшең аның атын карау, — дип кырт кисте председатель.

Бибинурның күңеле алдан ук сизенеп йөргән иде, тәки күзе төште Хөснетдиновның айгырга! Бәйләнергә сәбәбе дә чыгып тора бит аның.

Колхозны җитәкләвенә ел тулар-тулмаста, юаш кына холыклы Миңлекамал айгыр җигеп лесхозга барырга чыккан. Айгыр булгач, тиз генә әйләнеп кайта, янәсе. Урман юлы янындагы диләнкедә зелпе тамыры төяп ятучы күрше авылларның куштан гына чуар бияләре, айгырны абайлап, ярып кешнәп җибәрә. Кызыл айгыр да койрык чәнчеп кешнәп җавап кайтара. Кешнәшәләр болар, сөйләшәләр, бия өзелеп-өзелеп моны үз янына чакыра, «сине сөяр идем, коткар шушы зелпе тамырыннан!» дип дәшә кебек. Миңлекамал черки тавышы белән «тыр да тыр», кая ул, куштан бия чакырып торганда тыярсың тук ай-

гырны, элдереп трантасны сөйрәп диләнкәгә кереп тә китә. Чаба айгыр, чаба, кучәр башы биек төпкә эләгеп, председательне матур гына итеп җиргә сылый, тәртәсе сына, камыт баулары өзелә...

Трантассыз-нисез кайтып кергән, күзен кан баскан айгырны күргәч Бибинур аһ итте... Атның муенын кочып алды, өстенә чыбылдык ташлады: «Янган килеш суык су эчмәгән булса ярар иде, харап була хайван!»

Миңлекамалны, чуар биягә утыртып, туп-туры районга алып киткәннәр. Егылганда киемнәре ертылып кына калмаган, сул беләге шытырдап сынган икән.

Хөснетдинов мәсьәләне бик текә куйды:

— Айгыр миңа булсын! Хатын-кыз кулын тыңлый торган мал түгел ул. Сезгә әнә минем юаш та ярар! — диде.

— Бирмим, — дип карулашты Бибинур.

— Йә ул берәрегезне тибеп үтерәчәк, йә сез ачка үтерәчәксез аны.

— Моңа кадәр сакладык, моннан соң да үтермәбез.

— Кем хуҗа монда: синме, минме? Үлсә, кем җавап бирәчәк? Ә?!

Вәкил шулай каты торгач, сынык кулын гипслап муенына аскан Миңлекамал икеләнә язды, Бибинур гына бирешмәде:

— Бияләрне кая куярбыз, Миңкамал апа? — диде. — Әле алда тормыш бар бит!

— Мин сезгә айгыр табып бирәм, — диде, үз сүзен өстен чыгарыр өчен теләсә нинди вәгъдәләр дә биреп куык очыртырга яратучы Хөснетдинов.

— Шул айгыр сиңа булсын, вәкил абый. Безнең бияләрнең мәхәббәтләре кызыл айгырда, — дип уенга борып та маташты Бибинур, тик Миңлекамал белән Хөснетдинов, икәүләп кыстый торгач, аны җиңделәр. Кызыл айгыр вәкил кулына күчте. Айгырны авызлыклап, танавын умырып тотып: «Но, но! Кем кулына кергәнеңне белеп кер!» дип явызланып араннан алып чыгып киткәндә Бибинур үксеп, сыгылып төште. Айгыр да борылып-борылып аңа карый, карышып аякларын җиргә тери, камыт аяклы Хөснетдинов борылып аңа камчы белән яный.

Вәкилне озакламый башка колхозга күчерделәр, Миңлекамал җинеп сулап куйды.

— Үзе сорап күчкәндер ул, Миңкамал апа! — дип өзгәләнде Бибинур. — Айгырны бездән читкәрәк алып китәр өчен качкан.

— Нишләмәк кирәк соң, сеңелем, — диде Миңлекамал. — Тормыш дилбегәсе безнең кулда түгел.

Тормыш дилбегәсенең үз кулында түгеллеген әллә кайчаннан белә Бибинур, тик бу хәл белән аның һич тә килешәсе килми, төннәрен төшендә Хөснетдинов белән талашып уяна. Төшендә ул һәрвакыт Хөснетдиновны җиңә, кызыл айгырны ялыннан сыйпап үз урынына алып кайта, хуш исле йомшак тукранбашны кочагы белән, мул итеп улагына сала.

Кызыл айгырны аның балалары да ярата иде. Хәтимә — кыз кеше, ул да айгырның суык улагын күргәч:

— Әнкәй, безнең айгыр кайда? — дип сорады.

Бибинур җавап урынына нидер мыгырдады.

Сабир белән Нәҗип беравыздан:

— Сабан туе чабышларына да кайтмыймы инде ул? — дип борчылдылар.

Бибинур аңлап алды, балалар кызыл айгырның авылдан киткәнен ишеткәннәр, шуны белгәч өчәүләшеп төшкәннәр икән.

Икенче көн таң белән, яңа чабатасын киеп, иске шәлен ябынып, бер кыерчык ипи тотып ул районга чыгып китте. Үз урынына калган егеткә:

— Кем сораса да «кая киткәнен белмим!» диген, — дип, кат-кат кисәтте. — Колыннарны чыгарма, кичә дә Тумбарлы чокырында бүре күргәннәр.

Райбашкарма урнашкан асты таш, өсте агач озын йортны да, якшәмбе көннәрне шул йорт каршындагы зур мәйданда базар булганын да ул бик яхшы белә иде. Райбашкармасын белгәч ишегалдындагы ат абзарларын да бик тиз эзләп тапты, базардан йомышка кергән булып, тиз-тиз генә капкаларны ачып карады, кызыл айгыр монда юк иде. Көтәргә туры килде. Базар тарала башлады, Бибинур һаман шунда уралды, гел кирәк булмаган әйберләр сатулашты. Хөснетдинов трантас түренә киерелеп утырып кич кырын гына кайтты. Тәртә арасында мескен кызыл айгыр иде.

Керт-керт итеп коры печән кимерә башлаган айгыр Бибинурны таныды, башын калкытып, күзен уйнатып акрын гына кешнәп сәлам бирде. Бибинур ике куллап аның дымлы муенын сөйде, стенадан йөгән эзләп тапты, калтыранган куллары белән тезгенне тартып, атны урамга алып чыкты. Базар таралган, мәйдан буш, райбашкарманың аскы катында, бер бәләкәй тәрәзәдә генә тоныкут җемелди иде. Бибинур атка егетләрчә сикереп атланды һәм сызгырып җибәрде:

— Киттек, малкай!

Базар мәйданында тояк тавышлары тынып та бетмәде, милиция идарәсендә телефон шалтырады:

— Райбашкарманың кызыл айгырын урладылар!

Бибинур авылга кереп тормады, ындыр артлатып кына узды да, тауга менде, урманга керде һәм умартачы Гаптери картка айгырны тапшырды.

— Синдә дип берәү дә белмәс, бабай, яшәп торсын! Аннан җае чыгар. Күрәсеңме, күләгәсен генә калдырган бит малкайның. Кабыргаларын чакрымнан торып санарлык! Гаепләсәләр, әйдә, мин гаепле!

Бибинурны «ат урлаган» дип судка бирделәр.

Судка чакыру кәгазе алгач, ул Миңлекамалның җиңенә чытырдап ябышты. Күзләренә карарлык түгел иде Бибинурның, ут тулы күзләре куркыныч, түгәрәк яңагының сөякләре беленеп-калкып чыккан, йодрыклары йомарланган иде.

— Ә балалар? — дип инәлде ул. — Мине утыртып куйсалар алар нишләр?

— Сугыш заманы икәнен онытмаска кирәк иде, Бибинур апаем, — диде Миңлекамал юаш кына. — Җиңеллек булмас!

Ул ишегалдына таралган балаларын җыеп өйгә кертте, ишекне тышкы яктан бикләде.

— Ут-күздән генә сак булыгыз, калганын үзем белермен. Ашарыгызга бар, мин озакламам. Хәтимә, кызым, оланнарны кара!

Чүнниккә ул исерек кеше кебек алпан-тилпән менде, ярсуы шул кадәр кабарган иде, юлда беркемне күрмәде, «нишләрләр алар мине ябып куйсалар!» дип һаман үз-үзенә эндәште.

Бер менеп алгач кызыл айгырны районга кадәр куды. «На, малкай! Синдә ышаныч, коткарсаң син коткарасың минем газиз балаларымны, на!»

Районга җитәрәк юлда елга аша чыгарга кирәк, күпер такталары чәрдәкләнеп-вакланып беткән, җан-фәрманга юртып барган кызыл айгырның ал аягы такта ярыгына кереп кысылуы булды, Бибинур ат башы аша, алга, күпергә очып та төште. «Беттек! — дип уйлады ул, — айгырның аягы сынды! Инде хәзер котылмак юк!» Бәхеткә каршы, айгырның ак бәкәле бәләкәй генә тырналган булып чыкты. Күпер чыккач Бибинур аны җитәкләп барды, айгыр аз гына аксаклады, үр менеп җиткәндә аксаклау кимеде, ул моны балалар бәхетенә юрады. «Бәхе-

тегез бар икән, балакайларым, айгырның аягы сынган булса барыбыз да беткән идек!» дип уилады...

Райком алдындагы баганага атын ныгытып бәйләде дә Бибинур туп-туры беренче секретарь янына барып керде.

— Габдуллаҗан Абдуллин хатыны мин. Аксыргактан. Син аны белергә тиешле, ячейка оештырган кеше. Хәзер сугышта. Айгырны сиңа китердем, Әбләлимов абый. Синең атың начар түгел, атны таныйм, мәгәр бу аннан да шәп. Тамыры нык моның, үзәге таза. Армый юрта. Синдә булса, ичмасам, исән калыр. Яшь мал бит әле. Синең ат кадерләвеңне бөтенебез белеп тора.

Башта кырыс кына тыңлый башлаган Әбләлимовның киң битендәге сүрәнлек каядыр юкка чыкты, бераздан ул көлеп үк җибәрде.

— Чын күңелеңнән миңа дип китердеңме?

Мондый сорауны көтмәгән Бибинур:

— Чын күңелемнән, — дип пышылдады. — Мин башкача эшли дә алмыйм.

— Җәл түгелме?

— Җәл, Әбләлимов абый. Бик җәл.

— Молодец!.. Колыннар үстерәсең икән анда. Ишеттерделәр. Ник партиягә кермисең син?

— Грамыт ягы бик чамалы бит, Әбләлимов абый. Аннары балалар! Бер үземә өчәү.

— Анысын да ишеттем. Рәхмәт сиңа, Абдуллина!

— Нәрсә өчен, Әбләлимов абый?

— Колыннарыңны сакла. Токымнары әйбәт. Мин сезгә аз-маз курмы белән ярдәм итәрмен. Кайбер колхозларда атлар кыш чыга алмый. Ә сезнең бияләр колынлы. Минә бит ничек ул. Колыннарыңны барып күрәм әле.

— Килегез, Әбләлимов абый.

Секретарь телефон шалтыратты, судьяга эндәшә.

— Карале, әй, Петров, урланган айгыр табылды.

Икенче звоногы земотделга булды.

— Хөснетдинов, кагылма син айгырга, яме. Шулай килешик. Шулай кирәк. Халыкның инициативасын үтермик без. Күңеле көр булсын аның!

Айгырны җитәкләп, юл буе болыннарының иң тәмле, иң сусыл үләннәре белән сыйлый-сыйлый, күктә тирбәлгән тургайларга кушылып җырлый-җырлый бик озак кайтты Бибинур. Бу хәлләрне ишетсә Габдуллаҗан ни әйтер иде икән? «Балаларны ятим калдырган булсаң, мин сине...» дип әрләр идеме, әллә «булдыргансың, карчык, сүзеңне бирмәгәнсең» дип мактар идеме?!. «Нигә партиягә кермисең?» диде секретарь. Габдуллаҗан коммунист иде. Саф намуслы, азга да канәгать була белгән, үзеннән бигрәк авыл турында, башкалар турында уйлый торган кеше иде. Күңелең киң булсын өчен офыгың киң булу да кирәк. Белем — офык ул. Ни белә бу дөньяда Бибинур? Ни күргән? Әйе, әлегә, алар семьясыннан бер коммунист булгач та бик җиткән. Менә сугыш тәмамланыр, алар Габдуллаҗан белән икәү бик күп китаплар укырлар, газеталарга язылырлар, бергә яшәрләр, бергә уйлашырлар! Балаларны да укытырга кирәк булыр, алар әнкәләре төсле мәхрүм булып калмаслар... Габдуллаҗан гына исән булсын. Ул булса барысы да көйләнер. Иделгә таянма, әмма иргә ышан!

Уфаларга барам әле,
Уфа юлы ачылса.
«Уф, йөрәгем» димәс идем,
Янулары басылса...

Атның озын ялы, Бибинурның куе кара чәчләре җилдә уйный, кырлар өстенә хуш ис тулган, күбәләкләр оча... «Балаларны кырга алып

чыга алган да юк!» дип уйлады ул. Кәефе дә шәп, җину сөеченнән тәне дә җиңел, нигә җыры болай моңлы килеп чыкты соң'әле?

Авылга кайтып кереп, аръяктагы өч өйне узганнар гына иде, күпер өстендә айгыр тирә-юньне яңгыратып кешнәп җибәрде. Шуны ишетеп ике яктан ике кеше аңа каршы килә башлады. Ул, нидер сизенеп, тезгенне беләгенә урады.

— Кайда йөрисең син болай, Бибинур?

— Нәрсә бар? — Аның теле көрмәкләнде. «Балалар!.. Тыштан бикләп чыгып киткән кеше кичкә кадәр йөрдем! Сантый! Исәр».

— Габдуллаҗанның хәбәре бар.

— Яраланганмы?

— Түгел, үлгән. Балаларың бик елаша, Бибинур!

Ул айгырга очып менде дә, чабата үкчәләре белән ике янтыгын да төя башлады: «На, на, на!» Кая чаба инде болай Бибинур, авылы әллә кайчан артта калды бит. Үнда, каралҗым зәңгәр күктә сураеп кына ай калыкты. Кая чаба? Ат аңа борылып-борылып карый, тамагы кибеп әһелди, аның муен тамырлары туктаусыз дерелди. «Кая болай мәгънәсезгә куасың мине, хуҗам?» диме аның акыллы күзләре.

«Балакайларым, балаларым, газизләрем!» дип чыңлады аның күңеле. Яңа туган ай шаһит, күгелҗем күк шаһит, үзе менгән ат шаһит— үзе турында бер тамчы да уйлап карамады ул. Чабып авылдан чыгып китте, чабып кайтты. Капка төпләрендә аттан сикереп төште һәм йөгәнен салдырып айгырның артына берне шапылдатты.

— Бар, төш кардага! Курыкмыйча яшә! Синең яклаучыларың, ярдәмчеләрең бар. Караучыларың бар.

Караңгы өйгә капшанып керде. Ут яндырмады. Балаларын да капшап тапты. Өчесе дә чишенмичә-нитмичә сәкегә ауганнар да кочаклашып йоклаганнар. Өстәлдәге агач табакта — суынган бәрәңге. Идәнгә тоз түккәннәр — чыжтырдый. Ул озак кына караңгылыкка карап торды, сәке читенә яңагын куеп чүгеп төште, уң кулын каны чыгарлык итеп тешләде. Тәрәзәдән яңа туган ай карады, бүлмә шомлы сыек яктылык белән тулды. Урамнан аяк очларына гына басып кемнәрдер үтеп китте. Кайдадыр ат кешнәде. Кайдадыр җай белән генә өзелеп-өзелеп бер җыр җырладылар.

Күпер башы күк томан,
Күпсенмәгез, күп тормам.
Язын торсам, җәен тормам—
Сагынырсыз мин булмам.

«Балакайларым, балакайларым! — дип пышылдады аның канлы иреннәре. — Газизләрем, ятимнәрем минем! Мескеннәрем! Әткәгез исеме белән ант итәм, гомерем булса, берегезне дә ташламам! Һәммәгезне кеше иткәнче карармын!»

Кызыл айгыр озак кына карда янына төшмәде. Ул Бибинурдан аерыла алмыйча тып-тып юртып урамнан узды. Кешнәп аваз салды. Күрештеме, саубуллаштымы белеп булмый иде. Ай урагы тәрәзәдән читкә авышты. Мич арасында чикерткә сайрады. Айгырның кешнәве йөрәккә ук булып кадалды.

— Балакайларым, ятимнәрем минем!»

8

Кичә утырган урынмы бу?

Шушы, шушы... Әнә ич, сындырып-сындырып ташлаган шырпылары да үләндә калган. Җыеп аласы булыр.

Ах, кичә ничек рәхәт итеп, матур итеп уйланылган иде. Көне буе бер-

кем комачауламады дисәң дә була. Почта машинасы кайткач та артык каударланмады Бибинур. Инде көтмәсә дә була... Аксыргакка ничә машина сөенеч кайтса да, аңа өлеш юк. Хәбәр юк аңа. Беркем аны юксынмый, ул берәүгә дә кирәк түгел. Сигез ел бер хәбәр алганы юк ич инде. Сигез ел! Нигә быел шулай авыр соң әле? Ялгызлыкка күнегеп беткәч нигә тагын шулай яна? Нигә уянды бу хатирәләр? Нигә алар онытылып бетми икән?

Кичә монда аулак иде, тын диярлек иде. Ә бүген инде бөтенләй башка хәл. Буа алды тулы бала-чага, ятлар да бар, русча сөйләшүләр дә яңгырый. Су керәләр. Бибинур белә, якынрак шәһәрләрдән аксыргаклылар балаларын иртәрәк кайтарып куялар: «Җир исе иснн торсыннар, бабалары салган сукмаклардан йөрсеннәр!»

Аллакай гынам, бүген чәршәмбе бит инде! Бибинурның чүпрә дә таба алганы юк. Кунаклар кайтып төшсә?

Үзеңә генә булса, берсе дә кирәкми — чүпрәсе дә, коймагы да. Байтактан бирле үзеннән-үзе качып ашый: ике бәрәңге пешереп өстәл почмагына куя да йөри-йөри чемченеп ашап та бетерә. Утырсаң уйлата. Өйдә уйлаган уйлар авыр, өйдә уйлаган уйлар күз яшен чакыралар.

Монда кичә бик рәхәт булган иде аңа!

Көн бүген дә матур. Кояш. Сабан туе көнне дә шулай торсын берүк. Җиле дә таман гына. Яшь каеннарның җирне чуарлаган юка күләгәләре йөгереп-йөгереп уйныйлар. Малайлар Бибинур килеп утыргач нигәдер шикләнделәр, тавышлары тынды. Уйнагыз, малайлар, шаулагыз, гөрләгез!

Малайлар белән мавыгып ул янына ук килеп баскан Галикәйне дә абайламыйча калды. Карады да авызын учы белән каплады: Галикәй алагаем калын табанлы ботинка кигән. Биек билле, кесәләре алдан уелган чалбарының балаклары ялтыр-елтыр тимерле. Җиңсез юка күлмәгенең түшеннән дәү каракош очып китәргә әзерләнгән иде.

— Чистый клоун булгансың ич син! — диде Бибинур, кулын чәбәкләп. — Нишләп алай кыланасың?

— Төпчек малай җибәрә,— диде Галикәй, түшен тагын да киереп. — Мода үзгәргән саен биш-алты посылка чүпрәк сала! Ташласаң — җәл, ташламасаң... менә син дә көләсең ич, Бибинур. Урамнан узганда ятсынып этләр өреп кала. Табаны калын булса да, аякка ифрат җиңел нәрсә. Көлмә, көлмә!

Галикәй карт—Аксыргакның атаклы стилягасы. Шәһәрдә нинди кием модадан чыкканын беләсең килсә, аңа гына бар. Төпчек малае, театр художнигы, бар акчасын кием-салымга тотып яшәүче җилбәзәк егет, әткәсен иң гаҗәп киемнәр белән җәфалады, тар балакны авылда иң башлап Галикәй киде, егетләрдән дә алдарак киң балакка күчте, билле бишмәтләр, тире төймә таккан чуар түшле курткалар, — бары да булды Галикәйдә. Соңгы вакытларда ул шәһәр киемнәрен кими дә башлаган иде, бүген ни үзгәргәндер, әллә юри, шаярып кына шулай киенеп чыккан инде? Бибинурны үчекләр өчен кәмит булып киенгәнме?

— Кая барырга чыктың болай?

Бибинур сорамыйча түзә алмады.

— Чыктым шунда, — диде карт таркау гына.

— Нигә аны ачыклап әйтмисең?

— Тигез картай икән аны, Бибинур! — Галикәй Бибинур янына килеп утырды. — Яшьләр арасында ялгыз карт сәяккә бик читен.

— Читен дисең икән?

— Башка берәүгә әйтмәс идем, Бибинур. Син үзең дә читенлекнең ни икәнен беләсең бит. Ни уйлап утырасың?

Буа тавышы да колагына керә Бибинурның, балалар чыр-чуын да

ишетә — су керәләр алар, кычкыралар, көлешәләр. Галикәйнең соравы да читкә китмәде, ул, зәңгәр күзләрен кыса төшеп, аңа борылып карады.

— Син теге озын мәктәп директорын хәтерлисеңме? Керәшен иде үзе, Идрис абыйны әйтәм?

— Теге, тунын йонлы ягы белән өскә киеп йөргән әкәмәт кешенеме? Син мәзәк киенгән дип миннән көләсең, менә ул мәзәк кия иде туны! Хәтерлим.

— Хатынын, Хәнифә апаны онытгыңмы?

— Хатынын оныттым. Кылчык сыман гына шыр бер хатын иде бугай. Әллә шуларны уйлап утырасыңмы, әкият.

— Уйлыйм, Галикәй, аларны да уйлыйм.

— Һәй, эшең беткән икән!

— Син үткәннәрне бер дә уйламыйсыңмы?

— Төрле чак була.

— Уйлыйм да, куркам, Галикәй. Кеше күңеле сизгер була диләр бит. Үлеме, әҗәле якынлашканны сизә диләр күңелне. Әҗәлем еракта түгел кебек.

— Анысы инде, беребез дә мәңгегә килмәгән.

— Син сугыштан туры авылга кайталмадың, Галикәй. Шул Хәнифәне әйтәм. Сугыш беткән елны, җәй башында, сабан туе алдыннан кайтып төште бу. Өс-башы адәм карамаслык. Имәнгеч. Бөтен башы бет кенә. Сыерны саткан ел! Налугына, заемына акча җиткерә алмагач балалар авызыннан өзеп саткан идек мүкләкне. Кышлаган башак ашап байтак кеше кырылган ел. Ачлык! Хәнифә кайтып төште. «Сабан туе күрергә кайттым, Бибинур», ди. Шул бер сүзе җитә калды, бер сүзе! Алдына тезләнеп, тезләрен кочаклап җыладым бичараның. Мунчага күтәреп алып киттем, йөрерлек хәле юк иде. Сабан туен онытмаган бит, Аксыргакны онытмаган! Ташлыярны онытмаган! Шул бер сүзе өчен җәй буе карадым, эшкә йөртмәдем, ял иттердем, өс-башын рәтләдем. Күрәеп, ныгып китте. Бер тартма күкәй бирдем, каклаган казым бар иде, анысын юлга тыктым. Китте дә югалды. Үпкәләмим.

— Юмарт куллы син, Бибинур.

— Шуны уйлап утырам әле, ике тапкыр озаттым үзен, икесендә дә хат язмады. Нигә бер кайтып килмәскә, ә?

— Бәлки исән түгелдер?

— Исәндер, арык кеше озак яши диләр бит.

— Аңа да картлык килде, картлыктан да алама нәрсә юк, Галикәй.

Бибинур тагын беравык сүз дәшмичә генә утырды.

— Юк, — диде ул, башын чайкап. — Һәр яшьнең үз яме, үз куанычы бар. Мин картлыгымнан бер дә зарланмас идем дә... Әй, Галикәй, син улың белән яшисең бит!

— Әйттең сүз! — Галикәй сикереп үк торды. — Менә бу кәмит киемнәрне киленгә үч итеп киеп чыктым бүген. Ни кисәм, шуны күпсенәләр.

— Юаныч юк сиңа, Галикәй.

— Әнә, өч-дүрт карт, аптыраганнан бергә җыелып, җомга намазы укый башлаганнар.

— Эч пошканнандыр ул, Галикәй. Син дә йөрмисеңме соң?

Галикәй зур авызын тутырып көлеп куйды.

— Яшьтән үк ышанмыйм мин аллага!

— Шулай укмыни?

— Сәбәпчесе кем диген әле тагын. Мулла бабай аркасында булды. Искегә тисәң исең китәр, үткәннәремне телгә алырга өнәмәсәм дә сиңа сөйлим, Бибинур. Кызык кына ул. Әткәй белән әнкәйне беләсең, ярлы булсалар да дингә ышаналар, мулланы олылыйлар иде. Сәдакасын ил-

тәләр, корбан чалып хәзрәтне ашка чакыралар, мәш киләләр. Үзләре шыр надан инде бичаралар, әлифне таяк дип тә белмиләр. Шулай, бер бәйрәмдә ашка хәзрәт тә килергә тиеш. Казанда быкыр-быкыр ит кайный, мич төбендә бакра иләге хәтле бәлеш кабарып утыра. Исе, исе! «Бар, — ди әнкәй, — мулла бабаң озаклады. Хәйриләрдә ашта булырга тиеш, чаптырып кына алып кил үзен», — ди. Ә минем казан тулы ит янынннан, бәлеш яныннан беркая чыгасым килми. Әткәй мәрхүм капка төбенә бер чыкты, ике чыкты, өйдә читтән кайткан кунаклар да бар, ул да түзмәде, «барып кайт, улым» диде бу. Әткәйгә карышып тору юк, яланаяк кына әлдердем бер очтан бер очка! Бәлеш исе авылның бу очына кадәр таралган! Хәйри абзыйның кунаклары табын яныннан гына торып чыкканнар, кем комган белән кулын юа, кем каурый белән тешен чистарта. Арада хәзрәт бабай да бар. Мин аның колагына гына: «Хәзрәт бабай, әти тизрәк килеп җитсен, диде», дип пышылдадым. «Ә, алаймы, бәракалла, хәзер кузгалам!» диде дә, хуҗалар белән саубуллаша башлады. Мин аны урам якта көтеп тордым. Хушлаштылар, рәхмәтләр укылды, Сибгатулла хәзрәт артыш таягына таянып килеп тә чыкты. Хәтерлисеңме икән, җирән сакаллы, мәһабәт кәттә гәүдәсе өстенә, холкы-фигыле дә күркәм иде мәрхүмнең. Ике улы кызылларда сугышып йөргән өчен аклар җанын кыеп, үз лапасында асып киттеләр аны. Шул. Ул алдан бара, мин аның артыннан теркелдим. Шуннан. — Галикәй тагын авыз тутырып көлеп алды. — Әллә нинди ят, сәер тавыш килә. Башта бик озак аңламыйча, як-ягыма каранып бардым. Алга үрелеп күз салам, артка борылам, бер нәрсә дә юк, ә тавыш гел бездән калмый. Кош та түгел, арба да шыгырдамый, үзенә бер тырт та тырт дигән сәер аваз чыга. Кая ул, исеме безнең өйдә иман белән бергә олылап телгә алынган, ул ни кушса үтәлгән, үлгәч теге дөньяда оҗмахка юл ача торган кодрәтле, мәһабәт кешенең гап-гади авыл мужигы сыман шартлатып баруын мин күз алдыма да китермәгәнмен... Шунда җил исеп китте дә мин хәзрәт бабамның нишләп баруын аңлап алдым. Хәзерге аңым белән бик беләм, көненә җиде-сигез табында симез каз ите ашап, бәлеш төбе кимереп йөргән хәзрәт юлда аз-маз бушанмаса кайда җиңеләйсен? Ул да мине, сабан калагы хәтле малайны, кешегә чутламаган инде, биргән дә ишкән... Мәгәр шул кичтән хәзрәтләргә, догаларга, дингә ышанычым тәмам бетте!

Бибинурга да күңелле булып китте, тик ул Галикәй кебек буа өстендә йөзгән казларны куркытып шаркылдап көлә алмады, җиң очы белән иреннәрен генә каплап утырды.

— Әйбәт кеше иде мәрхүм, — дип куйды кинәт Галикәй.

— Театрларда гына хәзрәтләрне гел дурак, ахмак итеп күрсәтәләр.

Галикәй канатланып китеп, тагын нидер сөйләргә тотынган иде, Бибинурның тыңламаганын күреп, туктады, аңа иярәп башын күтәреп карады: почта машинасы килеп туктады, өйдән ябырылып кызлар чыкты, бушата башладылар. Хәзер Бибинурны бер генә уй борчый иде: көтәргәме, китәргәме? Кайсы яхшырак булыр?

— Нигә кармакларыңны алмадың, Галикәй?

Аптыраганнан гына сорау иде дә, Галикәй әйбәтләп җавап бирде:

— Капмый бу араларда. Әллә һава үзгәрергә тора инде.

Ачык тәрәзәдә кул күренде, Бибинур сикереп торды.

— Күрдеңме, Галикәй?

— Күрмәдем.

— Кул изәделәр, чакырдылар. Әнә тагын! Әйдә әле, Галикәй, әйдә әле!

Гәүдәсенең авырлыгын тоеп утырган Бибинурга мондый җиңеллек каян килгәндер, почта янына очып барып җитте, сунарчы Галикәй аның артыннан чак өлгерде. Тәрәзә каршысына барып бастылар.

Кызыл яулыклы, зәп-зәңгәр күзле Бибинур янында мыеклары хә-

тәр тырпайган каракошлы түшле Галикәйне күргәч, Миңлегөл көлмичә түзә алмады, учы белән авызын каплап пырх-пырх көлде.

— Ник чакырдың? — диде аны ашыктырып Бибинур.

— Галикәй бабайга посылка. Өеңә илтеп бирикме, монда гына аласыңмы?

— Кемнән тагын? — диде шикләнеп Галикәй.

— Төпчек улыңнан!

Галикәй кулын селтәп китә үк башлады.

— Тукта инде, — диде аны әрләп Бибинур. — Ай аллам! Буш тартма булса да килсен иде әле!

— Беләм мин. Тагын бакча карачкысы итәргә маташалар.

— Кире җибәрикме, Галикәй бабай? — дип сорады Миңлегөл.

— Ярар инде, ачып карыйк. Валлаһи дип әйтәм, адәм көлдерерлек посылка булса, кадаклап кире салам! Икмәктер, кояш йөзен күрмим.

— Булсын иде әле, килсен иде, — дип уфтанды, хәле китеп Бибинур.

Шулай да аның посылканы ачтырасы килми иде, кичә балыксыз кайтып хурлыкка калды Галикәй, бүген тагын чүп-чар, артык кием килсә...

— Ачмый тор, өеңә кайткач та өлгерерсең!

— Олы малайга күрсәтеп тә тормыйм мин аны. Бигрәк тә килен күрмәсен. Их, Бибинур, үз ишең белән тигез генә картай икән ул.

Ул Миңлегөлдән өтергә белән чүкеч сорап алды һәм посылка тартмасын житез генә каерып ачты. Посылка эчендәге әманәтләр ыспайлап ак кәгазьгә төрелгән иде, борынга тәмле ис килеп бәрелде. Яңа ис, кибет исе, күчтәнәч исе. Галикәй кытыршы учларын бер-берсенә ышкыды:

— Мал күренә әле монда!

Бибинурның борын яфраклары дерелдәп китте: кәгазь астыннан иң элек полиэтилен капчыкка тутырылган ун-унбиш кап чәй килеп чыкты. Һиндстан чәе, кәгазенә фил сурәте төшерелгән. Чәй астында биш-алты банка шпрот, өч кап кыйбатлы конфет, хөрмә, кап-кап солы печеньесы, тагын әллә нинди тәм-томнар да бар иде. Иң аста тагын бер төргәктә бик әйбәт, өр-яңа ирләр күлмәге һәм баш яулыгы...

— Әллә сине өйләнгән дип уйлаганнар инде болар! — дип кычкырды Бибинур.

— Ялгыз интекмә, өйлән дип хат саен яза малай. Вәт бу юлы кирәген белгән!

Яулыкны ул Бибинурның иңенә салды:

— Һай, килешә икән үзеңә, Бибинур. Сабан туе бүләге булыр, кырылма!

— Кирәкми, Галикәй, кичә генә яңа яулык сатып алдым, күрмисең дә, — диде Бибинур, бүләкне кире биреп.

— Юк, юк, син ал. — Галикәй шыпырт кына өстәп куйды: — Барыбер киленгә эләгә!

— Аңа күрсәтмә, жый да куй, — диде Бибинур. — Нигә миңа тагын бер яңа яулык? Ишетелсә, балалар яратмас.

— Эх, сине! — дип селтәде кулын Галикәй. — Мә, алайса, тот. Кәнфитнең бер кабы сиңа, балык яратканыңны да беләм, аны да ал. Чәйне аласың да аласың инде.

— Син миңа, жәлләмәсәң, әнә теге печеньены бир. Солы печеньесы бик тәмле була дип ишеткәнем бар, ашап караганым юк.

Бибинурга мул эләкте күчтәнәч — алъяпкычы тулды. Бер кап кәнфитне Галикәй почта кызларына бирде: «Бүлеп ашагыз!»

— Балалар янында тәмләп ашап та булмый, Бибинур, — дип дәвам итте ул. — Авыз да олы, чапылдый торгандыр инде... Нигә шуны

утырган саен телгә алалардыр: «Шапылдатма, эти», ди малай. «Тынычрак аша, эти», ди килен... Тәмле ризык кергәч авыз үзеннән-үзе шапылдый инде, аны тыеп булмый. Рәхәтләнеп тәлинкә ялаган юк, иң тәмлесе, өресе юынтык суга чыга.

Ул кинәт Галикәйне үз өендә, үз өстәле артында, үз табыны янында күрде. Культурный булып кылана торган, ипи телемен дә чәнечке очы белән генә авызына китергән киленен күрде. Ярдәм итәргә кирәк Галикәйгә, дип уйлады Бибинур. Әллә? Туп-туры өйгә алып кайтыргамы? Икесенә дә рәхәт, кулай булыр иде. Менә кайчаннан бирле бакчада утыралар, гел юк-барны сөйләшәләр, икесенә дә рәхәт. Солы печеньесыннан авыз иттеләр, чапылдыймы авыз, юкмы, карап-гаепләп торган кеше юк, рәхәт. Рәхәт тоткынлыктан мәшәкатьле иреккә чыгарырга кирәк аны!

Әгәр Зөһрәбану белән кавышсалар?

Зөһрәбануны да ялгызлыктан коткарганда ярыйдыр ла?

— Син, бар, бик әйбәтләп өс-башыңны алыштыр. Мыегыңны төзәт. Авызың күренми башлаган. Мин Зөһрәбану янына керә торам.

Галикәй аның тел төбен аңлап алды, «җиңеләя башлаганмы әллә бу апабыз?» дип күңелсезләнеп уйлады.

— Яулык бүләк иткән булып берәздән аларга төшәрсең.

— Сугышып бетмәссезме?

— Бетмәбез, курыкма. Татулашырга уйлыйм. Минемчә, аның бер генә юлы бар. Калган көннәрне хәсрәт-моңсыз гына үткәрергә уйлыйм. Менә син уйлап, әзерләнеп төш.

— Ни уйларга кушасың инде минем буш башка?

— Зөһрәбану янына кучәсең.

— Ә?!

— Нигә акаеп каттың, Галикәй?

— Соң аның агуы бүлгәләп таратсаң Татарстанны үтереп бетерергә җитә бит. Үлгәч аның каберенә кош кунычак түгел.

— Сабыр гына уйлашыйк әле.

Башта Бибинурның тәкъдиме шундый кызык, шулай мәгънәсез, хәтта ки мыскыл итү булып тоелган иде, Галикәй авызын җыя алмыйча шаркылдап почта буен яңгыратты, каен башына килеп кунган пар саескан да шүрләп урман ягына таба очып китте. Почта тәрәзәсенә кызлар өелде.

— Ну көлдердең, Бибинур. Валлаһи!

— Ә син көлмә. Син дә ялгыз, ул да ялгыз. Аңа кемдер кирәк. Гомере буе кемнедер көтеп яшәде ул. Мин беләм! Гомеренең ахырына бару куркыныч аңа хәзер. Ул бик уйлана, борчыла.

— Каян беләсең? — Галикәй көлүдән туктады. — Сөйләшкәнегез юк ич.

— Кайбер кеше белән сөйләшмәсәң дә, күңелләр гел аңлашып тора. Без бер тән, бер җан идек. Сизәм!

— Ә син ялгыз түгелме? Гомер актыгына бару сиңа куркыныч түгелме?

— Минем балаларым бар, — диде Бибинур тыйнак кына. — Мин алар белән яшим.

Галикәй сүгенгәнен сизми дә калды:

— Соң, ул шиңгән кишерләрне бала дип кем әйтә?!

— Син үз балаларыңны да кеше алдында хурлама, Зөһрәбану янына төшкәч ялгыш сүз ычкындыра күрмә... Минекеләргә дә сүз әйтмә. Балалар түгел, заман үзгәрде. Алар башкача яши.

— Аларга да ике-икен дүрттер инде?

— Анысын кем белгән? Тик алар башка заман кешеләре. Мин аларны аңламыйм. Аңламаган нәрсәмне олылыйм мин. Әйдә, хәерле бул-

сын! Мин алар булганга куана алам. Миңа күп кирәкми, шул да житкән.

«Ник берегез кайтмый? Ник берегез хат язмый?» дип күңеле өзгәләнсә дә, Бибинур тыштан тыныч, сабыр иде.

Галикәй посылка тартмасын ике куллап корсагына терәп кайтып китте, Бибинур:

— Кара, озаклама, төшеп жит! Аны-моны сиздермә, сабан туе бүләге итеп яулык керттем, диген. Калганын үзем жайлармын.

Бүген чәршәмбе. Чәршәмбедә башланган эш уңай барып чыгамы? Чәршәмбедә олы эш башлыйлармы? Бибинурның боларны күзәтеп торырга, күңелендә билгеләп барырга вакыты булмады. Ул көн дип тормады, төн дип тормады, гел эшкә чапты. Чәршәмбедә башланганы булгандыр, уңышсыз, уңышлы тәмамлангандыр, ул эш башларга тәвәккәл иде. Шәт-иншалла, бусы да уңышлы тәмамланыр әле, дип уйлады.

Гомере бик күп калса, ул ярсынып ашыкмас иде. Ә болай кем белгән? Төгәлләнәсе эшләр төгәлләнергә тиеш. Бурычлы килеш ничек китмәк кирәк?

Күңел түрендә Бибинур үзен Зөһрәбану алдында гаепле саный иде: ул ашыгып-кабаланып карт кешегә кияүгә чыкмаса, «намусы таплы булганга шулай ашыгып чыкты ул», дигән кара гайбәт таралмаса, мөгаен, Зөһрәбану да үз парын тапкан булыр иде. Тәндә көч-сихәт барында Зөһрәбану белән араны рәтләп куясы килә. Бу эшне калдырырга ярамый. Теге дөньяда да каргыш ишетеп ятармы Бибинур? Ә теге дөнья дигәннәре чынлап та булып куйса? Аның Габдуллажаны — ил өчен шәһит киткән асыл сөяк — жәннәттә булып, Бибинур аның белән күрешә алмыйча газапланып жәһәннәмдә янармы? Аллага ышанып бетмәсә дә, ни булмас, берәүнең дә кайтып сөйләгәне юк, ул куркып кына жиргә дә, күккә дә карап алды...

Ул барып кергәндә, Зөһрәбану, жиргә чүгәләп, ярык тагарагында тавыкларга көрпә болгата иде. Иске кара пиджагын мунчала бау белән буган, аягында дәү иске галушлар, балакларына тигәнәк сарган. Авызындагы ипине чәйни дә шуны көрпәгә коя. Бибинур кергәнне ишетмәде дә. Тавыклары сырып алган, талашалар, чукышалар, бер читтәрәк күкрәк киереп тук әтәч йөренә.

— Исәнме, Зөһрәбану.

Ипи катысын чәйни-чәйни Зөһрәбану Бибинурга күтәрелеп карады да торды, пиджак итәгенә ябышкан ипи валчыкларын сыпырып тагаракка төшерде, аннан соң гына жавап бирде:

— Исән. Үзең сау гына йөрисеңме?

Тындылар. Бер карында яткан куш жаннар, нигә сүзегез юк? Гомер буе читләштегез, ни бүләсегез бар иде? Ни файда күрдегез?

Икесенең дә телендә шул иде, тик берсе дә кайтарып әйтмәде. Тавыкларны караган булдылар, астан-аска гына бер-берсенә күз салдылар. Берсендә зәңгәр күз, икенчесендә кара. Ә сүз ялганмады, ялганып китә алмады.

— Тавыкны шактый мул асрыйсың икән, — дигән булды Бибинур.

— Жан көекләре инде. Юньләп күкәй салганнары да юк. Ашарга дисәң, убыр кебек умыралар.

— Кош-корт ашый инде, — диде Бибинур битараф кына.

— Син элек каз асрый идең, хәзер бездән бугай?!

— Бизелде. Мантымадым мин алардан.

— И-и, кош-кортка да әллә ни булды. Бәбкәләре кырыла, теге агулы ашлык бик зыянлы ди бит.

Тагын юк-барны сөйләшеп алдылар. Бибинур: «Нигә өенә чакырмый инде бу надан?» дип уйлады. Зөһрәбану: «Нигә керде икән бу Бибинур?» дип баш ватты. Ул арада булмады, югары очтан жил-жил төшеп килүче Галикәй күренде.

— Нигә монда торабыз соң әле? Әйдә, өйгә керик, Зөһрәбану, — диде Бибинур. — Аннан өс-башыңны алышыр идең. Сабан туе алды, я берәрсе килеп керер.

— Керик соң, — диде Зөһрәбану, теләр-теләмәс кенә. Үзенең кызыксынуы артты, кერә-керешкә билбавын чишеп караңгы почмакка ташлады, галушларын болдыр тактасы астына ук, күз күрмәс аулакка тыкты, таушалган шакмаклы яулыгын да салып ыргытты. Чәчләре мул икән әле аның, елкылдап ук тормаса да, күперенке күренә.

— Туып-үскән йорт! Әткәсе салган өй. Нигезгә яткан юан-юан бүрәнәләр череп муртайган, басылып бер-беренә иңгәннәр. Тәрәзә борыслары кыеш та мыеш, рамнары череп каралган. Ир-ат кулы юк. Ир-ат кулы тимәгән. Өй эчендә генә һаман шул татлы-хәсрәтле ис — эремчек суы исе.

— Уйладым-уйладым да, кереп чыгарга булдым әле, — диде Бибинур, алъяпкычына төйнәлгән күчтәнәчләрне капшап. «Галикәй кергәч чәй эчәргә булыр, бу саранбикәдән әллә ни көтеп булмас!»

— Нигә кермәскә? — диде чыра телә башлаган җиреннән калкынып Зөһрәбану. Ул нидер сизенгән кебек, Бибинур юкка гына кермәс, дип уйлап, ашыга-ашыга чыра телде, самаварына су тутырды, ут кабызды. Шул арада өс-башын да карап өлгерде, озын гына итәкле билле зәңгәр ефәк күлмәген киде. Яулыгы гына искерәк иде, шуңа карап Бибинур елмаеп куйды.

— Самаварың исән икән әле.

— Бик чыдамлы нәрсә булды, бик түземле. Үзе тиз кайнап чыга, бер тамчы су типкәне юк, рәхәтләнәм! Чәйнек чәе ләззәтле булмый.

Ишегалдында аяк тавышы ишетелде, Галикәй юри йөткеренеп, өряңа галушларын, чип-чиста булса да, озак кына сөртеп азапланды.

— Синең аяк артың җиңел булды, ахрысы. Тагын кемдер бар.

— Кем йөри икән анда? Ә, бу Галикәй ич!

— Бәй, бер дә бусагамны атлап узган кеше түгел. И ходаем, бербер хәл бармы әллә?

— Ни булсын? — диде Бибинур, исе китмичә генә. — Йөридер. Сабан туе җитә бит!

Аны-моны ачыкларга өлгергәнче, ишек ачылды, иң әүвәл Галикәйнең гадәттәгедән текәрәк өскә караган мыек чылгыйлары, аннан тукмак борыны, вак бәлеш хәтле авызы, аннан соң гына үзе күренде. Аягында ак оек, чалбары да яңа, килешеп тора, буй-буй соргылт лавсаннан теккән, бүлтәйгән кесәләре янда, кешечә, күлмәге дә буй-буй, озын җиңе каптырган, күлмәк якасының өстәге бер төймәсе эләктермәгән. «Яшьләрчә киенгән абзагыз! Күрдегезме?» дигән кебек, ул ике игезәк карчык алдына тып итеп кереп басты. Бибинур Зөһрәбануга карады. Зөһрәбану чөеп бәйләгән яулыгын сиздермичә генә җилкәсенә төшереп кунак алдынарак чыкты:

— Әйдүк, Галикәй абзый. Уз.

— Исән-сау гына торасыңмы, Зөһрәбану! — диде Галикәй. — Бәй, Бибинур да монда икән ич!

«Риза! Риза булмаса, алай тиз төшмәс иде!» дип сөенеп уйлады Бибинур. Хәзер эш Зөһрәбануда гына калды.

Өчесе өч җиргә утырып өч уй уйладылар.

«Тәртә арасына кергәч чыгымчы ат та юашлана!»

Бу — Галикәй...

«Ходаем, юкка гына йөрми болар. Тикмәгә генә кермәгән!»

Бусы — Зөһрәбану.

«Башлаган эшемне ахырына җиткермичә туктаганым юк!»

Монысы — Бибинур.

Сүзсезлектән житез самавар коткарды — гөрелдәп кайнап чыкты, идәнгә чәчрәп су түгелде. Бибинур самаварга ябышты, Зөһрәбану мун-

чала белән идәнне сөртеп алды, өстәл янына утырыштылар. Чәй чынаяклары килде, бал калаклары, ипи телемнәре, Бибинур алъяпкычын чишеп кәнфитен, печеньесын өстәлгә таратты, чәй ясалды, Галикәй чалбар кесәсеннән күз явын алырлык, елкылдап торган юка яулык тартып чыгарды.

— Сиңа, Зөһрәбану. Сабан туе бүләге. Ал, ал, әллә ниләр уйлап та торма, гаҗәпләнмә дә. Ал, дим!

Галикәй Зөһрәбануның яулыгын тартып алып, иңөстенә үз бүләген ташлады. Ирләр катында яланбаш утырырга гадәтләнмәгән карчык тиз-тиз яңа яулыкны бәйләп тә куйды, көзге каршысына барып бер бөтерелеп тә алды.

— Матур, — диде эчкерсез сокланып Бибинур.

— А кәкже,— дигән булды Галикәй, бүксәсен киереп.

Зөһрәбану елап җибәрде.

Бүлтәйгән икенче кесәдән башланмаган Һиндстан чәе чыкты.

— Бүләккә каршы бүләгем генә юк, — дип каударланды Зөһрәбану. Ул тәмам югалып калган, күзләре рәхәтләнеп елмаялар, битенә барлыгы күптән онытылган сыек алсулык йөгергән иде. — Бүләк белән йөрисез икән!

— Бар ул бездә маллар! — дип шапырынды Галикәй. Бибинур аңа ялт кына карап алды, сүзсез генә берәр чынаяк чәй эчтеләр. Галикәй чынаягын тубырлы-тубырлы биш бармагы өстенә утыртып, тимерче күреге күк өрә-өрә, рәхәтләнеп, шопырдатып эчте, аңа беркем бер сүз әйтмәде.

— Кече малайдан посылка алдым бүген. Ипле булып чыкты анысы. Үз янына да чакыра. Китәсе килми. Сабан туена гына кайта алмаганнар. Анысы жәл. Вчүтеки авылны онытып бетерергә ярамый. Хәер, анысы бар инде, авылда яшәп тә аның гадәтләрен саннамаучылар бар. Примергә минем киленне алыйк.

— Балаларны яманламыйк әйдә, — дип сүзне кыскартты Бибинур. Ул, дөресен әйткәндә, бик гаҗәпләнеп утыра иде, башта, Галикәй Зөһрәбануның башыннан яулыгын тартып алгач, «Беттек, чыра агачы белән төя икән безне!» дип уйлаган иде. Карый, күрә — ипле генә йөри хуҗабикәң, кая ул, дуламый да, чәпчеми дә, Галикәйгә матур-матур карап куя.

— Олыладың, Галикәй абзый. — Матур карашка өстәп нинди ипле сүзләр дә әйтә беләсең икән син, әй!

Бибинур да яулыкны мактады:

— Төсеңә килешә, Зөһрәбану.

— Бибинурга бүләк булдымы? — дип сорады Зөһрәбану.

— Аңа да әләкте, — дип горләде икенче чынаягын биш бармагына утырткан Галикәй. — Малай тиешен белеп кенә җибәргән бу юлы!

— Бу яулыкның бер хикмәте бар, — дип сүз кыстырды Бибинур. — Ул сине күптән җәмәгатьле булган дип беләдер.

— Өйләнә, ялгызың бусарып ятма! — дип хат саен яза.

Зөһрәбану кинәт сагайды, чәең тезенә түкте, йөзе кырысланды, йомшак-тәмле сүзләре тешенә сыланып онытылдылар.

«Хәзер, хәзер!» дип ашыктырды күңеле Бибинурны, тик ул Зөһрәбану янында сак булырга кирәген, сабырлык аша гына максатка ирешеп буласын аңлый иде. Сүз тагын сабан туена әйләнеп кайтты, кемнәр кайтыр, кемнәр кайтмас дип санап чыктылар: фәләннәр бик еракта тора, кайтып җитә алмаслар дип хафаландылар... Сүз тагын чәй янына, күчтәнәчләргә, күчтәнәчләрдән төпчек малайга, аның акыллы киңәшләренә әйләнеп кайтты да, Галикәй: «Помры башлы минем төпчек, хат саен шуны яза миңа!» дип тәмамлады. Аннан ашыгып-ашыгып чәен йота башлады, эре тешләре арасында Зөһрәбануның шикәр шакмаклары тегермән ташлары арасына кереп кысылган иген бөртеге ке-

бек онландылар, бер шакмак капты, икене алды Галикәй. Зөһрәбану бая чәй түгелгән тезен уа башлады. Һәм, һич көтмәгәндә, ботын тотып карады. Тәне таза, нык иде әле Зөһрәбануның.

— Без сиңа бер олы киңәш белән кердек бит, Зөһрәбану, — диде, ниһаять, Бибинур. Галикәй шикәрен вакламыйча гына йотып җибәрде, ашыгып чынаягын каплады.

— Эч тагын берне, Галикәй абзый.

— Булды, булды, бик рәхмәт.

— Нинди киңәш икән ул? — дигән булды Зөһрәбану, яулык читен тешләп.

— Һәммәбезнең үзенә күрә тормышы бар, дигәндәй, син яшәп ятасың, мин дә шулай, алга барам. Менә Галикәйнең генә тормыш көйләнеп бетмәгән. Төпчек улы читтә яшәсә дә аңлый, акыллы бала, киңәше туры.

— Көйләнгән ич аның тормышы! — дип, юри генә каршы килеп маташты Зөһрәбану. Галикәй өендә нинди сәмум җилләре искәнен ул бөтен кешедән яхшырак белә иде, югыйсә!

— Турысын әйткәндә, өйдә тынычлык юк аңа. Яшьләр арасына сыеп бетми.

Галикәй корсагын сыпырып кикереп куйды.

— Менә син шуны гына әйт, Зөһрәбану, — диде ул. — Малай бүгенгесе көндә «башка чыгам» дип бытырдый. Өч ел элек кенә йорт яңарттык, күреп йөрисең, шыңгырдап торган нараттан салдым өйне. Кай җире ошамый диген? Ә-ә, мин ошамыйм, менә нәрсәдә хикмәт! Мине ялгыз калдырып чыгып китмәкче булалармы? Түгел, шәһәргә җибәрәселәре килә, котылмакчылар. Сүз юк, малайның мондагысы да әйбәт, килен дә ничава... Бер көн мунчадан ак ыштан белән кайткан идем. Чалбар кияргә онытылган. Килен «фу» дип борынын җыера... Гарипме әллә мин, кыек-мыекмы?

Зөһрәбану, ике кулы белән дә тезләренә суккалап:

— Мондый эштә миннән нинди киңәш кирәк соң сезгә? Минем баш бик юка, ишеткәнем дә әләгеп тормый хәзер, — диде дә Бибинурга карады.

Бибинур:

— Әллә, мин әйтәм... — дип башлаган иде, Галикәй аны бүлдерде.

— Тукта әле, Бибинур. Үзем әйтеп карыйм. Син ялгыз, Зөһрәбану, ялгызлыкны беләбез. Әллә соң бергә-бергә тора башлыйбызмы?

Зөһрәбану дер-дер калтырарга тотынды: сүз әйтмәкче була — иреннәре дер-дер, кулы белән күрсәтмәкче була — бармаклары дер-дер килә.

— Галикәйне беләсең, җайсыз кеше түгел. Аракы белән дуслыгы чамалы. Ир исе килерлек кенә. Холкы ипле.

— Мине адәм көлкесенә калдырырга йөрисезме? — Зөһрәбануның кашлары югары күтәрелде.

— Шундый ук әшәке кеше мени мин? — диде Галикәй, бик җитди итеп.

— Алай дигәнем юк.

— Алай димә, Зөһрәбану. Яучы булып караганым юк, тик монда качыш-качыш уйнарга кермәдек. Галикәй таза, сәламәт, бер-берегезгә юаныч, терәк булырсыз. Картлык көннәрегезне уртак итәрсез.

— Нигә үзең чыкмыйсың, алайса, аңа?

— Миңа сүз кушканы юк. Аннары минем, беләсең ич, балалар...

«Ну, хәйләкәр дә инде соң бу хатын-кыз!» — дип сокланды Галикәй. — Сүз кушканы юк дип, чәпчи башлаган Зөһрәбануны эретте дә куйды бит!»

Ул сиздермичә генә Бибинурга күз кысты: «Молодец!»

— Хәзер аш салам, чырлый тавыгым бар, шуны суям.

— Суябыз аны, Зөһрәбану, — диде Галикәй, җиңен сызгана ук башлап.

— Мина китсәм дә ярыйдыр, шәт. Рәхмәт үзенә, Зөһрәбану. Сүземне җиргә екмадың, монысы өчен мең рәхмәт.

Зөһрәбану каушаудан берни әйтергә дә өлгермәде, Галикәй шаулап:

— Ярый, ярый, Бибинур. Тик шулай да ашка соңга калма. Башка кунагыбыз юк, — дип алып та китте. — Шулаймы, Зөһрәбану?

— Шулай, шулай, Галикәй абый.

Бу ике тапкыр кабатланган «шулай» һәммәсенә дә ризалык булып яңгырады.

Ул кичне Бибинур ут яндырмады. Зөһрәбануларга ашка да төшеп йөрмәде. Аксыргак урамында хәрәкәт көчәйде, аның кеше күзенә бик чалынып йөрисе килмәде. «Жигули»лар узды, «Москвич»лар чапты, кемнәрдер пар атта үттеләр. Гармун тавышы тынмады. Бүген чәршәмбе генә иде әле, югыйсә! Бер көн киткән кайгы телеграммаларын алып сөенешкән кешеләр Сахалинда, Губахада, Татар бугазында дәррәү яу кузгалганнар икән, кайтып та җиткәннәр. Аксыргакның тар урамнары киңәйгән! Әйдә, кайтсыннар.

Солы печеньесы гаҗәп тәмле икән. Гомере буе солы игеп, солы арасында уралып, шуның печеньесын Бибинур беренче тапкыр авыз итте. Печеньедан солы умачы тәме, талкан тәме, кичке учаклар тәме, ат улагы исе, ат тире исе килгән кебек булды.

Галикәй белән Зөһрәбану янына төшеп йөрмәде бүгенгә, сәкегә менеп ятканда үз өстеннән бик олы бурыч төшкәнен, сыңары белән арасы яхшыруын аңлады. Галикәй дә, шуны көтеп йөргәндәй, бик тиз ризалашты, анысы гаҗәп түгел, тормыш үзенекен итә. Зөһрәбанунын шулай сөенеп, ансат кына күнеп калуына исе китте Бибинурның. Әллә ул да шуны уйлап, шуны алга куеп, өметләнеп яшәгәнме?

Өстән олы бурыч төште, тагын ни кирәк, инде дөньялыктан тыныч кына китә алсам иде, дип уйлады ул, күзләре белән түшәмгә текәлеп. Тик балалары гына аның киләчәк белән бәйләнешен өзәләр. Әниләренең киләчәк көннәренә чик куялар кебек.

Болай дип беренче генә уйлавы түгел иде Бибинурның, икенче мәртәбә дөнья белән хушлашырга җыенуы иде бу, моннан биш-алты ел элек тә нәкъ шундый уйлар белән түшәмгә карап яткан иде. Бетте дип санаган иде, ул чагында бетмәгән булып чыкты. Тормышында һич күз алдына китермәгән, уйга да кертеп карамаган үзгәрешләр башланды. Әгәр бу юлы да шулай булып чыкса?!.

Син бер төрле уйлыйсың, дөнья икенче яктан үзенекен эшләп куя.

## 9

Картаюны төрле кеше төрлечә каршылый. Төрлечә кичерә. Берәүләр кинәт кенә сәламәтлеккә туймый башлый: күз начар күрә («җеп сапларга кеше кирәк хәзер!!»), колак томалана («и, безнең заманда сарыгына тиклем «бә-ә» дип урам тутырып кычкырып кайта торган ие, хәзерге заман малының да мәне юк, авызлары ачык, тавышлары юк!»), аппетит начарлана («авызның тәме беттеме, ашаган ризыгым ләззәтле түгел!»).

Икенче берәүләрнең сәламәтлегендә үзгәреш сизелмәсә дә, рухлары төшә, эшкә кул бармый, эш тәме югала. Элеккеге гадәтләр үзгәрә, кием-салымга мөнәсәбәт алмашына, «ни кисәң дә ярый ла хәзер!», кыскасы, картаю галәмәте һәркемгә төрлечә, һ ә р к е м г ә үзенчә генә килә.

Бер дә картаймас кебек йөргән Бибинур бер елны үзендә зур үзгәреш сизде. Күзе әйбәт күрә күрүен, энгердә дә нәзек энәләрне саплый ала, урамнан узган машина номерларын да ачык абайлый, киногабарса да, алдагы рәтләргә елышмый. Колагы да сак: яз житеп, кар эреп ерманакларга су төшә башлаганда, тәүге тургайлар килгәч, алар тавышын, гадәттә, беренче булып ул ишетә. Тургай килгәч тә тәрәзәләрнең эчке рамнарын алып куя да өенә яктылык һәм язгы авазлар кереп тула.

Моңарчы табигать үзгәрешләренә үтә сизгер жан иде ул: ел саен, яңа ел адыннан численник сатып ала да үзе аерата мөһим дип санаган вакыйгаларны шәмәхә карандаш очы белән тырнап шунда теркәп бара иде. Аның чормасында табигать яңалыклары теркәлгән байтак численниклар хәзер дә саклана булыр әле! Гади генә, кыска гына итеп язып куя. Әмма һәр язганы аның өчен олы әһәмияткә ия: «Фәләненче мартта тургайлар килде», дип язган икән, бу инде Бибинур чамасыз нык дулкынланган көн. «Апрельнең фәләнендә Ташлыяр тушлады, бәке янына барырлык түгел». «Бүген су ташый башлады, таң алдыннан боз кузгалды», дип язган икән, бу хәбәрләргә Бибинурның әллә нихәтле хатирәләре бәйләнгән. «Кибеткә сатин кайтты, мендәр тышлыгы, түбән оч хатыннары талаша-талаша алып бетерделәр». «Әзһәр хатыны Кәмәрия игезәк малай алып кайтты, бәхетләре белән килсеннәр, ярабби, безнең кебек булмасыннар!» «Сабан туенда быел да Йолдыз кашка алга чыкты, кызыл айгыр токымы».

Болар берсе дә буш сүз түгел, тиктомалга гына көнгә-елга бәйләнмәгән, болар Бибинурның тормыш белән бәйләнеше, яшәешенең иң кадерле истәлекләре...

Пенсиягә аны иртәрәк чыгардылар, яше житсә дә эштән китми иде әле Бибинур. Авылда хатын-кызга эш кимеде. Атлар саны азайды, айгырлар вакланды, бияләр юашланды. Төп эш булып фермада сыер саву гына калды. Бибинурның бу җәһәттән яшьләр белән алышырга йөрәге житмәде.

Пенсиягә чыгуны да картлык дип санамады ул, әмма бер ел үттеме, икеме, тормыш агышы, колхоз эшләре белән генә түгел, ел фасыллары, табигать үзгәрешләре белән дә акрын-акрын багланышы өзелде аның. Численник алудан да шып туктады. Элекме, элек язгы жылы жилләр исә башлаганда Бибинурны тыяр хәл юк иде. Өйдә тора алмый иде ул, беренче күргән тургаена, беренче сайраган сыерчыкка, өер-өер куанып очкан каргаларга кайнар сәламен бирми калмый иде ул. Аерата зәһәр, зәмһәрир суыклары белән жан ияләренең тенкәсен корткан кышлар узгач, ул туктап чыпчык-песнәкләрнең хәлен сораша иде: «Исән чыктыгызмы, кошкайлар? Түзә алдыгызмы? Менә шөкер, менә куаныч!»

Җәйгә кергәч аны бөтенләй танып булмый, үзгәрә иде Бибинур! Һәр тәрәзне киң ачып куеп өйне хуш ис белән тутыра иде. Сабан туйлары житә башласа йокысы, ялы онытыла иде. Өйне сап-сары балавыздай юып чыгара, мендәр-ястыкларны әйләндерә-әйләндерә кояш күзендә киптерә, сыек чыбык белән ярып тузанны кага. Мич-морҗаны шомырт чәчәге төсенә кертеп агарта, жиз самаварын кояш көнләшерлек итеп ачы катык, вак ком белән ышкып ялтырата. Агач табаклар, бизәкле агач кашыклар, чуен-чүлмәкләр, эреле-ваклы табалар, бәйрәм демонстрациясенә чыккан кебек, киштәләрдә рәт-рәт тезеләләр. Тәрәзә төбендә чүпләм башлы ап-ак сөлге өстендә суган кабыгы суында манылган күкәйләр тәгәрәшеп ята, өстәлдән төрле-төрле тәкәләр, коймаклар, бавырсаклар, чәкчәкләр өзелми. Ел саен диярлек балаларга ни дә булса кием яңартмый калмый иде Бибинур — кыскасы, ай буе мәш килә, ай буе янып, яшәреп, очып йөри торган иде.

Иң яратканы ат чабышы иде аның. Үз авылы чабышкылары баш

килсә, ул аерата бәхетле итеп тоя иде. Кыз чагында да, кияүгә чыккан елларны да, соңрак сугыштан соңгы кысан елларда да ат чабышына багышлап чиккән сөлге бирмәгән елы булмады аның. Тирә-якның байтак егетләре Аксыргак сабан туена киеп Бибинур чиккән сөлгеләргә тир сөртте.

Көзге моңсу айларда да ул тулаем бәхетле иде: сары яфраклар коелып тирбәлә-тирбәлә Ташлыяр елгасының дулкыннарында әллә кайларга, ерак сәфәрләргә киткәнне сүзсез-өнсез, күзләрен зур ачып, сөенеченнән онытылып күзәтә иде Бибинур.

Кышның үз гүзәллеге! Беренче кырпак төшеп, ап-ак юрган ябынган ишегалдында каз-тавык эзләренең чуар матурлыгын әйт син! Иртән ишекне ачып җибәрүгә күкрәккә тыгыз, салкынча һава килеп бәрелә, гәүдә җиңеләя, адымнар ныгый, очып китәсе, җырлыйсы, биисе килә Бибинурның. Ә декабрьның сыкылы таңында, яңа яуган ак мамыкка шыгыр-шыгыр басып, әле йолдызлар да сүнеп өлгермәгән бер мәлдә, иңендә чуар көянтә уйнатып, бәкегә суга төшүләр нинди олы бәхет иде! Күрше картның, рәтен белеп кенә, тупас калун белән бәке чапканын карап тору нинди хозур! Боз кисәкләре шыбырдашып, иртәнге нурда кыйммәтле асылташлар кебек җемелдәшеп синең аяк йөзеңә төшеп сибеләләр. Ерак та түгел тал чыбыктан пырх итеп көртлекләр очып күтәрелә. Моржаларда төтен, төтен! Кар бүрекләр кигән, йокычан өйләргә тереклек нуры, җан кертә бит әнә шул төтен баганалар! И кышкы бураннарның сихере! Җәяүле йөгерек бураннар! Бибинурның санап чыгара алмаслык эзләрен күмдегез ич сез Аксыргак кырларында! Сыерчык бураннары китергән дымлы кар бөртекләре, сез Бибинурның куе кара керфекләренә кунып күпме ял иттегез! Язгы бураннардай яуган шомырт чәчәкләре, Бибинур менгән атларның кайнар тояклары астында калып күпме тапталдыгыз сез! Язгы беренче күкрәүләр, тол хатынны сак йокысыннан ничә кат сискәндереп уяттыгыз? Ишек шакыйлар дип белеп ул ничә таңнар яланаяк өйалдына йөгереп чыкты?

Елларның, айларның гына түгел, атналарның, көннәрнең тууын, яралуын белеп, тоеп яшәмәдеме ул? Табигатьнең бар матурлыгына, муллыгына ул да хуҗа иде бит! Болыннарда тукранбашлар кабарып, ромашкалар җилдә тирбәлгәндә аның арыган тәненә ял булды, көч керде. Табигатьнең могҗизалары турында газиз балалары белән ничә тапкырлар сөенеп сөйләшмәгән ул: «Хәтимә, кызым, кара! Салават күпере!» «Улым, Сабир, күрче, ләйсән янгыр ява!» «Нәҗибем, бәләкәчем, синең иптәшләрең — сыерчыклар килгән!»

Һәммәсе тиңдәшсез олы куаныч, һәммәсе балалары белән аны якынайта, аны олылый. Язгы күкрәүләргә, Аксыргак күген туктаусыз юып торган ак болытларга Бибинур кирәк булгандырмы-юкмы, мәгәр март башларында өй кыегыннан тезелешеп сузылган боз сөңгеләр, язгы ташуларның шашкын гөрелтесе, болын өстен бизәп утырган ак чәчәкләр, — һәммәсе дә аның өчен бик кирәк, бик мөһим иде. Ул алар белән бергә ел саен туды да, яз-җәй, табигать белән аның бер еллык гомере сиздермичә генә үлә, китә торды. Табигатьнең бар мизгелләренә дә Бибинур да кирәк булгандыр, мөгаен. Сөенер күзләр юк икән — нигә ярала бу таңнар? Нигә атыла бу йолдызлар? Кем өчен соң бу куетыгыз апрель җилләре? Нигә күк тутырып йолдызлар кабына? Үзенең эчке мәгънәсен тәртипкә салучы, аңлаучы һәм аңлатучы кодрәт иясе кешене дә Табигать бөек максат белән тудырмаганмыни?! Күз, колак, борын, ниһаять, күңел белән җан Табигатьне аңлау өчен яралмаганмыни?!

Табигать баласы **Кеше** булуына, күпне күрә алуына, күргәнен аңлый һәм ярата алуына куанып яшәде Бибинур. Табигать белән бер булу аңа бик күп четерекле хәлләрне җиңәргә, моң-кайгыга баш бирмәскә ярдәм итте. Ялгызлыкны оныттырып торды.

Һәм көннәрдән бер көнне бөтенесе үзгәрде. Яз көне иде. Бакчы, бөреләрне уятып җылы сулышлы җилләр килеп җитте — ә ул аларны сизми калды. Урман кары кузгалгач, таудан сугылып-бәрелеп гөрләвек-ташкыннар төште, ә ул башка еллардагы төсле, айлы кичтә, капка баганасына аркасын терәп су тавышын тыңлап хозурланмады. Яз быел сиздермичә, канны уятмыйча, мыштым гына, астыртын гына килде, җәй дә Бибинур катнашыннан башка гына дөньяга хуҗа булып алды, болыннарны, су буйларын сихерле яшеллек белән күмде. Күзгә сары яфракларга бу юлы исе китмәде аның, көз җиткәнен суык, әрсез җилләр исә башлагач кына абайлады. Беренче кар бөртекләре сихерле чәчәкләр сыман юкка гына аның тәрәзәсе алдында бөтерелеп уйнадылар, Бибинур аларга бөтенләй игътибар итмәде.

Менә син, сәламәтлеге ходайга шөкер, күзе җете, тамагына ризык уза, ни ашаса шуннан канәгать, колагы да сак, армый да диярлек, бар да элеккечә калды, ә шулай да быел нидер үзгәрде, дөнья белән бәйләныш өзелде, табигать белән уртаклык тукталды. Һәм Бибинур: «Әһә, миңа да картлык килеп җитте», дип нәтиҗә ясады. Картаюына ышанмады, исе китте, мич башына менеп ятты да ике көн, ике төн кузгалмады. Мичкә якмады, ашарга пешермәде, киез катасын аягына элеп почмактагы чапчактан бакыр чүмеч тутырып суык су эчте дә иске тунын ябынып һаман мич башында ятты.

«Картлык килде, тәмам!»

Беренче көнне исе киткән иде, икенче көнне бераз тынычланды: хафаланмады. Уйланды. Берәүләр: «Их, бу дөнья миннән кала! — дип уфтаналар, — Идел кала, туганнар кала—дип кайгыралар,—ничек ташлап китәсең?» — дип ачы күз яше түгәләр. Бибинур киресен уйлады: «Шөкер, әле дә ярый, мин китеп барсам да алар калачак!» — дип сөенде. «Мин калып, алар югала торган булса, нинди күңелсез һәм мәгънәсез булыр иде бу дөнья!» — дип юанды.

Картаюны сизгәч, аның к и т м ә с к ә килгәнлеген аңлагач, кешеләр үлем турында уйламый булдыра алмыйлар, аны каршыларга әзерләнә башлыйлар. Үлемтеккә әйбер җыя, кәфенлек хәстәрли башлыйлар. Бибинур да үлем турында уйлады.

Күршеләр аның чыгып йөрмәвенә шунда ук игътибар иттеләр, җыйнаулашып киңәштеләр дә, Бибинур белән бик әйбәт мөнәсәбәттә яшәгән Зәкия карчыкны араларыннан вәкил итеп сайладылар. Зәкия әби таяк очы белән Бибинурның тәрәзәсен чак кына кагып:

— Бибинур карчык, син исәнме? — дип сорады.

Бибинур, мич башыннан төшмичә генә җавап бирде:

— Исән, исән! Ни булсын ди миңа?

— Бер дә төтенең чыкмый.

— Ямау ямап ята идем әле, — дип кетердәде әби.

— Нәрсә ямыйсың, әү?

— Ни ямыйм ди, Зәкия. Дөнья белән алыш-бирешне тәмамларга әзерләнәм. Башкарасы эшләр калмаганмы, рәнҗетелгән җаннар юкмы, дим. Барысын уйлап, хәтернең тишек-тошыкларын ямап ятам шунда.

— Ә, ярый. Шөкер. Яма.

Зәкия карчык өйгә үтеп тормады, ишеккә таба бармады да, хуҗаның балалары ташлаганнан бирле өенә кеше чакырмавын беләләр: очраклы кеше килеп кергәндә дә Бибинур уңайсызлана, борчыла, атна буе чиргә сабышып, кәефсезләнеп йөри. Зәкия дә тәрәзә аша гына сөйләште, башкалар урам ягында ук тыңлап тордылар. Капка тавышы ишетелүгә Бибинур үзе атылып килеп чыга торган иде, бүген әнә ята...

— Я, ничек? — дип сорадылар күршеләр беравыздан.

— Болай тавышы көр чыга, бер дә чирлегә охшамаган, — диде Зәкия.

— Шөкер, алайса, — диделәр күршеләр, җиңел сулап.
— Шулай да, күз-колак булганда ярар.
— Мәзәкләнә башлаган, ахрысы, ул. Морҗасыннан ике көн инде төтен күренмәде.

Дөнья белән алыш-биреше тәмам дип уйлау Бибинурга җиңел булмады, һич! Ике көн хатирәләр тозагыннан ычкына алмыйча мич башында боргаланып ятты. Өе тәмам суынды, тышкы кат пыялаларга катлы-катлы булып зәңгәр боз катты. Өченче көнне торды, мич башыннан төште, кочагы белән каен утыны алып керде, мич гөмбәзенә кадәр тутырып якты да, урындыгын мич каршысына тартып китереп, аңа мендәр куйды, шуңа утырды. Коры утын гөмбәзгә сыймыйча аңа таба ыргылды, ул утның мәңгелеге алдында сихерләнеп, керфек тә какмыйча байтак карап утырды; мич авызындагы корымга ут капты. Бәләкәй чакта, мич авызындагы корымга ут капканда ул кул чәбәкләп: «Әнә урыс марҗалары йөгерә-йөгерә җиләк җыялар!» дип кычкыра иде... Ә хәзер сүрән генә елмаеп куйды да, чүмеч белән су алып килеп корымга сипте...

Аннан кыстыбый пешерде.

Габдуллаҗаны бик кыстыбый ярата иде. Төпчекләре Нәҗип тә әткәсенә охшаган, кыстыбыйны бик яратып ашый иде.

Өенә җылы төшеп, ашап-эчкәч, иске шәлен бөркәнде, билен яулык белән кысып буды, кар бик тирән ятканчы дип зиратка Гайшә кабере янына китте.

Ул чакта татарлар арасында зиратка барып йөрүләр сирәк иде, карга сукмакны үзе салды.

Гайшәнең ире өчен корбан булуы, Габдуллаҗан куеныннан Гайшәнең урынын алуы, Бибинурның дөньялыкта үз ихтыяры белән башкарган гамәлләрнең иң олысы, иң җаваплысы иде. Яхшылык эшләдеме ул, яманлыкмы — Бибинур тулысы белән моны берничек тә бәяләп бетерә алмый иде. Шуңамы, Аксыргак кешеләреннән үзгә буларак, зиратка еш кына барып йөри, бигрәк тә язын, кар киткәч, кабер өстен чистарта, себерә, көздән җыеп куйган чәчәк орлыклары сибә иде.

Бүген менә, кагыйдәсенә каршы буларак, кар ерып бара.

Адымы чыпчык атламы кебек бәләкәй, гәүдәсе җиңел, әзе мамык карда да җиргә кадәр төшеп җитә алмый. Аның артыннан тоташ бер сай буразна сызылып барды, карасаң, адәм узган дип тә уйламассың.

Гайшәнең баш очында биш почмаклы йолдыз уелган язулы ак таш тора.

Пионерлар килеп йөри монда, мәктәп балалары, Беренче Май бәйрәмендә чүлмәк-чүлмәк гөл китерәләр. Сабан туена кайткан авылдашлары да кайвакытта чәчәк бәйләме калдырып китәләр. Әмма Бибинурның Гайшәгә үз мөнәсәбәте, икесе аңлый торган гына олы мөнәсәбәт. Зиратта кеше-мазар булганда ул Гайшә янына барып та тормый, кешеләр таралганны, зиратның тып-тын әрвахлар белән калганын көтә. Чөнки зиратка Бибинурны Гайшәнең фаҗигале үлеме генә түгел, бурычы, җаваплылык та йөртә. Бибинур алып калды ич Гайшәнең өч баласын! Аның өч баласын үстереп, тәрбияләп, үзенчә әзерләп олы дөньяга ул чыгарып җибәрде!

Балалары турында ул хәзер авылда беркем белән дә сөйләшми, аксыргаклыларның алар турында сүз кузгатканын да яратмый, сөйләштерми дә. Шул сәбәпле өенә кеше кергәнне дә өнәми. Өйдә балалар турында сүз кузгалмый калмый шул! Балалар турында ул дөньяда бары тик бер кеше белән — аларны тудырган ана — Гайшә белән генә сөйләшә ала. Алар, ике ана, берсе тудырган, берсе үстергән ана сөйләшә алалар, сөйләшергә сүзләре дә күп була...

Бүген зират буп-буш, тып-тын.

Гайшә кабере өстендәге куе ботаклы пар каеңда пыр да пыр песнәкләр оча, кошлар бер чакта да Бибинурдан курыкмыйлар. Агач арасыннан житез генә үтеп кергән декабрь җиле көмеш кар бөртекләрен бөтереп кузгата. Тик бу минутларда Бибинур карчык берни дә күрми, берни дә ишетми инде. Ул Гайшә баш очындагы ташка сарган кар бөртекләрен җиң очы белән сакланып кына кагып төшерде дә, тирән көрсенеп сүзен башлады, Гайшәгә эндәште:

— Гайшә! — Аның калтыранган иреннәре арасыннан сүзе сыныпсытылып чыкты. — Минә ни уйладым әле мин: миңа да бу дөньяны кичеп сезнең янга килер вакыт бер җитәр. Беләм, минем баш очыма берәү дә йолдыз кадамас, мин бик гади яшәдем, гади кеше булып калдым. Шулай да үкенмим, үз бурычымны үтәдем бугай. Беркем дә минем турыда яман сүз әйтә алмас. Бер кем дә! Мин шулай уйлыйм, бәлки, хаталанамдыр. Син Зөһрәбануга карама, Гайшә, аны тыңлама син! Бәхете булмады аның, шуңа күрә генә күңеле көйсез. Көйсез күңел белән яшәү читен, беләсең. Рәнҗемим мин аңа, миндә дә гаеп бардыр. Ул бәхетле булсын өчен тырышмадым, әллә нигә күңелем тартмады. Синең алда да гаебем бардыр, Гайшә. Булмый калмас. Мин шулай уйлыйм. Шулай дип беләм. Шуңа синең катыңа киләм. Аңлашыйк, Гайшә. Кешеләр сөйли, күп сөйлиләр. Балалар мине ташлады дип, аларны гаеплиләр. Кем уйлаган дөньялар болайга әйләнеп китәр дип. Шулай да мин аларны гаепләмим. Рәнҗемим мин аларга! Ата йортын ташладылар, диләр. Имеш, мәнә ничә еллар инде хат та язмыйлар. Ярдәм дә итмиләр, имеш. Анысы да хак, тик мин ярдәмгә мохтаҗ түгел, Гайшә. Һичбер мохтаҗлыгым юк, хак тәгалә шаһит, пинсәм чыга. Авыл картларын да ташламый хөкүмәт, шөкер. Әйе, пинсәне күбрәк алып, балаларның үзләренә ярдәм иткәндә ярар иде дә. Анысы шулай, Гайшә, бик дөрес уйлап ятасың, сирәк-мирәк хат язгаласалар икебезнең дә йөзебез ил алдында ак булыр иде. Аннары, нәнекәчләрем, берәр генә мәртәбә, ел да димим, ике-өч елга бер генә тапкыр Аксыргакның сабан туена кайтсалар ни әйтер идек кана? Синең катыңа җыйнаулашып, балалары белән килә алсак, бик тә сөенеч булыр иде дә... Әнә бит кайлардан кайталар! Беркем дә кайтмаса, кайтмый башласа, ул сабан туеның ни яме калыр? Онытылып бетәр ул, туганнар кайда очрашып сөйләшерләр? Үзләренең тамырлары кайда икәнне ничек белерләр? Кем сөйләр аларга барын да? Баланың баласы — балдан татлы, диләр. Шулайдыр. Балаларның балаларын күреп булмады. Синең дә күргәнең юк. Үзем чыдар да идем, мәнә син рәнҗеп ятасындыр?! Барын эшләдем мин, Гайшә, тир дә түктем, елга-елга яшь тә агыздым, эшләдем, тау-тау иген үстердем, көтү-көтү колыннар тәрбияләдем, бары да булды, җаным, үземә язганнан канәгать, бер генә үкенечем калды — бала сөеп туймадым. Балаларның балаларын күрмәдек без синең белән!.. Балаларыбыз начар дип кеше юкка сөйли, рәнҗеп ятма. Мин дә рәнҗемим, түзик. Кеше хәлен кеше беләмени?.. Мәнә олы кызыбыз Хәтимәне генә алыйк. Башта ук мәшәкатьле яши башладылар бит. Бухгалтерлыкка укып колхозда әйбәт кенә эшли башлаган иде, Писмәнгә, нефтәгә киткән егеткә кияүгә чыкты. Яңа урында оя кору җиңелме әллә?! Келәтне сүтеп саттым, бар акчасын аларга бирдем. Тимерле агач сандыкны алып киттеләр, ике пар киез итек бирдем, дүрт мендәр. Көзен, юган ак йоннан юрган сырып илттем! Нигә иде безгә келәт? Сиңа кирәкме, миңамы? Алар насыпушка дигән өй салып керде, аннан яңа өйгә күчтеләр, аннан хөкүмәт таш пулаттан фатир бирде. Иске өйләрен сатып матай алдылар. Матай да эшләгән кешегә бик кирәк әйбер, ярты акчасын мин түләдем. «Акча күп төшә!» дип, кияү бер заман Себергә үк күчте, анда да нефтә тапканнар икән. Сабирга килгәндә, аның да үз тормышы! Аксыргак авылыннан чыгып ташкалабыз Казанның үзендә, шәһәрнең кап уртасында өч бүлмәле квартир

алып тормыш көтә башлау җиңелме әллә?! Башта шкафлары фанер төсле аксылдан иде, соңыннан Рига каласыннан кайткан караңгы шкафлар алдылар. Киленгә анысы ошамады. Сабир бик нык йөреп, әллә кемнәрне майлап, әллә кемнәрне җайлап чикләвек агачыннан ясаган шкафлар, диваннар алып кайтты. Урындыкларын күрсәң син, кәкре аяклы, кәкре аркалы, утырырга куркыныч, егылып муен сындырырсың кебек, икмәктер менә, Гайшә! Кешедән артта калсынмыни, сүзем юк, министрның ярдәмчесе булып эшли бит Сабирыбыз, Гайшә! Барыбызга да нинди олы куаныч! Бөтен Аксыргак шакката инде, үстерден малайны, Бибинур дип, бөтенесе мактый! Аннан Идел буенда дача салдылар. Дача дигәннәре хикмәт икән аның, шулкадәр кыйбатка төште, ике ел акча салып тордым. Ике ел, ай саен утызар тәңкә, Гайшәкәем, җәлләмәдем! Дачалары да Идел буенда бер икән шул аларның хәзер! Аннан машина сатып алдылар, машинага тимер түбәле, биш йозаклы таш оя кирәк икән, аңа киткән акчаны санарга куркыныч, Гайшә! Әле ярый, районда музей дигән бер нәрсә ачтылар. Кыз чагымнан килгән ашъяулыкларны, тастымалларымны, кашагаларны, түрләмәләрне, чиккән сөлгеләрне, аякчуларны, паласларны, энҗеле калфагыма тиклем шунда илтеп саттым. Шул чүпрәк-чапракка да акча түләрләр икән. И куанды Сабир! И сөенде килен! Хат язалар да язалар болар, рәхмәт укыйлар. Мин сөенәм, алар сөенә! Музейдан алган акчадан Нәҗипкә дә өлеш чыгардым. Төпчек бала — әни иркәсе. Яратты бит диңгез буен! Ел саен бара. Башта ялгыз йөрде, өйләнгәч хатынын алып бара башлады, кызы тугач өчәү йөри башладылар. Йөрсеннәр, Гайшә, күрсеннәр, замана аларныкы. Әлек барына да өлгерә идем, ат та карыйм, йортта да кош-корт асрыйм, җөй дә тегә идем. Теге, кылый Гомәр хатыны Мөһәлилә белән ярыша-ярыша тегә торган идек! Карчык-корчыкка мин тегә идем бит, мудысын белмәсәм дә, акчасы килә иде, күп тектем мин күлмәк-күпчекне, Гайшә! «Зингер» машинам бик әйбәт иде, келтер-келтер килеп арган көнелне дә күтәреп утырыр иде. Хәзер машинам юк, сөйләгәнмендер инде сиңа боларны, әллә нигә тагын яңабаштан кабатлап кына азапланам.

Шуннан бер елны алар өчесе дә сабан туена кайттылар. Кияү дә, киленнәр дә, балалары да юк иде. Сөенешеп күрештек тә, хәерлегә булмаган икән, яңадан Аксыргакка кайта алмадылар мескеннәр. Минем тормышны яратмадылар... «Келәтне кая куйдың?» ди Нәҗип. «Тегү машинасың ник бирдең?» ди Сабир. «Өйне шып-шыр калдыргансың», ди Хәтимәм...

Син авылдашларга рәнҗеп ятма, Гайшә, алар болай гына, яратып кына искә алалар безнең балаларны. Ятим үссәләр дә кеше булдылар, теләгән нәрсәләре бар, теләгән җирләрендә йөриләр. Аксыргакта ни кызык тапсыннар алар? Үз тормышлары бар, без шуңа бик риза, Гайшә, бик риза!

Фани дөньядан бакый дөньяга күчәр көннәрем житәр, Гайшә... Син рәнҗеп ята күрмә анда, мине караңгы чырай белән каршылама! Кыямәт көнне очрашырбыз әле, Габдуллаҗан да шунда булыр. Юк, юк, ул синеке!.. Синең өлешеңә кермәм, һич тә рәнҗемичә читтән генә карап торырмын. Шулай да, бер тапкыр күз тутырып карарга рөхсәт итәрсең инде, Гайшә? Габдуллаҗан сиңа булыр. Миңа караганда синең хакың күбрәк, олырак! Күбрәк, Гайшә! Мин шуны белеп яшәдем. Мин ни биргән аңа? Син өч бала тудырдың! Син аның өчен корбан булдың. Ә мин? Фи, минем өлешем бик бәләкәй монда! Мин читтән ябышкан бер кыерчык кына! Балалар мине ташласалар да урынында, тик сине оныттып бетерүләре генә җанны кыйный бераз. Печтек кенә кыйный, Гайшә.

Я, хуш. Бездә инде кыш. Аякка таракан явыз керә башлады. Әрвахлар, сез дә хушыгыз.

Ул тагын да бәләкәйләнә, адымнары тарая, гәүдәсе җиңеләя, баягыдан да сайрак буразна сызып яңа сукмактан туп-туры зират капкасына таба атлый башлый. Әле баш очыннан, әле яннан очып песнәкләр аны агачлыктан чыкканчы озата баралар. Ул зират капкасын әйбәтләп элде, каеннарга карап саубуллашты, белгән барлы-юклы догаларын укыды һәм артына да карамыйча кайтып китте. Олы юлга чыккач аны машина куып узды, тик ул күтәрелеп тә карамады. Кыр өстенә рәхәт тынлык хуҗа, кыш көне генә була торган гаҗәеп киңлектә күз чагыла торган матурлык иде, тик болар берсе дә бүген Бибинурны нигәдер әсәрендермәде.

Ул кышны Бибинур кибеткә бик сирәк керде, театрлар килгәндә дә клубка чыкмады, почтага бөтенләй эз дә басмады дияргә була.

Көрт басып бетергән капка төбеннән итек кунычына кар тутыра-тутыра Зәкия карчык көч-хәл белән аның ишегалдына керә дә таяк башы белән тәрәзәсен кага.

— Бибинур карчык, син исәнме?

— Исән-исән!

— Нигә бер дә төтенең чыкмый?

— Күзгә күренми торган төтен чыгара торган чак бит.

— Алай да?

— Хәзер, хәзер. Кабызып маташа идем. Утыны чиме, кадалгыры!...

Кыйшык моржа өстендә сыек кына төтен уйный башлый, ул арада бала-чага шау-гөр килеп мәктәпкә кузгала, Бибинур карчыкның тырышып-тырышып тәрәз бозын тыны белән эретеп урамнан күз дә алмаганын берәү дә белми. Быел җәйгә-кышка, табигатьнең безнең канны, рухны үзгәртә торган сихәтле алмашынуларына тәмам битараф булып, җылы мич башыннан әҗәлен көтеп яткан карчык, дөньядагы бер тавышка гына һаман сикереп тора иде: урамда бала-чага тавышы яңгыраса, ул кыптыр-кыптыр барып җитә, тәрәзәнең суык борысына сөялә һәм сәгатьләр буе хәрәкәтсез тыңлап тора ала иде.

«И гомерләр! И гомерләр!»

Яз да җитте. Яз җиткәнне тоймады быел аның җаны, ташу карарга төшмәде Бибинур, тал ботагын сындырып өстәле уртасында сулы шешәгә утыртмады, бәрмәнчекләргә карап сөенмәде, каргаларның нәзек ботакларны кабып арлы-бирле очканнарын, оя типкәннәрен күзәтмәде. Ул, озакламый килеренә ышанып, әҗәлен көтте. Балаларның язгы тавышлары яңгыраганда гына аның зәп-зәңгәр күзләрендә нур уянып ала, ирен читләре сизелмәслек кенә елмаялар. Шушы тере күзәнәкләренең калуына, саклануына ул үзе дә бик гаҗәпләнә һәм аптырый...

Һәм җәй башының иң матур көннәренең берсендә аның җиргә чүгә башлаган йорт-кураларын карарга яңа председатель Җиһангир Сәфәргалин килеп керде. Аның аз гына бөдрәләнеп торган кызыл чәче тукталусыз агылып торган нурлар арасында бөтенләй кызыл, комач кебек булып күренде. Ул таяк тотып, бөкрәеп, нидер укына-укына өйдән чыгып килгән Бибинурны күргәч, рәхәтләнеп елмайды. Аңа карап Бибинур да елмайды, гәүдәсе кинәт турайды.

## 10

Әйе, авыл кешесенең тормышы башкалар күз алдында уза.

Авылда син бер нәрсә дә яшерә алмыйсың: йортыңның бер почмагы инә башлавын да, чиләк күтәреп чыкканда адымың авыраюын да, иңбашларыңның аска салынуын да, өй эченнән көннәрдән бер көнне шып-шыр калуын да кеше күзеннән яшерә алмыйсың. Синең нәрсә ашап, ни эчкәнеңә кадәр белеп торалар авылда. Анда кеше көчле мик-

роскоп астына эләккән күзәнәк кебек — кая тырпылдаса да күренеп тора. Картаюны да яшерә алмыйсың авылда, чиреңсөйләргә табип я тыңлаучы эзлисең.

Авыл кешесенең бердәнбер яшерен биләмәсе — күңел сере генә кала, күңел сереңбулса, ул синең бердәнбер кеше кулы тимәс монополияң! Син монда тулаем хуҗа, теләмисең икән, күңел серенне берәүгә чишеп тормыйсың, ул синең белән яши, синең белән картая, синең белән бергә үлә дә...

Яшь чагында гомер кеше күзе алдында уза, анда әле серне тотуы кыен. Күңеленә гыйшык иңсә аны кешедән ничек яшереп тормак кирәк? Бик белдермим дисәң дә авыз әле көлә, әле җырлый, әле елый. Әйтмәсәң дә бөтен кеше күреп тора, аякларың кирәкмәс җирдә дә тырпылдый, әһә, диләр, бу егетнең күңел агачына мәхәббәт дигән кош кунган. Юк, дисәң дә, «гашыйк түгел!» дип күкрәгенне төйсәң дә, кич саен синең Борһаннар турыннан үтеп-киткәнеңне күреп торалар. Борһанның кыяр хәтле танавын карарга йөрмисең син анда, Борһанның ак пәрдәләре артыннан кара күзле Гөлчирә күренмәсме дип сагалыйсың. Синең гел алар турында «бозау эзләвеңне» мең күз күреп тора. Мең күзнең биш йөз теле була, алар бергә сөйли башласамы? Каян инде сер саклау!

Олыгайгач башка мәсьәлә. Олыгайгач күңел серен сакларга да була. Шунысы үкенеч, олыгайган күңелләргә сер иңми. Иңсә дә сирәк иңә, бик сирәк.

Бибинур карчыкның яшьлектә дә, балалар белән яшәп ятканда да, инде картайдым дигәндә дә күңел сере булмады. Кояштыр, юк иде. Без аның гомер юлы буйлап йөгереп кенә уздык, иң әһәмиятле вакыйгаларга тукталдык, болар барысы да аксыргаклыларга билгеле нәрсәләр. Хөснетдиновның аны кымтырыклап маташканын да бөтен авыл белә. Айгыр урлап кайтуы да тирә-юньгә дан булды!..

Яшьли өлкән иргә чыкса да, башкаларга күз кысып йөрмәде ул, печәнлектә шыпырт кына ятлар белән аунамады, урлашмады, гайбәт сөйләмәде, берәүне дә тулаем дошман күрмәде, әләкли белмәде, бурычын түләмичә калмады. Зөһрәбану аны нинди каргыш сүзләре белән рәнҗеткәндә дә гаепне үзеннән эзләде, эзләгәч тапты, игез сыңарының сүзләрен үткәреп җибәрде.

Авыр сүзләр ишетсәгез,
Үткәреп җибәрегез!

Бу җыр аның кагыйдәсе иде...

Кимсетсәләр, гафу итә белде, очраганда кешеләрне сөендерде, кайгылы хәбәрләрне дә җиңеләйтеп җиткерде, көчсезне яклады, көчлеләрне тыелырга өйрәтте, явызны үгетләде, усалның күңеленә шәфкать җылысы җибәрергә тырышты.

Боларның һәммәсенә аксыргаклылар шаһит. Бөтен авыл — олысы, кечесе аның бөтен тормышын күреп, уртак яшәделәр.

Аксыргак авылы өчен бер генә нәрсә авыр табышмак иде — шундый изге, йомшак күңелле ананы нигә балалары үз итмәде? Нигә ташлап киттеләр алар аны? Тапкан гына ана түгел бит, үстергән дә ана. Бибинур балаларга ана гына түгел, ата да булды, Габдуллаҗанны да алыштырды ләбаса.

Бусы Бибинурның үзе өчен дә чишелмәслек тирән сер иде. Дөрес, ул моны Гайшә мәрхүмәгә үзенчә, тормыш агышына бик тыгыз бәйләп аңлата ала иде. Тик үз сүзләренә үзе дә ышанып бетми бит.

Нигә шулай гамьсез, миһербансыз булып чыкты аның балалары?!

Шул бимазалы сорауга җавап эзләп чыгып килә иде Бибинур, кулыннан таягы төшеп китте: председатель дә, ул да таякны җирдән алырга оныттылар...

— Исәнме, әбекәй, — диде Җиһангир.

— Исәнме, улым, — диде ул кинәт һәм гаҗәпләнеп куйды. «Улым» дип бик күптәннән әйткәне юк инде аның! Беркемгә дә әйтми иде ул сүзне, ә яңа председательгә ычкындырды.

Керүченең тавышы шактый нык, иңбашлары да калын, күкрәк мускуллары юка күлмәген кабартып күпереп тора, яңаклары килешле түгәрәк, таман булса да борыны аз гына кәкрәеп тора, борын яфраклары киң, няк очы сизелерлек икегә аерылып, бугаз алмасы очлы бүлтәеп тора.

— Ни хәлләрдә яшәп ятасың?

— Бик әйбәт яшим, — диде теле. Ни дисен, гомер буе чәчрәп яшәгән кеше «үлем килгәнне көтеп ятам», дисеңме?! — Әйбәт кенә яшәп ятам.

Хәзер аны өйгә чакырырга кирәк иде, чакырмасаң яхшы түгел. Чакыргач чәйсез ярамый. Мондый сөйкемле председательне ничек борып чыгарасың?..

Белә инде Бибинур, белә, бик төптән аңлый, Җиһангир Сәфәргалиннын нигә кергәнен сизенде: хәзер сорау алу башланачак, председатель елмая-елмая аның җанында казыначак. Кергәләделәр инде, булгалады. Һәммәсенең авызында бер сүз: «Йортны карарга кирәк, әби йортны! Аксыргакта салам түбәле бердәнбер йорт калган! Колхоз да ярдәм итәр. Әмма түбәне булса да алыштырырга күптән вакыт. Оят!»

Түбә саламын алып ташларга кирәклеген белмиме әллә Бибинур. Бик яхшы аңлый, салам түбә шундый матур авылны ямьсезләп тора ич. Тик керүчеләрнең берсе дә Бибинурдан ни өчен алыштырмавын сорамый. Йорт та, түбә дә хәзер Габдуллаҗаннан калган бердәнбер истәлек, чын ядкарь иде. Келәт инде юк. Кар базы бар иде — ишелде. Габдуллаҗаннан калган кием-салымнар тузды. Йорт җиһазлары таралды. Инде ындыр киртәләре дә ишелеп беткән иде, рәхмәт, күршеләр җыелып, Ташлыяр ярларыннан чи тал алып кайтып, килешле генә читән үреп куйдылар. Габдуллаҗанның каккан казыгы да калмады! Инде йортны да ишсәләрме? Юк, юк, бусына Бибинур һичбер вакыт риза булачак түгел. Ишәрләр, тик Бибинур дөнья куйганнан соң. Анда инде сүзе юк, Габдуллаҗан рухы да рәнҗемәс, Гайшә дә «сакламадың иремнең хатирәсен!» дип үпкәләп каршыламас.

Тик бу председатель керергә, ярым чүгәләгән өйгә бәйләнергә ашыкмады, кулы белән баскычка күрсәтеп:

— Вакытыгыз булса, утырып торыйк шушында, — диде.

Утырдылар. Сүз башларга да ашыкмады Җиһангир. Бибинур гаҗәпләнеп аңа карап-карап алса да, һаман тын гына утыра бирде, урамны күзәтте, ишегалдына, ишегалдын баскан чирәмгә карап торды.

— Мондый ишегаллары хәзер юк, — диде ул бераздан.

— Нинди? — дип сорады шикләнеп карчык.

— Матур. Ямь-яшел. Хуш исле. Малай чакта безнең ишегалды да шундый була иде. Әй ауның идек шунда. Мәтәлчек ата идек! Качышлы уйный идек.

— Хәзер балалар качышлы уйнамый, — диде Бибинур таркау гына.

— Мин дә шаккатам аңа! Качышлы уйнамыйлар, тычкан салыш бетте, күз бәйләш тә онытылды. Нигә икән, белмисезме?

Бибинурның фикере чуалып калды: тукта әле, нәрсәгә аңа «Качышлы» уены? «Күз бәйләш»нең Бибинурга ни кирәге бар? Бетсә ни дә, калса ни.

— Менә сез балалар бакчасында эшләгәндә нәниләргә нинди уеннар уйната идегез?

Бусы да һич көтелмәгән сорау иде, тиз генә җавабын да таба алмады Бибинур, башта:

— Әллә тагын, — дип куйды. — Булгандыр инде, барын да уйнаганбыздыр.

— Авылларның үз төсен сакларга кирәк. Менә шул нәрсә борчый мине. Авыл бит ул — сандугачлар оясы. Шагыйрьләр авылда гына туа! Шәһәр шагыйрьләренә нигәдер ышанып бетмим мин. Шагыйрь я авылда туарга, я озак кына анда яшәп авылны яратырга тиеш. Менә Пушкин. Шәһәрдә туган, ә Болдино белән Кистеневка булмаса, нянясы булмаса, рус милләте үзенең бөек икәнлеген Пушкин аша ача алыр идеме икән? Яки менә безнең Тукайны алыйк.

«Акыллы председатель килде дип сөйләгәннәр иде, бик жилъяк, җиңел нәмәрсә икән!» дип сызланды Бибинурның күңеле.

— Матур! — диде председатель.
— Нәрсә матур?
— Әнә ич, бүрәнә башларына шөпшә оялаган, очалар.
— Әйдә, өйгә кер. Чәй куям, — диде тәмам аптыраган Бибинур.

Җиһангир баш селкеде:

— Рәхмәт, әби. Монда да бик күңелле ич. Шушы йортны, йомшак каз үләне баскан ишегалдын күргәч, малай чак искә төшеп китте.

— Әле малай чагың бик еракта да калмагандыр?
— Ерактамы, түгелме, барыбер кире кайтасы юк ич.
— Анысы шулай...
— Әби, — диде кинәт кенә Җиһангир. — Нигә җыелышларга төшмисез? Мин өлкәннәрне җыеп сөйләшкәләдем. Сезне әлек бик актив булган, диләр. Хәзер ни үзгәрде? Авырыйсызмы, дисәм, сезне сәламәт диләр. Сәламәтлек — матур картаю билгесе ул.

— Картаелды инде, — диде Бибинур шүрләп кенә.

Җиһангир көлеп үк җибәрде.

— Картаймагыз. Безнең алдагы планнар бик кызыклы, бик матур. Бакча ясарга уйлыйбыз, Ташлыярны буып куярга да исәп. Төшеп йөрегез, туп-туры үземә керегез. Бәлки сезнең дә кабул булып бетмәгән теләкләрегез бардыр? Бергәләп уйлашыйк. Сез бит Аксыргакның ветераннары.

Төпченмәде Җиһангир, сорашмады, әллә барын белеп кергән идеме, сәламәтлек, тынычлык теләп ишегалдыннан чыгып та китте. Председательнең аяк авазлары тынгач, нишләргә белмичә аптырап, Бибинур карчык болдырда бик озак утырды. Бер узды Зәкия карчык аның капка төбеннән, ике узды:

— Утырасыңмы, карчык, әү?
— Утырам, күрше, утырам!
— Көне бик әйбәт шул, көне!
— Әйбәт, әйбәт, күрше.
— Чәй эчәргә кермисеңме?
— Хәзер үзем дә кайнатам, хәзер.

Күптәнге күршеләр, борынгы күршеләр. Бибинур Зәкияне нинди сорау борчыганын бик яхшы белә: председательнең кергәнен-чыкканын күреп калган ул, Җиһангирның Бибинур белән шактый гына сөйләшеп утырганын да саклап торган, хәзер әнә шул гап-гади сүзләр белән ул күршесенең кылын тартып карый: «Ни сөйләштегез рәис белән?» дип белергә тырыша. Ә белү кирәк! Чөнки Бибинурның язмышы бер Зәкияне генә кызыксындырмый, бөтен күрше-тирә андагы үзгәрешне шәйләп, чамалап, «әллә әзерләнә башладымы ул да?» дип белешеп торалар. Аксыргакта: «Бибинурны картлар йортына җибәрәләр икән», дигән хәбәр дә таралып яткан чак иде. Бик беләсе килә иде Зәкиянең, тик Бибинур тел язмады, Җиһангир белән ни килешүен Зәкиягә белдермәде, чөнки үзе дә берни белмичә, бик нык аптырап кына калган иде.

Кич белән аны идарәгә чакыртып җитмеш биш тәңкә акча бирделәр. Кул куеп алды. «Бер сиңа гына түгел, ветераннарның һәммәсенә дә өлеш чыгардык, кашыңны җыерма», — диде бухгалтер.

Бибинур «ветеран»ның нинди сүз икәнен Галикәйдән сорады.

— Нигә ул сиңа? — дип кайтарды Галикәй.

— Миңа акча бирделәр.

— Ә нигә миңа юк? Мин ветеран түгелмени?

Галикәйгә акча язарга онытканнар икән, ул дулап идарәгә төшеп китте, Бибинур «ветеран»ның ни аңлатканын тагын белми калды.

Җитмеш биш тәңкә өй арасына бик ярады, дөге ярмасы алып кайтты Бибинур, чәен-шикәрен савытларга тутырып куйды. Күңеле күтәрелде.

Юк, җитмеш биш сум акча биргәне өчен түгел, кереп чыкканы өчен дә түгел, вакчылланып юкны-барны сорашып утырмаганы өчен дә түгел (гәрчә болары өчен дә Бибинур күңеленнән генә Җиһангирга каткат рәхмәт укыды!) әллә нәрсә өчен һәм әллә ничек кенә Бибинурның күңеле күтәрелде. Зәкия карчык Сәфәргалиннның нигә кергәнен белә алса да, аның Бибинурда нинди тәэсир ясап чыгып киткәнен белә алмады. Һәм белә алачак та түгел.

Олыгайгач та тормыш үзгәрә торган көннәр була икән.

«Инде бетте, тәмам!» дип соңгы ноктаны куярга җыенганда да кан кинәт кайнарлана икән!..

Шул көннән, шул иртәдән, шушы очрашудан, шушы сәер, аңлаешсыз сөйләшүдән Бибинурның тормышы кинәт үзгәрде. Яңадан кырыкка төрләнде.

Ничек, нинди сүзләр сайлап аңлатырга бу үзгәрешне?

— Сүз — пычак, яралавы мөмкин. Сүз — ефәк, ялганмавы ихтимал. Йөз меңләгән сүзләр арасыннан иң кирәген ничек сайлап алырга соң?

Иң башта Бибинур кадимнән калган, чит-читләре күгәреп тоныкланган көзгесен чолан почмагына чыгарып атты да, ике тәрәзә арасына, түргә, бәләкәй булса да көмеш кебек ап-ак көзге кайтарып элде. Бу һич көтелмәгән хәл иде. Аннары эчке рамнарын алып, тәрәзә пыялаларын кайнар су белән ышкый-ышкый ике көн юды. Быел бу эш тә күздә тотылмаган иде.

Пыялалар яктыргач рамнарның саргаеп катканлыгы фаш булды. Менә кайчан ярап куйды «ветераннарга бүләк акчасы!» Районга барып ак буяу алып кайтты Бибинур — каян тапкандыр, җәй башында андый да ак буяуны кода-кодагые булган житезләр генә таба ала иде — шәпләп рамнарын акка буяды. Ап-ак рамлы, яп-якты пыялалы өй эченә нур кереп тулды, түрдәге көзгедә чагылып идәндә нәни кояшчык күчеп йөрде.

Тәрәзә пәрдәләрен кайнатып юды, үтүкләп элде, тамырларында җан калса да, балчыгын алыштырмаганга, сусызлыктан саргаеп тәрәзә төбендә утырган яран гөленең коры ботакларын кисеп, сары яфракларын тунап, һәрбер тамырын бармак белән аралап яңа чүлмәккә, яңа туфракка утыртты.

Тәрәзәләрне ачып җибәрде дә, ишек катына ук барып, биленә таянып өй эчен бик җентекләп карады. Әйе, җиһаз юк. Җиһаз нәрсәгә аңа? Иске тимер караваты бар, шөкер. Кече як бүлмә тактасы сапсары итеп юылган. Идән такталары гына шәптән үк түгел. Алары да түзмәслек түгел. Биергә җыенмый ич Бибинур, туй уздырасы да юк! Аннан урамга чыгып, кулларын артка куйган килеш, үз турларыннан өч мәртәбә арлы-бирле үтте әбекәебез.

Ишегалдына ике, урам якка ике тәрәзә караган. Дүртесендә дә апак пәрдәләр җилферди, пәрдәләрнең вак-вак челтәр тишекләре читтән бөтенләй күренми дә икән. Урам як тәрәзәсендә матур булып ялтырап торган гөл чүлмәге күренеп-күренеп китә. Менә шул яран шаулап чә-

чәк атсын әле, күрерсез. Атачак, шундый уңдырышлы, сумала кебек кап-кара туфрак кертеп тутырды Бибинур, шау чәчәктә утырачак.

Өченче кат үткәнендә Зәкия түзмәде, Бибинурның каршысына чыгып, аны көтеп алды.

— Кайнашасыңмы, карчык?

— Кайнашам, күрше, кайнашам.

— Ходай хәерле итсен!

Кая китте инде бу Бибинур теркелдәп?

Зәкия карчык, үткер күзле карчыгадай, Бибинур ихатасыннан күзен алмый иде бу арада. Кызыксынырга артык сәбәбе дә юк, бары тик эшсезлектән, яңалык көтеп кенә күзәтә башлаган иде, күршесе аны тәмам хәйран калдырды: я йөгерә-йөгерә суга төшеп китә, я юынтык суларын чыгарып түгә. Күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган, җиңнәрен сызганган, яулыгын чөеп бәйләгән. Күзе аяк башында, аста, үзе җил-җил чаба гына! Байтак тын торган өй эченнән әле балта, әле чүкеч тавышы килә. Ә балтасын Галикәйләргә барып үткенләтеп кайтты.

Зәкия карчык, Бибинурдан яшькә калышмаса да, карты белән тигез картайганга яшәү һәм үлем турында сирәк уйлый торган кеше, Бибинурны чын күңеленнән кызганып уфылдады: «Ходай хәерле итсен, карчыкның зиһене тарала мәллә? Әҗәле җитәдер, мөгаен!»

Һәм ул Бибинурның балалары турында уйлады. «Моңарчы кайтмады, моннан соң да кайтмаслар, алла боерса. Бибинурның өен ватып утын итәрбез. Урынына кызыл кирпечтән, яңача итеп, верандалар кирт-ләп өй салырбыз да олы улны башка чыгарырбыз. Чаллыга китәм дип котырып йөри, җибәрмәбез, алла боерса, ә Бибинур карчыкны үзебез карап җирләрбез, ил алдында да, ходай каршында да языклы булып калмабыз».

Су алып кайта Бибинур, чәй кайната. «Газдан куркам, шартлап күршеләремне харап итәрмен», — дип газ да керттермәгән иде, идарәгә барып, бригадир Хөснулланы җилтерәтеп инде газ керттерде.

Бер көнне, кичләтеп кенә, аулаграк чакта, көтүләр кайткач Зәкия янына Зөһрәбану да менде. «Ничек анда безнеке, яшәп ятамы?» «Йөри, күз тимәсен, бик сихәт йөри. Кышны авыррак чыккан иде, хәзер менә, ходайга мең шөкер, яшәреп китте». «Әстәгъфирулла тәүбә! Җиңеләя башлаган диючеләр булды бит!» Зәкиянең йөзе яктырды, тик ул моны Зөһрәбануга сиздермәде: «Каян белдең?» дип кенә сорады.

Зөһрәбануның да үз планы бар: Бибинурдан калгач, арзанга гына булса да өен сатып җибәрермен дип уйлый иде. Моны Зәкия дә сизенеп йөри, шуның өчен ул мең хәйлә табып Зөһрәбануны Бибинур янына кертмәде, тиз-тиз генә самавар куеп чәй белән сыйлады, «кагылып торма инде син аның янына, бер дә кеше кергәнне яратмый!» дип куйды. «Кырагайлыгы бетмәде инде!» дип килеште Зөһрәбану, җиденче чынаягын эчкәч.

Игезәк сыңарын гаҗәпләндергән хәлне аңа кибетче Әсмабикә сөйләгән иде. «Бер көн шулай кибет ачылуга Бибинур әби төшеп җиткән. Карыйм, һаман ишек катында таптана. Сөйләшми! Беркемгә бер сүзен дәшми! Ситсыларны тарткалап карады, яңа кайткан радиоалгычларны борды. Синнән яшерен серем юк, Зөһрәбану апа, аз-маз чәем бар иде. Кирәк була бит, я кем чирләп китә! Запассыз торырга ярамый. Шуны уйлагандыр да чәй сорарга төшкәндер дип уйлыйм хәзер. Ике пачка бирермен дип чамалап та куйдым. Менә берзаман кибеттә икәү генә торып калдык. Ул миңа карый, мин аңа. Ул эндәшми, мин көтәм. Бер якынрак килә, бер ишек ягыннан әйләнә, чистый мәзәк инде! Шуннан күлмәк кесәсеннән таушалып беткән өчлек чыгарды. «Әсмабикә,— ди миңа, — менә шул акчага хушбуй бирсәң иде!» Берәрсенә бүләккә ала дип уйлыйм. Сорап бактым. «Юк, бүләккә түгел әле, үземә,» — ди.

«Ниндирәкне бирим?» дип сорыйм тегеннән. «Гомеремдә кулланган нәрсә түгел дисәң дә хак, Әсмабикә. Вакыты да җитмәде, теләгем дә булмады», ди Зөһрәбану апа, кызганып чак җылап җибәрмәдем, үзем иң яраткан «Ясмин» хушбуен бирдем, өстәвенә ике кап чәй тоттырдым. Алмый, көч-хәл белән күндердем. «Кибеткә килгән һәммә кешегә чәй тарата башласаң, синдә әндри казнасы юк бит», ди. «Бөтен кешегә бирмим, сиңа гына» дигән идем, ник әйткәнемә үкендем. «Нишләп башкалардан аерып куясың? Минем кай җирем ким дә, кай җирем артык?!»

Зөһрәбану да Бибинурның бу кыланышын игътибарсыз калдырмады. Тик Зәкия белән алар әле бер карарга да килә алмадылар, һәрберсе үз уен өстен санап аерылыштылар.

Шул көннән Бибинур бер киноны, бер театрны калдырмый башлады. Җыелышларда иң алдагы рәткә алдынгылар белән янәшә барып утырды. Бакча утыртканда башыннан-ахырына кадәр шунда кайнашты. Тамырлары корыган каеннарны җыеп китеп, түбә саламнарын бастырды. Кыскасы, мәш килде. Хәзер ул гел өйдә утыра алмый; күпер сугучылар янына барып чыга, чишмәдән суык су алып килә, әйрән таба, йомычка җыеша. Ни кушсалар шуны үти, кая җибәрсәләр шунда теркелди. Кайсы иртәләрдә эшчеләрдән алда күпер янына барып җитә. Буа буа башлагач, ул аннан кайтмады диярлек. Җиһангир Сәфәргалиин көлемсерәп: «Бибинур әби, сезне төзүчеләр штатына алыйкмы әллә?» дип аны мактады.

Бер җәй узды, көз үтте, икенче җәй бетеп барганда фельдшер кыз Бибинурларга керде. «Хәлең ничек, әби?» дип сорады. Бибинур бер сүз әйтмичә баш бармагын күрсәтте һәм кетердәтеп көлде генә.

Күпер сукканда да, бакча утыртканда да, буа ясаганда да ул бары тик Җиһангир Сәфәргалиины күрер өчен генә барып йөрде бит. Бусы инде Бибинур карчыкның күңел сере иде. Ул, Зәкия карчыкның, башкаларның «җиңеләйгән» дигән карарын ишетеп, эченнән генә елмаеп йөрде. «Сөйли бирсеннәр әйдә, шулай уйласыннар!» Фикерләре ялгыш юлга кереп киткән аксыргаклылар карчыкның яшь председательгә булган сәер мөнәсәбәтен сизенми калдылар. Бибинур үзе дә хәйләкәр булып чыкты, шулай дип кенә белсеннәр өчен ул кайчагында күрәләтә арттырып та җибәрә иде. Барган җиреннән шып туктый да, әйтик, уйга кала, янындан узучыларны күрмәмешкә салыша.

Ничек дип атарга инде бу мөнәсәбәтне?

Ничек дисәң дә, ышансаң-ышанмасаң да, Бибинур карчык Җиһангирны күрмичә, аның калын тавышын ишетмичә бер генә көн дә яши алмый башлады. Дөресен әйткәндә, Бибинур карчыкның сизгер, мәхәббәтле йөрәге инде берәүгә дә гашыйк булмыйча калган иде бит! Мирзаһитны ул егет аны хөрмәт иткәнгә генә якын күрде. «Кирәк, яшь үзып бара!» дип кенә аулак өйләргә барып йөрде. Габдуллаҗанны да яратырга өлгермәде, өч баласы булмаса, ул аның дөньяда барлыгын да яхшылап белмичә яшәр иде. Дөрес, гөнаһасы булмасын, иренә күнекте, тән-тәнгә, җан-җанга якынайгач, уртак тормышлары, уртак язмышлары берләштергәч ул аны чит итә алмады, бар булганынча сөйде, иркәләде. Тик уртаклыкның тирәнендә барыбер балалар иде. Балалар өчен кияүгә чыкты, балалар өчен тугры булды. «Каян шул «площадкага» кереп бәйләндем» дип икеле-микеле уйларга баткан чаклары да булмады түгел, булды. «Шунда кермәгән булсам, бала-чаганы яратырга өлгермәсәм...» Тик мондый авыр үкенү минутлары балалардан өзелеп хат көткән өметсез чакларда гына булып ала торган иде.

Җирне-күкне, язны-көзне, йомшак каз бәбкәләрен, ишек алдында койрык чәнчеп чапкан озын бәкәлле бозауларны, колынның ефәктәй юка койрыгын, тугры песнәк белән купшы тургайны, бәрәңге дурычмагын, кыстыбыйны, чиккән сөлгеләрне, уймакланып аккан Ташлыяр-

ны, Аксыргакның аңа гына хас баллы төтен исен — һәммәсен яратырга мөмкин. Сабан туенда чабышкы атлар көмеш тояклары белән кара җирне тупырдатып чапкан чакта йөрәгең күкрәк читлеген кысып «мена атылып чыгам, мена түзмим!» дип тибәргә мөмкин. Әмма кеше күңеленең иң югары ноктасы — кешене ярату! Тик моның бер авыр шарты бар: чакма ташы белән чын корыч бәрелешкәндә генә көлтә-көлтә очкын чәчрәп чыга.

Күпләр яратуны татымыйча кияүгә чыга, аннан күнегә, бала-чагасын, туган-төяген, гаиләнең гореф-гадәтләрен, ниһаять, байлыгын ярата башлый һәм бәхетле була. Күпләр кияүгә чыккач кына бөтенләй читтә үзләренең чакма ташларын очраталар һәм гомергә бәхетсез булалар. Аларның күпчелеге язмыш белән ризалаша. Бибинурга исә табигать ярата белә торган йөрәк биргән иде, аңа Аксыргак таулары кебек биек, мәгърур һәм серле Ташлыяр елгасы кебек агып бетми торган мәхәббәт биргән иде. Тик ул башкалар кебек яшәмәде, бәби тапканчы ук балаларны яратып өлгерде. Балалар аша гына ирен күңеленә якын итте.

Кемне дә булса яраттымы ул моңарчы? Уйлап карый да, башын чайкый: юк, яратмады. Булмады аның андый кешесе, булмады! Балаларын сөйде. Ә нәтиҗә? Бәлки әнә шул күңелсез нәтиҗә аның җанын һаман нәрсәдер эзләргә мәҗбүр иткәндер дә?! Әгәр ул бетмәс мәхәббәтен балаларыннан оныкларына күчерсә бу хәлләр бәлки бөтенләй булмый да калыр иде? Кем белсен...

Йөрәк яратудан туймый икән. Мәхәббәткә лаек йөрәк һаман яшь, тибә, эзләнә икән. Бар икән әле Бибинурның йөрәге, картаеп сүнәргә өлгермәгән икән. Тән таушалган, күз нуры зәңгәрләнеп коела башлаган, күз төпләренә көзнең күгелҗем тоҗымнары таралган, ә йөрәк шул килеш яшь калган икән. «Тип!» дип җанландырып булмый торган, «туктал» дип боерык биреп тукталмаган йөрәкнең хуҗасы бары тик мәхәббәт кенә икән! Ул боерса туктый, ул кушса, рәхәт сызланып, һаман туктаусыз тибә икән ул.

Җиһангир урамнан үтеп киткәнне күреп калса Бибинурга бәйрәм!
Җиһангир җыелышта чыгыш ясаса аның өчен шатлык!
Урамда очрап сәлам дә биреп китсә аның өчен могҗиза!
Ул утырткан бакча аның өчен хәзер җәннәт бакчасы!
Аксыргак авылы аның өчен хәзер иң изге урын — чөнки һәр карыш җирендә Җиһангирның аяк эзләре бар.
Ташлыяр елгасы Бибинур өчен сер дәрьясы!

Әйе, ул кеше. Яшь ала, күрә ала, татый, иртәнге чык белән кичке шәфәкъ утлары аның җанына тәэсирсез узмый. Беренче сандугачлар, яшел уҗым кылычлары, язгы күкрәүләр, салават күпере — һәммәсе кирәк Бибинурга. Һәммәсе! Ул аларның барысын да, дөньяның дүрт ягын, тауларны-елгаларны — бөтенесен-бөтенесен күкрәгенә сыйдыра ала, чөнки аның йөрәгенә мәхәббәт кагылды. Мәхәббәт кагылган йөрәкнең күләме чиксез! Аңа ай-йолдызлары белән бөтен галәм кереп урнаша ала. Мәхәббәтле йөрәк — юмарт, мәхәббәтле йөрәк — гадел, мәхәббәтле йөрәк — бәхетле.

Хәзер ул яшәреп китте, адымы үзгәрде. Ни булды бу Бибинурга, диләр сыман яшел сукмаклар.

Ни булды безнең әбекәйгә, дип ак болытлар Аксыргак түбәсеннән китә алмыйча әйләнәләр шикелле. Ни булды безнең хуҗабызга, диләр кебек шау чәчәктә утырган яран гөлләре. Сандугач та аның бакчасына кунып сайрый, тургайлар да аның баш очына менәләр. Ул төшсә Ташлыяр елгасының агышы үзгәрә, моңланып, сөенә-сөенә ага елга. Айлы төннәрдә аның тәрәзәсенә сихри күләгәләр куна, кайдадыр тау буйларында, әйтерсең, фәрештәләр җырлаша.

Күңел сере бар кешенең генә гомере тулы, түгәрәк икән.

Бибинур хәзер моны да белә!

Күңел сере бар чагында гына яшәү кызык.

Күңел сере бар чагында гына яшәү җиңел.

Күңел сере бар чагында гына яшәү ифрат авыр...

«Кемгә сөйлим серләремне?» дигән шагыйрь...

Бибинурның сер сөйләр кешесе юк иде.

Шулай да бер мәлне, саксыз кыланып, чак кына юләрлек эшләп ташламады Бибинур... Җиһангир идарә йортына якын гына ирле-хатынлы яшәп яткан Миңлекамалларда фатирда тора иде. Миңлекамалның да бәбие булмады, ире Хәтмулла фронттан кат-кат яраланып, яра өстенә фин фронтында ук бөер-бавырына суык тидереп кайтты. Бәбиләре булмаса да тату яшәделәр. Миңлекамал белән Бибинур артык якынаеп китә алмадылар, ни дисәң дә, сугыш елларында Миңлекамал председатель булып торды, Бибинур ат карады, якынаерга ничектер мөмкинлек тә юк иде.

Әмма хәзер Бибинурның Миңлекамал белән бик якын, сердәш, дус буласы килде. Кодрәт белән якынаер иде хәтта! Якын кешесе булса теләгән вакытта, бер йомышсыз да барып керер яки юк-бар йомыш тапкан булып та кереп чыгар иде. Ә хәзер, һич истә-оста югында, көтмәгәндә барып кереп юк-бар сүзләргә сәбәп булуың бар. Җиһангир торган йортта үзе турында юк-бар сүзнең яңгыравын теләми иде Бибинур.

Нишләргә? Теләкләреңнең берсе дә үтәлми икән, кая барырга? Ни кылырга? Мондый чакта сердәш кирәк, сереңне уртаклашыр өчен чын ахирәт дус кирәк. Андый дусты Аксыргакта юк иде Бибинурның. Бар иде барын дөньяда бер кеше, Хәнифә апасы бар иде аның, менә аңа чын йөрәген ачып биреп, күңел серенең авырлыгыннан аз булса да котылыр иде Бибинур, тик Хәнифә әллә кайчан юкка чыккан, эзе югалган иде.

Хәнифәне Бибинур аптыраганнан гына искә алды. Кемнеңдер рухи ярдәменә мохтаҗ булганга гына. Югыйсә, ул беләсе килгән сораулар-га җавапның күбесен Миңлекамал да бирә алган булыр иде. Нигә элегрәк аның белән якынаю юлларын эзләмәде Бибинур? Дөнья белән саубуллашып йөргәндә очраклы бер арада аны уйларга вакыты бар идеме соң аның? Хәлләр болайга әйләнеп китәр дип кем уйлаган? Кем уйлаган? Ә хәзер беләсе килә: чыдары юк, җаны эзләнә, күңеленә тынычлык бетте.

Ник семьясын алып килми Җиһангир? Моны да беләсе килә Бибинурның.

Бар диләр — хатыны да, улы да бар диләр бит. «Хатыны килми, килмәячәк тә», ди икенчеләре. Шундый ирнең кадерен белмәгән ахмак хатыннар да булыр икән?! Ире бар килеш ничек ялгыз яшәргә риза-лаша ул?! Ялгызлыкның тәмуг газабына тиң икәнен белми микәнни ул? Ялгызлык — хатын-кыз өчен иң усал корт, ул үзәгеңә төшеп, бәгыреңне кимерә ич!.

Миңлекамалларга ул иртәнге күлемдә, төш алдыннанрак барып керде, куркып кына ишек катында басып калды.

— Өйдәләрме болар?

— Ә, Бибинур, күзгә-башка күренмисең, ни хәлләрдә? — Миңлекамал да картайган, битен эре-эре җыерчыклар баскан, биле танып белмәслек булып юанайган, симезлеге күлмәгенең бөтен җиреннән бәрептөртеп тора. — Үзең исән-аман гына йөрисеңме?

— Узып бара идем, тукта әле, мин әйтәм...

— Кереп йөр, бергә эшләдек, бергә яшәдек! Теге камыт аякны, Хөснетдиновны онытмадыңмы?

— Оныту кая ул каһәр сукканны.

Миңлекамал күлмәгенең бөтен сырларын дереЛдәтеп көлә башлады, күзләреннән яшь атылып чыкканчы көлде.

— Усал идең инде үзең дә, Бибинур.

— Усаллык та таман әле андыйларга.

— Юк инде Хөснетдинов, үлеп киткән.

— Шулаймыни?..

Бибинур бер генә мизгелгә Хөснетдиновны күз алдыннан уздырды, кызганмады, әллә бар иде үлгән вәкил аның өчен, әллә бөтенләй булмады дамы? Миңлекамал да жәлләми аны, күренеп тора, көлә-көлә сөйли.

Кинәт аңа эсселе-суыклы булып китте: ул үлгәч тә шулай матәм хәбәрен кешеләр бер-берсенә көлә-көлә тапшырырлар микәнни?! Юк, алай булмас!. Кем дә булса чын күңеленнән кызганыр әле. Галикәй, күршеләр, бәлки Жиһангир да кызганып куяр?! Уйдан-уйга сикереп Бибинур Миңлекамалның ни сөйләгәнен тыңларга өлгермәде, ул бары тик аның елмаюын, күрешүләренә сөенгәнен генә аңлады. Менә аның сүзләре дә колакта урын таба башладылар:

— Кичә кичтән кер чылатып яткан идем. Бүген әллә нишләп теге сынган кулым авыртып уяндым.

— Һаман авыртамы?

— Авырткалый, нәләт.

— Авырткан кул белән кер юасыңмы?

— Үзебезнең керләр генә булса түзәр дә идем, фатирчыбызның, Жиһангирның күлмәкләрен дә юасы иде. Бер дә якасы керләнгәнне яратмый.

— Миңлекамал, кая үзем генә юып бирим.

Юдырмас, ачуланыр дип уйлаган иде Бибинур, Миңлекамал, киресенчә, шатланып риза булды. Бер-ике минут эчендә өялдыннан олы тасны алып керде, икәүләп казаннан аңа кайнар су тутырдылар, мич өстендәге дәү чиләктән керләрне китереп аудардылар. Бибинур Миңлекамалның алъяпкычын бәйләп алды, билен буды һәм җиңнәрен сызганып эшкә дә кереште. Миңлекамалларга кергәндә мондый бәхет көтәр дип уйламаган да иде ул! Кер тутырган таска сихерләнгән кебек беравык карап торды Бибинур, күзен ала алмады. Аның керләре, аныкы, Жиһангирныкы! Рәхмәт Миңлекамалга, рәхмәт кайчандыр аның кулын сындырган кызыл айгырга! Хәзер дә ярдәмгә килә белдең, сөйкемле ат!.. Аның күлмәкләре. Менә бу җиңнәр аның юантык беләкләренә тиеп иркәләп торган. Күлмәк якасыннан аның тән исе — тәмле ис килә! Барын да ап-актан, киҗе-мамыктан тукыганны кия икән Жиһангир. Еш алышкангамы, юасы керләре байтак җыелган.

Кая китте Бибинурның өлкәнлеге, тән арганлыгы, җан талчыгуы— аның ун бармагы арасында ак күбек диңгез ярындагы су кебек кабарынып уйный, тирә-якка пар атып су чәчри, ак майкалар, күлмәкләр, ак кульяулыклар ак камыр кебек изеләләр, сыгылалар, чупырдый-чупырдый сөенешеп тагын да агаралар. Изә Бибинур, баса Бибинур, сыга Бибинур. «Һай, көчең дә бар икән соң, Бибинур!» ди аның янына ук керергә дә шүрләп Миңлекамал. Бибинур дәшми, ялтыр, чиста маңгаена юешләнеп төшеп ябышкан чәчләрен кул сырты белән күтәреп кенә куя. Бәхетле көн бүген аның өчен — чөнки ул яраткан кешесенә яхшылык эшли ала — хатын-кыз яхшылыгы. Яраткан кешесенең эшен башкара.

Күптән түгел генә үзәк газеталарның берсе хатын-кызлар арасында да сорау-тикшерү уздырды. Хәзерге заманның укымышлы, олы дәүләт эшләре йөкләнгән, үтә җаваплы урыннарда утырган хатын-кызлардан:

— Әгәр мөмкинлек булса, сез ирегезгә һәм балаларыгызга аш-су пешерүдән бөтенләй баш тартыр идегезме? — дип сораганнар.

«Дөрес»,— дип килешкәннәр хатын-кызлар,— кухня хатын-кызның бик күп вакытын һәм егәрен ала. Төрле-төрле машиналар, ярдәмче җиһазлар чыкты, ярымфабрикатлар күбәйде, мәгәр хатын-кызның кухнядагы хезмәте җиңеләймәде. Шулай да безне ирләребезгә, балаларыбызга аш-су, тәмле ризыклар пешерү бәхетеннән мәхрүм итмәгез!» — дип кискен җавап биргәннәр.

Әле ярый, шөкер, дөнья төрле! Дөньяның төрлелеген үз файдаларына гына борып, аш-су әзерләүдән бөтенләй тайчынырга маташкан ялкаулар, биләмчеләр, гайбәтчеләргә гыйбрәт буларак, бик күп хатын-кызларыбыз, тегенди-мондыйлары гына түгел — академиклар, профессорлар, атказанган сәнгать эшлеклеләре, уңган терлекчеләр, эшчеләр, аш-су пешерүнең мәшәкать булу өстенә иргә, балаларга мәхәббәт билгесе икәнен дә аңлыйлар һәм бу олы бәхеттән үзләрен мәхрүм итмәүне үтенәләр. Тормышның нигезе — мәхәббәт кенә түгел, мәшәкать тә.

Әгәр бу сорауны Бибинур ишеткән булсамы?! Аның уйларын сыйдырыр өчен газетаның бер бите генә җитмәс иде. Әгәр бу сорауны сугыштан соң әле үзләренә пар таба алмаган толлар, ялгызаклар ишеткән булса! Алар ни язмас иде!.. Ни дип җавап бирерләр иде, әгәр аларның күңелен кузгатсалар?!.

Керләре яңа яуган кар кебек ак булганчы тырышты Бибинур, аннары ике чиләк алып буага, а н ы ң буасына, а н ы ң керләрен чайкарга төшеп китте. Ак күлмәкләр җиңнәрен җәеп Ташлыяр елгасында озак чайкалдылар. Ак булсын, йомшак булсын аның күлмәкләре!.. Шуны киеп ул урам уртасыннан узсын! Таңны каршыласын! Дөньяның матурлыгына сокланып кичке шәфәкъне карап торсын! Ярабби, шулай була күрсен.

Кайтып барганда бер дә ашыкмады Бибинур, ипләп кенә, яшь чагындагы кебек кәз-кәз басып, чиләкләрен уйнатып кына кайтты. Чиләгенә кунып кояш ял итте, чиләгенә кунып кош сайрады кебек. Мәхәббәт унсигездә генә килә дип кем әйтә ала моннан соң? Гыйшык уты бары яшь йөрәкләрне генә җирсетә дип кайсы китапта язылган?

Дөрес, карт мәхәббәт пулат ватар дигән акыллы сүзләр бар. Тик ул дөреслектә бары тик ир кеше мәхәббәте генә күз алдында тотылган. Имеш, хатын-кыз мәхәббәтенең гомере — күбәләк гомере. Имеш, хатын-кыз гыйшкы — язгы ташу кебек, бер күтәрелеп бәреlә дә тына! «Яшен житсә кырыкка, — эшең китәр шырыкка», дип тә куйганнар... Бәлки дөрестер, бәлки юктыр да. Буа өстендә вак дулкыннар тирбәтеп чайкалган күлмәк гашыйк булмаган күзләргә аккош канаты булып күренә аламы?.. Күлмәкне кулыннан юри дә ычкындыргалады Бибинур, күлмәк тирбәлә-тирбәлә аның янында йөзде, әйләнде. Су чәчрәтеп уйнады ул, тезенә менеп җиткән су аның җылы тәнен кытыклады, рәхәтлек белән күмде. Моны ни дип, нинди сүзләр белән аңлатырга? Җырлыйсы килде аның, сулыгып-сулыгып, күкрәкләре бушаганчы җылыйсы килде!..

Аннан тирләп-пешеп икәүләп бер самавар чәй эчтеләр. Миңлекамаллар җитеш торалар: бакчаларында алмагачлар, алмагач арасында — аллы-кызыллы умарталар. Ә кортлары выж да выж килеп байлык, бәрәкәт ташый. Бибинур кортлардан курыкмады, агач араларына тартылган бауларга керне үзе элде.

— Сиңа азрак күчтәнәч тыгыйм, Бибинур, — дип, Миңлекамал чолан ишеген ачкан иде, Бибинур аның терсәгеннән килеп тотты.

— Нинди күчтәнәч ди ул тагын? Үзеңә рәхмәт!

— Миңа ни өчен?

— Мондый да тәмле чәйне үз гомеремдә эчкәнем юк иде! Шуның өчен!

Ул көлә-көлә саубуллашты, өенә кайтып җиткәнче йөзендә елмаю

сүнмәде, шулай елмайган килеш йокыга талды, төшенә дә сөенечләр генә керде. Ак казлар өере каңгылдашып ак күпер аша чыкты. Кайдадыр ак, сары әләмнәр җилфердәде. Болын өстен ап-ак энҗе чәчкәләр каплаган иде... Йоклаганда да аның йөзеннән, йомык күзләреннән нур агыла иде. Зәкия карчык әллә ничә кат укынып аның тәрәзәләренә карады: әллә таң да ата инде?..

Аны йокысыннан да Зәкия карчык уятты:

— Карчык, карчык! Ишетәсеңме, председателебез Җиһангир Сәфәргалин дөнья куйган!..

«Мин юганнарны кияргә өлгермәде! — дип өзгәләнде Бибинур. — Өлгермәде!»

## 11

Менә, ниһаять, җомга да килеп җитте.

Тагын бер сикерәсе дә шимбәне узасы, аннан — якшәмбе. Базар көн. Урыс атнасы. Төрле-төрлечә атап йөртәләр ул көнне. Якшәмбедә сабан туй. Бүген кунаклар нагытып кайта башлый. Самолетлар бүген Аксыргакка карап оча. Поездлар Кәҗә башы урамына караган юлда кабалана. Пароходлар Ташлыяр елгасына юл тота...

Бибинурның гына көтәсе дә, китәсе дә юк.

Нинди татлы, яшерен өметләр белән яшәреп быелгы тамашаны көтә иде дә бит, булмады. Сабан туенда ул а н ы күрәчәк иде. Былтыргы кебек у л да көрәшкә керер дип өметләнә иде.

Былтыр тракторчы егет белән алыштылар. Егете төп кебек юан һәм таза иде, Җиһангирны күтәреп алды да, бераз һавада тотты, аннан мәйдан читенәрәк илтеп куйды.

— Син олы кеше, Җиһангир абый, егасым килми! Җиһангир аның аркасыннан кагып торды. Быел менә ул юк. Көрәш тә, ат чабышы да, йөгереш тә а н н а н башка гына узачак. Һич уйламаганда әҗәл алды да китте. Әллә саташып, әллә ялгышып алып китте аның матур җанын?!.

Яшь, уңган председательнең үлеме аксыргаклыларны бер мәлгә тетрәтсә дә, сабан туен каршылауны беркадәр сүрелдерсә дә, нишлисең, бер кешенең үлеме җирдәге хәлләрне үзгәртә алмый. Кунаклар кайта, аларның күбесенә Җиһангир бөтенләй чит кеше, ишетеп бер көрсенәләр дә, йөзләргә тагын бәйрәмчә елмаю куна, кайгыны шатлык алыштыра.

Бибинур өчен хәзер аннан да кадерлерәк кеше юк. Килде дә аңа — үлемгә кул биргән карчыкка әллә күпме гомер өстәп китте. Гомернең дә нинди өстәде диген әле — мәхәббәт нуры белән яктыртылганын, гыйшык уты белән җылытылганын.

Кимлекне татыды. Эш рәхәтен татыды. Ир бәхетен дә белде. Бала да сөйде. Тупаслык, әрсезлек, өметсезлек тә бик таныш аңа. Ачлык, ялангачлык та аны читләтмәде. Толлык ачысы бик озакка иярде аңа. Ялгызлык газабын да белә! Мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлекне дә кичерде. Зөһрәбану аша хыянәт ачысын да эчте! Ниһаять, бик соңарып кына булса да, гомеренең соңында, мәхәббәт тә килде Бибинурга. Килде!

Кайгыны уртаклашып, сагышны онытып, ялгызлыкны җиңеп була. Кимлекне юри күрмәмешкә салышып яшисең. Картлыкта килгән мәхәббәтне генә уртак итеп булмый.

Миңлекамал сизгер хатын иде, югыйсә, ул булып ул да берни сизми калды. Бибинурның яшәреп, көлә-көлә чыгып китүен, авылда таралган хәбәргә ышанып, «җиңеләя башлаган бичара Бибинур!» дип кенә аңлады. Ак күлмәк түшенә тамган алмаз яшьләрне — мәхәббәт билгесен күрми-белми калды.

Җиһангирга мең рәхмәт өстенә тагын бер рәхмәт — әгәр ул булмаса Бибинурның гомере бәлки инде чикләнгән дә булыр иде. Әгәр гомере чикләнсә, ул Зөһрәбану белән Галикәйне кавыштыра алмас иде. Мәңгелеккә олы бурыч белән китәр иде. Гайшә алдында ни җавап бирер иде дә, Габдуллаҗаны белән ничек очрашыр иде?!

Җаны саф кешегә бу дөньядан күңел гаебе белән китү авыр. Ул яктан да эше тәгәлләнде Бибинурның, күңеле почмакланды. Галикәй белән Зөһрәбану кавышканнар дип уйлады ул һәм ялгышмады.

Бүген җомга көн. Бүген ул тып-тыныч. Тыныч диярлек. Ниһаять, үзенә язганны башкарды, дөньядагы барлык бурычын үтәде. Барысы да язмыш китабында шулай язылган идеме икән? Юктыр, фашизмны язмыш китабында алдан күрә алмаганнардыр. Югыйсә, ул кабәхәт Гитлер анасы карынында ук әҗәлен тапкан булыр иде.

Бүген монда рәхәт. Бакча әлегә тып-тын. Буа гына шаулый. Бүген ул тагын аның тавышын тыңлый. Беркөн генә, Җиһангирның керләрен юганда, ул буа тавышын бөтенләй ишетми торды. Гаҗәп, чыннан да! Буада кер юды үзе, ә арык шавын ишетмәде. Бүген аермачык ишетә. Авылда яңгыраган көр әтәч тавышларын да ишетә, көтүгә куылмаган бүлтерек бәрәннәр беэлдәве дә аңа килеп ирешә. Димәк, бүген кемнәрдәдер чалу итеннән өреле токмач, бавыр һәм шулпалы бәлешләр пешәчәк! Ләкин Бибинур башка тавышларны шунда ук оныта бара.

Урам уртасыннан, урамга сыймыйча Галикәй төшеп килә. Адымнарын гына кара син аның, гуардин солдат мыни, метр гына атламыйдыр. Авызы ерык, ерык авызына юан папирос ябышкан. Ир-ат күкрәген киереп урамның кап уртасыннан бара икән, аның инде бөтен теләге тормышка ашкан дигән сүз. Кыяфәтен генә күрегезче бу абзыкайның! Чын ирнең кыяфәте бик күпне сөйли, әгәр ул ташудан соңгы елга сыман юаш кына килә икән, моннан бик күп мәгънә чыгарып булыр иде. Галикәй давылланып, очынып төшеп килә.

Их, Җиһангир да исән булса! Юк, буасы гына шаулый, каядыр өндәп, әллә нинди сихерле өннәр чыгарып шаулый буа!

Хәзер моннан китәргә дә була.

Их, менә шулай йокымсырап утырганда гына тирбәлә-тирбәлә мәңгелек елгасына кушылып китеп агасы иде! Күзгә җылы кояш төшеп торсын. Янәшәндә агачлардан сибелгән юка күләгәләр биешеп ятсын. Җылы, татлы җил иссен. Агасы да, агасы иде... Оеп, тынычланып йокымсырады Бибинур. Кемдер аның исемен атап дәшкәч, чәчрәп уянды. «Әҗәле килеп җиттеме әллә?» Сискәнеп аягын тотып карады — капкайнар, сулышы да тигез, куркып уянган йөрәге генә шашып-ашкынып тибә. «Бибинур эби-и!»

Аны чакыралар ич! Ул кулын каш өстенә куеп почта тәрәзәсенә карады. Кабаланмады, ашыкмады. Ачык тәрәзәдән үрелеп Миңлегөл кул болгады.

— Килче монда, Бибинур эби!

Йөрәге жу итеп китте: кайсысы?! Кайсы кайта? Телеграмма бармы, хатмы? Хәтимәме? Сабирдыр әле! Әллә Нәҗипме? Төпчеген уйлагач ана күңеленә җылы йөгерде.

Бик озак узды ул бакча эскәмиясе белән почта ишеге арасын, бик авыр атлап узды. Миңлегөл ишек катына чыгып ук аны көтеп тора иде.

— Син тәгаен мине чакырдыңмы?

— Сине, Бибинур эби. Йоклап киткән идеңме әллә?

— Оятлы булдым.

— Янына барасым калган да, эш бик тыгыз. Бәйрәм алды бит.

— Зыян юк, Миңлегөл, зыян юк.

— Менә болай иде, Бибинур эби...

— Белмим, нәрсәдер бит, — диде ул каушап.

Миңлегөл чак кына сабыр итеп торды.

— Синең көн туды исә почта янына төшеп утырганыңны күреп барыбызның да йөрәге әрни, Бибинур әби.

— И-и, — диде әби, елмайгандай итеп. — Эше юк кеше кая барсын? Мин почтага төшмим лә, бакчада гына утырам. Элек каравыл өенә җыела торган булганнар, хәзер, шөкер, бакчабыз бар.

Миңлегөл аның бер мәлдә сүрелеп киткән күзләренә карап, башын чайкады.

— Болай гына төшмисең, алдашма, Бибинур әби!

— Алай ук каты әйтмә инде, Миңлегөл.

Миңлегөл ашыгыбрак сөйли башлады.

— Балаларыңнан хәбәр көтәсең син, әйеме? Ә алардан бер хәбәр дә юк. Без, авыл комсомоллары, аларга хат язып карадык. «Әнкәгез бик тилмерә, ялгызлык яман нәрсә, ник аны онытгыгыз?» дип сорадык.

— Кирәкмәс иде.

— Җиһангир абый кушты.

— Җиһангир?

— Әйе, ул. Сине быел яңа йортлы да итмәкче иде ул, Бибинур әби. Әллә нигә бик якын күрә иде үзеңне.

Карчыкның керфекләре яшькә чыланды.

— Балаларга кагылмаска иде!

— Сине генә түгел, бөтен авылны рәнҗетте ич алар!

— Рәнҗиләрме? — Бибинур шаккатты. — Дөрес әйтәсеңме?

— Сине жәллиләр, шуңа белдермиләр.

— Ник жәлләргә? — диде карчык җәберсенеп. — Үз көнемне үзем күрәм. Тамагым тук, өстем бөтен.

— Үзең күрәсең шул! — диде Миңлегөл кискен генә итеп. — Мин синең балаларыңның шул яманлыгы хакында газетага язган идем, редакциягә.

— Редакциягә?

— Өчесе дә әйбәт урында эшлиләр, акча алалар, энкәләренә кулъяулык та сатып алып биргәннәре юк, дидем. Саран бакалар! Эшләгән җирләрендә аларның кемлеген белмиләр булыр, энкәләренең соңгы самаварына тиклем талап алып киткәннәрен ишеткәннәре юктыр! Ак булып түш киереп йөриләрдер, акыл өйрәтеп! Фельетон басылып чыккач сикерешерләр, эссе табага басарлар әле!

Тарта Бибинурның керфеге, үтереп тарта. Колагы шаулый, башы әйләнә, күз төпләре чамасыз кычыта!

— Ничек диден син, ничек? — Ул кечерәеп, йомарланып болдырга барып утырды. — Кабатла әле!

— Эссе табага бастырам мин аларны дим!

— Кирәкмәс иде, хата кылгансың, — дип кабатлады Бибинур, тәмам хәле бетеп.

— Әле генә миңа Казаннан шалтыраттылар. Иртәгә редакциядән корреспондент килеп җитәчәк.

— Ни өчен?

— Асылда ул безнең Аксыргак сабан туен язачак. Бер очтан синең хәлне дә тикшерәчәк.

— Мин нишлим ди инде хәзер?

— Өеңдә генә тор, Бибинур әби. Шул гына. Бер кыздырыйк әле шул кансызларны, башкаларга да сабак булыр, кыздырыйк! — Миңлегөлгә «кыздыру, биетү», бик ошый иде, ахрысы, ул кемнәрнедер күз алдына китереп көлеп җибәрде. — Бирешмә, Бибинур әби!

Карчык чытлык Миңлегөлгә әллә ниләр аңлатмакчы булып кулын бутады, тик сүзен дә, рәвешен дә табалмады. Бары тик үзеннән бигрәк

балалары өстенә куркынычлы бер хәл туып килгәнен аңлады һәм куркып китте.

Бая йокымсыраган җайлы урыны хәзер каты, кытыршы һәм борчулы иде. Алай утырып карады Бибинур, хәле киткән аякларын болай таба сузды — җай ала алмады. Кая борылса да аның күзенә кояш төшкән кебек, күз кабаклары сызлый һәм һаман нидер комачаулый иде. Киемнәре шул ук, аягында да шул ук Арча чыгарган чигүле башлы иске башмак, урыны да шул ук. Ул, башмагын салып, бармак тирәсендә оешмадымы дип, оек куныларын тартып-тартып карады, кат-кат какты: «вак таш тәгәрәп кердеме әллә?»

Байтак изалангач кына аңлап алды: буа шавы комачаулый икән аңа! Үткәннәр җыр булып тезелеп акканда буа тавышы аңа тугры юлдаш иде, хәзер, Миңлегөл белән сөйләшкәннән соң киләчәк турында, иртәгәге көн турында уйлана башлагач буа тавышы аның уйларын тыя-туктата, туктаусыз өзгәли икән! Димәк, монда озак утырырга ярамый, монда озак торып булмый. Иртәгәгә аның уе әзер булырга тиеш, ә уйлар уйланылмый!

Гаҗәп: тормыш дигәнеңнең тагын бер мәрәкәсе килеп чыга бит. Бусы башкаларына караганда куркынычрак булмагае әле, чөнки ул аның үзенә түгел, балаларына яный! Кичә, өченче көн үз хәле хәл булса, бүген балалар турында уйларга кирәк. Алар турында аннан-моннан гына уйларга ярамый, җиңел генә уйлап булмый, Бибинур җиңел уйларга өйрәнмәгән дә. Балаларның һәр адымын ул сагаеп күзәтте, аларның һәр теләген үтәргә әзер торды, кулыннан килгәнне үтәде дә. Хәзер генә, башына ялгыш авыр әйбер төшкән кебек, ияге түшенә тиде, башы сызлады, колагында нинди ят тавыш, быжан вызлаган күк, бимазалап тора башлады.

Ул ашыга-ашыга өенә кайтты, нигәдер капка келәсен элде, ишеккә таяк терәү салды. Түргә узды, өстәл янына утырды, терсәген өстәлгә, яңагын учына куйды.

Ничек борчылмыйсың ди? Бәйрәм халкы яңа хәбәрләргә сусап кайта, бәйрәмдә хәбәр коры үләнгә төшкән ут ул — тиз тарала! Бөтен илдә Аксыргак халкы сабан туена җыйналганда, дуслар табышканда, гашыйклар кавышканда, батырлар, йөгерешчеләр, аркан тартучылар, ирләр, үсмерләр, хатын-кызлар, алдынгылар макталганда «Габдуллаҗан солдат балалары юньсезлеккә чыкты!» дип бөтен дөньяга рисвай итсеннәрме? Ай тиле кыз, тиле кыз, ай башсыз Миңлегөл! Нәрсә уйлап чыгарган бит, киңәш-табыш юк. Казанына ук хәбәр итеп өлгергән. Җиһангир абый кушты дигән була, кушмас, кушмагандыр. «Монысы чеп-чи ялган!» дип әрнеп уйлады Бибинур. Хәзер бит барчасы гәҗит укый, Галикәй кулына килеп керсә гәҗитеңне ашап ук бетерә кебек. Габдуллаҗан белән Гайшә ни уйлап ятырлар? «Исән башың белән шул хаксызлыкны кылырга рөхсәт бирдеңме?!» дип мәңгелеккә рәнҗерләр. Их, Миңлегөл, тиле кыз! Сабырлык юк хәзерге яшьләрдә, түземлелек аз. Менә чит кеше килеп төшәр. Арага чит күз керер. Чит тел аның балаларының исемен ямьсезләп тәкрарлар. Нишлисең, Бибинурның хәле шундый.

Әгәр дә мәгәр... Тукта! Өе таза булса, вак-төяк нәрсәләрне юнәтсә, гәҗит кешесен ничек тә көйләп озатыр иде. «Балалар язгалап тора, акча да салгалыйлар, һич нәмәгә мохтаҗлыгым юк!» дияр иде. Инде хатларны күрсәтүне сораган тәкъдирдә, бар ич алар, әнә матчага кыстырган җирдә торалар.

Бибинур урындык куеп, хатларны үрелеп алды. Тик болар барысы да сугыш еллары хатлары, Габдуллаҗан хатирәләре иде.

Кояш төшлекне узгач аның өенә күләгә төште. Көн чалт аяз иде, кинәт табигатьне сискәндереп күк күкрәде, юк болыттан тәрәзәгә тып

та тып тамчылар килеп сыланды. «Болыты да хәбәр китерә! — дип уйлады Бибинур сызланып. — Тәрәзәгә кага!»

Ул тәрәзәләр нык ябылганмы дип карады, морҗа юшкесен тикшерде, күзгә өстенә ал яулыгын ташлады. Идән уртасына баскан иде, тагын дөбердәде күк, ул куркынып ләхәүләсен укыды. «Яшерен сугып харап итеп куймасын тагын! Үләргә ярамый, һич тә ярамый! Әле алда олы эшләр тора!»

Күк, аның белән ризалашмаган төсле, тагын дөбердәде, Бибинур тәрәзә пәрдәләрен тартканда, пыялада алмаз белән сызгандагы кебек эзләр ясалды. Яңгыры шуның белән туктады да, бик еракта, саңгырау гына мөгердәп алды да, күк ачылды, яктырып кояш чыкты. Бибинур пәрдәләрен күтәреп тормады, юшкесен ачмады. Кая барып сугылырга белмичә чоланга чыкты, аннан буш күәс күтәреп керде. Күптән ипи пешермәгәнгә күәс эчен үрмәкүчләр үз итеп куе-куе пәрәвез сарганнар, тузан җыйганнар. Ул газ өстендә су кайнатып тиз-тиз күәсен юып алды, аны кече якка, кеше күзенә күренерлек урынга — сәке түренә куйды. Суны җылытырга гына куйган иде, оныткан икән, кайнап ук чыкты. Күәс янына түгәрәк агач табакларны матурлап тезде. Түгәл тугызау икән алары. Унау иде, берсен төшереп ярды шул, кулы чергән нәрсә.

Аннары сабы китек чәйнегенә чәйне мул тамызып, ашык-пошык кына чәй эчкән итте. Ул хәзер ни эшләсә дә ашыга, кабалана, чынаягын куеп әле анда, әле монда барып тотына, ни кылганын аңлап та бетерә алмый иде.

Өстәлдә сыңар чынаяк...

Өстәл янында бәләкәй генә зәңгәр күзле Бибинур. Япа-ялгызы. Әмма шушы бәләкәй Бибинурның бүгенге уйлары дөньяның дүрт ягына да тоташырга җитә. Кемгә кирәк булды икән соң ул? Кемгә хаҗәт аның мазасы? Үзенеке үзенә җиткән, аның турында Казан белән сөйләшеп, кеше чакыртып тору ниемә кирәк?

Булды заманнар, аның да газеталарда макталасы килгән чаклары булды. Башкалар гектарыннан сиксән-туксан пот иген алып ил буенча мақталганда аның да үз исемен газеталарда күрәсе килде. Һич югында, исемен идарә янындагы Мактау тактасына язып куйсыннар иде! Валлаһи, үзе өчен түгел, аңа артыгы берни дә кирәкми иде, балалары өчен кирәк иде бу мактау! Әтиле өйләрдә балаларына әнкәләрен әтиләре мактый. Ятим, үги ананы кем мактасын?! Кем аның дәрәҗәсен күтәрсен?! Ә бала алдында ананың дәрәҗәсе бик югары йөрергә тиешлеген Бибинурның нечкә күңеле сызлана-сызлана сизә иде. Юк шул, бик кирәк чагында аны мактамадылар, әйбәт килгән елларда да газетага язып чыкмадылар. Хәзер мең кат кайгыртып язсаң да, әллә нинди үтемле сүзләр әйтсәң дә, балаларның мәхәббәтен яулап алырың юк. Мәхәббәт бер чакта да кире кайтмый. Көчләп сорап алган мәхәббәт нигә кирәк аңа? Чынын татырга өлгергән бәхетле Бибинур мәхәббәтнең асылын, ни икәнен, тәмен, бәһасын бик яхшы белә. И башсыз Миңлегөл! Балалар мәхәббәтен кире кайтарырга кодрәтең бармы синең? Андый кодрәткә балаларын ничә еллар тәрбия иткән Бибинур үзе дә ия була алмады, Гәҗит аша куркытып алган мәхәббәт ялган була бит инде! И Миңлегөл, Миңлегөл!

Җиһангир килеп гомерен озайтмаса бүгенге көнне күрмәс тә иде бәлки Бибинур, бу сүзләрне ишетмәгән дә булып иде. Әллә бер Миңлегөл сүзе генә түгелме бу? Әллә бөтен авыл аны кызганамы? Әллә авылдашлары аны һаман яраталармы? Һәм ярат канга эшлиләрме алар моны? Үзе өчен яшәмәде дә ич ул, алар өчен тир түкте, алар дип яшәде... Чукынышып бетсеннәр, гәҗит кешесенә барын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирер. «Ташладылар», дияр. «Оныклардан аердылар», дияр. Шытырдатып язып чыгарсыннар әйдә, сүз аларны да эзләп тапсын.

Бибинур койган күз яшьләренең ачылыгын алар да хет бер тапкыр тойсын!

Бу юлы күктән түгел, аның тәне буйлап тагын яшен уты узды: ә Габдуллаҗан?! Ә Гайшә?! Ул асылзатлар ни әйтер? Моңарчы аларның исеме халык телендә зур хөрмәт белән яд ителә иде. Ә хәзер газетада басылган кара хәбәрнең күләгәсе аларның шул якты йөзләренә дә төшәрме? Бибинур үзе нишләр, ни әйтер? «Алай бик әйбәт кеше икән-сең, нигә балаларың шундый начар?» дип йөзенә бәреп әйтмәсләрме аның?

Кинәт ул буа тавышын ишеткән күк булды: шаулый бит ул, шаулый! Чакыра! Чакырганын бер Бибинур ишетәдер бүген Аксыргакта! Инде дөньялыкта эшең күп калмаган икән — сине кая чакырулары мөмкин?.. Тотарга да суга чумарга? Чумарга да — чыкмаска. Иң дөресе шул булыр. «Тукта, тиле!» диде шунда күңеленең бер ягы. «Аксыргакка, сабан туена, күңелле арадашлык, туганлык һәм мәхәббәт бәйрәменә синең актыккы бүләгең җүләрлек булырмы?!»

Кинәт күк күкрәде, үз уйларыннан үзе каушап төшкән Бибинур тагын ләхәүләсен кабатлады, идәнгә чүкте. Күк түгел лә, капка кагалар икән! Әнә ич, шакылдаталар! Кайсыгыз йөри анда, тагын кемгә ни кирәк?! Ник онытып тормыйсыз аның дөньяда барлыгын! Бер бүгенгә генә булса да онытыгыз! Юк бит ул, күбәләктәй җаны очып чыгарга талпына! Сәкесенә менеп ята да, кулларын түшенә кушырып, күзләрен йома. Бетте. Вәссәләм! Җиһангир оланның җанын вакытсыз кыйган, әрсез әҗәл, син кайда йөрисең? Нигә буташтырып керәсең син ишекләрне? Нигә? Сан өчен генә булса нигә Бибинурның актык гомерен аңа бүләк итмәдең. Бу көннәрне у л күрер иде, у л!.. Бибинурга нигә бу көннәр? Аның катына әҗәл түгел, иртәгә Казан кешесе килеп керер. Төпченер. Казыныр...

Ул сөрлегеп, алга иелеп ишегалдына чыкты.

— Карчык, капкаң ник бикле?

— Ә, бая, күк кинәт күкрәгәч, онытылып бикләп кергәнмендер шул.

Ачык капкада Зәкия карчыкның бөтен җыерчыклары нур белән тулы чырае балкыды.

— Карчык, олы улым кайтып төште. Бүген берүк, кичке чәйгә керергә онытма. Менә сиңа күчтәнәче дә бар.

Зәкия күршесе, юка, шома кәгазьне сүтеп, Бибинурның калтыранган ябык кулларына күз явын алырлык мәк чәчкәләре төшкән күлмәклек китереп тоттырды.

— Бисмилла!.. Җылы тәнеңдә тузсын, күрше. Ә бусы үземнән.

Күлмәк өстенә шыгырдап торган өчлек акча ятты.

— Кайтарырга бүләгем юк бит, — дип каударланды Бибинур. — Рәхмәт, Зәкия, барыгызга да. Олыладыгыз.

— Үзе дә кермәкче иде, кая ул, бетереп алып чыгып та киттеләр. Кайта кунак, кайта кунак! Керер, керми калмас, боерган булса.

— Рәхмәт яусын, күрше.

Кунак, кунак... Зәкиянең олысы кайткан. Ул да укыр гәҗитне, башкалар да. «Бу Бибинур карчыкка ни җитмәгән тагын, зарланып гәҗиткә яздырган» дип уйлар халык. Һәммәсе шулай дияр. Димәк, гәҗиткә яздырмаска кирәк, корреспондент дигәннәрен Аксыргакка бөтенләй китертмәскә кирәк дип, уйлады ул. Уйлады да тагын аптырашта калды: юлга чыккан кешене ничек туктатмак кирәк? Бер синең өчен генә йөрми, потың бер тиен, Аксыргакның атаклы сабан туен мәнгеләштерергә килә! Кәртечкәгә төшерә торгандыр, я булмаса кинога, аннан телевизор аша бөтен дөньяга күрсәтерләр. «Ә, бу теге Аксыргакмы әле? — диярләр кешеләр. — Гәҗиткә дә яздылар аларны, Бибинур исемле корткага һаман нидер җитми икән анда!»

Шулай диячәкләр, шулай дип кенә беләчәкләр.
Килүчене туктатып булмый диган сүз. Киләчәк ул, киләчәк тә туптуры Бибинурның түренә узачак. Чәй куяр иде — самавары юк. «Балаларым ярдәмнән ташламый!» дияр иде, өй эче шып-шыр.
Ярый, мәк чәчәкле күлмәклекне «кызым бәйрәмгә салды» дияр... «Ал яулыгым олы улым бүләге», дисәң дә ышана инде ул килгән кеше!» «Балаларым ташламады», дип ышандырыр. Алай дияргә дә уңайсыз шул. Хәзер кемгә барып кермә, кукыраеп ап-ак холодильник утыра. Стеналарда гына түгел, идәннәрдә дә кыйммәтле келәмнәр. Ялтыр-елтыр шкафлар. Кемгә Берлиннан кайткан, кемгә Бухарестан! Казан чыгарганны алып ваксынмый хәзер авыл халкы! Ялтыр-елтыр шкафларда алтын-көмеш путалы чынаяклар, бәллүр чәркәләр. Көмеш кашыклар, көмеш чәнечкеләр. Итне дә хәзер чәнечке белән генә эләктерәләр.
Ә Бибинурның ние бар? Түрендә шымытыр башы, кече ягында буш күәсе дә ярык тагарагы. Үлемтек, кәфенлек тутырган сандыгы...
Килгән кеше — йөргән кеше, бер карауда барын аңлап алачак. Миңлегөл ни диде әле: «Соңгы әйберләреңне талап алып киттеләр», дидеме. Килгән кеше «Габдуллаҗан солдаттан мирас булып калган Тула самавары кайда?» дип сораса, ни диярсең? «Гайшә апаның төсе булып сакланган «Зингер» машинасын да карыйсы килә», дисә ни дип җавап бирерсең?
Килер, язар, хәзер аны берничек тә тыя торган түгел, моннан соң Аксыргакта, авылдашларына аралашып, Габдуллаҗан белән Гайшәне белгән кешеләр арасында ул ничек яшәр? Чакырып китергәнгә әҗәл йөрми, ничек гомер итәр Бибинур?!
Димәк, бер генә юл кала, бары тик бер генә әмәле бар — гәҗиттән килгән корреспондентны ничек тә җайларга кирәк. «Ир кеше килсен иде», дип теләде ул, хатын-кызның өй эчендә күзе үткенрәк була!» Тик ничек җаен табарга? Акча төртсәң — алмас. Үтенеп сорасаң — тыңламас. Әмәлен табарга кирәк, ә кайда соң аның әмәле? Әмәлен тапсаң да өең буп-буш, самавар очкан, җөй машинасы юк. Аларсыз Бибинур ике кулсыз. Җиһангир нәнәм, Бибинурның шушы көнгә төшәсен алдан уйламадыңмыни? Әгәр син исән булсаң, баш орып синең катыңа гына барыр иде ул! Тик бүген син юк, син кузгаткан авыр мәсьәлә генә бар... Рухың да дәшми ичмасам! Тып-тын! Буаң шаулый да, яшь каеннарың нидер сөйләшә. Тик Бибинур карчык алар ымын да аңларлык хәлдә түгел шул бүген. Эш сүздән узган, иртәгә корреспондент килеп төшәчәк. Нишләргә? Әгәр түрдә самавар балкып утырса? «Зингер» машинасы күренсә? Тегендә-монда төрле-төрле чүпрәк, эленкеләр өй өчен бизәп торса? Димәк, самаварын да, җөй машинасын да табарга, юнәтергә кирәк.
Аксыргакта бармы икән ул борынгы Тула самавары? Калган булырга тиеш, капкачына һәм подносына бер төрле тамга салынган: «Тульский оружейный завод. 1926 год». Сакланмыйча, нибарысы илле ел узган ич! Җөй машиналары да булырга тиеш әле, нык иде, чыдам иде ул «Зингер» машиналары! Шәйхуллаларда бар бугай, тик аларда аяклы машина. Миңлекамалларда бар барын, тик моңарчы йомышка йөрешмәгән кешедән ничек сорап торасың? Бәйрәм арасында эш тотам дисәң, рәнҗерләр. Кунак өстенә кунак кайтканда кем сиңа самаварын биреп торсын?
Бибинур нәкъ үзләренеке төсле самавар белән җөй машинасын тагын кайдадыр күрде бит. Әйе, Җиһангирны соңгы юлга озата баргач, аларда, этиләрендә, кызыл сакаллы Вәли картларда күрде.
Аларда сакланган әнә, Бибинур гына саклый алмады. Җырлый торган үтә борынгы сәгатьләре дә бар иде. Аны да алып киттеләр. Керосин лампасын да калдырмадылар. Пыяладан койган озынча ике ваза

бар иде, чәчәк кадап куя иде Бибинур, аларны Хәтимә бик ошатты. Күзләренә ни күренсә, шуны алдылар. «Иске әйбер модада!» имеш. Менә хәзер иске нәрсәләр аркасында аптырап утыр инде. Әнә, Вәли карт, ярма ташына хәтле саклаган. Киленнәре усал булса да бер нәрсәне дә алып китмәгән бит.

Ишекле-түрле байтак аптырап йөргәннән соң ул бер акылга килде: «Әйе, мин аларга серне ача да алам, әйбер-караларын бер көнгә сорап тора да алам. Аларда башка әйберләр дә булырга тиеш. Вәли карт мине бу бәладән йолып алачак!»

Үз тапкырлыгына үзе сокланды Бибинур, сөенеченнән хәле җиңеләеп китте, күз карашы гына түгел, адымнары да мәгънә алды — сабыр гына, барын уйлап, бөртекләп уйлап бетереп Тегәрҗеп авылына барырга әзерләнә башлады.

Иң әүвәл баруның сәбәбен бер сүздән аңлашырлык итеп уйлап куярга кирәк. Керер дә, боргаланмый-нитми генә эч серен сөйләп бирер: «Балаларым хакына килдем, яман исемнәре илгә чыкмасын дип йөрим!» дияр. Вәли картлар үзләре хәсрәттә йөзәләр, кеше хәлен аңларлар. Хәзердән тәвәккәлләп чыгып китсә, караңгылы-яктылыда барып керер, Вәли картның таныш шоферлары бар, үзе шулай диде, әйберкараларны төяп тиз генә китереп тә китәрләр! Таң атканчы өйне танымаслык итәр Бибинур! Бу юлы акчасы да жәл түгел, берне түгел өч сумын бирер!

Өй эче тагын караңгыланды, Бибинур һава хәлен белешергә дип ишек алдына чыкты, чыннан да көн бераз салынып тора, әнә теге, көнбатыштагы ертык итәкле болытлар, җир сугарырга җыеналар түгелме?

Яңгыр түгел, таш яуса да барырга кирәк Бибинурга, самавар һәм җөй машинасы алып кайтырга кирәк, аннары күз күрер, кем-кемне хәйләләр! Миңлегөлне дә өйгә чакырырмын, күрсен, күреп күзләре шар булсын.

Ул юлга да көндез кигән болгар башмагын киде — башка аяк киеме юк та иде, күнегелгән башмак җиңел дә булыр диде, башына ике кат яулык бәйләде, кулына элек көтү куган, өске башы төерле, аскы очы сүсәреп беткән чикләвек таяк алды. Тиз кайтырга чыккан кеше кебек ишекне бикләмәде, кеше юклыгына ышангач кына урамга чыкты: «Бисмилла!»

Бибинурның өй сакларга яратмавын белгән күршеләре, карчыкның бу юлы таяк белән үк чыгуын, ашыга-ашыга түбән очка юл алуын күрсәләр дә, бер дә аны-моны уйламадылар. «Җаны түзми!» дип уйлады берсе. «Берәрсенә ашка барамы әллә?» дип уйлады икенчесе.

Зәкия дә аның кызыл яулыгын абайлады, ул да «Һай илгәзәк тә инде бу Бибинур! Кичкә безгә ашка керәсе бар, тагын каядыр чыгып китте әле. Кайтып җитәр җитүен, бик озак юанып көттермәсә генә ярар иде!» дип уйлады. Урамга чыкмады, кулы камырлы иде. Тәрәзәдән генә күз белән озатып калды, Бибинур чыннан да бик олы сәфәре бар кеше сыман, җил-җил атлап бара иде, менә күздән дә гаип булды. Кая китте, кемгә керде, Зәкия анысын чамаламый да калды.

Аягы тарттымы, күңеле өндәдеме, Бибинур үзе үскән йортка, төп нигез йортына кереп китте. Туктап та тормады, болдырга менде, шыгырдатып өйалды ишеген ачты. Өй ишеге ачык, аннан бала чактан ук таныш тәмле исләр килә, аз гына ачырак эремчек суы исе дә килеп киткән кебек булды. Ул ачык ишекнең янагына килеп тотынды, өйалдының тәрәзәсе юк, монда ярым караңгы, шуңамы, өй эче тагын да яктырак, тагын да нурлырак булып күренде. Һәм шушы хәлне күрде Бибинур: түрнең түрендә камзулын җилбәгәй җибәреп, ак күлмәгенең бөтен сәдәфләрен ычкындырып, биш бармагына Зөһрәбануның чәчәкле чынаягын утыртып, башмак иреннәре белән иске паровоз сыман пуф-пуф өрә-өрә Галикәй чәй эчеп утыра, муенына салган кызыл башлы

чүпләм сөлге белән маңгаен сөртеп-сөртеп ала. Яулыгын чөеп җибәргән, яңа алъяпкыч ябынган, бәбәйтәкле озын күлмәк кигән Зөһрәбану бибиии газ плитәсе янында коймак чожлата. Бибинурның ашыйсы килеп, ашказаны сулкылдап куйды, бавыр асты тартышты. Әмма Зөһрәбану кулындагы канатның май белән коймак арасында тиз-тиз йөргәнен күргәч, ул үзенең монда артык икәнен дә, ашыгырга кирәк икәнлеген дә аңлап алды һәм аяк очларына баса-баса өйалды ишеген япты, култыксага ябыша-ябыша баскычтан төште — бер такта шыгырдамады, бөгелмәде.

Тәрәзә төбендә, Галикәйнең уң кул ягында, чуар кәгазьле башланган шешә тора, шуны ят иткән, исен яратмаган бохар песие сыртын дугалап савыт тирәсендә әйләнә — аны да абайлап өлгерде Бибинур.

Ә ул кергәнне берсе дә сизмәде, тамак кырганын да ишетмәделәр, өй сөенеч белән мөлдерәмә тулган иде. Бибинур Галикәйнең канәгатьлек белән өскә тырпайган мыек чылгыйларын, аның чәйне шопырдатып эчә алу хокукын яулап алуыннан айдай балкыган йөзен күреп чын күңеленнән сөенде. Зөһрәбану да идәннән күтәрелеп, әйтерсең түшәмгә басып йөри башлаган иде!

Ашыкса да, ниндидер күренмәс җепләр аны ишегалды уртасында беразга бәйләп тотты. Мондагы һәр карыш җир, һәр багана, һәр казык, кирпеч, таш ялгашлар аңа таныш. Ул шушы оя кешесе, биредә байтак еллар яшәмәсә дә берсе дә онытылмаган. Онытылмас та. «Ялгашның чите кителгән. Трактор белән утын керткәндә почмагына тиеп киткәннәр. Быел да лапас астына карлыгач оялаган икән. Кыек астындагы күгәрчен ояларын чистарттымы икән? Шөкер, бу йортка хуҗа килде. Ир килде! Хуҗасы бар җирнең генә, хуҗасы бар йортның гына киләчәге бар. Киләчәк булмаса нинди кызганыч һәм мескен булыр иде безнең яшәү». Бәлки шундый ук сүзләр белән уйлмагандыр Бибинур, мәгәр фикере шул иде.

Ул уйларын ишегалдында тәмамлый алмады, урамга да ияртеп чыкты, капка келәсенә тотынгач тагын бер тапкыр тәрәзәләргә карады. Күкрәгеп нидер китереп кысты, ияге тагын түшенә тиде, керфекләре тагын дымланды. «Ник соң еларга гына торам әле мин бүген?» дип уйлады ул, нык булырга тырышып, йодрыкларын йомарлады, җиргә катырак басарга тырышты. Кемнәрдер аңа сәлам биреп узды, кемнәрдер тәрәз ачып аны бәйрәм белән котладылар, тырышып-тырышып чәйгә чакырдылар, әмма ул тукталып тормады, сәламгә каршы сәлам бирде, чакыруларга рәхмәт укыды, ул танымаганнар да байтак очрады. Болары яшьләр — читтә туып, читтә үскән аксыргаклылар.

Буа өстеннән чykkанда «Миңлегөл очрамаса гына ярар иде!» дип курыкса да, беразга адымын акрынайтты, бөтенләй диярлек туктады. Уйлары төзек түгел, хәтере чуалган, максаты гына ачык иде — дөрес ниятләгән, тизрәк Вәли картларга барып җитәргә генә кирәк!

Аннан тауга менә башлады, монда яңгыр ныграк яуган икән, әйтәм җирле, күкрәве хәтәр генә булды. Тау киртләченә җитәрәк, сулышы кысылып тукталды да, авылга борылып карады. Болытлар арасында йөзеп арган кояш буага төшеп ял итә. Авылның теге очына көтү кереп килә. Терлек иртәрәк кайтамы, әллә Бибинур соңгарак калып чыктымы алга?

Тауның соңгы яртысын ул шактый озак узды, еш-еш туктап, тын алып, күкрәген кысып торды, йөрәге туктаусыз какты. Янгыр җебеткән кызыл балчыкта аягы таеп-таеп китте, бер мәртәбә чак кына ерганакка мәтәлмәде, «ходаем егылып ятасы булсаң!» дип куркынып шомланды.

Тау башында юл бераз җилләгән иде, шулай да уйсу урыннарда күгәрченнәр коенырлык кына күлләвекләр җыелып тора, болганчык су өстендә өер-өер булып черкиләр уйный. Черкиләр, көтү булып су өс-

теннән күтәрелделәр дә, күңелдәге шомны арттырып, аның тирәсендә оча башладылар. Кайдадыр машина тавышы яңгыраган кебек булды, әмма юл буп-буш иде. Бераз атлагач аның сулышы тигезләнде, Бибинур кулларын тиз-тиз селтәп бара башлады. Авыл аста күмелеп, алда урман шәйләнгәч аның шомлануы артты.

Ул, әле алдына, әле артына карый-карый сөрлегеп, адымнарын ешайтты.

Урманга житәрәк юл тагын йомшады, кулдагы таяк тирәнгәрәк бата башлады, ул яулыгын бер яккарак кайтарып колагын ачты, таягын култык астына кыстырды.

Урман аны салкынча эңгере, юеш яфраклары һәм шикләндергеч тынлык белән каршы алды. Ялгыш кына юл кырындагы куакка кагылган иде, өстенә мул булып салкынча чык коелды. Юл аулак булгач куаклар чатлы-ботлы ботакларын әллә кайларга сузганнар — әле итәгеннән, әле жиңеннән тартып, алар Бибинурның барышын акырынайттылар, аягы ә дигәнче манма су булды.

Кайдадыр якында гына эт өрде. Теге юлы Жиһангирны жирләп кайтканда да эт тавышы колакка чалынган иде. Ул чакта төнлә кайтса да бу кадәр шикләнмәгән иде, хәзер «нинди эт йөрер икән монда?» дип куркып уйланды. Бу тирәдә лесник та тормый, урман хужалыгы бөтенләй башка якта. Якында гына башка авыл да юк. Бүре уласа икән, төлке чинаса икән, ә монда эт өрә! Сәер иде, сәерлеге аркасында куркыныч иде. Куркыныч аның адымнарын тизләтмәде, ул баягыдан да акрынрак, каранырак бара башлады.

Яңгыр сибәләргә тотынды. Мәкерле, тавышсыз гына коя торган төнге яңгыр. Ул таягын ике куллап тотып, сугарга әзерләнеп бара башлады. Юлга ук чыккан куе ботакларны таягы белән аралады, су тамчыларын кагып-кагып төшерде. Чама белән елгага житәргә тиеш иде кебек, әмма алда һаман тигез һәм аулак юл әле.

Ниһаять, сөзәк ярдан төшә башлады, аягы таеп лып итеп артына утырды, ботакларга ябышып, көч-хәл белән торды, аска карады, чокыр төбендә үләннәрне бер якка бөгеп, үз ихтыярына буйсындырып тавышсыз гына кара су ага иде. Су шактый салкын булганга, ул теге як ярга чыгуга бер-ике тапкыр нык кына төчкерде, хәтта үз тавышыннан үзе курыкты. Үргә менә башлады. Котырып үскән балтырганнар, шома көпшәләр ул ябышкан саен шартлап өзелеп чыга иде. Ул тагын төчкерде һәм кинәт аның чәчләре кыймылдап куйды. Яр өстендә, бик якында гына татлы, серле тынлыкны бозып алама тавышлы эт өрергә тотынды.

Нәкъ шул вакытта аның хәлсез кулы нык тамырлы зелпе куагын кармап тапты, ул бер талпынды, ике омтылды һәм, яр өстенә менеп житәм дигәндә генә, коты чыгып, туктап калды. Юл уртасыннан, нәкъ аның каршысына таралып кына эт өере чабып килә иде. Ул кулларын бутап чәрелдәп кычкырып жибәрде һәм артына утырып, әле генә ни интегеп менгән үрдән аска шуып төште, елганың үзе килгән ярына ташланды. Этләр ярны иңләп савылып аска төштеләр дә чокырны тутырып аккан су янына житкәч беразга тыелдылар. Иң алдан килгәне баягы кебек карлыккан аваз салып өрә башлады. Шушы тукталыш Бибинурны коткарды, ул үрмәләп яр өстенә менеп житте һәм юлында беренче очраган дәү чыршы кәүсәсенә килеп сыенды.

«Өзгәләп ташлар бу явызлар!» дип мыгырданды ул, бераз әл-хәл алгач. Шунда чыршы астында гына яткан ап-ак сөякләрне күргәч, башы әйләнеп чак егылмады: «Әллә шушы явызларның өненә үк эләктеме?»

Ул үз хәленең үтә яман икәнлеген күңеле белән төшенсә дә, баланең зурлыгын бөтене белән күз алдына китереп бетерә алмый иде.

Былтыр көз Галикәй сөйләгән бер тарих шулчак кылт итеп исенә төште.

«Бер көн таудан төшеп киләм, Кырынды тавын беләсең, урман, чокыр да чакыр, куе куакларда бүре балалый иде, тамагым янгач Бики чокырына чишмәгә сугылдым. Су эчәргә генә тезләнгән идем, янымда ике-өч эт чабып килеп чыкмасынмы? Бугазга сикерәләр, денсезләр. Әле дә ярый, саллы гына күсәк тоткан идем, як-якка селтим шуны, кулсыз кала яздым. Их, мылтык янда чак булса, дим. Үкенәм! Мылтык барын белә шул алар, кеше янында авыр сабак алып, төрле сәбәп аша иясез калган кыргый этләр. Кешене бер дә яратмый алар! Тырышып-тырышып бүреләрне кырып бетердек, котылдык явыздан дип авыз тутырып мактанабыз. Ә табигатьтә бүре бик кирәк икән. Бүре хуҗа икән. Көч икән ул адәм баласының дусты! Көчле хуҗа юк җирдә табигать-хуҗалыкны, әшәке, алама эт эләктерә. Кала хулиганнары төсле оешып алалар да, бер чакта да ялгыз йөрмиләр, ишкә куш табыла, өер җыела, башлык билгеләнә, әй көчәяләр соналар! Өч этнең берсе биялэй хәтле генә, иң явызы шул, килә дә ябыша. Таяк белән берне эләктергән идем йомгак кук тәгәрәп китте әнчек! Тегеләр дә аңа иярде. Эт ауларга махсус чыгасым бар әле, кырып бетерәсе бар әле шул мур кыргырларын. Бүреләрне әрәм итеп бетердек, бүре булса — аларның берсен калдырмый момент кырып бетерер иде!»

Шулай сөйләнгән иде Галикәй, бүре юклыктан файдаланып ирәйгән куркак әнчекләрне ул да кырып бетерә алмаган икән! Мөгаен, шулар чыкты инде Бибинур юлына.

Этләрнең ялгыз юлчыларга ташлануын, кешегә ачу итеп көтү-көтү сарык буып китүләрен, иң сөтләч сыерларның җиленнәрен умырып ашауларын соңгы елда Бибинурга бер Галикәй генә сөйләмәгән иде, әмма үз бәхете, үз хәсрәте белән артык юанып киткәнгә, андый хәбәрләргә артык игътибар биреп тормаган иде ул. Чын булган икән имешмимешләр! Кайчандыр кемгәдер дус булып яшәгән йорт этләре хуҗаларына ачуланып урман-кырларга чыгып китәләр дә, бөтен кешелеккә сугыш игълан итәләр. Ярый, кемдер сезне рәнҗеткән дә булсын ди, аның өчен нигә Бибинурны җәзаларга?

Бәлки Бибинурның үз Карабае ыруы да шушы өер арасындадыр?

Ул, елганың аръягында ырылдашып торган этләргә карап, мөмкин кадәр ягымлы, тәмле телле булырга тырышып эндәште:

— Карабай, Карабай! Нишлисең син, мин синең Бибинур нәнәң булам ич! Этләрнең алдагысы, кайчандыр булган кушаматын ишетеп, чак кына тынып торды да сырт йонын кабартты, башкаларны үз артыннан әйдәп өрә башлады, эт өере елганы кичеп бу як ярга менде, тик алар Бибинур янына килмәделәр, бер читтәрәк, коры җиргә, икенче чыршы төбе тирәсендә сузылышып яттылар. Бибинур урыныннан кузгалса, ырылдап өрергә тотындылар.

Галикәй хаклы, эт эт икәнен онытмасын өчен урманның чын хуҗасы бүре җитми икән хәзер! Бүренең үзен күрү дә кирәкми этләргә, дип сөйләде ул, алар аның исенә үк буйсыналар, улавын ишетсәләр койрыкларын бот арасына кыстыралар. Бүре барын белгән эт кенә кешене олылый белә, аны хуҗасы итеп саный. Әйе, эт кешенең дусты булып киткән, әллә никадәр кешене кар астыннан табып алган сенбернарлар бар, сукырларны җитәкләгән овчаркалар бар, егермешәр ел хуҗаларына тугрылык саклаган этләргә һәйкәлләр куелган, болар барысы да хак. Мәгәр этне кешегә сыенырга мәҗбүр иткән сәбәп бер — курку. Усал бүре юашрак бүрене кеше янына куып китергән дә, шуннан эт токымы башланган. Юаш бүредән туган бүре — инде эт булган. Әгәр шушы гасырлар буе килгән курку инстинктын оныта икән, эт этлеген дә югалта, бүре кебек акыллы һәм горур да булып бетә алмый.

Шулай дип сөйләгән иде Галикәй.

Менә хәзер ул шундыйларга тап булды. Бичара Бибинур, яхшылык белән кешене генә түгел, хайванны да үзгәртеп була дип инанган киң күңел, аны-моны уйламыйча һаман явызларны юмаларга, иркәләргә маташты.

— Карабай, син акыллы идең бит! Олыны олы итә белә идең. Яхшылыгымны тәмам онытып бетердеңмени, явыз. Әйт, иптәшләреңә әйт, тешләмәсеннәр мине!

Этләр аның ягымлы эндәшүенә ырлап җавап бирде.

Ул өметсезләнеп, аңгыраеп байтак утырды. Караңгылык тәмам куерды, яңгыр һаман килә-китә сибәләп торды, этләр чыршы астында күренмәс булдылар, мәгәр Бибинур карчык кузгала башлады исә, алар ырылдап аваз салалар иде. Хәлдән тайган карчык акырынлап ойый, онытыла башлады һәм йокыга китте. Бер мәлгә аңа бик җиңел һәм бик рәхәт кебек тоелды. Бер-берсенә ябышкан иреннәр язылдылар, ул елмайды һәм төш күрде... Төшендә ул мыштым гына агып яткан урман елгасы өстеннән оча башлады. Елгадан тирән ярлы тарлавыкка күчте. Тарлавык ниндидер торак-бинага барып тоташты. Ике якта да сансыз-исәпсез ишекләр тезелеп киткән иде. Мондый озын коридорны ул гомерендә бер генә мәртәбә — кызыл айгырның язмышын юллап райкомга баргач кына күргән иде. Тик бу тарлавык ул коридорга караганда йөз, мең мәртәбә озынрак, ишекләренең дә сан-исәбе юк иде. Ачык ишекләрдә таныш йөзләр дә чагылып-чагылып киткәли. Менә Габдуллаҗанның ап-ак чырае күренде. Ишекнең менә бу кечерегеннән башын югары күтәреп Гайшә чыгып килә. Кулында бала кулмәге. Кайдадыр, алардан бер читтә, балык җәтмәсе каплаган ишектә Галикәйнең хәтәр тырпайган мыегы күренде. Ник ул монда соң әле, дип уйлады Бибинур. Эндәшергә өлгермәде, тарлавык бетте, караңгылык тагын да куерды, ул оча-оча ниндидер кап-кара, җылан кабыгы төсле салкын, шома стенага килеп бәрелде. Кайда соң моның ишеге дип бик озак эзләде, ишек табылмады.

Якында гына этләр улашырга тотынды. Бераздан алар тынды. Бибинур карчык керфекләрен күтәрде һәм тирә-ягындагы бушлыкны абайлап көлеп җибәрде...

Иртә чалт аяз, кояшлы иде. Сабан туе алдыннан Аксыргак авылында гына була торган бәхетле шимбә иртәсе яралды.

1979

## Флера Гыйззәтуллина

### Иделдә өмә

1

Зәңгәр баржалар,
Ак пароходлар
Судан йөк тарта:
Әнә, карагыз!
Идел өстенә
Күз сала-сала
Печән чабабыз,
Печән чабабыз.

2

Яшь печәнлектән
Аңкый бал исе,
Кайнар учларга
Бал исе сеңә...
Селтәнгән саен
Кулга көч иңә:
Иделдә өмә!
Иделдә өмә!
Селтәнгән саен
Җилкенә йөрәк!
— Колач киң кирәк!
— Адым нык кирәк!..
Килгән адымнар
Тигез саклана:
Безнең ышаныч
Аклана, димәк!

3

Идел иректе,
Ярлар сөекле,
Ярлардан үрли
Хезмәт учагы.
Кем алга чыгар?
Кем алга чыгар?
Бәйрәмчә чуар
Идел кочагы.

Идел елдан-ел
Зурлап үстерә
Туган халкының
Хәләл өлешен...
Иделдән сузган
Тәүге покосым
Мәңге какшамас
Иминлек өчен.
Урта покосым
Урта буыннан
Кече буынга —
Туры юл башым.
...Болыннан кайткан
Айлы кичләрне
Хәтерлисеңме,
Яшьлек юлдашым?

Балдай хуш исле
Болын-кырларның,
Яңа җырларның
Юк иге-чиге...
Зәңгәр баржалар,
Ак пароходлар
Судан йөк тарта —
Тынычлык йөге!

### Төп йортта

Өч балам өч яктан
Кайталар төп йортка
Көн язга авыша башлагач...
Нигез-таш какшамас,
Тузгымас төп нигез —
Балалар төп йортны ташламас!

Олысы кечесен
Хезмәткә өйрәтсә,
Кечесе хөрмәтләр олысын...
Мин исән чагымда
Тигез өч агымга
Бүлермен йөрәгем җылысын.

Яшәүдән көч алып,
Төп йортка мич ягып
Көн итү — минем төп бурычым.
Өч балам — өч дөньям:
Чәчәкле өч язым,
Ап-аяз өч кояш чыгышым.

## Ярамас!

Авырып яттым, дисәм, ышанмаслар,
Яраландым, дисәм, ярамас! —
Җөйләттем дә сөрттем кан тапларын —
Җөйне кем дә сүтеп карамас!

...Әйтми түздем! Үзем генә белдем
Хәлләремнең авыр чакларын.
Кабат килдем дуслар каршысына
Киеп күлмәгемнең ап-агын.

— Исән-сау! — дип шатландылар дуслар,
Баштанаяк сынап карагач...
Тизрәк эшкә күмелергә кирәк!
Җиңелергә миңа ярамас!

## Сер сөйләдең миңа

Сер сөйләдең миңа, сер сөйләдең!
Алдыңмы соң сернең миндәген?..
Хәтереңдәме йөкле чана тартып
Минем белән тауга менгәнең? —
Тау башына басып күрсәткәнең:
— Әнә!— диеп,— бәхет юлларың!
Синнән миңа йөкле чана калды.
Йөк бавыннан талды кулларым.
...Йөккә башым куеп бер ял иттем,
Ярты юлны җәяү узгачтын...
Шуңадыр син җәяүле җил булып
Йөрәгемә кереп урнаштың.
Шуңадыр да холкым кырыс булды —
Әйләнәсе белән ел коры!..
Корылыкны сынык-сылтау итеп
Мин Себергә киттем туп-туры.
Анжиркага киттем: ал хыялның
Алжирлары торды бер читтә! —
Чүмәләмә йөк төялеп торды,
Чыныктырды тормыш ничек тә.
...Анжиркадан иң шәп күмер чыкты.
Буран купты язга табарак.
Мин бәхетне бик тиз танып алдым,
Бураннардан алдым аралап.
Ак буранда кара терриконнар![1] —
Күз карасы Себер төненең.
Даны уртак, уты-ялы уртак
Хезмәттәге олы җиңүнең.

---

[1] Шахтадан алынган породалар тавы.

Синең белән минем серләр уртак:
Серне сергә кушып ялгармын.
Төяләсе олау, сөйлисе сер —
Киләчәге янар тауларның.

## Басуларга чыксам

Түр басуда сөргән кара җирләр,
Үр башында кырку куралар...
Ир балалар курай моңнарына
Иртә төшенүчән булалар.

Ил картлары мактый ир баланың
Илдә яшәп гыйбрәт алганын.
Бу язымда мин дә җырларыма
Улым буразнасын ялгадым.

Игелексез ирне ил өнәмәс,
Картлар сүз сөйләмәс белмичә...
Тургай таңда хәбәр бирми калмас
Алдынгыга алмаш килдисә!

Шатлыкларын җырга ашырганда
Үз тиңдәшен җырчы кош таныр.
Илтифатлы илнең уллары да,
Кызлары да эшкә остадыр.

Илнең хәер-фатихасы бердер:
Уллар өчен, кызлар өчен дә.
Мин улымның хезмәт уңышларын
Бәрәкәтлим шигъри хисемдә.

Мәңге юлдаш итеп сайлыйм аңа
Биектәге гүзәл таң кошын...
Иң зур бәхет — күрү үз балаңның
Исән-имин эштән кайтышын.

## Җидегән йолдыз

Җидегән йолдыз, син бит җиде йолдыз!
Җиде маяк тирән төндәге...
Кешеләрдән күргән яхшылыклар
Яктылыкка мине өндәде.

Ул яхшылык гел өстәлеп торды.
Сулар һава, үтәр юл сыман.
— Яшәвеңнән син канәгатьме? — дип,
Сорап калдым һәрбер юлчыдан.

Гизәр киңлек сорап илгә бактым,
Айлы кичтә, кадер кичендә...
Илгизәрләр белән тиңләшкәннән
Зарар килми көчкә, зиһенгә.

Көрәшкәннән корал тупасланмый,
Маяк тоныкланмый барлаудан...
Кирәк түгел миңа таркалган яу,
Кирәк түгел миңа тар мәйдан!

Кирәк түгел миңа тапталган дан! —
Кулдан алмам данның сатлыгын...
Баш очымда җиде катлы күгем —
Җимерелмәс җиде шатлыгым!

Җиде таңнан җыйган гөл орлыгым
Җиде яран булып яралган!
Җидегән илен җиде әйләнсәм дә,
Күзем җирдән аерып алалмам!

Аерылгысыз җиде дус кулы ул, —
Җидегән юлы, тулган ай юлы!
Җиде дуста — җиде диңгез гизәм;
Сөзәм җиде диңгез байлыгы.

Тезәм алга җиде тел ачкычын
Әкияттәге җиде батырның...
Җирне ак биләүгә билисем бар! —
Батырларны шуңа чакырдым.

Билисем бар. Чөнки җир — Җидегәннең
Бишектәге сабый баласы...
Томрап торган сабый карашында
Яшәешнең бөек тарафы.

## Сүз хәнҗәрем

Дәү бүләкләр синнән өмет итмим,
Көтмим сүзнең йомшак, җылысын...
Бул син минем җиңү пәһлеваным,
Буйсынучым, буйсындыручым!?
Бул син минем якындагы язым,
Күгемдәге талгын күзәтчем.
Йөрәккә мин хәнҗәр белән яныйм,
Бар хатамны хәнҗәр төзәтсен.
Телеп алсын хәнҗәр җанымның бар
Кимчелекле, шикле өлешен...
Яр сөйсәм мин икеләнеп сөймим,
Сүз сөйләсәм, сөйлим дөресен.
Сүз озайса безнең, сүз хакларын,
Беләм, хәнҗәремнең акларын! —
Сиңа булган мәхәббәтемне мин,
Вакланмаган килеш сакладым.
Сүз хәнҗәрем әгәр сынып калса,
Хәнҗәр көрәштергән чакларда,
Мин үземне әсирлеккә яптым,
Әсир төшмәс өчен ятларга.
Мин үземне упкыннарга аттым,
Наганнардан аттым күп тапкыр...
Куй учыңны кайнар маңгаема,
Тик бер минут янда туктап тор,
Күренмәсен чәчрәп кан чыкканы,
Гөлгә чорна йөрәк турысын.
...Бул син минем көрәш пәһлеваным,
Буйсынучым, буйсындыручым.

Марсель Зарипов

# МӘҢГЕЛЕК ШӘҺӘР

ОЧЕРК

## I. Бәхетлеләр юлыннан



Менә мин Түбән Кама каласына китеп барам. Баштарак: «Әллә самолет белән генә очыйм микән?» — дип тә уйлаган идем. Нибары ярты сәгатьлек юл! Соңрак су юлы белән, ашыкмый-чарак барырга булдым. Ыгы-зыгылы аэровокзаллардан, турбореактив самолетларның каты тавышыннан, кирәгеннән күпкә артык әдәпле елмаеп каршы алучы стюардессалардан туеп беткәнмен инде. «Метеор»га утырырмын да Иделнең яр буйларын җай гына карап барырмын. Элекке таныш җирләрне искә төшерермен, яңа очрашу-күрешүләргә хәзерләнермен. Начармыни?!

Түбән Кама шәһәре, барган саен, үзенең яңа сыйфатлары белән ачыла, һәр килүем яңа кешеләр янына кайту кебек тоела, чөнки соңгы тапкыр күрешкәннән бирле алар тагын да тырышарак төшкәннәр, тагын да зуррак, кыюрак эшләр башкарганнардыр дип беләсең.

Элекке килүемдә бу кала үзенең илле меңенче кешесе — кранчылар Вера Захарова һәм Николай Самойловның Валерик исемле уллары тууын бәйрәм иткән иде. Ничек бәйрәм итүләрен тәфсилләп сөйләп тормыйм инде. Минем өчен аның асыл мәгънәсе шул: хис-тойгыларга саран бер техника заманында туган шәһәр гасырлар буена нәселдән-нәселгә, буыннан-буынга күчеп килгән гадәт-йолаларны онытмый.

Борын-борыннан безнең якларда, бала тугач, яшь киленчәкләр дә, әби-карчыклар да балалы йорт турында кайгыртуны үзләренең бурычлары итеп караганнар. Таза, бай яшәгәндә иң яхшы сыйларын, авыр елларда соңгы икмәкләрен китергәннәр. Балалы йортка мондый хөрмәт күрсәтү ана кешене, аның олы җанын, тырышлыгын ихтирам итү, туган җиргә, туган йортка тугрылык һәм яңа туган җан иясен кайгырту билгесе ул.

Түбән Камада бик еш бәби туе ясауларының сәбәбе дә шунда түгел микән? Кешеләрнең яңа туган һәр сабый турында, халыкның тамырын саклау турында кайгыртулары бик сөенечле хәл, әлбәттә.

...Менә тагын шундыйрак бер хәл искә төште. Андыйны Түбән Кама шәһәреннән башка җирдә очратып та булмас, шөт. Бервакыт кибеттән ниндидер әйбер аласым булды. Урамда очраган кешеләрдән: «Шундый-шундый әйберне каян табып булыр икән?» — дип сорагач, шушы шәһәргә хас ачык чырай белән:

— Менә шуннан туп-туры барыгыз, ике квартал үткәч, уңга борылырсыз, шунда «Дүрт танкист һәм ике эт» дигән кибет булыр, — дип, юл күрсәтеп җибәрделәр.

Кара син аны! Гадәттәгечә «Бакалея», «Гастроном», «Аяк киемнәре» яки «Киемсалым» гына түгел!..

«Дүрт танкист һәм ике эт» дигәннәре үзенә бер зур сәүдә комплексы булып чыкты: азык-төлек, аяк киеме, тукыма һәм трикотаж магазиннары янында тагын ике «өстәмә»се дә бар иде. Берсендә, Аэрофлот агентлыгын ачканга хәтле, самолетка билет саталар, икенчесендә кафетерий ачарга җыеналар икән. Билгеле, бу магазиннарның рәсми номерлары да бар, ә «Дүрт танкист белән ике эт»не халык кушкан.

Хикмәт бу исемнең уңышлымы яки уңышсызмы булуында түгел. Халык теленә кереп киткән икән — уңышлы булган, димәк. Биредә, минемчә, шәһәрнең характерындагы бик мөһим бер сыйфатны искәреп китәргә кирәк.

Түбән Камада йөз утыз мең кеше яши, бер миллион өч йөз мең квадрат метр квартир бар. Монда йортларны ялан җиргә берән-сәрән итеп салмыйлар, бәлки урамы-урамы белән, кварталлап тезиләр, завод һәм микрорайоннарда утыз магазин, 135 ашханә, кафе, ресторан, йорт кухнясы бар. Бөтенесен берьюлы гына санап бетерерлек тә түгел!

Проектчылар макетта ак пенопласт шакмаклар куеп, аларны шартлы тамгалар белән билгелиләр. Шул уенчык шакмаклар урынында чын йортлар калкып чыккач, ул биналарга әйбәт исем табарга тырышмыйлар, бәлки гади саннар белән генә билгелиләр. Балалар бакчасы һәм яслеләргә кушыла торган «Дюймовочка», «Светлячок», «Солнышко», «Теремок», «Аленушка», «Чебурашка», «Крокодил Гена» кебек исемнәрне балалар уйлап тапканнар. Ә олылар уйлап тапканы «Акчарлак» кафесы, «Кама» һәм «Волна» рестораннары, «Кристалл» һәм «Колос» кибетләре диган дүрт-биш исемнән артмый. Шуннан калганнары гади саннар белән йөртелә. Ә халык ул кибетләрне үзе кушкан исемнәр белән атап йөртә. Алар арасында уңышлылары, әйбәтләре байтак, әмма тел әйләнмәслекләре дә аз түгел. Макетта «13» саны белән билгеләнгән ерактагы микрорайонны «Тыйнда» дип атыйлар. Сәүдә комплексларына җиңелрәк әйтелешле «Өч баһадир», «Өч каенана», «Өч кыз» диган исемнәр кушылган. Бер бүлегендә аракы сата торган зур гастрономны «Хатыннар күз яше» дип атаганнар— монда бик күп ирләрнең кесәләре бушап кына калмаган, ә байтак гаиләнең җимерелүе сәбәбе башланган. Шуннан соң инде аракы сатуны тыйганнар.

Ләкин эчүчелеккә каршы көрәшкәндә иң җиңел юл белән генә эш итү ягын карыйлар, халыкка никадәр күбрәк мәшәкать тудырсаң, аракыны әзрәк эчәрләр дип уйлыйлар. Әмма эчүчелек бик зур социаль бәла ул, аны тирәнтен уйлап, үтемле чараларын кулланганда, сәүдә культурасын тагын да яхшырта төшкәндә генә җиңеп чыгарга мөмкин.

Хәзер ерактагы аракы кибетенә кешеләр үз машиналары белән генә түгел, йөк машиналары, автобус, үзбушаткычлар белән баралар, һәркайсы сумка тутырып запас алып кайтырга тырыша. Тәртип саклау өчен бер милиционер-старшинаны куялар, ә халык промбазадагы бу кибетне «А зори здесь тихие» дип атый.

Хәер, шәһәр халкының мондагы тапкырлыгы бер дә гаҗәп түгел, үзләренең уңай якларын гына күреп, кимчелекләренә күз салмаска көчсезләр генә тырыша, көчлеләр, киресенчә, андый кимчелекләрдән көлми калмыйлар. Түбән Кама ул яктан мактауга лаек: кирәк урынында көлә дә, шаярта да белә.

*

* *

Диңгездәй җәелгән су өстеннән «Метеор» оча да оча. Күңелем белән инде мин барасы җиремдә йөрим, анда кешеләр белән очрашасыларымны күз алдыма китерәм, бу юлы нинди яңалыклар күрермен икән? — дип уйлыйм. «Илле меңенче» Валерикны күз алдына китерәм — зур үскәндер инде, бакчага йөри торгандыр, әллә мәктәпкә үк кергәнме? Экскаваторы белән кала нигезенең беренче туфрагын көрәп алган атаклы Дмитрий Иванович Булавин кайда икән хәзер?

Монтаж мәйданчыгына, атаклы осталар челтәр үргән кебек, торбаларны, тимер чыбыкларны әллә ни хикмәтләр эшләтеп бетерүчеләр янына баргач, бригадир

Климаковны күрәсемне, узган юлы күрешкәндәге кебек, берәр кыю, тәвәккәл эше белән үземне шаккатырасын уйлыйм!

1973 елның июлендә беренче тапкыр Климаков белән очрашкан чакта һавада рәшә дулкыны тибрәнәме, әллә җылы дулкын реакторлардан чыгамы икәнен дә аерырлык түгел иде. Җомга көнне кич күккә ашып торган аппарат челтәрләре һәм эстакадалар арасында бер буш урын калган иде, дүшәмбе көнне карасам, шул төштә биек бер зур колонна басып тора. Исең-акылларың китәр! Әйтерсең, бу тезелешкә дию пәрие килеп чыккан да шушы могҗизаны эшләп куйган!

Җәй көннәрендә күкеләр моңайган, кышын тукраннар агач тукылдаткан төшләрдә хәзер зур шәһәр калкып чыкты. Монда инде җәен-кышын гына түгел, көненнән дә тормыш-тереклек туктап тормый, кешеләр корган хикмәтле аппаратлар-реакторларда табигатьтә җил, яңгыр, кояш ярдәмендә хасил булган нәрсәләр эшләнә: туктаусыз рәвештә бер матдә үзгәреп, икенчесенә әверелеп тора.

Күңелем, узгандагылардан кайтып, бүгенгене кичә, канатлы йөзгечтән төшкәч, Түбән Каманы күрәсемне уйлыйм. Шәһәрне, аның урамнарын, йортларын, эшкә ашыккан кешеләрен, утлары белән балкып торган төзелешләрен күз алдыма китерәм, узган баруымда әле бөтенләй тумаган-булмаган өр-яңа урам күрәм, «Б. В. Бызов исемендә» дигән язуын укыйм.

*

* *

Биредә мин ни сәбәпле Борис Васильевич Бызов дигән кешене телгә алуымны кыскача гына булса да аңлатып китим. Ул инде нефтьче-химиклар шәһәре Түбән Каманы сала башлаганга кадәр егерме дүрт ел элек үк дөньядан киткән. Әлбәттә, бу төштә шәһәр булачагын, Россиянең ике зур елгасы — Идел белән Кама кушылган төштә Түбән Кама каласы үсеп чыгар дип уена да китермәгәндер ул.

Бызов урамы. Аның исеме кушылган мәктәп, пионер дружинасы. Һөнәр осталыгын күрсәтү өчен ел саен яки махсус оештырыла торган конкурс, смотрлар — үз заманында зур хезмәтләре тиешле бәя алмый калган бу фидакарь кешенең истәлеген мәңгеләштерү өчен андый чаралар азмыни бездә!

Ачышлар һәм шуңа ирешүче галимнәр никадәр күп булса да, һәркайсының киләчәк буыннар хәтерендә яшәргә, аларның рәхмәтен ишетергә хаклары бар. Оныту, искә алмау — ул физик үлемнән дә рәхимсезрәк бер нәрсәдер, чөнки кеше үзе үлсә дә, исеме халык күңелендә яши бирә.

*

* *

Чыннан да, Б. В. Бызов турында ниләр беләбез соң без, нефть белән эш итүче, аны каучукка һәм башка полимерларга әйләндерүче Түбән Кама һәм тагын байтак яшь калаларның үсеп чыгуына сәбәп биргән кешене ни дәрәҗәдә хөрмәтләп искә алабыз?

Бызовның дуслары, шәкертләре аның төп тормыш баскычларын шактый тулы язып калдырганнар. Бызов Петербург университетының табигать бүлегендә укый, атаклы химик А. Е. Фаворский җитәкчелегендә диплом эше язып, кандидатлык дәрәҗәсе ала, ул замандагы гадәт буенча, чит илдә, Германиядә стажировка уза. Туган илгә кайткач, Бызов «Рус-Америка резин мануфактура ширкәте»ндә эшли. Бу ширкәт елына 2 миллион 330 мең пар галош җитештерә. Бызовның чит илләрдәге гыйльми басмаларда хезмәтләрен бастыру хокукы да була.

«Красный Треугольник» заводында лаборатория оештырып, ул нефтьтән каучук ясау юлларын эзли, политехник институтта укыта. Мин аның нефть каучугыннан ясалган галошның дүрт айга чыдавын, автомобиль көпчәгенең сигез мең километр йөрүен күргәч ничек сөенүен дә, 1928 елда аның ачышы ВСНХ тарафыннан «игътибарга лаеклы» дип кенә бәяләнүен белгәч, моны никадәр авыр кичергәнен дә күз алдына китерәм. ВКП(б) Үзәк Комитеты карарында: «Профессор Бызов ысулы белән ясалма каучук эшләүне мөмкин кадәр тизләтергә...» диелгән булса да, экспертлар:

«Бызов ысулын промышленность күләмендә гамәлгә ашыру файдалы түгел», диган нәтиҗәгә киләләр.

Фоторәсемендә Бызов — күзлекле, кырыс йөзле, ягымлы һәм хәйләкәррәк бер карашлы кеше булып чагылган. Гүя башкалар өчен сер булган нәрсәне үз күңеленнән табарга тырыша, изге бер кеше шикелле, башкалар белмәгәнне күрә.

Бызовның авыр гомер юлын, нефтьтән каучук ясау хыялының зур киртәләргә очравын кешелек дөньясының бүгенге зур үсеш юлындагы ялгышлар исәбенә кертергә кирәкмәс. Франклинның хәзер һәрбер мәктәп баласына билгеле булган яшен кайтаргычын Париждагы Фәннәр академиясе кире кага. Фултон Наполеонга җилкәнле корабларга пар двигателе куярга кирәк диган тәкъдимен әйткәч, император аны акылыннан язган бер кешегә саный. «Революциягә галимнәр кирәк түгел...» диган сылтау белән бөек химик Лавуазьеның башын кисканнәр.

Нефтьтән каучук ясау идеясен ни өчен «файдалы түгел» дип табуларын аңлар өчен тарих тәгәрмәчен бер кырык елга артка әйләндерергә, бүгенге нефть турында белгәннәребезне, аның ясалма материаллар эшләүдә төп чимал булуын онытып торырга, ул заманда бу җир асты хәзинәсенең кешеләр өчен фәкать яга торган май, мотор азыгы гына булганлыгын истә тотарга кирәк.

Тропик урманнарының каучук ясау өчен файдаланылган, сагыздай сузыла торган сыекчасы исә алтын, энҗе-мәрҗәннәргә караганда да кирәгрәк бер нәрсәдән санала. Европада да, Азиядә дә, яңа дөньяның иркен җирләрендә барлыкка килгән яшь Америкада да каучуктан башка эш алга бармаячагын аңлыйлар. Сыгылмалылык белән ныклыкны куша торган җирдә каучук кирәк икән. Автомобильгә 300 резина деталь кирәк. Хәзерге заманның җитез канатлы лайнерына ике тонна ярымнан артык, уртача зурлыктагы корабка исә җитмеш тонна резина тотыла... Машина, конвейердан төшкәч, кузгалып-йөреп китә алмаса, аны ясау нигә кирәк? Ә резина көпчәксез йөреп китә алмый ул! Шулай ук, резина булмаса, диңгез кораблары да ясап булмый. Резинадан эшләнгән йомшак, герметик скафандр булмаса, су төбенә дә төшә алмыйсың. Электр машиналарын изоляцияләрлек материалың булмаса, куәтле генераторлар һәм турбиналар булдырырга омтылу да буш хыял гына булып калыр иде...

Хәер, кеше диганең тормыш, яшәеш тудырган табигый киртәләр каршында туктап калмый.

1876 елда, каучук шаукымының иң кызган чагында, Европа, Азия һәм Америка флаглары күтәргән кораблар, тропик агачы гевея сагызын төяү өчен, эссе Бразилия портларына килеп туктаган вакытларда Амазонка елгасы буена Уикман исемле инглиз килеп чыга. Ул, тыелган булуга да карамастан, бу илдән гевея орлыклары урлап алып китә. Эссе яктан юеш, салкын, томанлы Британия атавына кайткач, байтак орлык тишелми, шулай да Лондон янындагы Король паркында эшләүче профессор-ботаникларның тырышлыгы белән ике меңләп орлык шытып үсеп китә. Утыз елдан соң инде, 1911 елда, инглизләр үзләренең тропик колонияләрендә беренче тапкыр гевея плантацияләреннән уңыш алалар.

Амазонка елгасы буендагы джунглиләрдә тормыш сүнә-сүрелә башлый. Капитаннар да хәзер, карталарына башка маршрутлар сызып, яңа плантацияләргә юл тоталар.

Кешеләрне гади аракы спиртеннән теләсә кайда каучук ясарга өйрәткән Сергей Васильевич Лебедевның хезмәтләреннән мин торган саен кисkenләшә, экономик конфликтларны, политик бәрелешләрне көчәйтә барган каучук өчен аяусыз көрәшнең математик аңлатмаларын карадым. Безнең гасыр башында «гевея бразилиенс» нең кыргый урманнары 54 мең тонна каучук биргән, культуралы плантацияләрдән исә нибары 4 кенә тонна алганнар. Ләкин шушы еллардан башлап кешеләр аны үзләре булдырырга тырышалар — басу-кырларда каучук бирә торган агачлар үстерергә керешәләр. 1929 елда табигый урманнардан җыйган каучук 29 мең 500 тоннага хәтле кими. Аның каравы тропик кояшы астында кеше кулы белән үстергән плантацияләрнең уңышы бик тиз үсеп китә. 1915 елда бу җирләрдән 108 мең, 1920 елда 305 мең тонна каучук кайтаралар. 1926 елда, Совет иле үзенең галимнәренә каучукны аппарат һәм реакторларда ясау юлларын табарга кушкан чакта, әлеге плантацияләрнең уңышы 617 мең тоннага җитә.

Беркадәр алгарак узып булса да әйтик: 1951 елда бөтен дөньяда каучук куллану бер миллион ярым тоннага җитә, 1957—58 елларда исә өч мәртәбә арта, 1966 елда инде капиталистик илләр өчен генә дә 5,8 миллион тонна табигый һәм ясалма каучук кирәк була.

Ә моңарчы хәлләр ничек булган? Эссе тропик кояшы астына, иң яхшы җирләргә утыртылган плантацияләрнең уңышы бик күп булмавы кешеләрне борчуга төшерә,

Шуннан соң каучук өчен көрәшнең икенче чоры башлана — аның ничек барлыкка килүенең серенә төшенергә, табигатьнең бу могҗизасын кешеләр теләсә кайда башкара алырлык гади бер эшкә әйләндерергә кирәк.

Сәяхәтче, географ һәм табигатьне өйрәнүче галим Александр фон Гумбольт каучук турында: «Резин ул — шундый аңлаешсыз, катлаулы бер нәрсә, аның хакында хәтта ходай да берни белми торгандыр», ди. Кешелек дөньясы дистәләрчә еллар, гасырлар дәвамында бөртекләп-бөртекләп белем-гыйлем туплый, табигать серләренә төшенү юлындагы бу мәсьәләгә адымлап-адымлап кына якынлаша башлый. Беренче бөтен дөнья сугышы вакытында, сугышучы эскадралар тропик плантацияләрен Европа илләре белән бәйләп торган җепне өзгәч, немецлар каучук мохтаҗлыгыннан ычкынырга, котылырга омтылып карыйлар. Кайзер Германиясе, иң ашыгыч эшләрен дә читкә куеп, реакторларда каучук ясарга керешә. Хәзерге көндә сәгать һәм минутлар эчендә уза торган процесс ул чагында айлар буена сузыла. Каучук бик кыйммәткә төшә. Шуңа күрә заводны ябалар, аппаратларны сүтеп ташлыйлар да бу эшкә кул селтиләр.

*
* *

Бераүләрнең уңышсызлыкка очрап, өметсезлеккә төшүе икенче бераүләрне яңадан-яңа батырлыкка, каһарманлыкка өндәмәсә, тормыш нишләр иде икән? Колумб Яңа дөньяны ачмас иде, Магеллан аңарчы һәлак булган бик күп сәяхәтчеләр эзеннән китмәс иде. Инде берничә экспедиция һәлак булганнан соң, кешелек дөньясының ике батыр улы — норвег Амундсен белән инглиз Скоттның әләме караңгы, салкын котыпта җилфердәмәс иде.

Лебедев белән Бызов — бер ил, хәтта бер шәһәр кешеләре, хезмәттәш дуслар— җиде юл чатында кая таба барырга белмичә, аптырап калган корабның капитаннары кебек, иң авыр вакытта рульне үз кулларына тотып, бу корабны тиешле юнәлештә алып китәләр. Икесе ике юл белән — берсе төп чимал итеп — спирт, икенчесе нефтьне ала.

Бу юлда эзләнүчеләрнең ике төркеме дә җентекле фәнни тикшеренүләрен, лаборатория аппаратларында ясаган беренче каучук брикетларын ВСНХның ябык конкурсына вакытында тапшыралар. Берсе девизын «Диалефин» дип, икенчесе «Берлектә — көч» дип куя. Бу ике галимнең вафат булулары да хәтта бер үк вакытка диярлек туры килә: аралары берничә генә ай, аларның каберләре өстендә дә бер үк Балтик җилләре исә.

Әмма язмыш дигәнең аларга дан-шөһрәтне тигез бүлмәгән! Лебедевка галим кеше үзе исән чакта ирешә алган бәхетнең иң зурысы туры килгәндер — ул үзе башлаган эшнең уңышлы булып бетүен, тормышка ашуын күрә. Бызов исә үзе сайлаган яңа юлда беренче адымнарын гына атлый, үзенең ачышына киләчәктә игътибар итәрләр дигән өмет кенә кала аңа.

1932 елда Ярославль шәһәрендә дөньяда беренче тапкыр ясалма каучук заводы эшли башлый. Аннары Ефремово, Воронеж һәм Казанда шундый ук заводлар төзелә. Теләкләре чынга ашкан бу вакытта Лебедев: «Үз фикереңнең шундый зур бер җанлы эшкә әверелүен күрүе тау чаклы бәхет икән ул», — дип яза.

Икенче бөтен дөнья сугышы вакытында ясалма каучукны Канада белән Америка Кушма Штатлары, 1957 елда Англия, 1958 елда Италия, шуннан соң инде Франция белән Япония дә җитештерә башлыйлар...

Җидкәнле җиңел кораблар белән Атлантика океанын кичү бер могҗиза булып

тоелган заманда Колумб белән аның юлдашларының исен китергән каучукны ясау хәзер океан-диңгезләрне кичеп йөрү кебек гади бер эшкә әйләнде.

*
* *

Зур байлык вәгъдә иткән бу ачышны ни сәбәпле «файдалы түгел» дип бәяләгәннәр соң? Нефтьтән ясалган беренче резин көпчәкләрнең сигез мең чакрымга гына түзүе бик аз, билгеле. Рус авиациясенең бабасы Жуковский аэропланы яки агалы-энеле Райтлар очкычы белән чагыштырганда тавыш тизлегеннән дә җитезрәк очучы хәзерге самолетлар арасында никадәр зур аерма! Түбән Камада нефть каучугыннан коела торган резин көпчәкләр хәзер йөз мең километр юл узалар.

Әлбәттә, Лебедев группасы ирешкән нәтиҗә белән генә канәгатьләнеп калган резинотрест җитәкчеләренең консерватизмы нефтьтән каучук ясау тәҗрибәләрен дәвам иттерүгә җитди киртә була, шулай да мондый тоткарлыклар озак дәвам итә алмый. Бызов исән чакта «җир мае»ннан каучук ясау фикеренең гамәлгә ашмавының төп сәбәбе — нефть булмауда.

1928 елда безнең ил нибары 11,6 миллион тонна нефть чыгара.

Россия революциягә хәтле үк нефтькә мохтаҗ булган булса, социализм иле яңа тормыш төзәргә керешкәч, «җир мае»ның кадере тагын да арта. Каучукны диңгез аръягындагы җирләрдән, плантация хуҗаларыннан артып калганны гына кайтарталар. 1927 елда Совет иле нибары 7,7 мең тонна гына каучук кулланып, капиталистик илләрдән бик күп калыша. АКШ 372,5 мең тонна, Англия 44,6 мең, Германия 38 мең тонна каучук тота. Советлар Союзыннан бары тик бәләкәй Япония генә калыша.

Шуннан соңгы сигез ел эчендә Советлар иленең экономикасы каучук куллануны биш тапкырга арттыра, ләкин Америка Кушма Штатлары да ярты миллиард тонна чамасы, Англия 99,5 мең тонна, Германия 62,9 мең тонна каучук файдалана. Хәтта үзенең экономикасын «сугыш сукмагы»на күчерергә ашыккан Япония дә 57,6 мең тонна каучук куллана. Индианнар уенчык итеп чөеп уйнаган сыгылмалы, йомшак каучук, политиклар кулына кергәч, стратегик көч-басым, үтерү-җимерү коралына әверелә.

«Әгәр дә мәгәр, әйтик, иртәгә сугыш башланып, читтән каучук кайтару тукталса, без бик кыен хәлдә калачакбыз», — ди Ленинград коммунистлары җитәкчесе Сергей Миронович Киров һәм каучук ясау буенча тикшеренүләрне, тәҗрибә заводларындагы эшләрне тоткарламыйча, озакка сузмыйча тизләтүне таләп итә!.. 1933 елда исә Германиядә власть башына нацистлар килә, «Германия барысыннан да өстен» дигән дәртле марш авазларында озакламый кешелек дөньясы өстенә төшәчәк бәлаказа, газап-михнәтләрнең шомы ишетелә башлый.

Тарихта тиңдәше булмаган бу сугышка барлык илләр туплар, самолетлар, дивизияләр һәм хәрби кораблар хәзерлиләр, үзләрен стратегик чимал булган металл, нефть һәм каучук белән яхшырак тәэмин итәргә тырышалар... Бер кеше гомере дәверендә дөньяның 23 илендә 48 автомобиль заводы төзегән Һенри Форд Амазонка елгасы буендагы каучук урманнарын сатып ала, 200 мең долларлык акча чегы белән Эдисон янына килеп, «гасыр пәйгамбәре»ннән үзенең даһилар һәм талантлар фирмасы белән бергә машиналарга «олтан» булдыруда ярдәм итүен үтенә. «Автомобиль короле» «уйлап табучылар короле» алдына гозер белән килә, капитал кешенең таланты алдында баш ия! Заманының ихтыяҗын тоеп яшәгән Эдисон каучук бирә торган үсемлекләр үстерергә керешә.

Ә Бызов нефтьтән каучук ясау эшен дәвам иттерә. Әмма ул чакта нефть бик аз була шул!

Синтетик каучук заводлары төзү мәсьәләсен хәл итү өчен, академик А. Е. Чичибабин председательлегендә, дүрт мәртәбә экспертлар җыела һәм, экономик шартларга, политик хәлләргә карап, илдә әле азык-төлекнең халыкка да җитеп бетмәвен, чималны ашлыктан, бәрәңгедән, шикәр чөгендереннән, кукуруздан алырга туры киләчәген белә торып, спиртны сайлыйлар. Академик Губкинның Идел-Урал арасында һәм Себердә, Әлмәт, Лениногорск, Ишембай, Октябрь, Сургут һәм Түбән Варта кебек нефть шәһәрләре үсеп чыгачагы турындагы фикеренә геология комитетын-

да: «Губкинның Себер нефте — Курск тимере шикелле үк бер авантюра!» — дип караган чакта ничек итеп «җир мае»на исәпләнгән яңа бер экономик тармак оештырасың?!

Советлар иле каучукны кырларда һәм плантацияләрдә «үстерергә» дигән икенче бер программа да кабул итә. Салкын яклы Россиядә гевея агачы булмаса да, сөтле сагыз бирә торган башка үсемлекләр бардыр бәлки? Иллеләп фәнни экспедиция биш меңгә якын үсемлекне тикшереп чыга. Каучуклы үләннәр үстерергә биш миллион гектар җир билгелиләр. Сугыштан соң 1946—1950 елларга исәпләнгән биш еллык планда унбиш ел элек үк кабул ителгән программаның бик мөһим икәнлеге тагын бер тапкыр раслап әйтелә: «Чәчү мәйданнарын һәм уңышны арттыру, каучуклы культураларны дөрес урнаштыру һәм аларны үстерү агротехникасын яхшырту юлы белән натураль каучук җитештерү өчен чимал базасы булдырырга», — диелә.



*
* *

Тормыштагы төп максаты чынга ашмый калган, халыкка аз танылган, үз иленең чын гражданины һәм патриоты булган Б. В. Бызовның шәхесе мине бик нык кызыксындыра.

Ай, бу язмыш дигәнең! Кешене күңеле-җаны теләмәгән эшләр эшләргә дә мәҗбүр итә! Бик шәп экспериментатор, талантлы оештыручы Бызов каучукны аппаратлар ярдәмендә дә күп итеп җитештерергә мөмкин икәнен һәм бу хыялын ничек итеп чынга ашырырга кирәген бик яхшы белгән кеше, миллионлаган гектар җирдә каучуклы үлән үстерүчеләр сафына баса, «Табигый каучук» дигән хезмәт яза. Бызов Бызовка каршы эшли башлый! Нефтьтән каучук ясау идеясен күтәреп чыккан кеше башкаларны күксагыз, таусагызлар үстереп, шуларны эшкәртү ысулларына өйрәтергә керешә!..

Кешенең ни сәбәпле болай яки тегеләй эшләгәнлеген белгәннән соң аның мондый сәер яклары аңлашыла инде. Дөнья өстендә сугыш болытлары куера башлый. Илгә каучук кирәк. Шарты, вакыты җиткәч кенә түгел, хәзер кирәк!

Бызов, чын мәгънәсендә намуслы, бер үк вакытта галим дә, шагыйрь дә булган, хыяллана да һәм чынлыкны да күрә белгән бер кеше, тропик кояшы кыздырмаган салкын климатлы илдә яшәүче ватандашларын каучуклы итәргә теләгән. Җир белән күкнең серләрен ачарга җыенганда очраклы хәлләргә карап кына чикләнеп калмаганнар. Гомеренең соңгы елларында дан-шөһрәт өчен түгел, бәлки ватанына, халкына файда итү теләге белән хезмәт итә ул!

Мин Бызовның соңгы хезмәтен — бик күп саннар китерелгән, рәсемнәр төшерелгән, фикер-нәтиҗәләр әйтелгән берничә дистә битлек кечерәк бер трактатын укып чыктым. Фикере аның ачык, аңлаешлы, теле гади, сүзләре төгәл, нәтиҗәләре ышандыргыч. Каучуклы үләннәрне ничек үстерү, алардан ничек итеп сыек сагыз алу турындагы бу кулланманы укыган чакта авторның бу нәрсәләргә түгел, бәлки моның нәкъ киресенә ышанып яшәгәнлеген күз алдына да китерүе кыен.

1937 елда партиянең XVIII съезды: «Идел белән Урал арасында яңа нефть базасы — «Икенче Баку» төзергә», — дигән карар чыгара. Биш елдан соң илдә җир астыннан 54 миллион тонна нефть чыгарырга исәп тотыла. Түбән Кама шәһәренең нигезен сала башлаган елны исә Татарстан 52 миллион тонна «җир мае» чыгара.

Шуннан бирле ике дистә чамасы ел узып китте. Менә мин шул шәһәргә барам — анда торбалар аша нефть китертеп, ул нефтьтән ни теләсәң шуны ясыйлар.

Партиянең өч съездда — XXIII, XXIV һәм XXV съездлары документында иң мөһим төзелешләр рәтенә теркәлгән бик зур предприятие турында язам мин.

Тарих дигәнең, үз юлларында адашып йөреп, күп вакытын әрәм итүе өчен гафу үтенгәндәй, ашыгып хатасын төзәтергә керешә. 1938 елда капиталистик илләрдә ясалма каучукның чагыштырмача өлеше ярты процент булса, 1966 елда инде 63,6 процентка җитә. Сумгаитта, Стәрлетамакта, Волжскида, Яңа Куйбышевта һәм менә хәзер мин бара торган Түбән Кама шәһәрендә, спирт кулланмыйча, турыдан-туры нефть белән «Эска» заводлары эшли. Боларда күп эшне Бызов һәм аның коллегалары исәпләгәнчә башкармасалар да, барыбер реакторларга агач, күмер, ашлык яки бәрәң-

гедән куган спирт түгел, бәлки җир астыннан әзер килеш табылган «җир мае» салалар. Яңа буыннар яңа юлдан китәләр. Әмма бу хәл башлап юл салучыларның дәрәҗәсен бер дә төшерми.

...Менә, ниһаять, Кама буендагы Красный Ключ дигән пристаньга да килеп җиттек. Яр буенда — дебаркадер, тау башында — йортлар, су читендә агачтан бурап салган бер өй тора, шунда, үзенең күптән уйлап йөргән бер китабын язарга дип, Федор Иванович Панферов килергә җыенган булган дип сөйлиләр. Тауга машиналар такырайтып бетергән юл менеп китә.

Мин, «Метеор»дан төшкәч, өскә мендем дә әйләнеп карадым. Искиткеч манзара! Кама елгасының аргы ягында борынгы Алабуга каласы күренеп тора: бу якта — шәм кебек төз наратлар, шушы урманда атаклы рәссам Шишкин үзенең үлемсез картиналарын язган диләр. Нарат урманы артыннан инде, яңа бер картинадагы шикелле, биш, тугыз, ундүрт катлы йортлары белән зур шәһәр башлана...

## II. Хикмәтле ике бөртек

Комбинаттагы эш вахтам нәкъ төнге унбердә башланды.

Төн уртасы узгач, тынычрак булып калды. Аппаратчыларның төнге смена башлыгы Сәлимов миңа киенергә кушты.

— Өскә менәбез, җайланмаларны карап киләбез, — диде ул. Шуннан соң без тышка, колонна һәм эстакадалар яктысына чыктык.

Исламҗан Исәнбай улы Сәлимовка утыз җиде яшь. Исеме, фамилиясе, әтисенең исеме татарча булса да, мари ул, Кама аръягындагы татар авыллары арасында кысылып утырган Колтак дигән кечкенә генә бер мари авылында туып үскән.

Сәлимов бала чагыннан ук өч телдә сөйләшеп үскән, татарча да, марича да, русча да бик әйбәт белә. Татар кызына өйләнгән, хатыны Нәзирә исемле икән, шәһәрдә аларның өч бүлмәле квартирлары, ике кызлары бар.

Тәбәнәк буйлы, тар гына җилкәле Сәлимов колонна, батарея, торбалар арасында урмандагы тиен шикелле елт-елт итеп кенә йөри, әле янга кереп китә, әле торбалар астына чума, култыксага тотынып та тормастан, тар гына тимер баскычлар буйлап йөгерә.

Мин аягым таеп егылып китмәгәем дип куркам, Сәлимов артыннан җитешә алмыйм. Ул башын борып кына карый да туктап мине көтеп тора, шәм шикелле төптөз колоннага төртеп күрсәтә — колоннаның иң очында самолетлар бәрелмәсен өчен кызыл ут янып тора — бер-ике сүз белән генә бу колоннаның эчендә нәрсә барлыгын аңлата.

— Пентан молекуласында бер углерод атомы «үз урынында түгел», аны теземенең уртасына «күчерергә» кирәк, шуннан соң инде нәкъ безгә кирәкле әйбер — изопентан хасил була. Изопентаннан мономер дигән чимал алына, мономердан каучук ясала. Анда инде җылытып-суытып кына әллә ни майтарып булмый, ак алтын катализаторы белән эш итәргә кирәк. Бик кыйммәтле нәрсәкәй ул, бер тоннасы 28 мең сум тора, эшкә тотылган реактивны бөртегенә хәтле кире кайтарабыз. Катализатор ел ярымнан алмаштырылырга тиешле булса да, без аның бер салганын кырык сигез ай буе эшләтү хәйләсен таптык.

Ул бу хикмәтләр турында кешеләр дөнья яралганнан бирле эшләп килгән җир сөрү, иген үстерү, икмәк салу турында сөйләгән кебек итеп кенә сөйли.

Янәшәдә генә, калпак эчендә, газда шартламый торган лампочкалар янып торса, аста исә, бөтен әйләнә-тирәбездә, гаҗәп зур бер тере җан иясе шикелле, аһ-уһ итеп, сызгыра-сызгыра пар бөркеп зур комбинат эшләп ята, аның торба, батарея, колонна һәм реакторлардан торган тимер карыны эчендә кешеләр матди дөньяның иң кечкенә кисәкчәләрен бер урыннан икенче урынга күчерәләр.

Бу зур промышленность конвейерының башка заводларында нилэр эшләгәнен уйлап, аппаратчыларның ничек эшләүләрен күзәтеп торганда, шушы реакторлар эчендә, комбинат дигән зур бер җан иясенең тимер карынында, күзгә дә күренмәслек материя кисәкчәләре — атомнарның, берсеннән аерылып, икенчесенә кушылып, урыннарын алмаша-алмаша, өр-яңа матдә хасил итүләрен күз алдына китерергә тырышам.

Әкиятме бу, әллә чынмы? Әгәр икесе дә дисәк? Бүгенге Түбән Кама каласы,

екияттәге кебек, хыялдан үсеп чыкмаганмыни? Андагы оста аппаратчылар Менделеевның периодик системасында «це» һәм «һаш» хәрефләре белән билгеләнгән ике бөртек — углерод һәм водородтан әллә нинди хикмәтләр ясыйлар түгелме соң?

*
* *

Тирән җир астыннан табылган нефть белән эш итү, аннан яңа нәрсәләр ясау унсигезенче гасырда башлана бугай. Тарих өчен ике йөз ел ара, әлбәттә, вакыт дәрьясында бер ком бөртеге генә ул.

Дмитрий Иванович Менделеев химикларның әлифбасы булган элементларның периодик таблицасын ачканга чаклы бер гасыр элек татар старшинасы Надыйр Уразматов улы Йосыф белән, үз җирләрендә ике завод корып, җир мае куа башлыйлар. 1753 елда Надыйр Уразматов үзенең кәсебенә фатиха бирүне үтенеп, патша түрәләренә болай дип яза: «Шул урыннардан сынамак өчен ун кадак чамасы әлеге нефтьне алдык; шул кара нефтьне Берг-Коллегиягә кабул итеп, сынап каравыгызны вә үзебезнең җирдә нефть заводы корырга рөхсәт бирүегезне сорыйбыз...» Тарих бу фактны расларлык кайбер мәгълүматлар саклап калган булса да, әлеге корылманың сызымнарын да, Россиядә генә түгел, бәлки бөтен дөньяда бик сирәк булган әлеге эшнең техник регламентын да сакламаган. Аталы-уллы Уразматовлар «химия хикмәтләре» белән эш итә белә торган башлы кешеләр булганнар, күрәсең. Алар нефтьне кайнатып була икәнлеген, кара җир маеның парыннан бөтенләй икенче бер ак сыекча алып булуын төшенгәннәр.

Әлбәттә, Уразматовларның бу эше алдан уйлап планлаштырылмаган очраклы бер ачыш — табыш кына булган һәм билгеле бер вакыттан соң ул эшне бөтенләй онытканнар.

— Нефть ягу ул мичкә акча ягу белән бер, — ди Дмитрий Иванович Менделеев һәм нефть белән ничек эш итәргә кирәклеген өйрәтә: «Рус промышленникларына Америка капиталистлары белән бергәләп дүрт тиенлек нәрсәне биш сум байлыкка әйләндерергә өйрәнергә кирәк», — ди.

*
* *

Сәлимов сменасында дүрт кеше бер җайланмада, тагын дүртесе икенче җайланмада дежур торалар.

Смена башлыгының таянычы булган бик әйбәт, ышанычлы егетләрнең кемнәр икәнлеген ике-өч сүз белән генә булса да әйтеп китик.

Яңа җайланмада эшләүче аппаратчылар арасында иң яше Сережа Постнов дигән егет. Ул комбинатта эшләгән чагында армиягә киткән булган, срогы тулгач, яңадан биреә кайткан. Эшкә шәһәр читендәге Афанасово дигән туган авылыннан килеп йөри.

Аппаратлар янында тавыш азрак, куәтле аппарат шавын тәрәзә пыялалары, стеналар «йота», күрәсең. Колак салыбрак тыңлап торсаң, үзе яза торган шәмәхә каралы каләмнең, кыштыр-кыштыр итеп, графаларга бүленгән картограммаларга су, пар, чималның кая күпме китүен теркәп барганлыгын ишетәсең. Мин, берничә сүз белән генә, тормыш хәлләрен, эш шартларын, акча якларын сорашкаладым. Сережа Постнов, ап-ак тешле, яшь, чибәр егет:

— Тормыш ярыйсы. Мөңләгән халык, романтика эзләп, әллә кайларга юл тота, ә романтика минем үз өемнең ишек төбенә килде, — диде.

Иң зур стажлысы өлкән аппаратчы Евгений Галиевич Дагелаков. Моңарчы ул сигез ел Гурьев шәһәрендә «полиэтилен»да эшләгән, аппаратларда төрле пластмасса әйберләр ясарга ярый торган вак кына ак борчаклар «койган», чакыру белән Түбән Камага килгән, бер ел да бер айдан квартирлы булган, үз янына гаиләсен китерткән. Хатыны Галина Ивановна да колонналар янында, этилен комплексында эшли.

Икенче «цэгэфеу» блогы «техниканың иң соңгы сүзе буенча» җитештерелгән булса да, искесендә эшләве кызыклырак. Бирeдә күпчелек хатын-кыз, алар янында тәртиплерәк, пөхтәрәк-җыйнаграк буласың.

Насослар янында Дания Шәйхетдинова дежур тора. Дания сигез сәгать буе бер ялгызы. Берәр хәл килеп чыкса гына ярдәмгә килеп җитәләр! Ул кара чәчле, аз сүзле яшь кенә бер кыз. Аның әйтергә теләгән уйларын күзенә карап та белеп була. Бишенче разрядлы оста. Аннан да зуррагы алтынчы разряд кына.

Зоя Алексеевна Плешанкова Даниягә караганда өлкәнрәк тә, тәҗрибәлерәк тә. Әңгәмәләремнең иң күңелдә калганы Зоя Алексеевна белән сөйләшүем булды — бик аңлаешлы, истә калырлык итеп, бөтенесенә дә төшендереп сөйли белә.

Лев Николаевич Толстойның «һәркем үзенчә бәхетле» дигән сүзләрен беркадәр үзгәртебрәк, конкрет кешеләргә карата куллансӑң, бу кечкенә генә тату коллективның ике кешесе — Гайсин белән Әхмәдиев турында да шулай дип әйтеп булыр иде.

Рифгать Гайсин — озын буйлы, кара чәчле, кара күзле, елмаеп-көлемсерәп торган шат карашлы бер егет — гаиләләрендә үзен химия эшенә багышларга карар иткән берданбер кеше.

Өлкән аппаратчы Амундсен Әхмәдиев гаиләсендә яшәү бәхете, бер сәгатькә дә, хәтта бер минутка да аерылмыйча, гел бергә булуда дип саныйлар. Хатыны Мәгъдәния белән бергәләп — Мәгъдәниясе күрше цехта өлкән аппаратчы булып эшли — алар икәү бер сменага китәләр, бергә кайталар, ике кызларын күрше карчыгы янында калдырып торалар.

Сәлимов җитәкчелегендә эшләүче тугыз кеше — беренче буын химиклар. Татарстан җирендә самолет ясаучылар, нефть чыгаручылар, тукучылар, медиклар, укытучылар һәм игенчеләрнең ата-бабадан килгән династияләре бар. Ә нефтьче-химикларның әле һәркайсы җирдән, крестьян тормышыннан аерылып бетмәгән, күбесенең авылда әти-әнисе, туганнары, кардәш ырулары, дус-ишләре бар. Бу сыйфатлар Сәлимов сменасына гына түгел, бәлки молекула-атомнар-тылсымлы бөртекләр белән эш итүче әллә ничә мең кешелек бөтен коллективка да хас...

Хәер, Түбән Кама шәһәрендәге химикларның төп профессиясенә — нефтьтән каучук ясау, углерод һәм водородтан яңа матдәләр, яңа материаллар китереп чыгаруга нибары бер кеше гомере чаклы гына вакыт узган булгач, икенче, өченче буыннар каян килсен әле!

Татарстан җиренең бүгенге яңа һөнәре, кешеләренең яңа язмышы барлыкка килсен өчен дистәләрчә еллар узу, фәнни эзләнүләр, социаль үзгәрешләр кирәк булган.

*

* *

Борынгырак заманда кешеләр нибары 19 гына элемент кулланганнар. Унтугызынчы гасырда инде беренчел элементларның саны алтмыштан артып, шулар нигезендә кешеләр тормыш итү өчен кирәкле матдә һәм материаллар, аппарат һәм машиналар, йорт һәм биналар ясый башлаганнар. Алтмыш саны үзе әллә ни зур булмаса да, шулардан ясалган матдә һәм әйберләрнең исәбе йөз меңнәргә, миллионга җиткән.

Чиратка икенче бер бурыч — яңа химиянең бик күп яңа ачышларын куллану бурычы килеп баса — бу кадәр яңа ачышлар хәтта галимнәрнең үзләренә дә, оста тәҗрибәче һәм теоретик-белгечләргә дә, кеше аягы басмаган кара урман, ерып чыга алмаслык очсыз-кырыйсыз чытырманлык булып тоелган.

Казан университетында бөек Зинин углеводородтан анилин чыгарып яңа химиянең үсешенә юл биргән лабораториядә бөек якташыбыз Александр Михайлович Бутлеров гомум теоретик кагыйдәләрне ача, матди дөньяны үзгәртү өчен кешеләр кулына ачкыч тоттыра.

Бутлеровның кабере Түбән Кама каласы белән бер үк якта, яхшы такыр юлдан ике сәгатьтә барып җитәсең. Бутлеров туган, аның гәүдәсе җирләнгән утар үзе күптән юкка чыккан инде. Читтән автомобиль һәм һава юллары узган, совхоз конторына якынрак төштә ферма, мастерской, торак йортлар сала башлаганнар. Ялгыз кабергә укучы балалар килеп, чүп үләннәреннән чистарткач һәм киртәсен рәтләгәч, кабер тирәсе яңадан тынып кала. Анда яз һәм көзен генә ашлык чәчкән, иген урган трактор, комбайн тавышлары ишетелә.

Бутлеровның ялгыз кабере янында мин дә булдым, өч акбаш чәчкәсе өзеп кабере читенә куйдым. Тирә-юнь тып-тын, һавада әйләнә-әйләнә ялгыз бер тилгән генә очып йөри иде. Нишләп соң әле без бу бөек кешенең соңгы йортын истән чыгардык, аны тормыштан бер читтә калдырганбыз, аның кабере өстендә киртәсе белән балчык өеменнән башка бер һәйкәл дә юк, дип мин исәннәргә мөрәҗәгать итмәкче булган идем дә, аннары кире уйладым. Хикмәт кабергә нинди зурлыктагы таш куюдамыни? Хикмәт — синең васыятьләреңнең үлмәвендә, кешеләрнең шуны тормышка ашыруларында бит!

*

* *

Элек нефтьне эшкәрткән чакта карышуы, бирешмәве өчен аны «перум афинус» дип атаганнар — аның бу сыйфаты молекула атомнарының активлыгы аз булуын, иң зур көч-куәткә дә каршы тора алуын күрсәтә. Әмма аның атомнарын урыннарыннан күчерсәң, молекуласына берәр атом өстәсәң яки киметсәң, шул ук углерод белән водородтан бөтенләй икенче төрле матдәләр хасил була икән. Ике йөз градус кызулыкта нефтьтән бензин куалар, ике йөз кырыкта — лигроин, өч йөз унбиштә — керосин, өч йөз кырык биштә — дизель ягулыгы аерып алалар.

Кызулык мең градуслар тирәсенә якынлашса, иң югары тылсым — углеводородлар аерыла башлый. Болар башлангыч чималда берничә тамчы микъдарында гына була, җитен орлыгындагы май, чәчәктәге татлы бал суы шикелле генә. Монда кешеләр сыек чимал белән эш итмиләр, реакторларда материал буларак газ кулланыла, ә аеру коралы — махсус катализаторлар һәм эреткечләр.

Бутан газыннан, ике водород атомын аерып, бутилен китереп чыгаралар. Операцияне яңадан кабатлагач, дивинил, ягъни Бызов ясап күрсәткән сыгылмалы каучукка әйләнә торган нәрсә хасил була. Атомнарны аерып алып, химиклар теле белән әйтсәк, дегидридлап, пропаннан пропилен, этаннан этилен хасил итәләр, ә этиленнән инде җаның ни тели — шуны ясый аласың. Бөтен кирәккә дә ярарлык стирол, бензол, полиэтилен... Шуннан ары инде нефть белән турыдан-туры уртаклыгы булмаган байтак кына башка матдәләр, әйберләр, кушылмалар тезелеп китә: ефәк, кислота, спирт, шартлаткыч, мех, дару, хушбуйлар — болары исә үз нәүбәтләрендә яңадан йөзләгән, меңләгән, миллионлаган яңа комбинацияләр ясарга нигез була.

*

* *

Бүген — авыр вахта. Сәлимовның аңлатуынча, эчләрендә ике меңләп көпшәсе булган, көпшәләрендә туктаусыз пар, кайнар су йөреп торган аппаратларның капкачларын ачып, азот өрдерергә кирәк икән. Азот хәвеф-хәтәрдән саклау өчен кулланыла.

Шактый мәшәкатьле эш икән. Башта слесарьлар килде. Әхмәдиев белән Гайсин, приборларны Зоя Алексеевна Плешенковага калдырып, нинди дер нечкә, катлаулы бер клапанны алмаштырырга киттеләр. Аппаратларны япканда да шактый озак маташтылар, приборны урнаштыра башлагач, слесарьлар нәкъ кирәклесен китермәгәннәр, ялгыш алып килгәннәр булып чыкты. Эшне төн уртасы узгач кына башкарып чыктылар. Шуннан соң бер аппаратны ябарга керештеләр. Гайсин белән Әхмәдиев, кулларына бакыр йөгертелгән ачкычлар тотып, өскә менеп киттеләр, Зоя Алексеевна приборлар янында борчылып тора, Сәлимов, уклардан күзен алмыйча, эстакадага боерыклар биреп, микрофонда «утыра».

— Арттыр! Кимет! Артка чигер. Тагын бераз. Туктат! Нәкъ үзе! — дип кычкыра ул микрофонга, бөтен дикъкатен җыеп, прибор укларына карый, караңгыдан ишетелеп торган аппарат һәм торба тавышларына колак сала.

Профилактика ясаганнан соң, аппаратны җайланманың гомуми режимына кертүләрен аңлап алдым, бу эшнең беткәнен көттем, моны аппаратларның тавышы үзгәрүеннән сизәргә тырышсам да, берни ишетә алмадым.

Сәлимов ак микрофонны урынына куйды да: «Булды! Тәмам!» — диде. Бераздан аппарат бүлмәсенә, елмаешып, Гайсин белән Әхмәдиев тә килеп керде. Әхмәдиев

шунда аска, комлы ящик янына тәмәке тартырга төшеп китте, ә без аерым бүлмәдә чәй хәзерләргә керештек. Ак алюмин чәйнек алып килеп, шуңа бер пачка грузин чәе салдык, бер тартма шикәр дә табылды. Менә аппаратчылар, эчләреннән нидер уйлана-уйлана, тирләп-пешеп кайнар чәй эчәләр, ә үзләренең күзләре приборларда, аларның укларына карап, торбаларда һәм аппарат эчләрендә ниләр хасил булганлыгын, кеше күзенә күренми торган атом һәм молекулаларның нишләүләрен күреп-белеп торалар. Сөйләшүебез дә шул чәй эчүебез турында, ял итү рухында гына.

— Нишләп алай битең кызарган?

— Чәй эчәбез ич.

— Нигә синең муеның нечкә?

— Су эчкәнгә...

Әнә шулай беравыкка эшне онытып торып (тик барыбер онытылмый шул!) ял итеп алу рәхәт тә соң! Җәй көне печән өстендә авыл агайлары, чалгы селтәп арыгач, шулай ял итеп, тамак ялгап алалар. Өйләреннән алып килгән ашамлыкларын уртак табынга куеп, хәл җыеп, сөйләшкәләп утыралар, ә үзләре күзләре белән генә күпме печән чабылганын чамалыйлар, көннәр болай матур чагында, печәнне, шәт, чабып бетереп, кибәнгә дә куеп өлгерербез, дип уйлыйлар.

*
* *

...Түбән Кама каласының иң төп эше — углерод һәм водород дигән тылсымлы ике бөртектән әллә ниләр китереп чыгару һөнәре барлыкка килгәнгә әле нибары утыз ел чамасы гына. Түбән Кама шәһәренең үз яшеннән аз гына артыграк!

1956 елда С. В. Лебедев исемендәге Бөтенсоюз фәнни-тикшерену институты хезмәткәрләре СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты А. А. Коротков җитәкчелегендә нефтьтән стереорегуляр төзелешле изопрен каучугы китереп чыгаралар. Алай гына да түгел, бу яңа каучук табигатьнекенә бәрабәр булып чыга, кайбер сыйфатлары белән хәтта узып та китә — эссегә, салкынга, кислота, селтеләргә бирешми, моңарчы билгеле булган ясалма каучуклардан күп яктан өстенрәк була.

1963 елда Стәрлетамак шәһәрендә изопрен каучугы ясау буенча беренче тәҗрибә заводы салына башлый. Шуннан соңгы елда Тольяттида «эска» заводы сафка баса.

Аннан элегрәк, 1958 елның апрелендә, Кама аръягына «Госхимпроект»тан Л. Самошин җитәкчелегендә эзләнү-тикшерену партиясе килә.

1958 елның 23 июнендә Татарстан совнархозы председателе Алексей Тихонович Шмарев, Түбән Кама химия комбинатын төзүне юллаучы комиссияне раслап, боерыкка кул куя.

Бер айдан соң, 1958 елның 23 июлендә, КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы Татарстан совнархозы карамагында яңа төр пластмасса, синтетик каучук, синтетик сумала ясау өчен ярым продукт һәм башка ясалма материаллар эшләп чыгара торган ике зур предприятие төзү турында карар кабул итәләр. Якынча чыгымнары өч миллиард ярым сум итеп билгеләнә.

Түбән Кама төбәгендә төзү эшенә тиз керешәләр. Илебез эшкә шул кадәр күп акча тотарга тиешлеген белеп алына: нефтьтән тулысынча файдалану, куәтле техника, әр-яңа технологик процессларга нигезләнгән заводлар салу зур табыш вәгъдә итә.

Беренче керешкәндә үк бу эш моңарчы булмаганча бик олыдан башлана. Мәсәлән, Тольятти, Волжск һәм Стәрлетамактагы синтетик каучук заводлары, технологиясе ягыннан яңача хәл ителгән булсалар да, экономика һәм хуҗалык ягыннан искечә фикерләүгә нигезләнеп — әзер чималдан кирәкле продукт ясауга исәпләнеп төзелгәннәр. Кама елгасының аскы агымындагы территориаль-производство комплексы исә башта ук иң алдынгы тенденцияләрне чагылдыра — чимал чыганаклары тирәсенә зур заводлар урнаштырып, илнең көч-куәтен тизрәк үстерүне, кеше акылы ирешкән иң яңа идеяләрне тиз арада тормышка ашыруны күздә тота.

Түбән Каманың уникаль заводлары киң бер төбәкнең табигать байлыкларын зур табыш белән эшкәртергә, чимал чыганакларына, Идел, Кама, Агыйдел, Вятка кебек су юлларына якын булудан тулырак файдаланырга мөмкинлек бирә.

Түбән Кама комбинатының реакторлары башта ук нефтьнең һавага очып әрәм була торган фракцияләрен эшкә файдалануны күздә тотып төзелә.

Элегрәк мондый нефть «парларын» бөтенләй тотмаганнар. Тота алмаганнар. Тота белмәгәннәр. Андый мөмкинлек булмаган.

Уч төбегезгә бензин тамызып, шуны бераз һавага тотып торыгыз — ике-өч минуттан бензин кибеп юкка чыгар. Әнә шундый бик тиз оча торган җиңел фракцияләрне—газларны нишләтергә, ничек итеп «учта» тотып калырга, җир астыннан чыгарганнан соң, ничек итеп чаннарда, торбаларда, газ куу станцияләрендә чакта һавага очырмыйча, химикларның аппаратларына китереп җиткерергә? Югалту биш процент... Технология белешмәләрендә, экономик кулланма-күрсәтмәләрдә, котылгысыз дип, күпме табигый югалту теркәлгән. Шулай итеп, бик тиз реакцияләшә, ясалма әйберләргә төп төзү материалы булып хезмәт итә торган иң яхшы углеводородлар һавага очып әрәм була иде.

Түбән Кама каласында беренче «цэгэфэу» блогы 1967 елның 19 июлендә эшли башлый. Төзүчеләр Түбән Камадагы кайнап торган эш мәйданында шәһәр, комбинат төзегән, беренче йортларны салган, беренче колонналарны күтәргән арада, кара алтын якларында, унбиш мең квадрат километрга җәелгән кыр-урманнарда, нефть һәм газ кудыру аппаратларын, торбаларны әйбәтләп томалап, бикләп куялар, ягъни тоташ ябык бер системага әйләндерәләр. Моннан соң инде скважиналарны герметик корылма итеп кенә төзиләр. Шул ук вакытта тырыш нефтьчеләребез промыселларны автоматлаштыру, телемеханика, яңа идарә ысуллары һәм принциплары нигезендә җиһазлыйлар.

Хәзерге вакытта промыселларда ябык скважиналарга җыйган нефть парларының бер кубометрыннан җитмеш биш грамм җиңел фракция алалар. Махсус тотрыклау җайланмаларында исә бер тонна нефтьтән егерме килограмм чамасы тотрыксыз бензин алына — болар әллә ни зур саннар түгел, билгеле, әмма күпләп җыйгач, бу хәзинә зур бер гигант эшләрлек чимал була!..

Кичә генә һавага очкан җиңел газлар хәзер реакторлар һәм аппаратларга керә. Әкияттәге юктан бар булган хыялый манзара кебек, чын тормышта зур бер кала, аппаратлар, колонналар, заводлар үсеп чыкты! Тик шунысы гына кызганыч: без олыгая барабыз, бездән соңгы һәр буын исә ата-бабаларыннан күбрәк белә, мондый могҗиза белән генә аларны шаккатырып булмый инде.

Яктыра башлады. Кояш чыгышы ягында сирәк-мирәк болытлар алсуланып тора. Мин инде берни дә сорашмыйм, аппаратчыларның ничек эшләүләрен генә күзәтеп торам: үз эшләрен бик җитез, бик төгәл башкаралар алар, һәркайсы бер-берен сүзеннән генә түгел, күз карашыннан да, сулышыннан да аңлап тора.

Атом кебек, инә очыннан да миллионнарча мәртәбә кечкенә бер материя бөртегенең нинди хикмәтләр эшләгәнен приборларга карап кына белү, «це» плюс «һаш» билгесе белән языла торган углерод һәм водород дигән кечкенә генә ике матдә бөртегеннән әллә нинди гаҗәп әйберләр китереп чыгару өчен күпме укырга, күпме эшләргә, үз һөнәреңнең гаҗәп зур остасы булырга кирәк.

Таш осталары таштан һәм кирпечтән соклангыч йортлар, сарайлар салалар. Ә менә материянең «кирпечләре» булган атомнар белән табигать законнары нигезендә генә эш итәргә кирәк, шул чагында гына һәр атом, һәр молекула кеше теләгән урынга барып урнаша.

Химиклар санап караганнар: кечкенә генә бер су тамчысында 3 000 000 000 тан артык молекула бар икән. Әгәр шул бөртекләрне бер җепкә тезсәң, бу җепнең озынлыгы Кояш белән Җир арасыннан ике тапкыр озынрак булачак икән.

Аппаратчыларның талчыкканлыклары сизелсә дә, күзләре очкынланып ялтырый. Вахтаның бетеп килгәнен, озакламый яңа смена килеп җитәчәген һәркайсы белеп тора.

Мин бу кешеләр белән аерылышасымны белсәм дә, күңелемнән бер нәрсәне уйлап юандым: үз икмәкләрен көч һәм тир түгеп табучы, тырыш, сабыр бу һөнәр осталары минем исемнән тиз генә чыкмаслар. Буш хыял, әкият заманнары үткән булса да, мин әлеге кечкенә хикмәтле ике бөртектән әллә нинди байлыклар ясаучы бу кешеләрне шәрык әкиятләрендәге тылсымчы карт итеп күз алдыма китерәм.

*Дәвамы бар.*

# БЕЗДӘ КУНАКТА: КАРАКАЛПАК ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

*Башта Казагыстан АССР (1925 елдан), аннары РСФСР (1930 елдан) составындагы Каракалпак автономияле өлкәсе 1932 елның 20 мартында илебездәге хәзерге 20 автономияле Совет Социалистик Республикаларның берсе итеlә. 1936 елның 5 декабреннан бирле ул — Үзбәкстан ССР составындагы административ берәмлек. Аның Арал диңгезе белән Аму-Дәрья елгасы арасындагы чүл зонасына җәелгән һәм көнбатыштагы Кызылком чүллеге өстәлгән территориясе безнең Татарстаныкыннан, мәсәлән, ике ярым чамасы зуррак. Республикадагы бөтен халык саны, 1979 елгы исәп буенча, 904 мең. Шулардан каракалпаклар төркинең кыпчак-нугай төркемчәсенә кергән телдә укый-яза һәм сөйләшә. Хәзер алар илдә 200 меңләп санала.*

*Үзе үк болай да кырыс, сусыз, кайбер урыннарының хәтта исеме кот алгыч (мәсәлән, «Барсаң — кайтмассың» дигән түбәнлек!..) булган каракалпак җирләрен 16 гасырда Бохара, 17—18 гасырларда казакъ ханнары һәм солтаннары талап, үзләренә бәйле итеп-буйсындырып яшиләр. 1723 елда исә ул җирләргә гаскәр белән басып ук кереп җирле халыкны көньякта Ташкент һәм Фәрганә тирәләренә, төньякта Арал диңгезе, хәтта Иделгә чаклы качып күченергә мәҗбүр итәләр. 1743 елда шундый ук һөҗүм тагын кабатлана һәм каракалпаклар, инде Яңадәрьяга күчеп, чыгыр ярдәмендә сугару системаларын өр-яңадан корырга тиеш булалар... Менә ни өчен атаклы* шайыр *(шагыйрь) Җиен — җрау үз халкын «таланган халык» дип җырлаган, ә Кулмурат шуны ук комсыз һәм ерткыч байлар таласын өчен бер аягыннан бәйләп куелган «кызыктыргыч каз» белән тиңләштергән... Менә ни өчен 1722 елда ук инде каракалпаклар үзләрен Россия карамагына алуны үтенеп Петр I гә мөрәҗәгать итәләр һәм 1742 елда патшаның шундый грамотасы эшләнә дә. Әмма, Россиядән гаять еракта булудан файдаланып, шул ук җирләрне 1811 елда Хива ханлыгы басып ала һәм хәтта аны бөтенләе белән Төркиягә бирергә җыена. 1873 елда рус гаскәрләренең Хивага походы гына милли үсеше тәмам тоткарланган каракалпакларны үлем белән тиң бу бәладан коткарып кала, җирләренең Россиягә өлешчә кушылуына китерә...*

*Бөек Октябрьга чаклы яшәгән бу ярым күчмә халыкның биштән бер өлеше диярлек бөтенләй җирсез була, нибары 0,6 проценты гына укый-яза белә.*

*Хәзер исә Совет Каракалпакстанында мамык һәм люцерна чистарту, металл һәм агач эшкәртү, кием тегү комбинатлары шаулап эшли, Кызкөткән һәм Пахтаарна исемле сугару каналларының йөз меңнән артык гектарлы зонасында күпләп дөге, кенаф, джут һәм кавын үстерелә, елга-күлләрдә һәм Арал диңгезендә күпләп балык (бөтен Үзбәкстанда тотылганның 98 проценты!) тотыла, атаклы карабаир токымлы атлар, каракүл сарык, ондатра һәм ефәк корты үрчетелә. Калын катламнар һәм тирән ятмалардан мрамор, гранит, кварцит, гипс кебек төзелеш материаллары, төсле һәм сирәк металлар рудасы, тоз алынган җирләрне тимер, асфальт һәм таш юллар челтәрли, Тахиа-Таш, Чимбай, Ходжейли, Кунград, Чалыш кебек яшь һәм яңа калалар елдан-ел матуррак итеп бизи!*

*Каракалпак дусларыбызның якты һәм көр тавышлы поэзиясе дә төсләргә әнә шундый бай, хисләргә әнә шулай мул хәзер. Чөнки ул буыннан буынга күптәннән күчә килгән бетмәс-төкәнмәс рухи хәзинә җирлегенә — иллегә якын эпос (егерме биш меңнән артык юллы «Кырык кыз», «Алпамыш», «Коблан» һ. б.) һәм лирик-эпик поэмалар («Маспатша», «Гарип-ашык» һ. б.) җирлегенә тирән тамыр җәеп үскән һәм үсә.*

*Халык хакын «Чабаннар» һәм «Уракчылар» кебек ялкынлы әсәрләрдә яклаган Көнхуҗа (1799—1880), халыкка тирән мәхәббәт белән «Башбаштак патша», «Налог» кебек шигырь һәм поэмалар язган, халыкның изүчеләргә һәм баскыннарга каршы хәрәкәтендә катнашкан Бердах (1827—1900), динчеләр һәм байлар дуамаллыгын, социаль тигезсезлекне рәхимсез сатира белән фаш иткән Отеш (1828—1902) һәм Омар (1879—1922) кебек классик поэзия вәкилләре үрнәген һәм традицияләрен бүгенге шагыйрьләр яңа заман шартларында баеталар.*

*Бу поэзиядә Ленин, партия, халык вәкиле образларын милли төсмерләр белән уңышлы чагылдырган һәм шигъри планда камил хәл иткән төрле буын шагыйрьләренең поэмалар язу тәҗрибәсе игътибарга лаек. Моңа мисал итеп Нурымбетов «Бахтиар»ын, Дабилов «Баһадир»ын, Дарибаев «Айпара»сын, Йосыпов «Укытучы»сын китерү дә җитәр кебек.*

*Каракалпакстанның инде май аенда ук башлана торган челләсендә миңа да тирләргә туры килгәне бар. Әдәби кичәләрдә халык шагыйре Аймурзаев Җалморза Мурзай улы белән дә чыгышлар ясадык. 1955—1956 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда бергә укыганда каләмдәшләр һәм шәрикләр буларак чын күңелдән дуслашкан һәм бик якыннан аралашкан идек. Күп милләтле совет әдәбиятының үсеш юлында ул куя, ул кабыза алган маякларны да хәзер инде куанып санап була: «Аму-Дәрья ярларында» — роман, «Көрәш», «Без көрәштә җиңдек», «Таня», «Якты юл» — поэмалар, «Бердах», «Уз таягың белән үзеңә», «Айгөл белән Азат», «Раушан», «Сөекле докторыбыз» — пьесалар. Ә шигырьләр, очерклар, публицистик язмалар һәм тәрҗемә китаплары?*

*Быел август аенда Каракалпак АССРда татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы үткәрелә. Киләсе елда исә шундый ук иҗат сабан туе — халыклар дуслыгы бәйрәмендә безнең республикага каракалпак дуслар киләчәк. Түбәндәге шигырьләр бәйләме хөрмәтле укучыларыбызга шул очрашуларның беренче карлыгачлары буларак тәкъдим ителә.*

**ЗӘКИ НУРИ.**

# Кармыс Досанов

## Туган туфрак

Аму-Дарья буйларының җирен күптән
Алтын дигән исем белән йөртә халык.
Алтынмы ул, әллә алтын түгел микән —
Белим дисәң, карыйк әйдә учка алып.

Бер уч туфрак алдың менә, учта күпме
Хәзинә бар — санау өчен айлар җитмәс.
Бу кырларда байлык белми икне-чикне,
Чәчәк аткан тирә-юньгә күз сал, иптәш!

Күр син әнә күз иңләмәс диңгез булып
Киң җәелгән мамык кырын — ак алтынны.
Күр син әнә алма пешеп, хөрмә тулып
Торган чакта бакчадагы саф ялкынны.

Һәм күз сал син алтын бодай үскән төшкә,
Тук башаклар йөге авыр — иелә сабак.
Бу туфракка язын бөртек дөге төшсә,
Көзләр сиңа меңләп бөртек бирә санап.

Яшел ефәк эскәтере киң басуның
Тукранбашның ал чәчәге белән чиккән,
Хәтерләтеп язгы ярсу, зур ташуны
Әнә киндер кыры шаулап күренә читтән.

Бу туфракта гөлләр үсә — гөл — җир яме! —
Бу туфракта агач ефәк бирә ала...
Алтын һич тә бирә алмый җир биргәнне,
Алтыннан кем мондый байлык күрә ала?!

Шундый безнең туган туфрак! Муллыкны ул
Шулай бирә — тик түгелсен тәнең тире.
Безнең кебек эшлекле һәм булдыклы ул,
Алтыннан да кыйммәт безнең дала җире.

## Ибраһим Йосыпов

### Тургай улеме

Канатларын җәеп өнсез-тынсыз ята
Кыргый әрем арасында, киң далада.
Бар дөньяга көмеш аваз сибә-сибә
Зәңгәр күктә оча алмас ул яңадан.

...Ул сыена иде җиргә, тыңлагандай
Яшәешнең мәңгелектән килгән сүзен.
Һәм атыла иде аяз киңлекләргә
Биеклекнең җаны итеп тоеп үзен.

Ә түбәндә — язгы дала, төс бәйрәме!
Гөлләр тибри җылы җилдә, уйный кылган,
Ә ул сайрый онытылып-онытылып,
Нәкъ салават күперенә кунган сыман...

Сокланды ул якты, иркен бу дөньяга,
Балкып торды күк гөмбәзе саф моңнардан,
Тынып калып аның җырын тыңлый әнә
Дала күрке — кыюсыз һәм нәфис җәйран.

Чылтыраудан туктап калды гүя чишмә,
Кылганнар да хәтта тынып калды төсле...
Тыңлый дөнья! — күккә менеп җырлый бүген
Җир илчесе, яз илчесе, ямь илчесе!

Бар дөньясын онытты ул сайрый-сайрый,
Тик куерды кара болыт, күкрәде күк.
Ялтырады ялтыр яшен! Егылды кош...
Һәм үлде җыр... Бөтен дөнья тетрәде күк!

Үлде җырчы... Кара көйде кыргый әрем,
Сыкранды җир, үксеп гөлләр бакты күккә.
Һәлак булды... Тик өлгерде соңгы җырын
Күтәрергә күз камашкыч биеклеккә!

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәсе.

## Җалморза Аймурзаев

### Казан утлары

Якты дөнья биреп изелгән җанга,
Юл күрсәтеп михнәт чиккән Ватанга,
Кояш булып балкыды бар җиһанга
Ильич яклары,
Казан утлары.

Ил яшәрде, эреп җирнең туңнары,
Елгалары ирек җырын тыңлады...
Сездә атты Кокушкино таңнары,
Ильич яклары,
Казан утлары.

Күбекләнеп тора бакча гөлләре,
Тауларының айдай якты йөзләре,
Ленинның Казанда булган көннәре —
Өмет байраклары.

Һәр таш саклый бөек Ленинның эзен,
Киләчәккә төбәп романтик йөзен
Дәвам итә бүген дә аның эшен
Ильич оныклары.

Чишмәләр, болаклар бергә берләште,
Елга булып, диңгез булып сүз дәште.
Каракалпак иленә дә нур чәчте
Ильич яклары,
Казан утлары.

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ тәрҗемәсе.

## Бабаш Исмәгыйлов

### Туган авылым

Чәчәк ата күңелем язгы кырдай
Авылым искә төшкән чагында.
Җыр дулкыны, ярсу Аму сыман,
Йөрәк ярларыма кагыла.

Авылымны минем хәтерлидер
Тагын бик күп кызлар-егетләр.
Бала чакның якты хыяллары
Белән алар шунда береккән.

Беренче кат тәпи басып киткән
Ак сукмаклар ничек онытылсын.
Пакь төшләргә керә ак сукмаклар,
Җанны назлый рәхәт сер, тылсым.

Әткәм-әнкәм тукыган келәм кебек
Балкыйсыз сез, туган кырларым.
Гомерем буе сезне сагынырмын мин,
Гомерем буе сезне җырлармын.

Кайчан гына кермим бакчаларга,
Язларынмы, җәен, көзенме —
Шау чәчәккә күмелеп утырган бер
Агач итеп тоям үземне.

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Байнияз Каипназаров

### Алмачуар чаптарым

Хәтеремдә: «Батыр бул!» — дип,
Атым сөйгән чакларың.
Яудан исән алып чыкты
Алмачуар чаптарым.

Чаптарымның күкрәге киң,
Йолдыз төсле күзләре.
Атка менми, яуга керми
Егет җаны түзәрме!

Җилдә сибелә яллары —
Гүя кызлар толымы.
Уктай оча, белә чөнки
Минем барыр юлымны.

Бар атларны узып чаба,
Чаба алга, яктыга.
Ике тамчы судай охшаш
Ул Чапаев атына.

Чабышларда һәрвакытта
Ул тик беренче килде.
Дошманнарны җиргә екты
Яшен уты шикелле...

Онытылмас Ватан өчен
Утка кергән чакларым.
Мең үлемнән алып чыкты
Алмачуар чаптарым.

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** тәрҗемәсе.

## Халмурат Сапаров

### Вакыт уза

Кемнәр анда эшсез ята?
Вакыт көтеп торалмый.
Узып киткән вакытларны
Беркем кире боралмый.

Уен-көлке, күңел ачу
Ялкауны кызыктыра.
Без эшләрне эшләп калыйк —
Вакытлар узып тора.

Мәктәпләргә дәшә вакыт,
Шигырьләр ятлаттыра.
Вакыт көтеп тора белми —
Гел алга атлап тора.

Ялынсак та китә вакыт
Киләчәккә туп-туры.
Китә ул хәлсез бабайга
Таягымны тоттырып.

Кояш көлә, нурлар уйный...
Маңгайга сырлар сызып,
Акрын гына, тып-тын гына
Вакытлар бара узып.

Гомер уза. Авыз ачып
Калабыз без еш кына:
Вакыт — алтын кош шикелле
Кулыбыздан ычкына.

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Толымбай Кабулов

### Далада таң ату

Киң далага чык син иртән —
Күктә сүнгән
Йолдыз, кара, чыкта кабына.
Уяналар әнә иркә гөлләр —
Күзен ача алар сак кына.

Таң атканда һава ярау, алсу,
Сихри төсләр анда тирбәлә.
Үзенә җыеп могҗизасын, чынын,
Кояш нуры сибелә түбәгә.
Әй яктырды дала, күңел — нурлы...
Шуннан менә үзе кабынды
Кояшкай — кызыл күбәләк ул гүя —
Җирне назлап, аңа кагылды...
Фикер килде миңа — Кояшлы уй,
Ягымлы һәм җылы... Әз генә
Тирбәлде дә саксаулны кочты,
Киң далага очты... Һәм менә
Нигез булып ул ятарга булды
Көндез язылачак шигъремә!

**БИКӘ РӘХИМОВА** тәрҗемәсе.

## Хуҗабәк Сәитов

### Безнең яшьлек

Кадерлем, безнең чәчләр дә чаларды,
Күпме язлар үтеп, ничә көз керде.
Картайсак та күңел һаман яшәреп
Гомерләргә кәүсәр суы бөркелде.

Гомер уза диеп берүк кайгырма,
Елларның ул безгә бәхет бирүе...
Уза вакыт... Безнең белән юл уза,
Уза вакыт. Вакыт — йөрәк тибүе.

Тибә йөрәк заман белән бер булып,
Ул кысыла узганнарга таң калып.
Бәхетле картлыкка илткән яшь гомер
Үзе олы вакыт икән — аңладык.

Бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй,
Илһамланган чагы азмы бәгырьнең.
Мәхәббәтем сиңа арткан шикелле,
Яшәүгә дә сөю арта, кадерлем.

Син үкенмә, безнең яшьлек бүген дә
Дәвам итә, юлларга тау-таш яра...
...Кеше булып яши алу — яшьлек ул!
Шул бәхетне кабатласын башкалар.

**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ** тәрҗемәсе.

## Галим Сәетназаров

### Дала кешеләргә гашыйк

Кешеләрдән башка дала кыргый,
Эчпошыргыч тавыш белән улый,
Наз күрмәсә, ялгызым, дип уйлый —
Дала кешеләргә гашыйк!

Аксакаллар белән уйчан булса,
Яшьләр белән шаян ул яшьләрчә,
Яшәгән саен ул гел яшәрә —
Дала кешеләргә гашыйк!

Иркен күкрәгендә кояш көче,
Байлыгы исәпсез, көләч йөзе,
Хәзинәсен бирә, юмарт үзе,—
Дала кешеләргә гашыйк!

Назлап сөя, бергә сынау үтә,
Кайгыртучан ана — Дала көн дә
Үз уларын яшәргә өйрәтә —
Дала кешеләргә гашыйк.

**БИКӘ РӘХИМОВА** тәрҗемәсе.

## Дәүләт Әетморатов

### Хыялда уйлану

... Ә каршымда еллар биеклеге,
Иң өстемнән кага болытлар.
Тауга карап мин дә тау булдым, дип
Горурлана торган минутлар.

Басып торам. Чиксез диңгез булып
Аста ята киңлек — гел зәңгәр!
Упкыннарны, чоңгылларны үтеп
Чыга алсаң көтә үзәннәр.

Максат кына булсын, кодрәт җитә...
Үзебездән тора калганы...

Дулкынланып еракларга дәшә
Кыяларның кырыс яллары.

Язмыш биеклеген әнә шулай
Кодрәт белән аласы иде,
Кешеләргә изге эшләр эшләп
Киләчәккә барасы иде.

... Алынасы азмы биеклекләр?
Салмак кына агыла болытлар.
Тауга карап тау булырмын, диеп
Дулкынлана торган минутлар.

**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ** тәрҗемәсе.

## Таҗетдин Сәетҗанов

### Бер карасам...

Бер карасам, елмаясың, көләсең,
Охшагансың минем сөйгән ярыма.
Бер карасам, моңаясың, сызасың, —
Охшагансың минем сөйгән ярыма.

Бер карасам, син кунаклар җыйгансың,
Бер карасам, инде ялгыз калгансың.
Һәм тагын бизәнгән-ясангансың, —
Охшагансың минем сөйгән ярыма.

Бер карасам, ыгы-зыгы киләсең,
Бөтен җирне син гөл итеп куясың.
Бер карасам, сагыш, моңны юасың, —
Охшагансың минем сөйгән ярыма.

Бер карасам, җырлыйсың да көләсең,
Бер карасам, эндәшмисең, сүрәнсең.
Яки үзең үгет, киңәш бирәсең —
Охшагансың минем сөйгән ярыма.

Бер карасам, Гүлайымдай [1] кыяфәт:
Уйлыйм җиргә килгән әллә бер афәт?
Ә балаңа синдә бөек мәхәббәт! —
Бигрәк охшагансың сөйгән ярыма.

**БИКӘ РӘХИМОВА** тәрҗемәсе.

## Җолдас Сәетназаров

### Ана

Кырау төшкән әткәм чәчләренә...
Көмеш кунган әнкәм толымына.
Тик күзләре якты нур чәчәләр
Сөеп баккан чакта улына.

Карашлары аның шундый назлы,
Әмма сагыш-моң да бар анда.
Язмышымны юрап төн йокламый,
Әйтерсең мин сабый һаман да.

Ул үпкәндә минем маңгаемнан,
Күрше кызының тавышын ишетәм:
«Биләүдәге бала булды инде...
Мәңге төшмәс, ахры, бишектән!»

— Күгәрченем-күршем, ил тоткасы
Булып җиргә туган балалар
Буйга җитсәләр дә ... ана өчен
Барыбер сабый булып калалар.

... Юлда тоткарланып, эштән тагын
Соңга калып кайтам бүген дә.
Нарасыен көтеп торган кебек
Көтә әнкәй капка төбендә.

**РӘШИТ ГӘРӘЙ** тәрҗемәсе.

## Толепберген Матмуратов

### Әйтә идең

Чәчләреңә гөлләр кадасам,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, ялгыз бакчада
Минем белән нигә каласың?

---

[1] Каракалпак халкының «Кырык кыз» дастаны героинясы исеме.

Йөзегеңне куйсам яшереп,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, язган хатымны
Түш кесәңә нигә саласың?

Иңнәреңә кулым куйганда,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, мине күрүгә,
Алсу йөзең нигә яна соң?

Иреннәрең балын эчкәндә,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман җирдә гөлләр үсәме? —
Йөрәгемдә йөрткән лалә син.

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе.

## Аяпбиргән Сейтеков

●

Карт ямансу, моңсу караш белән,
Өмет белән юлга текәлгән.
Яшь яшәлгән юкса, эшләр беткән,
Теләкләрнең барсы үтәлгән...

Карт өянке нидер сөйли аңа,
Карлыгачлар күккә атыла.
Вакыт — кырыс, вакыт — шундый
җитез,
Карамыйча чаба артына.

Каршысына килгән үсмерләргә
Текәлепләр карап кала ул.
Мөгаен, шул үсмерләргә карап,
Яшь чакларын искә ала ул.

Чыңлап килгән шат авазлар тыңлап,
Күңелләре аның туладыр.
Ерак калган яшьлек аһәңнәре
Кабат кайткан кебек буладыр.

Җитез җилләр исә, ә ул белә
Искән җилләр кире кайтмасны.
Шуңа күрә ак канатлы җилләр
Тетрәндереп куя картлачны.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Атахан Хоҗанбаев

### Яратам мин

Яратам мин туган җир күгендә,
Баш өстемдә яшь ай туганын.
Якын дусларымның тугры сүзле,
Акыллы һәм зирәк булганын.

Яратам мин сусыз далаларны
Мамык кыры иткән ирләрне;
Өй түрендә шаян, чандыр улым
Чыр-чу килеп уйнап йөргәнне.

Яратам мин илгә кунак килсә,
Ихлас зурлап каршы алырга.
Бәйрәмнәрдә дуслар хөрмәтенә
Җыр куярга мәҗлес-табынга.

Яратам мин илнең һәрбер таңы
Гел үзенчә матур булганны;
Без көн иткән Җирне киләчәккә
Илтә торган олы юлларны.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәсе.

## Базарбай Казакбаев

### Берсе үҗәт, берсе кире

1

Арып-талып эштән кайта,
Тик көтми аны табын.
Колагына иелә дә
Пышылдый карчык тагын:
— Әбәү, улым, ничек түзим?
Хатының бигрәк явыз.
Кашык шалтыратканга да
Чыгара, мөртәт, тавыш.
Каргасам — каргышым төшәр,
Еласам — күз яшьләрем;
И ходаем, күпме шулай
Газап чигеп яшәрмен.
Күршеләргә, аждаһа, дип
Хурлаган мине әнә.
Аер, улым, шул кәнтәйне,
Хатын бетмәс дөньяда.

2

Икенче яктан килә дә
Пышылдап әйтә килен:
— Белмисең лә хәлләремне,
И минем газиз ирем.
Бу кадәр дә игелексез
Каенана булыр икән,
Җитте, җаным, түзә алмыйм,
Аерылам синнән, китәм.
Ничек ди бит: янәсе, мин
Сине харап иткәнмен.
Имеш, мин гайбәт капчыгы,
Юха елан икәнмен.
Мондый хәлләрдән соң иплэп
Бала үстерү кайда?!
Гарык булдым!
Я — ул, я — мин,
Икенең берен сайла!..

3

Каенана карт, ләкин үҗәт,
Килен яшь, ләкин кире.
Ананың бердәнбер улы,
Хатынның бердәнбер ире
Ни үле дә ни тере.

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Әбдирәзәк Сәетҗанов

### Балалар өчен ике шигырь

**КЕМ БУЛАСЫҢ!**

— Ә син үскәч кем буласың? —
Дип сорыйбыз Ыкластан.
— Очучы булырга телим, —
Ди ул безгә ихластан.

Шулай дигәч, елышабыз
Ыкласның янына без:
— Самолетыңа безне дә
Утырт, — дип ялынабыз.

**СОРАУ**

Әтисе бик күпне белә.
Сорый улы аңардан:
— Укытучыбызның чәче
Ник шул кадәр агарган?

— Әйе, укытучыгызны
Һәммәгез яратасыз.
Тик нигәдер ул чәчләрне
Күбрәк сез агартасыз.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәләре.

# ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ СОРЫЙ

*Журнал каршында байтак еллар инде яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге эшләп килә. Анда әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләргә омтылышы булган бер төркем яшьләр, студентлар йөри. Яшь тәнкыйтьчеләр өлкән әдипләр, күренекле тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре белән очрашалар, үзләренең беренче иҗат тәҗрибәләрен укып тикшерәләр, аерым темага багышланган бәхәсләрдә катнашалар. Түгәрәкнең төп максаты, әлбәттә, әдәбиятны сөюче яшьләр арасыннан тәнкыйтьчеләр эзләү һәм аларга конкрет ярдәм, юнәлеш күрсәтү. Соңгы елларда республикабыз газета-журналларында яшь тәнкыйтьчеләр авазы торган саен ышанычлырак ишетелә бара икән — бу үзе зур куаныч түгелмени.*

*Бүген укучыларыбыз игътибарына әлеге түгәрәккә йөрүче берничә яшь авторның мәкалә һәм рецензияләре тәкъдим ителә. Алар кыскартып басыла һәм, әлбәттә, ул язмаларга әле кайбер кимчелекләр хас булуы да яшерен-батырын түгел. Шуңа да карамастан, яшь тәнкыйтьчеләрнең иҗади эзләнүләре игътибарга лаек дип уйлыйбыз.*

**РЕДАКЦИЯДӘН**

# МАТУРЛЫКНЫ КҮБРӘК КҮРЕРГӘ

Салават күперендәге төсләр балкышыдай, кеше хисләренең дә үз палитрасы бар. Шигъри әсәрдә ул хис-кичерешләр дөньясы яңадан ачылгандай була.

Рәшит Гәрәйнең «Үзеңә чакыр мине» дип исемләнгән яңа җыентыгын[1] укып чыккач, күңелгә әнә шундый уй килә. Бу китап шагыйрь иҗатының мәгълүм бер чорына йомгак, шигърият гөленең чәчәге-таҗы сыман. Иҗатына аның нинди сыйфатлар хас, заман белән бергә атлыймы ул? Шул сорауларга җавап эзләгәндә, Р. Гәрәй поэзиясенә хас бер үзенчәлек ачыла: күңел бишегебез булган табигатьне һәм авыл тормышын сурәтләү аның иҗатының үзәген тәшкил итә. Авыл — шагыйрь өчен бала чак бишекләсе гына түгел, ул аның яшәү мәгънәсе, рух чишмәсе дә. Шуңа күрә «төйгән мәк шикелле чем-чем кара» туфрак хакында язылган шигырьләр укучы күңеленә дә якын, кадерле.

**Уҗымнарым, бергә булсак та без,**
**Кирәк чакта аерым булсак та, —**
**Сулышыбыз бер үк туфракта ич,**
**Язмышыбыз бер үк туфракта.**

Шагыйрь изге туфракта игенченең уңганлыгын, юмартлыгын күрә, аның хезмәтен тарихи җирлектә, үткәннәр белән бәйле рәвештә сурәтли. Бу шигырьләрдә еш

[1] Р. Гәрәй. Үзеңә чакыр мине. Шигырьләр. Казан, 1979 ел.

кына лирик герой алгы планга чыга, ул сүз ала. Күрәсең, бу үзенчәлек авторның үз иҗатын тормыштан, халыктан аерым күрә алмавына бәйләнгәндер. Шагыйрь гади хезмәт кешесенең күңел хәзинәсен ачуга әнә шулай ирешә.

Р. Гәрәй шигъри фикерне сурәтле итеп ачу өчен төрле чаралардан иркен файдалана. Хезмәткә, җиргә мәхәббәт турында сөйләүче «Васыятен дә әйтеп калдырмаган» дигән шигырь бу яктан аеруча характерлы. Тыйнак кына чагыштырулар, төгәл детальләр яшәешнең мәңгелек тамырларын гәүдәләндерәләр.

**...Гыйлаҗ бабай кичтән күзен**
**йомган.**
**Мәңгелеккә йомган бу юлы.**
**Васыятен дә әйтеп калдырмаган, —**
**Тел яшерсән гүя барсыннан.**
**Серкәләнгән тик бер учма арыш**
**Чыкты аның мендәр астыннан.**

Шагыйрь иҗатында шатлык һәм кайгы, нәкъ тормыштагыча, бер-берсенә кушылып, бер-берсен алыштырып киләләр. Кешеләрне ныграк яраткан саен, ул аларның язмышы турында ныграк уйлана, алар күңелендәге матурлыкны күбрәк күрергә омтыла. Мөгаен, шуңа күрәдер, бу шигырьләрдәге тирән кешелекле хисләрне чагылдыручы ана образы укучының игътибарын аеруча җәлеп итә. Әнисеннән шагыйрь йөрәгенә җыр һәм моң, бакчадагы чәчәкләргә матурлык һәм тыйнаклык күчкән, ә зәңгәр төнгә ана күзләрендәге моңсулык калган. Улына тегеп биргән тәүге күлмәк Ык суында юа-юа тузып беткән булса да, аның җылысы күңелдән китми.

**Төшләремдә сине күрүләрем**
**Ул сагынуны нишләп басмый соң!**
**Калын көртләр дә юк... Капкабызны**
**Ник соң, әнкәй, үзең ачмыйсың!!**

Баксаң, әнисе өч ел элек өеп куйган мендәрләр дә шул килеш тора икән. Көн җылы булса да, ул бәйләгән бияләйләр кулда булмагач, йөрәккә салкын, күңелгә моңсу. Әнисе белән кайгыларын, эч серләрен уртаклашкан минутларда шагыйрь гаять кешелекле, саф күңелле булып күз алдына килә.

Иң матур сүзләр белән дә әйтеп аңлатып булмастай яшьлек хисләрен дә шагыйрь тыйнак һәм сокланып сурәтли. Яшьлекнең кадерен белергә, матурлыгын аңларга, олы хыялларга тугры булып калырга чакыра ул.

**Безне көткән тын күл өсләреннән**
**Очып әйләнәләр ят кошлар.**
**Әллә безнең бергә чагыбызны**
**Эзләп китте микән аккошлар.**

Еллар узган, олыгайган саен яшьлекнең гүзәл мизгелләре күңелгә якыная бара. Сөю хисе тормышны гына түгел, кешеләрне, хәтта язмышларны да үзгәртә. Яшьлекнең үз югалтулары һәм табышлары булмаса, ул шулкадәр матур, серле булып яңгырый алмас иде.

**Үзләренә җавап язылмаса,**
**Саргаялар икән хатлар да.**

Шигырь никадәр генә үкенечле яңгырамасын, аның асылында яткан фикер матур: җир йөзендә лирик герой белән кулга-кул тотынып, янәшә атларлык бер гүзәл бар. Дөньяда шундый зур мәхәббәте булган кеше — бәхетле. Шагыйрь безне әнә шул хакыйкатькә алып чыга.

Укучының шагыйрьгә ихтирамы никадәр зур булса, таләбе дә шуңа нисбәтле арта. Р. Гәрәй поэзиясенең гомуми торышы, үсеш тенденцияләре турында уйланган-

дә, анык уңышсыз яклары урынлы борчылу тудыра. Шагыйрьнең барлык шигырьләре дә бер тында язылмаган, ул эшләнеп, уйланып бетмәгән әсәрләрен дә бастырып чыгаргалый. «Туган җирен кем дә онытмый», «Синең мәхәббәтең хакында» кебек укучыны дулкынландырмый торган, узгынчы хисләргә генә корылган шигырьләрнең очравы шуны күрсәтә. Аларда шагыйрь үзенең туган ягына кайткан, якса аннан кире киткән чагын тасвирлый. Ник китә, кая китә, максаты нидән гыйбарәт? Сәбәбе нәрсәдә? Анысы сер булып кала.

Вакыт-вакыт капма-каршы мәгънәле фикерләр дә очрап куя. Мәсәлән, бер шигырендә Р. Гәрәй заманыбызны сокландыра торган батырлыклар хакында сөйләргә омтыла:

> **Миллион еллар тып-тын**
> **яткан Галәм**
> **Ишетә тагын кеше тавышын...**

Кешенең галәмне үзләштерүенә сокланып язылган бу юллар артык гомуми, риторик характерда. Шигырьне укып чыккач, космонавтлар шулай безне сокландырыр өчен якса күктән торып сөйләшер өчен генә космоска күтәрелделәрмени дигән сорау туа.

Тулаем алганда, Р. Гәрәйнең күпчелек шигырьләре мәгънәви бөтенлеге, үзәк өзгеч моңы белән әсәрләндерә, бер ишетүдә үк отып калган көй-моң булып күңелдә йөри:

> **Балыкчы карт быел соңгы тапкыр**
> **Шул таллардан чишә көймәсен...**
> **Чал табигать салкын кышны көтә,**
> **Алдан тоеп язлар киләсен.**

Шагыйрьнең укучы күңеленә юл-ачкыч табу сере шунда: ул бер-берсенә капма-каршы булган күренешләрне тасвирлаганда да ак-карага гына бүлми, тормыштагы күп төрле бизәкләрне, авазларны күз алдында тота. Яшәү ямен аңлау — дөньядагы уңай күренешләрдән генә тәм табу дигән сүз түгел. Караңгылык турында язганда да шагыйрь яктылыкны расларга омтыла. Поэзия чәчәге әнә шундый күп төрле бизәкләр ярдәмендә ачыла алу сәләте белән матур да бит.

**ХӘКИМҖАН ЯНОВ.**

# ЯҢА ЯЗМЫШЛАР АЧЫЛГАНДА

Яңа сызылган буразналар елга дулкыннарына, ә сирәк-мирәк очраган ак ташлар дулкында сикерешеп уйнаган ак чабакларга охшаган икән! «Диңгезнең яры булмагач, су кергәндә киемнәрне кайда калдырасың, әти?» — дип, дөньяга үзенең гаҗәпләнүле карашын текәп торган нәни шул малай белән без аның олы дөньясы буйлап сәяхәт итәбез, тормышны өйрәнәбез, эзләнәбез, яңалыкларга хәйран калабыз.

Фәнис Яруллинның «Язмышлар язылганда» повесте әнә шулай үзенчәлекле башланып китүе белән үк безнең игътибарны җәлеп итә. Укучы, үзе дә сизмәстән, дөньяга балалар күзе белән карый башлый. Кечкенә Фәйрүзә белән бергәләп Ыкка су кирергә йөгерә, көннәр буе умарталыкта чуала. Самими бала чак үзенең бөтен матурлыгы, эчкерсезлеге белән кабат безнең күз алдыбызга әйләнеп кайта.

Повестьның үзәк герое — Рәйханә. Ул безнең алда төрле яклап ачыла бара. Әсәрдә Рәйханә тормышының бик катлаулы чоры — формалашу һәм балалыктан үсмерлеккә күчү чоры тасвирлана. Язучы бу процессны зур осталык, психологик тө-

гәллек белән күрсәтә алган. Повесть ахырында инде Рәйханә тормышта үз урынын табып килүче умартачы кыз булып хәтердә кала.

«Әле язмышлар языла гына», — ди автор. Укучы матур башланган язмышның дәвамы да матур булачагына ышана.

Ф. Яруллинның әдәби язмышына тагын бер сәхифә өстәлде. Сүз дә юк, матур сәхифә, якты сәхифә!

Ихтыярсыздан күңелгә шигырь юллары килә:

**Күктә күпме йолдыз бар!**
**Таң йолдызы, төнгесе...**
**Гади күзгә күренми**
**Йолдызларның күбесе...**

**Без игътибар итмәгән**
**Күктә күпме балкыш бар!**
**Ачылмаган йолдыз күк**
**Җирдә күпме язмыш бар.**

Ачылмаган язмышлар... Бу сүзләр уйланырга мәҗбүр итә. Чыннан да, күпме әле алар — ачылмаган, ләкин һәркайсы зур бер дөнья булган язмышлар! Юк, сүз атаклы кешеләр турында түгел, ә менә иң гади кешеләр турында бара.

Яңа сөрелгән буразнада игенче басып тора. Кулында күперер торган кара туфрак. Аның өчен гади туфрак кына түгел бу, ул гүяки учына җир шарының бер кисәген салган. Туган җирнең бәрәкәтен, икмәк тәмен, яшәү ямен үзенә сеңдергән бу туфрак изге аның өчен. Сез аның күзләренә карагыз! Бу игенче үзе ачылмаган олы язмыш түгелмени?

Станогы янында басып, аннан чәчрәгән очкыннарда үзе генә аңлый торган матурлыкны күреп, шат елмаеп торучы эшче үзе бер олы язмыш түгелмени?

Әнә бер малай үзеннән зуррак кар йомарламын тырыша-тырыша үргә таба тәгәрәтеп маташа, ул да бит үзе яңа бер дөнья.

Ф. Яруллин үзенең әсәрләрендә менә шундый артык күзгә бәрелеп тормаган язмышларны мәйданга чыгара, укучыга гадәти күренешләрдә матурлыкны күрергә ярдәм итә.

...Сезнең яңа тибеп чыккан чишмә күргәнегез бардыр. Ул үләннәр, ташлар арасыннан килеп чыга да, табигатьнең иркә баласы кебек, җырлый-җырлый ага башлый. Үзенең яшәеше белән җанны иркәли, табигатькә тагын бер бизәк өсти.

60 нчы еллар башында әдәбиятыбызга үзләренә генә хас җыр-моңнары белән килеп кергән бер төркем яшьләр арасында гадилеге, якты хыяллары, матур тойгылары белән укучыны җәлеп иткән Фәнис Яруллин да бар иде. Без шигырьләре аша аның үзен күрдек, көчле ихтыярына сокландык, матбугатта чыккан һәр яңа шигыре өчен шагыйрьнең үзе белән бергә куандык. Менә аның иҗат чишмәсе тормыш гүзәллеген, дөнья матурлыгын, кешелекнең бөеклеген мактый-мактый еллар аша ага да ага.

Шагыйрь күңелендә меңнәрчә язмышларның юллары кисешә. Ул дөньяның сизгер барометры кебек: җир йөзендәге һәр үзгәрешне тоя, аны үз йөрәге аша үткәреп, кешеләргә җиткерә. Ф. Яруллинның «Ике сонет» дигән шигырендә мондый юллар бар:

**Каерса да язмыш минем канатымны,**
**Ала алмас кешеләрне яратуны.**

Әйе, Ф. Яруллинның күңеле тирә-юньгә, кешеләргә, тормышка мәхәббәт белән тулы. Моңа аның шигырьләре шаһит. Шул шигырьләр аны кыю рәвештә татар әдәбиятының киң мәйданына алып чыктылар, шагыйрь итеп таныттылар.

Егет кешенең күңелендә йөгәне-ияре белән ат ятар, диләр. Ф. Яруллинның иҗат чишмәсе шулай талгын гына агып яткан җирдән кисәк борылышлар ясый башлады. Аның «Җилкәннәр җилдә сынала» дигән зур күләмле проза әсәре басылып чыкты.

Повесть герое Фәниярның язмышы укучы язмышы белән үрелеп китте. Көчле рухлы бу егет һәркайсыбызны чын-чыннан соклландырды. Җилкәнне язмышның иң усал, иң рәхимсез җилләре сынады, ләкин ега алмады. Шуңа куанды укучы, шуңа үз итте Фәниярны. Кызганмады, нәкъ менә яратты, чөнки ул егет кызгануларданөстен иде. Без әсәрдәге Ана образына да тирән ихтирам белән, рәхмәт хисе белән карадык. Язмыш җиле бер Фәниярны гына түгел, аны да сынады. Ә сөйгәне белән тормыш давылларына каршы бару өчен курыкмыйча үз иңен куйган яшь кызга кем генә сокланмады икән.

Якты образлар күп иде әсәрдә, чөнки автор кешеләрне ярата, тормышны матур итеп күрергә тели һәм күрсәтә белә. Повестьның йөгерек тел белән язылуы да укучының аны җылы һәм җиңел кабул итүенә ярдәм итә.

Күп тә үтмәде, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ф. Яруллинның «Әнә килә автомобиль» спектакле куела башлады, тамашачыларның игътибарын казанды.

Шулай итеп, Ф. Яруллин безнең алда балалар өчен дә, зурлар өчен дә кызыклы шагыйрь, прозаик, драматург булуы белән ачылып китте.

**Шигырьләр дә кешеләр күк;**
**Кайберсе озак яши,**
**Кайсы тугач та үлә.**
**Мәңге үлмәс, мәңге сулмас**
**Шигырь язасы килә,**

— ди Ф. Яруллин бер шигырендә. Без аның иҗатында яңа сәхифәләр ачыласына, талантының яңа үрләр яулаячагына ышанабыз.

Язмыш дәвам итә. Язмышлар языла әле.

**ХАЛИСӘ ХӘКИМУЛЛИНА.**

# ЕЛЛАР ЧАЛЫМЫ

Шигърияттнең йөзе күп төрле, ул борынгы мифлардагы алла кебек: кайсы яктан карасаң, шул яктан йөзен күрәсең. Мәйданга яңа буын шагыйрьләр килүе шигърияткә тагын бер тарафтан караш ташларга мөмкинлек бирә. Мине шигърият турындагы уйлануларга этәргәне дә шулар арасында, Марсель Галиевнең «Еллар чалымы»[1] исемле җыентыгы.

Саклык белән генә салынган шигъри нәкышләр. Буяуларның сайланышында нәфислеккә омтылыш сизелә. Хис-тойгыларның миниатюр сурәтләрендә гомер эзе буйлап кирегә туктаусыз йөгерүче хәтер гәүдәләнә. Үтә таныш, газиз күренешләр: әни, авыл, туган як табигате, яшьлектә сөйгән яр... Иске әрнүләр кузгала, бәхетле мизгелләр кабат кайткандай була. Аларның шагыйрь күңелендәге биләмәләре нигә шулкадәр киң әле?

Бүгенгенең чын бәһасын аңлау өчен кичәгене истән чыгармаска кирәк. Шул хакыйкать шагыйрьне уйга этәргәнме? Югыйсә, үзе әйтмешли, «ни җитмәгән, әгәр берни тоймый бүгенгеңдә генә яшәсәң?..» Бәлки үзенең үткәне турында курыкмыйча, ихлас сөйләргә мөмкин булудандыр. Ә бүгенге көн, үзеңнең хәзерге асылың турында туры сүз әйтү исә авыр, катлаулырак.. Әллә югалтулар тетрәткәнме шагыйрь күңелен? («Югалтулар аша гына әрнү-хәтер уяна».) Рухының иминлеген, тынычлыгын сакларга, җитмәгәнне хәтердәге, хыялдагы белән тутырырга омтылуданмы бу шигырьләр?

Китеп югалучы һәр мизгел кабатланмас мәгънәгә ия. Аны тотып алу, үз вакытында аңлау мөһим. Марсельнең әнә шул мизгелне, үзгәрүчән тойгы, хиснең кыска җилпенешен тотып ала алган әсәрләре байтак. Шигырьләрендә истәлекләр күп урын алуның сәбәбе дә әнә шунда ята.

[1] Марсель Галиев. Еллар чалымы. Шигырьләр. Казан, 1979.

Тормыш югалтулар, табышлардан тора. Кеше гомере — төрле халәтләрнең бер-бер артлы алышынуы, үзгәрешләр. Менә шул үзгәрешләр эчендә үзеңне югалтмау кирәк. Моның өчен тотнаклы бер таяныч булу шарт. Марсельнең ул таянычы — аның үз күңеле, хәтере. Бу аңа үз асылын үзгәртми сакларга мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең хәтере, чыннан да, зур көчкә ия, әмма ул гел үткән көннәр коя-шында җылынып кына гомер кичермидер ич? Китабының исеме «Еллар чалымы». Бүгенге көн чалымы да бардыр ич аның иҗатында? Китабына шундый исем куеп, М. Галиев, билгеле, шигырьләрендә чагылучы чор билгеләренә ишарәләгән.

Шуларның, безнең карашка, шактый мөһим тоелганына тукталыйк. Безнең чор— катлаулы, кискен үзгәрешләр заманы. Бүгенге көннең кызыклы типларыннан бер-се — шәһәрләшеп килүче кичәге авыл кешесе. Ул каршылыклы хисләр, уйлар иясе. Хисләр драматизмы, авылны онытa алмау — бу типның үзенчәлекле сыйфаты. Әдә-биятның бүгенге көндәге мөһим бурычы — әнә шул кешенең каршылыклы рухи дөньясын ачып салу. Бездә бу өлкәдә уңышлы гына эшләүче шагыйрьләр бар иде инде. Шулар сафына М. Галиев тә килә. Ул да чор тудырган типның характер сый-фатларын ачуга өлеш кертә. Аның лирик герое «олы шәһәрдә» яши, авылны, анда-гы әнисен, туган як урманнарын сагына. Йорт тойгысы аның өчен авыл төшенчәсе белән бәйләнешен өзмәгән әле. Һәм шул ук вакытта ул авылга бөтенләйгә үк кайт-маячак инде. Әйтик, М. Шабаев лирик героеннан аермалы буларак, ул өзгәләнеп, авылга ашыкмый. Әмма, шулай да, еш кына болай була:

**...Эссе җәй. Олы шәһәрдә**
**ачылды кинәт хәтердә —**
**шул урман, учак, тугай.**
**Мыштым гына килеп, авыл**
**чабудан тартты бугай.**

Бу — шәһәрдә чакта шулай. Ә авылга кайтса:

**Бу якларның керләнмәгән кары,**
**исе дә юк салкын буранның.**
**Ә бит нидер искәртәсе килә**
**шау уятып бөтен урамны!**

Авыл, беренче карашка, үзгәрмәгән кебек тоелса да, геройның җаны моңа ыша-на алмый. Ләкин авыл үзгәрә. Һәм аның кары да инде ул кадәр үк чиста түгел. М. Галиев шигырьләрендә авыл тормышы идиллик пландарак сурәтләнә. Ягъни, китапта авыл, аның табигате, кешеләре турында сүз булса да, күренешләрнең төбе-нәрәк төшү, тирәнгәрәк керү җитенкерәми әле.

Китаптагы чор чалымнарының тагын берсен әйтеп үтәргә мөмкин. Ул — авторның туган халкы тарихына, үткән тормышына илтифатлылыгы. Әлбәттә, тарих турындагы уйланулары яшь шагыйрьгә файдалы булыр. Тарихилык фикерләргә тирәнлек, җан-лылык бирә, зур гомумиләштерүләргә этәрә. «Фани көндә мәңгелеккә табынып» яшәүче, дөньядагы үзгәрешләрнең, яшәү асылына төшенергә омтылып иҗат итүче шагыйрь, әлбәттә, иртәме-соңмы, шундый гомумиләштерүләргә килергә тиеш. Әмма әлегә аның иҗатында гомумиләштерүләр зурлыгы, фикер куәте бик үк сизелми.

Бирелә, мөгаен, аның иҗатының характерлы бер сыйфаты роль уйныйдыр. М. Га-лиев шигырьләренә этюд сыманлык хас. Шигъриятькә ул нәкыш сәнгате ысулларын күчерә: нинди дә булса бер фикерне, хисне, рухи халәтне генә ачып бирүгә хезмәт итүче сурәт, ул сурәтнең ачыклыгы, детальләрнең киң мәгънәлелеге, композиция-нең җыйнаклыгы. Ул шигъри этюдлар, пейзаж миниатюралары яза. Әйтерсең, ша-гыйрь дикъкатькә лаек мәгънәле бирәр күренешне ала да, тормыш агымыннан ае-рып, тәэсире, хисе суынгалаганчы, тиз генә кәгазьгә төшерә.

Бу иҗатның ике канаты бар: фикер һәм сурәт. Әлегә сурәтләүче як фикерләүче яктан көчлерәк кебек. Һәр шигырьдә рәссам кулы, рәссам күзе сизелә. Билгеле бер дәрәҗәдә хәзерге рус поэзиясе йогынтысын кичерүенә дә карамастан, М. Галиев шигъри миниатюраларының күбесендә үзе булып кала алган. Аның китабының — димәк, иҗатының әлегә кадәрге чорының да — йөзен әнә шул шигырьләр билгели.

Кайбер әсәрләрендә ул лирик кичерешен фәлсәфи формада ачарга омтылып карый. Ләкин шигырь тукымасы аша остазлары стиленә хас үзенчәлекләр саркып чыккан. Мәсәлән, «Безнең туу — үзе ачыш», «Аксакаллар сүзе», «Карап бла» шигырьләрен укыйсың да, юк, М. Галиев, түгелдер, Р. Әхмәтҗанов яки Р. Фәйзуллин бугай бу дисең.

Юк, бу — М. Галиевнең үз стиле формалашмаган дигән сүз түгел. Әгәр яшь шагыйрь бөтәннәр йогынтысыннан арынып бетмәгән икән — димәк, аның стиле җитәрлек көч алмаган, иҗатының табигатенә әверелмәгән әле.

Ләкин иң мөһиме — шагыйрьнең дөньяга, кешегә үз карашы бар. Тормыш шигъриятен, кеше күңеле матурлыгын үзенчә күрсәтеп бирә белүе бар.

**ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЕВ.**

# КӨННӘР ЯЗГА АВЫШКАЧ

Гәрәй Рәхим укучыларга күбрәк үзенең шигырьләре белән таныш. Аның соңгы елларда иҗат ителгән повестьлары да әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну уятты.

Язучының «Көннәр язга авышкач»[1] исемле повестенда талантлы архитектор Тимер һәм аның әнисе Фәкилә апа образлары аерым бер җылылык белән сурәтләнәләр. Әсәрдә аларның тормышындагы иң катлаулы-киеренке бер чор тасвирлана. Тимернең больницада дәваланган чагы, ә Фәкилә апа авыруы белән өендә көрәшеп ята: врачлар анда рак табалар... Әсәрнең үзәгендә — шушы геройларның язмышы, үткән һәм киләчәк турындагы уйлары.

Тимер образы аеруча ачык, бөтен яшәеше, барлыгы белән күз алдына килә. Безне, аның эш — хәрәкәтләреннән бигрәк, эчке дөньясы, уйланулары кызыксындыра төшә. Тимер, үзе әйтмешли, вәкаләтле трибуналардан торып чыгыш ясаячак, гүзәл архитектура биналары иҗат иткән һәм тагын иҗат итәсе кеше. Аның күңелендә каршылыклы уйлар кайный. Язучы бу әсәрендә менә шул процессны ачып бирә.

Кайчакта без дөнья мәшәкатьләре артыннан куып, тупаслана төшәбез, күңелебез катылана, тирә-юньдәге гүзәллектән ләззәт таба алмый башлыйбыз. Ә Тимер андый түгел. Ул тормышның, табигатьнең кечкенә генә үзгәрешләреннән дә үзенә күңел юанычы таба, хискә бирелә, үзенә бертөрле мәгънә чыгара. Аның күңел дөньясы саф һәм чиста. Ул ярата һәм соклана белә.

«Көннәр язга авышкач» әсәре укучыны тормыш-яшәеш хакында уйлануларга чакыра. Шулай да повестьның кайбер урыннары ясалмарак килеп чыккан. Мәсәлән, беренче бүлектә Тимернең врач белән сөйләшүе кебек күренешләр әсәргә артык ямау булып торалар сыман.

Тимер үткәннәрне искә төшерә, әнисе, авылы хакында уйлый, шуннан тәм, ләззәт таба. Ләкин ул шуларны уйларга үзен мәҗбүр итә төсле. Геройның эчке дөньясын беркадәр схемага салып бирү, табигыйлеген югалту түгелме бу?

Кешегә бер генә гомер бирелгән. Ул шул байлыкны ничек сарыф итәр — бу аның үзеннән тора. Берәүләр үткән юлларына борылып карагач кына үзләренең мәгънәсезгә узган гомерләрен күрсәләр, икенчеләр яшәгән гомерләре белән хаклы рәвештә горурлана ала. Фәкилә апа безнең күз алдына олы җанлы, хезмәт сөючән кеше булып килеп баса.

«Мичнең коймак пешерү өчен иң өлгергән чагы,— дип уйлады Фәкилә апа,— яңа төшкән күмер өстендә пешерергә яратам мин коймакны».

Гади генә эштән дә тәм, ләззәт табып, аның җаен-көен белеп эшләү — татар хатын-кызларына хас сыйфат. Аларның бөтен матурлыгы, горурлыгы шундадыр.

Әсәрдән күргәнебезчә, Фәкилә апаның тормышы үкенечле булмаган. Аның гомере балаларында дәвам итә.

Гомумән, Г. Рәхимнең бу повесте укучыны уйландыра, күңелгә кайгы сала, шатлык өсти, кеше булырга, дөньяга аек күз белән карарга өнди.

**ЗИННУР ХӨСНЕТДИНОВ.**

[1] Г. Рәхим. Көннәр язга авышкач. Повестьлар. Казан, 1979 ел.

# ГАДИЛӘР, ГАДӘТИЛӘР...

Кемне дә булса өзелеп яраткан, кемгәдер гашыйк булган берәүдән: «Ни өчен яратасың үзен?» дип сорап, бу көнгәчә әле һичкем тулы, ышандырырлык җавап алмагандыр. Әлеге мәкаләне язарга керешеп үз-үземне шундыйрак хәлгә — кыен хәлгә—калдырмаммы дигән шик белән, кулга язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала» китабын[1] алам. Анда өч әсәр — «Без кырык беренче ел балалары» һәм «Кеше китә — җыры кала» повестьлары, «Бер моң» дип исемләнгән хикәя. Повестьлар һәр икесе таныш, байтактан һәм яхшы таныш. Аларны укып тормыш турында, халык язмышы, ил язмышы турындагы уйларга бер генә мәртәбә биреленмәгән. Тын гына укып утырган җирдән, ычкынып киткәндәй, рәхәтләнеп көлүләр дә бер генә булмагандыр. Нишлисең, әсәрләре шундый — уйлата да, көлдерә дә, елмаеп кына укыган җирдән күзгә яшь, күңелгә моң да тутыра. Киресенчә дә була — бугазыңа төер килеп тыгыла, язмышларның авырлыгы җанны тетрәтә, ә үзең ихтыярсыздан кеткелди башлыйсың. Сәер халәт — үз-үзеңне аңламый торасың. Шул рәвешле — табигый булмаган хәлдә калган укучы бер мин генә түгел, монысы да мәгълүм. Нидер бар, язучы иҗатының ниндидер галәмәте, бер сере бар, димәк. Шуны тотып алсаң икән дә, һәр кешене ышандырырлык итеп күрсәтеп бирә белсәң икән. Төнкыйтьче өчен нинди зур иҗат бәхете булыр иде ул...

Ике повесть һәм бер хикәя — бер үк чорга караган вакыйгалар, бер үк тема, бер үк язучы әсәрләре. Тема җәһәтеннән алар язучының моңа кадәр дөнья күргән, укучыга бәхетле сәгатьләр бүләк иткән «Фронтовиклар»дан да нык аерылып тормыйлар. Искә алынган әсәрләрнең һәркайсында авыл һәм Бөек Ватан сугышына бәйле вакыйгалар үзәккә куелган. Тасвирланган язмышлар шул ике дөнья эчендә хәрәкәт итәләр һәм алар аерылгысыз җепләр белән үзара береккән. Шуңа күрә һәр әсәр турында аерым-аерым сөйләшергә омтылып та, безгә әледән-әле М. Мәһдиев иҗаты хакында гомумән фикер йөртергә туры киләчәк. Шуның өстенә китапка кергән повестьларны үзара бәйләп торган башка җепләр дә бардыр төсле. Әйтик, аларда бер үк чорда, бер үк төбәктә яшәгән геройлар тасвирлана һәм алар һәммәсе уртак максат, уртак авырлыклар, уртак моң белән яшиләр. Характер үзенчәлекләре белән һәркайсы үзгә бер тип булса да, язмышлары уртак — халык язмышы һәм ил язмышы белән аерылгысыз береккән. «Кеше китә — җыры кала»да сурәтләнгән Шәйхи карт һәм Шәяхмәт, Тимерхан һәм Хисмәт, Васфикамал белән Хәкимулла — болар мөстәкыйль тормыш көтәргә өлгергән, шәхес буларак формалашкан кешеләр. Ә «Без кырык беренче ел балалары»ндагы Әлтафи һәм Әркәшәләр, Зарифуллин һәм Гыйззәтуллиннар, тормыш авырлыкларын шулай ук җилкәләренә алырга өлгергән булсалар да, чынлыкта характерлары, холык-фигыльләре, үзүзен тотышлары белән әле үсмерләр.

«Кеше китә — җыры кала» әсәрендә язучы халкыбызның Бөек Ватан сугышы чорындагы батырлыгын, ныклыгын оптимистик бер моң, җыр буларак күңеленнән уздыра, характерлы образлар, детальләр аша фронт һәм тылдагы геройлыкларның асылы, табигате хакында уйларга чакыра. Шәйхи карт, Шәяхмәт һәм Тимерхан, Хисмәт һәм Хәкимулла, Миңлегали һәм Нургали — болар төрле буын вәкилләре һәм, бәхәссез ки, шул чор татар авыллары өчен үз кордашлары арасында аеруча характерлы образлар. Аларның тормышларында без укучыны шаккатырырлык һични күрмибез, тыныч тормышта булсын, фронтта булсын, алар — Совет иленең меңләгән, миллионлаган

[1] Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

гражданнары кебек гади кешеләр, гадәти кешеләр — кылган батырлыкларына үрелеп карасаң баштан бүрегең төшәрдәй геройлар, каһарманнар түгел. Бер татар авылының гади кешеләре.

«Без кырык беренче ел балалары»ндагы ач яңаклы оптимистлар да шул ук гади генә татар авылында үскән. Аерма тик шунда — боларның әлегә балалыклары чыгып бетмәгән. Балалыклары чыкмаган, ә сугыш афәтенең кырыслыклары инде үзләрен бермә-бер олыгайткан. Шаярганда, уйнаганда алар үзләренең табигый халәте — үсмер чакларына кайтса, ятимлектә, салкында һәм туйганчы бер ашау турындагы хыялга чумганда Зарифуллин һәм Әркәшәләр, ирексездән, нарасый сабыйларга әверелә дә кала, күңелгә аерата якын булып кызгандырып та куялар. Шунда ук аларның рухи һәм физик тазалыгы, камиллеге, тапкырлык һәм җорлыклары барыннан да өстен чыга, барын оныттыра. Аларның зур омтылышларына һәм җегәренә сокланып куясың. Әсәрнең бетмәс-төкәнмәс оптимистик рухы әнә шул нигездән күтәрелә. Һәм, нәтиҗәдә, повестьта сурәтләнгән яшүсмерләр «Кеше китә — җыры кала»дагы Шәйхи картның оныклары, Тимерхан һәм Хисмәтләрнең уллары-кызлары, Миңлегали һәм Нургалинең бертуган энеләре булып күз алдына киләләр. Барысы да бер үк халык вәкилләре, бер үк токым. Ә инде «Бер моң» хикәясендәге Мөхәммәтхан, ул, берсүзсез, Әлтафиларның сабакташы булырга тиеш, үзенең сабырлыгы, басынкылыгы һәм өлкәннәргә хас моңсулыгы белән генә ул алар арасында артык күзгә ташланмагандыр. Әйтерсең, нәкъ менә шуңарга язучы аны аерым алып күрсәтергә кирәк тапкан.

Шулай итеп, төрле елларда язылган өч әсәр бергә оешып, аерым-аерым яшәүләреннән туктый һәм бер-берен тулыландыручы бөтенне тәшкил итәләр кебек. Ил өстенә, халык өстенә, авыл өстенә кырык беренче елда килгән афәт — ныклыкка һәм тазалыкка иң кырыс сынауларның берсе. Шундый шартларда да бердәмлеген, рухи гүзәллеген саклаган — җырын югалтмаган халык яшәргә, мәңге яшәргә, бәхетле киләчәккә лаек. Ватанының, үз халкының ныклыгына, күңеле һәм рухы көрлегенә инанган язучы безгә, шул рәвешле, батырлыкка һәм оптимизмга дан җырлаган киң панорамалы китап тәкъдим итә.

Мөхәммәт Мәһдиев геройлары... Уйлана калсаң, үзләре бер дөнья. Роман һәм повестьларда, гадәттә, бер яисә ике үзәк герой була, алар башка эпизодик образлардан нык аерылып, биек пьедесталга бастыргандай, әллә каян күренеп торалар. Һәрхәлдә, без шуңарга күнеккән. «Фронтовиклар»дагы Рушадны искә алмаганда, әдипнең башка әсәрләреннән андый образны күрсәтүе кыен. Яхшымы бу, түгелме? Бер уңай образны калку итеп тасвирламагач та ул нинди проза әсәре? Повестьларның әһәмияте нидә? Авторның әйтергә теләгән фикере аның күпләгән образларына таралып, чәчелеп, сибелеп бетмиме? Мәһдиев иҗаты турында сүз чыкканда, мондый сорау һәм шикләнүләр, чынлап та, урынлы тоелырга мөмкин.

Шулай да ашыкмыйк. Мәһдиевнең яңалыгы, новаторлыгы, аның әсәрләрен үз иттергән, яраттырган нәрсә дә бәлки шундадыр... Инде әдәбиятның җирлеге булган тормышка, үзебезнең чынбарлыкка мөрәҗәгать итсәк, анда да кешеләр геройларга һәм эпизодик образларга бүленеп куелмаган ич. Бигрәк тә безнең социалистик чынбарлыкта — һәр шәхеснең гармонияле үсеше өчен шартлар тудырылган туган илебездә моның шулай булуы мәгълүм һәм табигый. Һәрхәлдә, без гадәтләнгән, әдәбиятта тасвирланган шәхесләр арасындагы аерма, масштаблар төрлелеге тормышның үзендәгедән күпкә кискенрәк. Сәнгать әсәрендә моның шулай булуы табигый дә. Шулай да ул катгый канун булмаса кирәк.

Дөрес, физик тазалыгы, акылы, кешелеклелеге, рухи матурлыгы яисә башка яклары һәм сыйфатлары белән кешеләр һәркайсы үзгә, бер-беренә охшамаган. Әмма, барыннан да элек, ул кеше бит әле. Димәк, аның үз мохите, үзенә күрә гүзәл бер дөньясы бар. Аны аңлый белергә, таный белергә генә кирәктер. Ә инде Ватан язмышы куркыныч астында торганда ил язмышын үз язмышы иткән шәхесләрне, төрле-төрле булган хәлләрендә дә, бердәй гүзәл һәм матур кеше — халык вәкиле итеп күрергә омтылу, һичшиксез, гайре табигый түгел.

Масштаблар гына бер чама, максатлар гына уртак, ә үзләре берсеннән-берсе гыйбрәтлерәк, үзенчәлеклерәк. Әйтик, Әлтафи — Гыйззәтуллиннан үзенең тапкырлыгы, җорлыгы һәм физик тазалыгы белән бер башка югарырак. Тәвәккәллектә дә аңарга җиткән юк. Ләкин язучының үзенчәлекләренә дә карамастан, Әлтафи Гыйззәтуллиннан бер баш өстен кеше буларак күз алдына килми. Гәрчә ул гадәттән тыш кызыклы образ булса да. Чөнки Гыйззәтуллин үзенең туган як табигатенә бирелгәнлеге, аны күп кенә

нечкәлекләренә кадәр аңлый, тоя, кичерә белүе белән сокландыра. Аның кичерешләре, рухи дөньясы Әлтафиныкына караганда күпкә баерак дип уйларга нигез бар. Шул рәвешле, аерым образларның йөзен, индивидуальлеген билгеләп торган калку сыйфатлар да геройларын бердәй гади, бердәй гадәти итеп күрә һәм сурәтли белгән, үз иткән язучының иҗат принципларына каршы килми.

«Кеше китә — җыры кала»дан ике кордаш Миңлегали белән Хәкимуллага тукталсак та, без шул ук иҗат алымнарына тап булырбыз. Штрихлар белән генә тасвирлансалар да аларның ачык, якты образлары күз алдында янәшә торалар. Эшкә килгәндә тиңе булмаган, усаллык, кырыслыктан да мәхрүм ителмичә, әрсезләнеп дөнья көтәргә ашкынган Васфикамал да, гадәти булган хәлендә, үз чорының кабатланмас бер тибы буларак хәтердә калган. Саный китсәң, повестьларда искә алынган һәр образны бер-бер артлы тезеп чыгарга кирәк. Һәркайсының үз йөзе, үз җыры, кабатланмас үз моңы бар. Язучы әнә шул кешеләрне бер дәрәҗәдә үз итә, ярата. Килеш-килбәт һәм холык-фигыльләрендәге үзгәлекләргә һәм җитешсезлекләргә дә карамыйча ярата ул аларны. Шуңа да коллективтан, массадан аерылып торган гадәттән тыш геройны тасвирлаудан язучы аңлы рәвештә читләшә. Олы максат, изге максат белән янып яшәгән кешеләр аның өчен һәммәсе дә кадерле, якын. Аларны ул кемнәндер өстен, кайсыдыр яклары белән артык булганнары өчен түгел, иң авыр шартларда да бергә булганнары, үзләре булып калганнары, тормышка һәм кешеләргә җылы мөнәсәбәтләрен, киләчәккә ышанычны, күңел көрлекләрен җуймаулары өчен ярата. М. Мәһдиев иҗат иткән гүзәл образлар галереясы укучыны да иң элек әлеге үзенчәлекләре белән җәлеп итә. Миңа калса, халкыбызның Бөек Ватан сугышы чорында фронтта һәм тылда күрсәткән каһарманлыгына багышланган җыр нәкъ менә шундый булырга тиеш иде. Мәһдиевнең, традициягә кергән, аерылып торган геройлар һәм эпизодик образлардан баш тартып, гадәти, әмма шул гадәтилекләре хәлендә гүзәл һәм батыр булып калган, сокландырган кешеләрне тасвирлап чыгуы — ул әдипнең иҗади казанышы һәм новаторлыгы. һәм искәртелгәнчә, бигрәк тә шунысы куанычлы, язучы иҗатының әлеге принцибы үз чынбарлыгыбызның объектив закончалыкларына нигезләнгән.

М. Мәһдиев иҗатының төп үзенчәлеге — әлбәттә, тормышка һәм халык рухына тугрылык. Тормыштан, табигыйлектән аңлы рәвештә читләшкән язучылар бездә, гомумән, сирәк күренеш. Прозабыз аксакаллары Г. Бәширов, М. Әмир, Ә. Еники, А. Расих, Ф. Хөсниләрнең, аның үз буыны вәкилләре Г. Ахунов, А. Гыйләҗевләрнең дә йөз тотканы үзләре кичергән, үз башларыннан узган тормыш бит, алар да әсәрләрен шул ук халык рухыннан чумырып алган әдипләр. Ләкин, тормышка тугрылыклары бер дәрәҗәдә булса да, һәркайсының иҗаты үзенчә балкый, үзенчә дулкынландыра һәм уйлануларга этәрә. Димәк, язучының талант үзенчәлеге тормышның үзеннән алынган вакыйгаларны үзенчә, оригиналь итеп тасвирлый белүдә ачыклана. М. Мәһдиев повестьларындагы бу оригинальлекнең бер кырына инде тукталып узган идек, ул— үз геройларын тормыштагыча гадилекләрендә, гадәтилекләрендә яшәтү, кемне дә булса аерым алып югары күтәрми һәм кемнәрнедер, искә алынганнар икән, онытмау, күләгәдә калдырмый тасвирлау, нәни штрихлар белән булса да эпизодик геройның да җанын, рухын ачып салу.

Эпизодлар рәвешендә генә искә алынган образларны да укучы күңеленә кереп калырдай ачык штрихлар белән тасвирлауга язучы ничек ирешә соң? Бу сорауга җавап эзләү, миңа калса, М. Мәһдиевкә хас икенче бер ачыклау аша гына мөмкин. Көндәлек тормыш детальләренә, әйләнә-тирәдәгеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә, рухи дөньясына үтә игътибарлы язучы ул. Язучыны төрле даирәдә — әдип һәм журналистлар, студентлар, республикабыз авылларындагы укучылары арасында очратканым бар. Кайда да үзенә кызыклы әңгәмәдәш, юлдаш эзләр һәм алар аңарга берөзлексез очрый тора. Чөнки, барыннан да элек, ул үзе кызыклы әңгәмәдәш. М. Мәһдиев повестьларындагы гыйбрәтле һәм җор образлар, уйлавымча, әсәр язылганчы ук әлеге очрашулардан алынган детальләрдән тупланып үзара сөйләшә, гәпләшә һәм аралашу эзли.

Язучы иҗат лабораториясенә шул рәвешле бер караш ташлау да күп нәрсәне ачыклый булса кирәк. Менә ни өчен аның повестьлары гадәттән тыш мавыктыргыч һәм җанлы укыла, менә ни өчен ул повестьларда сурәтләнгән гади генә кешеләрнең рухи байлыгына, тапкырлыгына һәм җорлыгына, һәркайсының үзенчә гыйбрәтлелегенә сокланып туймыйсың. «Без кырык беренче ел балалары»ннан әлеге дә баягы Әлтафины

алыйк. Бу үсмердәге тәвәккәллек, фантазия һәм тапкырлыкның очы-кырые юктыр сыман. Әлифне таяк дип белмәгәндә дә, буш сүздән фәлсәфә куертып, укытучыга җавап бирәме, сәгать төзәтә яисә мич чыгарырга керешәме, режиссерлык итә яисә концертта катнашамы — һәр очракта аның үз-үзен тотышына таң каласың. Ә бит ул аз гына да кыланмый, кәмит ясыйм дип эшләми боларны. Чираттагы һәр галәмәт аның үзенә ятышып тора, үз холкы, үз фантазиясе җимеше. Ул яши — язучы фантазиясендә генә түгел, тормышның үзендә яши. Миңа калса, Әлтафи — М. Шолоховның Щукарь картыдай киң катлам әдәбият сөючеләрнең гомум симпатиясен яулап алырга сәләтле, гыйбрәтле образ. М. Мәһдиев стилен һәм рухын тулысынча ачып бирерлек тәрҗемәче табылганда, ул рус телендә дә зур яңгыраш алыр иде.

Әлтафиның сабакташлары һәм нәни генә штрихлар белән сурәтләнгән училище укытучылары — һәркайсы бер-берен һич кабатламаган уникаль образлар буларак күз алдына килә. Нечкә зәвык һәм зур таләпчәнлеккә буйсындырылган тел һәм сурәтләү чаралары ни дәрәҗәдә сәнгатьчә тәэсир итү көченә ия була икән... Сокланып куясың. Шул уңайдан «Кеше китә — җыры кала»га мөрәҗәгать итеп, Атҗабар авылыннан Хисмәтне искә төшерү кызыклы булыр. Юк, ул авторның игътибар үзәгендә булган образлардан түгел. Шуңа да карамастан, кечкенә генә бер эпизодта үзенең ихлас чыгышы белән хәтергә уелып кала. Кара чыршылар авылдашларын фронтка озата, күрше авыллар да килеп җиткән. Шунда ат арбалары әйләнәсендә митингтай нәрсә оешып ала. Кара чыршылыларга Хисмәтнең әйтер сүзе бар икән, ул арбага менеп баса:

— Бәхил булыгыз, туганнар, дуслар... Атҗабардан бүген чыгып китүчеләр арасында мин иң өлкәне. Беренче категория. Без кая барганыбызны беләбез. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар — едвали. Сугышның нәрсә икәнен мин беләм. Фин сугышын күрдем. Бусы фин сугышы гына түгел. Фашист армиясе бик кабәхәт армия ул, тиомать. Безгә кайтулар — едвали. Бәхил булыгыз. Тату яшәгез. Кара чыршылар! Миңа үпкәләүчеләр бардыр арагызда. Заманында җир селкетеп йөрдек. Үпкә-сапкагыз булса — онытыгыз. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, едвали. Дөньяда фашист дигән эт чылбырдан ычкынган. Ә ул — бик хәтәр эт. Едвали кайтырбыз.

Бер карашка, ничектер, өзек-төтек, буталчык җөмләләрдән торган шушы чыгышта Ватанын сакларга барган кеше ачылып китә. Үзенең ихласлыгы, кешелеклелеге һәм нечкә күңеллелеге белән ачыла. Аның: «Безгә кайтулар булмас инде. Едвали кайтырбыз», — кебек сүзләре кабатланып килеп, образ күңелендәге аерылышу сагышын үзгә бер тулылык белән ачып сала. Хисмәтнең чыгышы моңсу, ләкин анда оптимистик рух булуын да тоемлау кыен түгел. Туган яклар, таныш-белешләр белән аерылышу авыр, бәлки башка очрашырга да туры килмәс, ә иң мөһиме ачык — Хисмәт җиңүгә ныклы ышаныч белән китә фронтка. Шул ук вакытта аның Ватанны сакларга китүчеләр арасында булуы белән горурлануы да ачык төсмерләнә.

Телебезнең гади сөйләм теленең мәгънәви сыйдырышлылыгын шул рәвешле күрсәтеп торган эпизодлар М. Мәһдиев әсәрләрендә сирәк күренеш түгел. Ә инде язучының зур уңышы булган «Кеше китә — җыры кала» повесте, бу күзлектән, яшь язучылар өчен чын мәгънәсендә гыйбрәтле иҗат мәктәбе булып тора.

М. Мәһдиев иҗат иткән образларның җанлы һәм гыйбрәтле булып оешуында, аларның җорлыгы һәм тапкырлыгында халкыбызның бетмәс-төкәнмәс күңел байлыклары, рухи хәзинәсе чагылыш таба. Бу кадәресе бәхәссез! Ләкин шуның белән бергә язучының үз фантазиясе ролен дә, яратып, мавыгып иҗат иткән образлары белән бер булып яши алу, сөйләшә белү сәләтене ия булуын да истән чыгару дөрес булмас. Образларның табигый яшәешенә, бөтенлегенә зыян китерми генә ул аларга хыял офыкларында туган гыйбрәтле детальләр, мавыктыргыч уйлар һәм кәмит кыланышлар өстәп җибәрергә һәрчак әзер тора. Җай чыкканда, мыек астыннан гына үзләреннән көлеп алырга, кайбер әкәмәтләр ясап арттырыбрак җибәрергә дә күп сорамый. Бер сүз белән — иҗат итә.

Дөрес, язучының кызык ясыйм, әкәмәт ясыйм дип вакыт-вакыт чама дилбегәсен кулдан ычкындыруын да искәртми ярамас. Мисал өчен, «Без кырык беренче ел балалары»нда, нигездә, яшь буынга атап язылган әсәрдә вульгаррак төсмер алган детальләрнең әледән-әле кабатланып килүе урынсыз булса кирәк. Беренчедән, 7, 11, 38, 46, 84, 108, 116 нчы битләрдә урын алган ул детальләр әсәрнең төп идея эчтәлегенә, аерым образларның бөтенлегенә берни дә өстәми. Икенчедән, бу мәсьәләдә безнең

халыкның, димәк, әдәбиятыбызның да үз критерийлары, әхлак нормалары бар. Заманчалаштырам, европачалаштырам, кызык ясыйм дип, андый тамашаларга бару урынсыз, миңа калса. Һәрхәлдә, Мәһдиев таланты аларга мохтаҗ түгел!

Мәһдиев повестьларында еш кына авторның оригиналь күзәтүләре, табигать янсә кеше холкының аерым үзенчәлекләре хакындагы уйлануларга килеп юлыгасың. Әйтик, Мәһдиевнең кияүгә чыкмаган кызлар, бәйләнчек ирләр психологиясе турындагы фәлсәфәсе күпләрдә кызыксыну уятырга, хәтта кемгәдер тормышында файда итәргә дә мөмкин. Миңа исә «Без кырык беренче ел балалары»ндагы табигать һәм кеше характеры, холкы турындагы фәлсәфи уйланулар аеруча кызыклы тоелды («Таңнар кайда да матур»... дип исемләнгән бүлек). Чынлап та, янәшәдә генә урнашкан ике авыл кешеләрен үзара аерып торган характерлы үзенчәлекләр очрый. Һәм бу аерымлыкларның нигезендә шул авылларга хас тирәлек, әйтик, урман, тау, су һәм чишмәләрнең тәэсире булуы бер дә гаҗәп түгел. Әдип шул рәвешле гомумиләштерү һәм күзәтүләре белән уртаклаша икән, бу, уйлавымча, аның иҗади кыюлыгы һәм мөстәкыйль фәлсәфи фикерләүгә сәләте турында гына сөйли. Мәһдиев иҗатына хас бу үзенчәлек, берсүзсез, әлеге китапта урын алган повестьларның идея-эстетик бөтенлегенә, образларның тормышчанлыгына да сизелерлек өлеш кертә.

М. Мәһдиев иҗаты турында сүз чыкканда, еш кына аның повестьларында эзлекле бер сюжет сызыгы булмауга игътибар юнәлтелә. Һәм вакыт-вакыт бу үзенчәлекне авторның зур кимчелеге санап, шуңа бәйле рәвештә аның әсәрләрендә масштаблы геройлар сирәк күренә дигәнрәк нәтиҗә ясарга теләүчеләр дә юк түгел. Мондый бәядә, бер карашка, чынлап та, дөреслек бар кебек. Традицион фикергә нигезләнгән логика шуны таләп итә. Ә традицияләргә, кабул ителгән гомуми канунннарга тугрылык безнең татар прозасына аеруча хас сыйфат. Бер яктан бу яхшы, чөнки традицияләребез тормышчан һәм реалистик — ышанычлылар. Ләкин сюжет сызыгын «А»дан «Я»га кадәр бер туры итеп кенә күз алдына китерү, шулай да берьяклылык булыр иде. Сюжетлылык төшенчәсен бер үк геройларның табигый үсеше, вакыйгалар эчендәге эзлекле хәрәкәте белән бәйләргә гадәтләнелгән. Ә чигә әле вакыйгаларны тормышның нәкъ үзендәгедәй күп тармаклы итеп сурәтләү, пәрәвез оясындагы җепселләрдәй үзара үрелгән язмышларны табигый бөтенлекләрендә тасвирларга омтылу прозага чит булырга тиеш!? Тема бөтенлеге, идея бөтенлеге булганда, сюжет сызыкларының күп тармаклылыгы әдәби әсәрне тарката, аның бөтен бер сәнгать әсәре буларак кабул ителүенә зыян итә дип һич кенә дә әйтеп булмый. Халык иҗатыннан, халык җырларыннан ук килгән традициянең яңача бер чагылышы түгелме соң бу? Шунда ук дөнья әдәбияты, аерым алганда бүгенге совет прозасында да моның үрнәкләре аз түгел. В. Астафьевның «Балык — патша»сын гына алыйк. Ул да бер бөтен повесть буларак тәкъдим ителә ич (сокландыргыч гүзәл һәм сәнгатьчә камил әсәр дип беләм), гәрчә аның бүлекләрендә гомум бер сюжет сызыгы түгел, даими образлар да юк. М. Мәһдиев повестьлары турында сүз чыкканда сюжетсызлык түгел, күп тармаклы, күп сызыклы сюжетлылык хакында уйланырга һәм бу алымның тагы да зуррак, әлегәчә ачылмаган эчке мөмкинлекләрдән торуына игътибар юнәлтергә тиешбездер.

Дөрес, М. Мәһдиев иҗатының бу үзенчәлеге — күп тармаклылыкның роман һәм повестьлар өчен табигый булып та, хикәя жанры өчен чит булуын искәртми мөмкин түгел. М. Мәһдиев талантының әлегәчә хикәя жанрында ачыла алмавы да, миңа калса, шул хакта сөйли. Китаптагы «Бер моң» хикәясенең мөтәкыйль әсәр, аерым хикәя булудан бигрәк, күләмле әсәрнең бер бүлеге сыманрак кабул ителүе дә шул турыда сөйли. Вакыйганың гыйбрәтлелеге, теленең җорлыгы белән мавыктырса да, «Бер моң»да Мәһдиев повестьларына хас бөтенлек һәм җыйнаклык җитенкерәми. Язучы әлегәчә хикәя жанрында үзен ачканы юк. Әмма ул ачышның булачагына һич шикләнмим. М. Мәһдиевтә А. П. Чехов, Ә. Еники, В. Шукшиннарга хас халык рухын нечкә сиземләү бар. Халыкның җанлы теленә, җорлыгына ачкыч тапкан әдип хикәя жанрында да, һичшиксез, үз формаларын, үзенчәлекле сурәтләү чараларын табар әле. Ышанам!

М. Мәһдиев иҗатының, башланып китүедәй, зур киләчәге булуына, аның һәр әсәре укучы тарафыннан көтеп алыначагына, язучының якындагы елларда тагы да олырак аудиторияләр яулаячагына ышанам. Мәкаләне ышаныч белән йомгаклаудан да ышанычлырак ни булырга мөмкин...

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

# КҮҢЕЛГӘ КИЛГӘН УЙЛАР

**Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,**
**Сөн суында юган иң элек...**

Кем турында сүз барганны белү өчен шушы ике юл бик җитә кебек. Әйе, сүз Роберт Миңнуллинның «Сөенсеннәр әле каеннар» җыентыгы[1] турында барачак. Яшь авторның яңа китабын укып чыгу белән аның беренче китабына да күз саласың: чагыштырасың, уйланасың. Үсеш бармы, автор бер урында таптанмыймы?

Барыннан да элек, үсеш-үзгәреш лирик геройда күренә. Аның инде дөньяга карашы формалашкан: ил гаме, халык гаме белән яши, ул замана баласы, «канатларын көйдерә-көйдерә» булса да кояшка омтыла.

**Мәйданнарга тик көчлеләр чыга,**
**Тик көчлеләр яуда бирешми.**
**Ут уйната торган чагыбыз бит —**
**Көчсез булу безгә килешми!**

Аның яңа «КамАЗ»лар төзисе, «БАМ»нар саласы бар. Ә гомер дигән нәрсә бакый түгел, йөрәктә яшьлек ялкыны, тәндә куәт, беләктә көч барында кулдан килгәнне эшләп калырга кирәк. «Хакыбыз юк көчсез булырга», «Кояшка омтылу», «Янарга икән янарга» шигырьләре әнә шул турыда сөйли.

Лирик геройның туган җиренә, тормышка мәхәббәте һәр шигырьнең рухыннан бөркелеп тора. Ул чын мәгънәсендә үзенең туган авылына, Сөнгә, каеннарга, талларына гашыйк. Бу хискә ул шулкадәр тугрылыклы ки, әлеге тойгы аның уйларын, теләкләрен, омтылышларын һәр даим бизәп тора.

Менә безнең героебыз самолетта көньякка оча:

**Туган якның кыр казларын,**
**Бәлки, табармын әле,**
**Үзебезгә кайтыгыз дип**
**Әйтеп карармын әле.**

Кара диңгезгә багышлап язган шигыренә дә «Сөн дулкыны» дип исем бирә шагыйрь. Хикмәт! Анда да Сөн дулкыны килеп кушылган икән, әмма ул зур диңгездә үзенең «төсен, тәмен, гамен югалткан һәм үзе дә югалып, тынып, күмелеп калган...» Монда инде уйлану, борчылу, фәлсәфә ярылып ята.

Шагыйрь «Аерма мине моңнан» шигырендә инде моңа кадәр киная, уйлану, күчермә образлар аша тасвирлап килгән төп фикерен укучыга турыдан-туры ачып бирә: туган якларын ташлап китүенә үкенә, әрни. һәм, ниһаять, үз авылында аны кунак итеп кенә санауларына («Нинди кунак ди мин...» шигырендә) борчыла башлый. Уйланулар, борчылулар, үз-үзеннән канәгатьсезлек хисе тынгылык бирми аңа. Әйбәт фал инде бу! Яхшыга юрыйк!

Ә бит кайчандыр ул:

**Киткәнгә дә шактый булган икән.**
**Килеп күрешәләр — танымыйм.**
**Сыйлашырга шәрәб табылса да,**
**Сөйләшергә сүзләр табылмый.**

**Фәлсәфәләр,**
**Уй — шөгыльләр башка,**
**Башларда да башка мәшәкать.**
**Бар әңгәмә — бала чакка кайту,**
**Кабатлана шулай ничә кат...**

— дигән кеше иде. Бәхеткә каршы, яңа китапта мондый кешенең эзе дә юк. Бирегә сәламәт рухлы, якты, мөлаем, самими язылган шигырьләр тупланган.

Лирик герой «ямь-яшел аэропортка акчарлак булып куна», җиргә яз кайтуның сөенчесен туган ягыннан үзе ала. Карлар аның иңенә «ак өметләр» булып ява, дөньяда актан башка төсләр барына аның ышанасы да килми. Әледән әле шигырьләргә ак каеннар, ак моң, ак күгәрчен, акчарлак, ак чәчәкләр килеп керә. Табигать аклыгы шагыйрьнең саф хисләре, якты уйлары белән берләшә.

Туган як пейзажын сурәтләгәндә палитрадагы барлык төсләр хәрәкәткә килә, Роберт биредә үз стихиясендә:

**Каеннар да әзерләнгән**
**Яз булып кагынырга.**
**Мин үзем дә әзер бүген**
**Яз булып кабынырга.**

**Кыенсынып басып торам**
**Карларга кагылырга;**
**Ашкынып тора алар да**
**Яз булып агылырга.**

[1] Роберт Миңнуллин. Сөенсеннәр әле каеннар. Татарстан китап нәшрияты, 1979 ел.

Шагыйрь лирик хисләрен, җитди фәлсәфи фикерне җиңелчә юмор белән өретеп бирә белә. «...Сөюдән шашкан йолдызлар Агыйделгә ташлана», давылдан соң җир өстенә чыгып, ялангачланып калган имән тамырлары өчен пошынып язылган шигырьдә дә шаян сүз кыстырырга җай таба:

**Көйрәячәк, кибәчәкләр**
**Алар кояш утында.**
**Ә аннары берәр абзый**
**Төяп китәр утынга...**

Сүзләр мәгънәсеннән, яңгырашыннан файдалана белү шигырьдән-шигырьгә үсә бара. Шигырьләрнең стилендә Шәүкәт Галиевнең уңай йогынтысы сизелә, эчтәлекләрендә юк-юк та Такташ аһәңнәре ишетелеп китә. Алдагы көннәрнең яктылыгына, барыр юлларның аклыгына, максатларның олылыгына ышаныч тудыра бу шигырьләр.

Шулай да китаптагы барлык шигырьләрне дә уңышлы дип әйтеп булмый. Кыска шигырьләр хәзер модада (яхшы мәгънәсендә). Әмма Роберт «Яратабыз!» дигән юмористик парчасыннан башка кыска шигырьләрен җыентыкка кертмәсә дә берни югалтмаган булыр иде.

КАБЕР ТАШЫНДАГЫ ЯЗУ

**Яман булгач, нинди аерма —**
**Кешеме ул, әллә бүреме!**
**Бу кешенең безгә бердәнбер**
**Яхшылыгы булды—үлеме...**

яки

**Мин бөек тә, мин мәңгелек**
**Дип үзен хис итте.**
**Һәм, чыннан да, ул беркөнне**
**Мәңгеле . . . . китте.**

Бу дүртьюллыклар күңелдә авыр тәэсир калдыра. Яман кешене исән чакта тиргәп калырга кирәк, үлгән кешене яманлау гадәткә кермәгән.

Җыентыкта «Җиңү» исемле поэмадан фрагментлар бирелгән. Поэма үзе бармы? Нигә фрагментлар гына? Стиленә, алымына карагандa ул тирән фәлсәфи һәм колачлы әйбер булырга тиеш. Әмма бар кадәреннән әлегә берни аңлашылмый. Фрагментларны укыгач, куркыныч төш күреп уянган кеше кебек тоясың үзеңне. Р. Миңнуллин бу әсәре белән үзенең гадилегенә, мөлаемлыгына зыян китермәс микән?

Кайбер тәгъбирләрнең дә урынсыз булуы күзгә ташлана. «Иртәнге пейзаж» дигән матур гына шигырь йолдыз шәрабларының табында ташып торуларын(?) әйтү өчен генә язылган соңгы строфаның бөтенләй кирәге юк. «Үлән» шигырендә дә шул ук хәл. Нигездә уңышлы гына булган шигырьнең тәмен җибәргән соңгы юллар — көчләп тагылган юллар булса кирәк:

**Төртеп чыккан яшь бер үлән**
**Кара карны кайнатып.**
**Җәй көтеп алҗыган җирне**
**Җибәрде ул айнытып.**
**Ефәк шикелле бу үлән,**
**Кыяклары яшелдән.**
**Елкылдап тора. Әйтерсең**
**Чәчрәп калган яшеннән.**
**Җәйнең җаны түгел микән**
**Яшь үлән — яшел тылсым!**
**Ни булса да булсын, әмма**
**Аягы җиңел булсын!..**

Шигырь шушында бетте ләбаса?! Ә аны көчләп сузалар:

**Талпына үлән яшәргә,**
**Үзе — яшел борынлы.**
**Ә үзеннән көнләшсәң дә,**
**Көнләшсәң дә урынлы.**

Сузалар диюем шуннан, бәлки шигырьдән бүселеп торган мондый урыннарны китапның редакторлары да күрергә тиештер. Автор да үз-үзенә таләпчәнлекне арттырган булса зыян итмәс иде. Шигырьләрнең берсендә генә дә «лирик мин»нән башка кеше юк. Оста кул белән ясалган туган як пейзажы һәм шунда япа-ялгыз, кая барып бәрелергә белми йөргән «лирик герой». Кешесез шигырьләр... Бер «лирик мин»не күпме сыгарга мөмкин? Өстәвенә аның тормыш тәҗрибәсе дә аз булса? Иң аянычы шул, әлеге кимчелек бер Роберт Миңнуллин иҗатына гына карамый. Соңгы 10—15 ел эчендәге шигырьләрдә кешенең эчке дөньясын, рухи байлыгын, интеллектын үлчәү берәмлеге булып бердәнбер «лирик мин» калып бара. Ә ул «мин»нәрне игезәкләр диярсең, чөнки яшь шагыйрьләр барысы да диярлек бер юлдан киләләр: авыл — мәктәп, Казан — университет, редакция. Ул кабат-кабат балачагына кайта, туган ягын сагына, аның табигатен тасвирлый. Бу очракта эмоцияләр көчле була, әлбәттә, әмма хис һәм тойгы никадәр генә кайнар булмасын, әйтер сүз вак, фикер кәрлә булганда шигырь максатка ирешми кала. Андый шигырьләргә социаль күренешләрнең асылына үтеп керү җитми, авторның «лирик мин»е тирән итеп кичерә белүче үзенчә

акыллы гына кеше булса да, күп очракта социаль эчтәлектән мәхрүм була, абстракт-гуманистик тенденцияләрне алга сөрә. Бу хәл тормышны өйрәнү-тикшерү сферасын тарайтып кына калмый, поэзиянең мөмкинлекләрен дә чикли, нәтиҗәдә, шагыйрьләр үзләре дә сизмичә берсен-берсе кабатлый башлыйлар. Шигырьләрне укыганда аларда-гы ясалмалылыкны, авторның тирән акыллы, төпле булып күренергә тырышуын күреп торасың. Ул үзенең кечкенә генә шәхси үпкәләве турында да авыз тутырып, шау-шу килеп сөйли, ә инде кешелек дөньясын борчыган мәсьәләләргә килеп орынса, сүлпән генә, ярым пышылдап берәр сүз әйтеп үтә.

Менә авыл. Ул заманыбызга хас темплар белән үскән, үзгәргән: тормыш та башка, кешеләр дә башка. Әгәр шагыйрь әллә нигә бер туган авылына кайтып, кайчандыр үзе белән бер парта артында утырган, бергә печән чапкан, аулак өйләргә йөргән иске дустын танымый, аның белән сөйләшер сүз тапмый икән (бу очракта мин Р. Миңнуллинның «Кайткан саен» шигырен күздә тотам) бүгенге көн героен тудыру турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шагыйрь үзен тудырган, үстергән, үзенә талант һәм канат биргән авылга ешрак кайтсын, үзенә сөт-каймак җитештергән чибәрнең күзләренә тутырыбрак карасын, үзенә ипи ашатучы егетнең күңеленә тирәнрәк үтеп керсен иде.

Соңгы еллар поэзиясенә хас булган уртак кимчелекләр турындагы фикерләр нигә бер Роберт Миңнуллин мисалында әйтелә соң? Беренчедән, болар аның шигырьләренә дә турыдан-туры кагыла, икенчедән, сүз Роберттан башланган икән, димәк, аның бу йогынтыдан арынырлык чамасы барлыкка ышанасың. Сөн буйларын, ак каеннарын, әнисен, сөеклесен шундый көчле итеп ярата белгән лирик шагыйрь үзе белән кайчандыр бер партада утырган кызның (әйтик, ул хәзер фермада сыер сава) гүзәл портретын, үзе белән кайчандыр бергә печән чапкан дустының (хәзер ул алдынгы механизатор булырга мөмкин) образын тудыра алмасмыни?!

Бәлки нәкъ менә Роберт Миңнуллин безгә замандашның моңарчы әдәбиятыбызда тиңе булмаган тулы канлы образын иҗат итәр! «Сөенсеннәр әле каеннар!» китабын укыгач күңелгә әнә шундый уйлар килде.

**ЛӘЛӘ ХӘЙДӘРОВА.**

## Укучының күңел дәфтәренә

**Кабардин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Еш тикшереп торган кеше бернәрсәсен дә җуймый.*
*Мәкерле хуҗа кунакны озак озата.*

**Казакъ мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Чәчмәгән уңыш — тумаган бала.*
*Кул кычыткан җирне кашый, сүз әйткән җирдә кала.*
*Иртәгә булыр тавыктан бүгенге йомырка яхшы.*
*Тизнең барсы да яхшы, тик үлем тиз килмәсен.*
*Зур диңгездә су кипми, бөек халык — үлемсез.*
*Акыллының — йөрәктә, ә юләрнеке — телдә.*
*Ничек кенә сикерсә дә бака сазда калачак.*
*Сунәр алдыннан һәммә ут бер дөрләп ала.*
*Үләсе килгән тычкан мәче койрыгын тартыр.*
*Карга күпме «кар-р!» итсә дә, сандугач була алмый.*

# ГОМӘР ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Гомәр Гали татар совет әдәбияты тарихында барыннан да элек күренекле тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак урын алган әдип. 20—30 нчы еллар тәнкыйтен аның татар совет әдәбиятының формалашу үзенчәлекләрен, яңа пролетар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен киң чагылдырган әдәби тәнкыйть мәкаләләреннән башка күз алдына да китерүе кыен. Ул тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр, татар әдәбиятында социалистик реализм методын нигезләүгә зур өлеш керткән талантлы замандашлары Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъдиләр белән бер сафка басып, үзен милли әдәбият һәм сәнгатьнең һәр уңышы һәм кимчелеге өчен җаваплы тоеп иҗат иткән шәхесләрнең берсе.

Гомәр Гали бер үк вакытта классик әдәбиятка гаять игътибарлы тәнкыйтьче. Аның Г. Тукай, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин кебек әдипләр иҗатына багышланган тикшеренүләре үз вакытында җитди тарихи әһәмияткә ия булалар. Г. Гали татар әдәбиятын тугандаш халыклар әдәбиятлары яктылыгында өйрәнүгә зур игътибар бирә, рус әдәбияты ясаган уңай йогынтыны кат-кат ассызыклап күрсәтүне кирәк саный. Тәнкыйтьченең «М. Горькийның татар язучысы Шәриф Камалга йогынтысы» дип исемләнгән күләмле тикшеренүе исә аның шушы юлдагы иң җитди хезмәтеннән саналырга тиеш була (кызганычка каршы, ул тәмамланмый кала).

Г. Галинең әдәбият дөньясында ут уйнаткан тәнкыйтьче булып өлгерүенә аның бай тормыш юлы һәм күп кырлы иҗтимагый эшчәнлеге дә аз йогынты ясамый. Ярлы крестьян улы буларак, ул бик яшьли эшкә тартыла — Донбасс шахталарына барып чыга, пролетариат вәкилләре белән аралаша. Революциядән соң күп тә үтми, үз теләге белән Советларны яклап Кызыл Армия сафларына керә, гражданнар сугышы чорында аяусыз көрәшләрдә катнаша, зур чыныгу ала. 1924 елда партия сафларына керә.

Гражданнар сугышы тәмамлангач та ул Казанга кайта һәм төрле матбугат органнарында актив эшләп килә. Республика яшьләр газетасын оештыруга зур өлеш кертә, 1925—1927 елларда «Безнең юл» журналының (хәзерге «Казан утлары»ның чишмә башы) редакторы, 1927 елдан Татгосиздатта өлкән редактор булып эшли. Бер үк вакытта Казан югары уку йортларында татар әдәбияты буенча дәресләр бирә. 1925 елда Парижда узган Халыкара сәнгать күргәзмәсендә Татарстан вәкиле буларак катнаша.

Г. Гали, А. М. Горький, А. С. Серафимович, А. А. Фадеев кебек күренекле рус совет язучылары белән якыннан таныш була. Алар белән аралашу, шәхси очрашулар тәнкыйтьченең дөньяга карашына, идея-эстетик үсешенә уңай йогынты ясый.

Г. Гали үзенең иҗат эшчәнлеген тәнкыйть һәм әдәбият белеме белән генә чикләми. Ул күпләгән очерклар һәм публицистик мәкаләләр, китаплар авторы, аның балалар һәм зурлар өчен язылган хикәяләре үз вакытында әледән-әле басыла киләләр. Әдипнең Татарстан китап нәшриятында 1958 елда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»е аның күп кырлы иҗат эшчәнлеген күз алдына китергән иң зур җыентык булып тора.

Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме, язучы һәм публицист Гомәр Галинең иҗаты 20—30 нчы еллар әдәбияты тарихында җуелмас урын алады.

# ҺӘРВАКЫТ АЛГЫ СЫЗЫКТА

*Мөхәммәт Әблиевнең туууна 80 ел*

Иҗатын һәм гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган язучы Мөхәммәт Әблиевнең тууына 80 ел тулды.

Ул Кама Тамагы районының Даныш авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Сигез яшеннән тамак ялы өчен байларга һәм сәүдәгәрләргә бил бөккән.

Бөек Октябрь революциясе җиңүен М. Әблиев Казанда каршылый. 1918 елда үзе теләп азык-төлек отрядына языла. Туку фабрикасында эшли. Тиздән комсомол путевкасы белән Көнчыгыш халыкларының партия мәктәбенә укырга керә һәм, аны тәмамлагач, эшче яшьләр арасында тәрбияче була.

1921 елда комсомолец М. Әблиев үз теләге белән Кызыл Армия сафларына китә, Урта Азиядә басмачыларны тар-мар итүдә катнаша. Шул чордан башлап аның тормышы армия хезмәтенә бәйле. Берләштерелгән татар-башкорт мәктәбен тәмамлагач, ул 1 нче татар укчы полкына взвод командиры итеп билгеләнә. Басмачы өерләргә каршы хәрби операцияләрдә катнаша. Аннан соң Ленинградтагы Ленин орденлы хәрби-политик академиядә белем ала. Ак финнәр белән сугыш башлангач, полк комиссары М. Әблиев көрәшнең алгы сызыгында була. Немец-фашист илбасарларга каршы яуның беренче көннәреннән үк утка керә һәм авыр бәрелешләрнең берсендә батырларча һәлак була.

Мөхәммәт Әблиев — берничә пьеса, повесть һәм хикәя авторы. Гомере бик иртә өзелгән язучы, катлаулы шартларда — походларда, сугыш тынып торган арада гына язарга туры килсә дә, үз иҗатына зур таләпчәнлек белән карый. Шуңа күрә аның әсәрләре сәнгатьчә бөтенлеге, заманча яңгырашы белән хәзер дә укучыларның игътибарын җәлеп итә.

Татар әдәбияты тарихына М. Әблиев исеме иң беренче чиратта «Шәмсекамәр» драмасы белән керде. Ул аны 1929 елда яза. Пьеса өстендә эшләгәндә яшь язучыга тәҗрибәле драматург Кәрим Тинчурин булышлык күрсәтә. Бу иҗади дуслыкның нәтиҗәләре бик куанычлы булып чыга.

Әсәр киеренке драматизмы, үзенчәлекле образлары белән аерылып тора. Анда революциягә кадәрге татар авылында барган вакыйгалар сурәтләнә. Мәкер һәм хәйлә ярдәмендә Сәләхи бай Шәмсекамәрне ире Хафиздан аерырга маташа. Хафиз хатынының үзенә хыянәт итүе турындагы ялага ышана. Шәмсекамәр шәригатьнең рәхимсез кануннары белән йөзгә-йөз очраша, төрле кимсетелү-җәберләүләргә дучар була. Ләкин саф намусы, горурлыгы һәм үз дәрәҗәсен яхшы белү бу кимсетелгән татар хатынына кыргый гадәтләр авырлыгыннан сыгылып төшмәслек көч бирә.

М. Әблиевнең «Шәмсекамәр» спектакле Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә зур уңыш казанды, озак еллар буе репертуардан төшми уйналды, пьеса күп кенә татар, башкорт сәхнәләрен әйләнеп чыкты, ә сугыштан соңгы елларда аны Үзбәк академия театры куйды.

# ЯЗУЧЫ-ПЕДАГОГ

*Гали Рәфикыйның тууына 90 ел*

Гали Лотфрахман улы Рәфиков (Гали Рәфикый)ның туган җире — элекке Уфа губернасы, Бәләбәй өязенең Җилдәр волосте (хәзерге Миякә районы), Баязит авылы. Башлангыч белемне ул Стәрлебашта ала. Г. Рәфикый заманында дан тоткан, Х. Ямашев, Г. Коләхметовлар укыган Казан «Учительская школа»сын тәмамлау бәхетенә ирешә.

Аның иseme матбугатта беренче мәртәбә 1910 елда ук күренә. «Вакыт» газетасының 1910 елгы 6 нчы январь санында Төркестанда җир тетрәү тәэсире белән язылган «Зилзилә» исемле шигыре басыла. Әмма иҗатының чын-чынлап тамыр җәюе Казанда укыган вакытларына туры килә. Аның таланты хикәя жанрында ачыла. 1912—1916 елларда 20 дән артык әсәре дөньяга чыга.

Г. Рәфикый — заманының алдынгы карашлы укымышлысы, демократик әдәбияткa теләктәшлеге Г. Тукайга мәхәббәтендә дә күренә. Шагыйрьнең үлүенә бер ел тулу уңае белән кайгы белдереп язылган «Тукайны тәхаттыр»[1] исемле мәкаләсендә мондый юллар бар: «Габдулла әфәнде халык хисләре белән хисләнеп, үзенең күңеленнән кайнап чыккан шигырләре белән халыкның күңелен, үзенчә әйтсәк, «шүрәлечә» кытыклады.» («Аң», 1914 ел, 7 нче сан).

Г. Рәфикый әсәрләрендә без татар әдәбиятының прогрессив традицияләре белән очрашабыз. Һәртөрле дини кануннардан, искелек йолаларыннан азат булган ирек сөюче хөр шәхес идеалы аның иҗатында төп урын алып тора. «Рауза» (1914), «Яшь йөрәкнең ашкынуы» (1915), «Ходай кушмый» (1915) исемле хикәяләрендә чорына күрә алдынгы карашлы кешеләр искелек, дини фанатизм белән каршылыкка керә, тормышны үзгәртеп кору өчен көрәш юлына басмаса да, торгынлык богауларыннан котылу чарасын эзлиләр.

Г. Рәфикый әсәрләрендә үз чорының төрле катлау кешеләре урын ала. Стиленә тулаем җитди тонда хикәяләү, тигез агым, бераз гына романтик буяуларга бирелү хас. Халыктан ерак торган интеллигент образларын иҗат иткәндә, аңарда ирония чаткылары да ялтырап китә.

Әле Татар укытучылар мәктәбенә кергәнче, 1909—1912 елларда Г. Рәфикый Пишпәктә (хәзерге Фрунзе шәһәрендә) балалар укыта. Шуңа күрә аңа Урта Азия халкы тормышы таныш. Казакъ, кыргыз хатын-кызларының үзәк Россия хатын-кызларына караганда да хокуксызрак булуларын үз күзе белән күрә һәм мондагы чынбарлыкның нәкъ шушы ягына игътибар итә. «Вакытлы никах» (1913), «Алатау буйларында» (1913) хикәяләрендә Төркестан хатын-кызларының аянычлы язмышын сурәтли. Сафлык һәм кимсетелү — шушы бер-берсеннән ерак торган ике сыйфатны янәшә куя әсәрләрдә фаҗигане тагын да тирәнәйтебрәк күрсәтә.

Г. Рәфикыйның байтак әсәрләрендә персонажларның эчке кичерешләрен бирү, геройларны психологик планда ачу өстенлек ала. Язучы әдәбиятның кешедә дәрт рухына омтылыш, күтәренкелек тәрбияләвен яклый, күңел төшенкелеге тудыра торган әсәрләргә каршы чыга. Реакция һәм империалистик сугыш тәэсирендә пессимистик яңгырашлы әсәрләр ишәйгән елларда Г. Рәфикый классик традицияләргә турылыклы булып кала. Хатирә формасында язылган «Ыссык-Күл» (1913) исемле очеркы Г. Рәфикый иҗатының яңа ягын ача: монда ул оста пейзажчы, тасвирчы, табигатьне нечкәләп күзәтүче, аның гади күзгә чалынмаган үзенчәлекләрен тотып ала белүче.

Г. Рәфикый әсәрләре үз вакытында матбугатта уңай бәя алган. «Ил» газетасының 1914 елгы 31 май санында: «Үз халкымыз мәгыйшәтеннән һәм Төркестан һәм Еде су төрекләре хәятын тасвир итеп язучы Г. Рәфикый әфәнденең бәгъзе әсәрләре игътибар бирлә укучыларның дикъкатьләрен җәлеп итә торган нәрсәләрдер», — диелгән.

Г. Рәфикый — балалар язучысы да. Аның балаларга багышланган хикәяләре 1913—1915 елларда «Ак юл» журналында дөнья күрәләр. Балалар әдәбияты өлкәсендә дә әдип яшь буынны тәрбия итү буенча заман куйган таләпләр — мәгърифәт һәм кешелеклелек идеаллары яктылыгында торып иҗат итә. XX йөз башы балалар әдәбиятында яшь буынны рухи яктан гариплhistoricalндерүче иске хорафатларга, зарарлы йолаларга каршы көрәш көчәя. Әдәбиятта атеизм мотивлары шактый тирәнәя. «Тәрбиятел әтфаль», «Ак юл» журналларында дөньяны фәнни караштан чыгып аңлаткан очерклар, мәкаләләр басыла. Пишпәктә укыткан чагында Г. Рәфикый да рус галиме һәм язучысы Н. А. Рубакин, педагог һәм методист В. П. Вахтеров хезмәтләреннән файдаланып, «Шура» журналында ике ел буе (1911—1912) үсемлекләрнең тереклеге, кеше организмының төзелеше турында башлангыч мәгълүматлар бирә торган

[1] Тәхаттыр — искә алу.

күп санлы фәнни-популяр очерклар, мәкаләләр бастыра, Табигать белеме һәм география укытучысы буларак, балаларны фән нигезләре белән коралландырырга тырыша.

Г. Рәфикый — тәрҗемәче дә. Ул А. Н. Куприн, И. С. Тургенев, Г. Х. Андерсен әкиятләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Г. Рәфикый Бөек Октябрь җиңүен хуплап каршылаучы язучылар рәтенә керә.

Авторның мәкаләләрендә күзгаткан күп кенә фикерләре бүгенге көн белән дә аваздаш. 1938 елда Г. Рәфикый Г. Еникиев белән берлектә «Грамматика русского языка» дигән дәреслек төзи. Бишенче-алтынчы классларда рус теле укыту өчен эшләнгән бу дәреслекнең өч басмасы дөнья күрә.

Быел 29 июльдә Г. Рәфикыйның тууына 90 ел тула. Без культурабызны үстерү юлында армый-талмый хезмәт иткән бу язучы педагогны зур ихтирам белән искә алабыз.

**ФАТЫЙМА ИБРАҺИМОВА.**

# ӘНВӘР БАКИРОВКА 60 ЯШЬ

Күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әнвәр Бакиров үзенең юбилеен зур иҗади уңышлар белән каршылый. Әсәрләренең исемлеген генә күздән кичергәндә дә, композитор иҗатының колачы киң булуын — аның иң гади, кечкенә күләмле жанрлардан башлап, опера, симфония, оратория кебек катлаулы жанрларда эшләвен күрәсең. Патриотик һәм лирик җырлар, балалар өчен җырлар — барысы 250гә якын. Скрипка, виолончель өчен һәм фортепьяно пьесалары, баян өчен биюләр — 42, хор өчен җырлар, кантата, симфоник әсәрләр, ораторияләр — 6. Спектакльләргә эшләнгән музыкаль оформлениеләр, музыкаль комедия, опера, балетлар, мәктәптә музыка, җыр дәресләре алып бару өчен китаплар...

Әнвәр Бакиров музыкасы халыкчан моңы, тирән, актуаль эчтәлеге, оптимистик яңгырашы һәм профессиональ җитлеккәнлеге белән җәлеп итә.

Бу сыйфатларга ирешү юлы бик кечкенә чактан башлана. Булачак композитор музыкаль гаиләдә тәрбияләнә. Ул 1920 елның 7 июлендә Казанда хезмәткәр семьясында туа. Әтисе Закир ага да, әнисе Газизә апа да оста гармунчы булалар. Ике апасы мандолинада, абыйсы кубызда, курайда, кларнетта уйный. Өйдә һәрвакыт халык көйләре яңгырый торган була. Нәни Әнвәр җыр-моң бишегендә, нечкә күңелле, музыкаль зәвыклы булып үсә. 1924 елны гаилә Биектау районына — Закир аганың туган авылы Әлдермешкә күчә. Закир аганың ике кызы һәм улы — укытучылар — спектакль, концертлар кую, сабан туйларының музыкаль өлешен оештыру белән авылдашлары алдында ихтирам казаналар. Үсә төшкәч, бу концертларда Әнвәр дә катнаша башлый. Аннан ул, Казанга абыйсы янына килеп, Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә укый. VII классны тәмамлагач, Ә. Бакиров Казан музыка училищесының скрипка классында укый башлый. 1940—1946 елларда ул Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Демобилизацияләнгәннән соң, Казан консерваториясендә белем ала. 1953 елны Әнвәр Бакиров СССР Композиторлар союзына керә.

Консерваториядә укыган елларында ук Әнвәр Бакиров мәктәптә җыр дәресе укытучылары өчен кулланма-дәреслек яза. Музыка буенча татар телендәге бу беренче дәреслекне киң җәмәгатьчелек куанып каршылый. Студент Ә. Бакировның виолончель һәм фортепьяно өчен язган сонатасы да югары бәя ала. Аны Мәскәүнең «Музыка» нәшрияты рус һәм инглиз телләрендә аңлатмалар белән бастырып чыгара.

Композитор йөзләгән җырлары белән үзен эшчән иҗатчы, планета һәм илебездәге вакыйгаларга сизгер, халык тормышына бик игътибарлы музыкант-гражданин итеп танытты. Аның җырлары арасында батырлыкка рухландыручы героик җыр-маршлар, туган ил табигатенең гүзәллеген сурәтләгән әсәрләр, агымлы лирик һәм дәртле шаян җырлар бар. Аларда Әнвәр Бакировка гына хас күтәренке рух сизелә, үзенчәлекле моң яңгырый. Композиторны заманыбызның иң актуаль мәсьәләләре дулкынландыра.

Бөек Ватан сугышыннан соң, бөтен дөньядагы прогрессив көчләр тынычлык өчен көрәшкә күтәрелгәндә, Әнвәр Бакиров шагыйрь Шәйхи Маннур белән иҗади дуслыкта «Ана җыры»н яза. Аннан соң концерт программаларында аның Мөхәммәт Садри сүзләренә «Тынычлык җыры», Сәхаб Урайский сүзләренә «Тынычлык сугышны җиңәр», Мөнир Мазунов сүзләренә язылган «Тынычлык-дуслык иле» дигән җырлары урын ала. Кама буенда колачы, масштаблары белән тиңдәшсез төзелеш башлангач, Әнвәр Бакиров шагыйрә Саҗидә Сөләйманова белән бергә төзелеш батырларына багышлап «Яшьлек каласы» дигән җыр иҗат итә. Бу әсәр иң яхшы патриотик җырга уздырылган Бөтенроссия конкурсында III урынны ала. Бөек төзелеш пафосы композиторның зур күләмле әсәрләренә дә күчә. Симфоник оркестр өчен язылган «КамАЗ увертюрасы»нда, «Кама киңлегендә» исемле җиде кисәктән торган ораториядә КамАЗ төзелешендә эшләүчеләрнең хезмәт шатлыгы гәүдәләнә.

Композитор лирик җырларында инсафлы, игелекле, гади, мөлаем, хезмәтчел замандашларыбызның хис-тойгыларын тулы чагылдыра. Ул җырлар йөрәккә үтеп керерлек самими, халыкчан интонацияләре белән аерылып торалар. Шуңа күрә Ә. Бакировның әсәрләре күңелләргә хуш килә. Аның «Кемгә сөйлим», «Белсәң иде», «Аппагым», «Барысы да күңелдә», «Сөя микән», «Әгәр белгән булсам», «Балыкчы җыры», «Кыр казлары киткәндә», «Җилләр тидермәс идем», «Мәк чәчәге», «Әйткән идең» кебек күп санлы җырларын яратып тыңлыйлар һәм җырлыйлар.

Иҗатының беренче адымнарында ук Әнвәр Бакиров республика театрлары сәхнәгә куйган аерым спектакльләргә музыка яза. Сәхнә серләренә төшенү, театраль музыка язудагы тәҗрибәсе катлаулырак әсәрләр — опера һәм балет көйләре иҗат итүгә юл сала. Бөек Октябрь революциясенең 40 еллыгына Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры композиторның сәхнә әсәрен — Тукай әкиятенә нигезләнгән «Алтын тарак» балетын куя. Бөтенроссия театрлары һәм музыкаль коллективларының бөек юбилейга багышланган фестивалендә «Алтын тарак» беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнә.

Шамил Бикчурин либреттосына язылган «Тальян моңы» музыкаль комедиясе Әлмәттә һәм Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куела. Татарстан нефтьчеләре тормышына багышланган бу әсәр зур уңыш белән берничә ел буе сәхнәдән төшми.

Г. Тукай поэмалары, халык әкиятләре мотивларына корылган «Су анасы» балеты халыкның яктыга, бәхеткә омтылышын, кара көчләргә каршы көрәше турында сөйли һәм әлеге әсәр Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры коллективына зур иҗади җиңү китерде. Композитор һәм спектакль республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Илебезнең күп шәһәрләрендә бу балет тамашачыларның кайнар мәхәббәтен казанды.

Әнвәр Бакиров үзенең иҗатында заманыбызның иң актуаль темаларын күтәрә дидек. Әмма ул заман куйган бурычларны иҗатында чагылдырып кына калмый, аларны хәл итүдә шәхес, коммунист буларак турыдан-туры катнаша. Алабугада һәм Лениногорск районының «Спартак» колхозында, мәсәлән, Ә. Бакиров тырышлыгы белән балалар музыка мәктәпләре ачылды. 1973 елдан башлап Чаллының сабан туе мәйданында җәй саен меңләгән җыр сөючеләрне берләштергән җыр бәйрәме уздыру матур традициягә әйләнде. Ә ул җыр бәйрәмен башлап җибәрүче, яшьләрдән КамАЗда меңкешелек хор оештыручы Әнвәр Бакиров була.

Үзенең 60 яшен Әнвәр Бакиров бөек шагыйребез тормышына багышланган «Тукай» операсы белән каршылый.

Әнвәр Бакировның киң колачлы иҗатын, актив эшчәнлеген тагын бер кат күз алдыннан уздырганда, аның әле студент чакта ук иҗат иткән «Яшьләр җыры» күңелдә чыңлап үтә. Дәртле, күтәренке рухта яңгыраган әлеге әсәр Ленин комсомолының 30 еллыгына багышланган конкурста беренче бүләккә лаек булган иде һәм ул яшьләрнең яраткан җырына әверелде. «Яшьләр җыры»нда композитор иҗатының лейтмотивы ишетелә, ул аның һаман алга, иҗади үсүгә, профессиональ нигуга омтылуын дәлилләп тора шикелле.

Кайнар йөрәкле, гаҗәп эшчән, бай иҗатлы композитор Әнвәр Бакиров яшьләрчә дәрт, ялкын белән яши, яңа иҗат үрләренә күтәрелә.

**ЗӘЙНӘП ХӘЙРУЛЛИНА.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

5 майда Пресса йортында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин республика газеталары, журналлар, радио, телевидение һәм нәшриятларның җитәкче работниклары белән очрашты.

Р. М. Мусин республиканың промышленность предприятиеләре, төзелеш, транспорт оешмалары, колхоз һәм совхозлар тарафыннан дәүләт планнарын һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүнең барышы, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү һәм аларны 1980 ел заданиеләрен, тулаем бишьеллыкны үтәүгә туплау, Татарстан АССРның 60 еллыгын һәм КПССның XXVI съездын лаеклы каршылау буенча массовый информация һәм пропаганда чараларының бурычлары турында сөйләде.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Инде традициягә кергәнчә, республикабызда һәр елны апрель аенда В. И. Ленинга багышлап сәнгать фестивале үткәрелә. Анда илебез һәм Татарстанның танылган коллективлары, күренекле сәнгать осталары катнаша. Нур өстенә нур булып, сәнгать фестивалենә шигырь бәйрәме килеп кушыла. Быелгы шигырь бәйрәме даһи юлбашчыбыз юбилеена, Бөек Җиңүнең 35 еллыгына һәм Татарстан Автономияле республикасы төзелүгә 60 ел тулуга багышлана. Республикабыз язучылары, культура эшлеклеләре Арча районының Тукай-Кырлай авылына бардылар. Г. Тукайның мемориаль музеенда булдылар, шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр куйдылар. Шигырь бәйрәме М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы янәшәсендәге Г. Тукай һәйкәле янында дәвам итте.

Г. Тукай һәйкәле алдында зур шигъри митинг булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты.

1980 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреатлары шагыйрь И. Юзеев белән скульптор В. Маликов чыгыш ясады. Алар әдәбиятсәнгать эшлеклеләре турында даими кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен партиябез һәм хөкүмәтебезгә эчкерсез рәхмәтләрен белдерделәр.

Аннары шагыйрьләрдән С. Хәким, М. Садри, Ә. Исхак, Н. Арсланов, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, Р. Фәйзуллин, Р. Моран һәм башкалар үз шигырьләрен һәм тәрҗемәләрен укыдылар. Митингта катнашучыларны «БАМстройпуть» төзелеш идарәсе вәкиле Г. Сычев кайнар котлады. РСФСРның халык артисты Ф. Насретдинов Г. Тукай турында җыр җырлады.

## ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘР — ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты әдәби берләшмә җитәкчеләренең ике көнлек семинарын үткәрде. Семинарны ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Сафин ачып җибәрде. Аннан соң Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары И. Юзеев, Татарстан Язучылар союзының рус секциясе председателе Г. Паушкинның доклады тыңланды.

КПСС өлкә комитетында бүлек мөдире М. М. Мусин, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Т. Миңнуллин, тәнкыйтьче Р. Мостафин чыгышлары да зур кызыксыну белән тыңланды.

Семинар эшендә түбәндәге әдәби берләшмә җитәкчеләре катнаштылар: Д. Вәлиев (Казан), Г. Кашапов (Чаллы), Н. Алешков (Чаллы), Ш. Мостафин (Кукмара), Р. Хисмәтуллин (Т. Кама), М. Зарецкий (Казан), М. Рафиков (Апас), В. Мальцев (Әлмәт), Р. Фәизов (Арча), Н. Әхмәдиев (Азнакай), Р. Вәлиуллин (Лениногорск), М. Федосенко (Т. Кама), Ә. Фәтхетдинова (Әгерҗе).

Әдәби берләшмә җитәкчеләре иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Кайберләре ВЛКСМ өлкә комитетының, Татарстан Язучылар союзының Почет грамоталары белән бүләкләнделәр.

Семинарда катнашучылар Г. Тукайның мемориал-музеенда булдылар, шигырь бәйрәмендә катнаштылар.

* * *

Татарстан Журналистлар союзы идарәсе, Хөсәен Ямашев исемендәге республика журналистлар премиясе комиссиясе тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, 1980 ел премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирергә карар итте:

Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы мөдире Флорид Имамәхмәтович **Әгъзәмовка**, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы урынбасары Нурулла Кәлимуллович **Габитовка**, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенең бүлек мөдире Хәбибулла Яруллович **Гобәйдуллинга** — Л. И. Брежневның «Кече

жир», «Янару», «Чирәм җир» китапларын, «Ленин юлы белән» дигән речьләр һәм мәкаләләр җыентыкларын татар теленә тәрҗемә итү өлкәсендәге зур эшләре өчен.

«Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Кояш Закировна **Тимбикова**га, «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре Мәдинә Габделхаковна **Маликова**га «Азат хатын» журналында басылган һәм 1979 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган яшь буынны коммунистик тәрбияләү турындагы очерклары һәм мәкаләләре өчен.

Казан телевидение студиясенең фильмнар эшли торган баш редакциясе өлкән редакторы Риорита Александровна **Рубцова**га үзәк телевидение өчен эшләнгән һәм 1979 елда күрсәтелгән «Чаллы» (аңлатмалы портрет) һәм «Ак йортыма кер» документаль телевизион фильмнар сценарие өчен.

* * *

СССР Язучылар союзы идарәсе секретарнаты СССР Язучылар союзының 1979 елгы әдәби тәнкыйть өлкәсендәге еллык премияләрен бирү турында карар чыгарды.

Быелгы лауреатлар арасында якташыбыз тәнкыйтьче Р. Мостафин да бар. Премиягә ул «Сибгат Хәким» исемле монографиясе («Советская Россия» нәшрияты»), «Җаваплылык хисе» исемле җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты) һәм вакытлы матбугатта танылган мәкаләләре өчен лаек булды.

* * *

Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть секциясенең чираттагы утырышы булды. Көн тәртибенә әдәбиятта шартлылык мәсьәләсе куелган иде.

Доклад белән филология фәннәре докторы И. Нуруллин чыкты. Соңыннан булган фикер алышуларда тәнкыйтьчеләр Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, әдәбият белгече Ф. Хатипов, филология фәннәре докторы Х. Госман һ. б. катнашты.

Чыгышларда хәзерге әдәбиятта шартлылыкның киң кулланылуы, зур роль уйнавы һәм аның татар әдәбиятында да кулланыла башлавы әйтелде.

## ҖӘЛИЛГӘ МЕМОРИАЛЬ ТАКТА

Җиңү көне алдыннан элекке Даугавпилс крепосте бастионнарының берсендә Советлар Союзы Герое, шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә мемориаль такта куелды. Анда рус, татар һәм латыш телләрендә шагыйрьнең:

«Бар җырымны илгә
багышладым,
Гомеремне дә бирәм
халкына»,

— дигән сүзләре язылган. Аннан астарак «1942 елның сентябрь — октябрендә Шталаг-340 концлагеренда татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил тоткынлыкта булды», дигән юлларны укыйбыз.

Мемориаль такта ачу хокукы Ян Фабрициус исемендәге Даугавпилс һава оборонасы югары авиация инженерлык училищесының политбүлек начальнигы В. Нечаев белән Ленин комсомолы исемендәге химия сүсе заводы мастеры Социалистик Хезмәт Герое А. Рыбаковка бирелде. Шагыйрьнең тормышы һәм көрәш юлы турында педагогия институтының өлкән укытучысы Э. Мекш сөйләде. Тантанада шагыйрьнең шигырьләре дә яңгырады. Анда Татарстаннан да кунаклар булды.

## СӘХНӘДӘ «ҖӘЛИЛ»

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында СССРның халык артисты композитор Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосы буенча иҗат ителгән «Җәлил» операсы премьерасы күрсәтелде. Әлеге әсәр сәхнәгә В. И. Ленинның тууына 110 ел, Бөек Җиңүнең 35 еллыгы һәм Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулу уңаеннан куелды. Бу — операның инде өченче тапкыр сәхнәләштерелүе. Беренче мәртәбә ул театр сәхнәсендә чирек гасыр элек куелган иде.

## КАРАКАЛПАК СӘХНӘСЕНДӘ

Каракалпак АССРның яшь тамашачылар театры Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә...» исемле моңсу комедиясе буенча эшләнгән спектакль премьерасын күрсәтте. Бөек Җиңүнең 35 еллыгы уңаеннан күрсәтелә торган бу спектакльне сәхнәгә режиссер Е. Ансатбаев куйган. Пьесаны каракалпак теленә Б. Исмаилов тәрҗемә иткән.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

25 нче апрельдә нефтьчеләрнең Техника йортында поэзия кичәсе булды. Кичәне Әлмәт шәһәр Советы председателе урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин ачты. Язучылар оешмасы җитәкчесе Ә. Маликов кереш сүз белән чыкты. Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты Гамил Афзал, шагыйрьләр Әдип Маликов, Клара Булатова, Энже Мәэминова, Роберт Рәкыйпов, Венера Туктарова үзләренең шигырьләрен укыдылар.

* * *

24 апрельдә күренекле әдип, РСФСРның М. Горький һәм ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким, шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллиннар Арча педагогия училищесында кунакта булдылар. Алар башта биредә эшли торган әдәбият түгәрәге членнары белән очрашып, студентларның язмалары буенча кызыклы сөйләшү уздырдылар. Соңыннан училище студентлары алдында үзләренең шигырьләрен укыдылар, сорауларга җавап бирделәр. Бу күңелле очрашу күмәкләп Г. Тукайның «Туган тел»ен җырлау белән тәмамланды.

# САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА



Татар совет әдәбияты зур югалту кичерде. Шушы елның 10 маенда, озакка сузылган каты авырудан соң, СССР Язучылар союзы члены, Татарстанның атказанган культура работнигы, КПСС члены, танылган шагыйрә Саҗидә Сөләйманова 54 нче яшендә вафат булды.

Саҗидә Гаделша кызы Сөләйманова 1926 елның 3 октябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Яңавыл авылында туа. 1950 елны Башкортстан педагогия институтын тәмамлагач, башта Башкортстанда, соңыннан Татарстан мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

1955 елны Әлмәткә килә. Бирердә С. Сөләйманованың әдәби иҗат эшчәнлеге башлана: республика газета-журналларында аның лирик җылылык һәм гражданлык хисләре белән сугарылган беренче шигырьләре басыла.

Саҗидә Сөләйманова, әдәбиятта егерме ел эшләп, дистәдән артык шигырь китабы бастырды. Шагыйрәнең каләме елданел ныгый, осталыгы арта барды. Ул хезмәт кешесенең, совет яшьләренең күңел матурлыгын җырлады, тормыш турында, кешенең яшәү мәгънәсе турында тирән эчтәлекле поэмалар, балладалар иҗат итте. Шагыйрәнең байтак шигырьләре республикабыз композиторлары тарафыннан көйгә салынды. Аның «Гөлбадран» повесте һәм хикәяләрен укучылар җылы каршылады.

С. Сөләйманованың рус телендә, Мәскәүдә һәм Казанда, өч җыентыгы басылды. Аерым шигырьләре илебез халыклары теленә тәрҗемә ителде.

С. Сөләйманова озак еллар «Азат хатын» журналының редколлегия члены булды, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты лекторы, Әлмәттә радиотапшырулар редакторы булып эшләде, республикабызда һәм илебезнең төрле өлкәләрендә укучылар белән очрашуларда актив катнашты.

С. Сөләйманованың хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән билгеләнде. Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Верховный Советы Президиумы аңа Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирде.

Танылган шагыйрә, педагог, җәмәгать эшлеклесе, коммунист каләмдәшебез Саҗидә Сөләйманованың якты хатирәсе безнең күңелләрдә озак сакланыр.

# МИРСӘЙ ӘМИР



Совет әдәбияты авыр югалтуга дучар булды — 1980 елның 1 июнендә халыкның иң популяр һәм иң яраткан язучыларыннан берсе — Мирсәй Әмир 74 нче яшендә вафат булды.

Мирсәй Әмир (Әмиров Мирсәяф Мәсәлимович) 1907 елның 6 январенда Башкортстан АССРның Мәләвез районы, Җиргән авылында крестьян семьясында туа. Әти-әнисеннән яшьли ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә. 1924 елда комсомолга керә, авыл комсомол ячейкасы секретаре була, ВЛКСМның волость комитеты члены итеп сайлана. Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1939 елда КПСС сафларына кабул ителә.

М. Әмирнең беренче әсәрләре егерменче еллар уртасында ук басыла. Шул вакыттан бирле аның 45 китабы чыкты. Әсәрләрендә ул үзен зур прозаик, драматург һәм публицист итеп танытты. Аның татар совет әдәбияты классикасына кергән «Агыйдел» повесте укучылар арасында зур популярлык һәм мәхәббәт казанды. Бу әсәрдә коллективлашу елларында авылда барган сыйнфый көрәш зур эмоциональ һәм художество көче белән күрсәтелә.

Бөек Ватан сугышы чорында М. Әмир «Ватан өчен» исемле фронт газетасы корреспонденты була. Газета битләрендә ул совет сугышчыларының батырлыгы турында хикәяләр һәм очерклар бастырып чыгара. Бу елларда язучы драматургия өлкәсендә аеруча актив эшли. Ул «Миңлекамал», «Партизан Иван», «Тормыш җыры», «Җыр дәвам итә», «Наилә» һәм башка пьесаларын яза. Бу әсәрләр Татарстан, Башкортстан һәм башка тугандаш республикалар сәхнәләрендә зур уңыш белән барды.

Сугыштан соңгы елларда язучының таланты яңа көч белән ачылды. Хезмәт сөючәнлек, актив тормыш позициясе, партиячел принципиальлек Мирсәй Әмиргә гаять кыйммәтле әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирде.

М. Әмир әсәрләренең художество тәэсиренең көче — тормышны тирәнтен белүдә, аңа актив мөнәсәбәттә булуда, чынбарлыгыбызның характерлы сыйфатларын тотып ала белүдә.

Нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге, үз иҗатына югары таләпчән булуы М. Әмирне илебезнең атаклы язучылары сафына бастырды. Аның әсәрләре рус, украин, белорус, казакъ, башкорт, чуваш, карел, болгар һәм чех телләренә тәрҗемә ителде.

М. Әмир иҗтимагый-политик тормышта актив катнашты. Ул КПССның XXIII съезды делегаты, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены булып сайланды. РСФСРның берничә чакырылыш Верховный Советы депутаты, РСФСР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары, РСФСР Верховный Советы Председателе урынбасары булды.

1934 елдан бирле СССР Язучылар союзы члены буларак, ул илебез язучыларының барлык съездларында катнашты, озак еллар СССР һәм РСФСР Язучылар союзы правлениеләренең члены булды. 1937, 1961—1967 елларда республика язучылар оешмасына җитәкчелек итте. Озак еллар буе «Казан утлары» журналының редколлегиясе члены булды, редакция эшенә зур ярдәм күрсәтеп торды.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте М. Әмирнең хезмәтләрен югары бәяләделәр. Ул Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрак ордены, медальләр белән бүләкләнде. Аңа Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Күренекле татар совет язучысы, ялкынлы коммунист, олы җанлы талант иясенең якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Инде журналның сез киләсе айда укыячак 8 нче санында нинди язмалар бирелүен тәфсилләп үтик.

Гадәттәгечә, сәхифәләрнең күбрәк өлешен проза әсәрләре тәшкил итә. Алар арасында язучы Ә. Баянның «Аргы яр» исемле яңа повесте, С. Шәмси, Ә. Сафиуллин, Р. Фәизов хикәяләре бар.

Поэзия бүлеге шагыйрьләребезнең бер көлтә яңа шигырьләрен тәкъдим итә. Ренат Харисов, Мәҗит Рафиков, Лена Шакирҗанова, Рифгать Закиров иҗатыннан алып бирелгән матур-матур шигырьләр укучылар күңеленә хуш килер, дип ышанабыз.

Әдипләребез соңгы вакытта публицистика һәм очерк жанрына да җитди игътибар бирә башладылар. Шул күңелле яңалыкның нәтиҗәсе буларак Р. Ишморатның Актаныш яклары турындагы зур күләмле очеркы, М. Зариповның Түбән Кама кешеләренә багышланган әсәре барлыкка килде. Журналның бу санында әлеге әсәрләрдән өзекләр басыла.

Тәнкыйть һәм библиография бүлегенә караган язмаларның күпчелеге татар әдәбияты классигы М. Гафуриның тууына 100 ел тулу вакыйгасына багышланган. Болардан тыш монда Ф. Галимуллинның язучы Г. Ахунов иҗатын анализлаган мәкаләсе һ. б. лар бар.

«Китап күзәтү», «Кыска рецензияләр», «Безнең календарь», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» рубрикалары шулай ук укучы күңелен җәлеп итәрлек материалларга бай.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ